
ISSN 0206-4189
Индекс 73210

# Казан утлары

2.2010





**Фатих Кәрими**
**(1870—1937)**

# Казан утлары
# Qazan utları

2010

2

(1048)

**ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:**
*Татарстан хөкүмәте,*
*Татарстан Язучылар берлеге,*
*Редакциянең хезмәт коллективы*

**НАШИРЕ:**
*«ТАТМЕДИА» ачык акционерлык җәмгыяте*



*БАШ МӨХӘРРИР*

**Равил Габдрахман улы Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Рабит Батулла**
**Зилә Вәлиева**
**Разил Вәлиев**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Тәлгат Галиуллин**
**Миркасыйм Госманов**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Илфак Ибраһимов**
**Дамир Исхаков**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Назиф Мириханов**
**Гәрәй Рәхим**
**Розалина Шаһиева**
**Рәфикъ Юныс**
*(баш мөхәррир урынбасары)*

---

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Рәдиф Гаташ, Марат Закир, Камил Кәримов, Рашат Низами, Алмаз Хәмзин.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Гөлзадә Бәйрәмова, Радик Вәлиев, Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева, Флера Сабирова.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Асия Рәхимова** (баш бухгалтер), **Эльвира Камалова.**


---


✉: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
☎☎: Баш мөхәррир—292-38-60.
Баш мөхәррир урынбасары—292-36-49.
Җаваплы сәркәтип, компьютер үзәге—562-11-28.
Шигърият, публицистика, фән һәм сәнгать бүлеге—292-38-61.
Чәчмә әсәрләр һәм әдәби тәнкыйть бүлеге—292-39-63.
Гамәли хезмәткәрләр—292-39-65.
Исәп-хисап бүлеге—292-93-16. kazanutlari@yandex.ru
**Факс**—(843) 562-11-28.
**E-mail:** kazanutlari@telebit.ru.

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ–НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ–СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА


## Бу санда


**ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Рим ИДИЯТУЛЛИН. Гомер—кыска кыйсса гына... *Шигырьләр* ..... 5
Рауль МИРХӘЙДӘРОВ. Җәяүле сәйран. *Роман* ..... 9
Мөхәммәт МИРЗА. Газәлләр, робагыйлар... ..... 45
Рашат НИЗАМИ. Сәйдәшнең соңгы елы. *Кыйсса* ..... 50
Әхмәт ГАДЕЛ. Табигатькә—сөю җырым... *Шигырьләр* ..... 79
Ленар ШӘЕХ. Бер көләчәк әле кояш та... *Шигырьләр* ..... 82
Алмаз ХӘМЗИН. Кырык сигез кило. *Хикәя* ..... 86
Рамилә МАЙОРОВА. Кая болай ярсый әле күңел?.. *Шигырьләр* ..... 96
Камил КӘРИМОВ. Күрше авыл кызы. *Бәян* ..... 98

**ИЛЬҺАМ ШАКИРОВКА 75 ЯШЬ**

Бөек җырчы турында сүз әйтәләр: Гәрәй РӘХИМ, Полад БЮЛЬ-БЮЛЬ ОГЛЫ, Юлай ШАМИЛ УГЛЫ, Рабин СӘФӘРГАЛИЕВ, Бибигөл ТЕЛӘГӘНОВА, Михаил ЛЬВОВ ..... 107

**ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ**

Адлер ТИМЕРГАЛИН. Ике сандык йакут. ..... 115
Илдус ФАЗЛЕТДИНОВ. Тетрәнүләр шигърияте. *(Р. Идиятуллинга 70 яшь)*. 124

**КИТАП КҮЗӘТҮ**

Айгөл ӘХМӘТГАЛИЕВА. Тугрылык. ..... 130

**СӘНГАТЬ**

Әзһәр ШАКИРОВ. Тарих сәхнәсендә—без эзлебез... *Артист монологы* ..... 134

«Татар энциклопедиясе» битләреннән. ..... 146

**ТАРИХ**

Альфред ХАЛИКОВ. Болгар-татар чыгышлы 500 рус фамилиясе. ..... 149

**ЮБИЛЕЙЛАР**

Фәүзия БӘЙРӘМОВА. Ул гел беренче рәттә булды.... *(Марат Мөлековның тууына 80 ел)* ..... 152
Әлфинур НӘҖИПОВА-ЗИННӘТУЛЛИНА. Гомер заяга узмаган. *(Фәрит Хатиповка 80 яшь)* ..... 155

**ЮМОР ҺӘМ САТИРА**

Туфан МИҢНУЛЛИН. Минһаҗ маҗаралары. ..... 162

**АК ҖИЛКӘН**

Яшүсмерләр өчен махсус сәхифә. ..... 174

Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ..... 187

# В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

«Проза и поэзия»: роман Р. МИР-ХАЙДАРОВА «Пешие прогулки» (прод.), притча Р. НИЗАМИ «Последний год Сайдаша», повесть К. КАРИМОВА «Девушка из соседнего села», рассказ А. ХАМЗИНА «Сорок восемь кило»; стихи Р. ИДИЯТУЛЛИНА, М. МИРЗЫ, А. АДИЛЯ, Л. ШАЕХА, Р. МАЙОРОВОЙ.
«75 лет И. Шакирову»: Г. РАХИМ, П. БЮЛЬ-БЮЛЬ ОГЛЫ, Ю. ШАМИЛЬ ОГЛЫ, Р. САФАРГАЛИЕВ, Б. ТУЛЕГЕНОВА, М. ЛЬВОВ о великом певце.
«Литературная критика»: рецензия А. ТИМЕРГАЛИНА на словарь «Г. Тукай. Язык поэзии»; статья Л. ФАЗЛЕТДИНОВОЙ к 70-летию Р. Идиятуллина.
«Книжное обозрение»: А. АХМЕТГАЛИЕВА. «Преданность».
«История»: А. ХАЛИКОВ. «500 русских фамилий булгаро-татарского происхождения» (прод.).
«Наука»: Ф. ГАРИПОВА. «История наших деревень» (прод.).
«Искусство»: А. ШАКИРОВ. Монолог артиста.
«Юбилеи»: статьи к 80-летию Ф. Хатипова и М. Мулюкова.
«Юмор-сатира»: Т. МИННУЛЛИН. «Приключения Мингаза».
«Белый парус»: специальная рубрика для подростков.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: Национальный музей Республики Татарстан; писатель Рустем САБИРОВ.

# IN THIS ISSUE:

*The magazine edits monthly*

«Prose and poetry»: novel by R. MIR-KHAYDAROV «Hiking» (continuation), a parable by R. NIZAMI «Saidash's last year», story by K. KARIMOV «Girl from neighboring village», story by A. KHAMZIN; poems by R. IDIYATULLIN, M. MIRZA, A. ADIL, L. SCHAECH, R. MAYOROVA.
«75th anniversary of I. Shakirov»: G. RAHIM, P. BUL-BUL OGLY, Yu. SHAMIL OGLY, R. SAFARGALIEV, B. TULEGENOVA, M. LVOV about the great singer.
«Literary Criticism»: review A. TIMERGALIN on the dictionary «G. Tukaya. Language of Poetry»; article L. FAZLETDINOV to the 70 th anniversary of R. Idiyatullin.
«Book review»: A. AHMETGALIEVA. «Devotion».
«History»: A. KHALIKOV. «500 Russian surnames Bulgar-Tatar origin» (cont'd).
«Science»: F. GARIPOVA. «The history of our villages» (cont'd).
«Art»: A. SHAKIROV. The monologue of the actor.
«Jubilee»: article by 80-th anniversary of F. Hatipova and M. Mulyukova.
«Humor-satire»: T. MINNULLIN. Adventures of Mingazov.
«White Sail»: special section for teenagers.
Diary of socio-cultural life.
On our cover: National Museum of Tatarstan; writer Rustem SABIROV.

★ Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★ Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★ Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 1.02.2010, график буенча 1.02.2010.
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108 1/16.
Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ О–73. Тираж 5063.
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы № 7. Индекс 73210 (физик затлар өчен), 16262 (юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2010 ел.



Рим
Идиятуллин

# ГОМЕР—КЫСКА КЫЙССА ГЫНА...

## Тукай туфрагы

**Бастым, Шагыйрь, җылы эзләреңә,**
**Куып җиткәч гомер баешы;**
**Ишетелә микән Итилләргә**
**Типкәләнгән йөрәк тавышы?**

**Музейларда күреп бабамнарның**
**Җаны качкан сука-урагын,**
**Телләремә терим күз яшеннән**
**Саркымаган тере туфрагын.**

**И уйландым каплаганда Җирне**
**Гасыр кичләренең томаны,—**
**Томаннарда күп томана туды,**
**Их, Тукайлар гына тумады...**

**Әллә хак сүз өзгеч заманнарда**
**Эскерт төбендәге энәме?**
**Бәндәләре әллә хөр хаятның**
**Ертык шәүләләре генәме?**

**Тукай бәгырь!**
**«Баягылар баягыча» түгел,**
**Уфаларны килеп күр әле!—**
**Татарымның кычытмаган телен**
**Кашып ята күпме шүрәле.**

Рим ИДИЯТУЛЛИН (1940)—*Башкортстанда (Уфада) яшәүче татар шагыйре; «Хәерле иртә», «Хәерле көн»; «Хәерле кич» исемле китаплар авторы.*

Яньчелде дә телем, изелде дә
Уралтауның кырчын ташында.
Кичер, Ходай, мөшрикләр һәрчак
Кояш баткан якка ашкына...

Бастым менә тере туфрагыңа,
Ишелгәндә гомер түшәме.
Тукай бәгырь!
Сискәнерлек сорау: туфрагыңда
Әткәң-әнкәң теле исәнме?

## Гомер

Сөенгәнме Әнкәм-Әткәм
Елак малай тууына?
Мич якканнар, ут элгәннәр,
Түзәлмичә улавыма;
Дөнья болай җылы гына.

Урам багам, күзем элеп,
Иске читән ярыгына;
Кайта көтү, керми безгә
Анау сыер ябыгы да;
Дөнья саран сабырына.

Күршенең телең йотарлык
Алмалары пешкән икән,
Җилләр тузгып, хет яшеле
Безнең якка төшсә икән?!
Җилләр бигрәк арык икән.

Тупыллардан өч кат биек
Тау башына яттым менеп;
Сансыз йолдыз соң мәртәбә
Балкый сихри сәйлән кебек;
Калды Әнкәм күз-яшь түгеп:

«Анда күмәч тәмле» дигәч,
Чыгып тайдым калаларга;
Кытыкламый шәрә үлән,
Таш шыгырдый табаннарда,—
Була хәлне чамаларга.

Калада да кояш көләч,
Күкләре дә аның зәңгәр,
Шул күкләрне күзләгәндә
Сихерләде илаһ чибәр,—
Күрсә, Мәҗнүн җиргә чүгәр!

Җанаш белән яратышып,
Кыз үстердек, ул үстердек;
Хәсрәт төшсә, басар өчен,
Сулар сибеп, гөл үстердек,—
Кош көнләшер оя үрдек.

Кызыкмадык малга, данга,
Байлык артса—хөрлек кими,
Мәгәр кала уртасында
«Салып кердек» биш катлы өй;
Барды дөнья шулай бер көй...

Кичкән гомер—ул бик моңсу
Беткән кыска кыйсса гына;
Иләдем ком, бөртек алтын
Бармы вакыт улагында?
Артыгын мин сорамыйм да.

Мең ел яшәп әйтә алмам:
Әллә уңдым, әллә туңдым;
Барын—бүлдем кешеләргә,
Ә үземә җыйдым югын;
Хак булдымы кичкән юлым?

Яшькә манчып, чәчтем сагыш,
Үрчедеме икән шәфкать?
Кешеләрем, кыйблагызны
Капламасын кара шәфәкъ!
Өмет—тулып пешкән башак.

Әйтеп нәзер бер энемә,
Күрдем күчү хәстәрен дә:
«Урын бүлдек... каберең,
Торсаң иде әзер генә!»—
Рәхмәт изге хәбәреңә!

Яшь түкмәгез хушлашканда,—
Җирдә бармы китми калган?!
Бәлки әле кайтырмын да,
Яткан урын булса салкын,—
Әгәренки кушса закун.

Ай калыксын, сулар аксын,
Кош сайрасын, талга кунып,
Су сибегез, бисмиллалап,
Рәнҗемәсен гөлләр, сулып!—
Күзәтермен малай булып,
Чардуганнар арасыннан...

## Уенчык елан

Берчак патша туеп бәхеттән,
Үзе теләп төште тәхеттән;

Шау килделәр илләр чатында,
Тел күтәрде түзем хатын да:

«Чәчеп үстермиләр ахмакны,—
Йә, кем ташлар сәхрә оҗмахны?!»

Әйтсә, хурлык гавам каршында:
Елан күрде тәхет астында.

Нинди елан диген!—карасы,
Күзләр якут бөртек чамасы,—

Салып ята тутык кабыгын...—
Җуйды хаким шунда сабырын;

Баш шартларлык уйлар уйлады,
Хәлне бик яманга юрады;

Баш тартулар авыр бәхеттән,
Ни кыласың!—китте тәхеттән.

...Тәхет илә байлык—бер айлык,
Итә патша бүген сукбайлык;

Пулат та юк хәзер, блат та,
Җария дә ятмый кочакта;

Хәтта хатын ятка олакты:
Кем иш иткән шәрә батракны?!

Патшаларга тү-тү пенсия!
Ә фәкыйрьлек—авыр миссия.

Тынчу подвалларда кон итмеш,
«Падишаһым, тормыш бик җитеш»,—

Диеп сайрый урынбасары,—
Кергән чакта төшнең начары.

Белеп булмый, дипме, алдагын,
Якут кашлы алтын балдагын

Калган иде ерак яшереп,—
Озын чәчтә йөртә нык төреп.

...Кул сузганда шулай бер кичтә
Чүплектәге куксел кумәчкә,

Елан... ялтыр күзле... кап-кара...
Тораташтай катты бичара.

Чак ис кергәч, салды каравыл;
Ярый, фәкыйрьдәше янда гел:

Шөкәтсезнең бәреп башына,
Алды атты асфальт ташына.

Тәти сукбай шыпан чигенә,
Батыр сукбай кушуч сугена:

«Сукыр күрер, едрид, ап-ачык,
Бу еланың—калай уенчык!»

Ул тел тибрәтмәде, акланып;
Тик башында хак уй ялтлады:

«Тәхет түре—тоташ ялганлык,
Тап хакыйкать тик бер йотымлык!

Ачы әрем кебек яманы
Үрчи анда. Көнчел яраны

Куйгандыр ла ялган еланны...
Фетнәчегә хәвеф кулайлы...»

Һәм шул кичтә сатып балдагын,
Ишләренең төпсез тамагын

Коендырды биш көн шәрабка,—
Мондый мәҗлес юктыр шәрыктә!

Каршылар ул тоеп иртәсен
Аң агарткан ачы тир исен...

...Тормышларны уйлыйм, тирәмдә
Ак чырайлы сукбай күргәндә;

Табибларга, мәйтәм, барырсың,
Байкап чыксаң тәхет тарихын;

Алыш анда: кайсы үчлерәк!
Бер-бер вакыт елан төслерәк,

Бер-бер хаким салса кабыгын,
Күр дә тор син: чүпкә абыныр,

Абыныр да таныр заманын,
«Хөр хәят!» дип ертмас тамагын.

Без бәхетле, яшик гел көлеп:
Хәерчелек, шөкер, мәңгелек...

## Син исәнме, табигатем?!

И үләнем!—
Хас та үксез бала кебексең син
Табигатьнең чиксез келәтендә:
Башын куеп, соңра башларыңа
Басып киткән залим сурәтендә
Кәеф-сафа корган кемсә—мин дә...

И ак чишмәм!—
Күңелгә чык төшә, күрешергә килсәм;
Челтер-челтер көйләр кайдан туар,
Чал ташларның битен кемнәр юар,—
Әнкәм сыман син дә кибеп үлсәң?—
Моң корыса, кавем тәмам шиңәр.

И чәчәгем!—
Шушы җылы җирне мең төсләргә
Миннән соң да бизәр киләчәгем.
Таҗларыңда җемел чык тамчысы,
Күзләремне чәнчи яшь ачысы,—
Яшәп тузгач тойдым яшәү тәмен.

...И син кешем!
Сөттәй актан, хәләл хактан гына
Тукылмаган нигә эчең-тышың?!
Юк, көл түгел, гөл калдырыр идең
Нәфсе җигеп дөнья кумасаң!
Их!
Көчсез булып тусаң ичмасам!..

***

Картайган да, сыңар аять ятлап,
Иман күндермәкче, чүп сөйләп;
Сакал агартканнар күп ул хәзер,
Аксакаллар гына бик сирәк.

## Тарихларын тирәнәйтергә маташучыларга

Канау казып, сөяк тапкан саен,
Тирәнәйтәм димә тарихны!
Ахмак кына дәрьяларга тиңләр,
Тәүләп күрсә сап-сай арыкны...

Рауль
Мирхәйдәров

# ҖӘЯҮЛЕ СӘЙРАН

РОМАН

Дөресен әйткәндә, комиссия нәтиҗәләре белән аны бюро алдыннан таныштырганнар иде. Нәтиҗә буталчык, төгәлсезлеге күзгә бәрелеп тора. Белгечләр керамика тупланмасын томанлы бәяләгәннәр. Ике тапкыр «Сотби» Лондон аукционын дәлил итеп китергәннәр, соңгы елларда анда төрле илләрдән китерелгән шәхси керамика җыелмалары сатулар ешайды. Мисалга Әнкарадан Кемаль әфәнденең сиксән дүрт мең фунт стерлингка сатылган коллекциясен китергәннәр; генерал Чарлз Грейныкы да телгә алынган, анысының гасыр башында Мисырдан алып чыккан коллекциясен «Сотби» аукционында йөз меңгә бәяләгәннәр. Белгечләр тагын шунысын да онытмаганнар: көнбатыш журналистлары Турганова күргәзмәләренә карата язылган рецензияләрендә экспонатларның бик кыйммәтле булуын искәрткәннәр, ә газетадагылар исә, тупланманың сатылуга куелмасын белеп, аны бик юмарт бәяләгәннәр. Менә шуңа журналистлар тарафыннан китерелгән бәя «Сотби» аукционында Әнкара һәм Порт-Саид коллекцияләре өчен куелган хактан күпкә югары килеп чыккан. Хезмәт хакына яшәүче теләсә кайсы совет кешесен гипнозлаган шушы сан бюро башланганчы өлкә комитеты бүлмәләрен кат-кат урады һәм булачак утырышка тон бирде. Имеш-мимеш, кеше сүзләре, кар йомарламын хәтерләтеп, яңа төсмерләр белән баетыла-баетыла таралуы буенча, мөгаен, яктылык тизлеген дә уздырадыр; күп тә үтмәде, инде белгечләр керамика җыелмасын якынча йөз илле мең дип бәяләгәннәр дигәнне онытып, өлкә прокуроры шул күләмдәге акча җыйган икән дигәне таралды, соңрак бу коточкыч сумманы аның фамилиясе белән янәшә куеп, кем ничек тели, шулай төрләндерергә кереште. Тик бу адәм ышанмаслык сүзләр өлкә прокурорының язмышын хәл иткән бюродан соң таралды һәм җәелгәннән-җәелә барды.

Билгеле, бюро әгъзалары полковник Иргашев комиссиясенең дә, Ташкенттан килгән тикшерүчеләрнең дә эш нәтиҗәләре турында хәбәрдар иделәр. Өстәвенә, ташкентныкылар, йорт яны бакчасындагы ачык һава музее—кайсы яклап карасаң да, кычкырып торган тыйнаксызлык дип тамга салдылар.

---

*Дәвамы. Башы узган елның 12 нче санында.*

Ләкин йортның һәр почмагын капшап чыккан комиссия прокурорның бик гади көн күрүе турында, ичмасам, ник бер сүз кыстырсын! Югыйсә, аның өендә зиннәтле дип әйтерлек бер генә әйбер дә юк иде бит.

Сөен Бикхуҗаевның башка фамилия йөрткән кече энеләреннән берсе бюро әгъзасы икән. Ул беренче булып чыгыш ясарга уйламаган, әмма җыелганнарның ике комиссия чыгарган нәтиҗәләр белән тулысынча килешеп бетмәүләрен чамалап, сүз алырга мәҗбүр булды.

—Мине дөрес аңлавыгызны телим. Янарак кына зур югалту кичергән, сәламәтлеге какшаган кешенең йөзенә бәреп дөреслекне әйтү миңа да ансат түгел, тик коммунистлык бурычым мине шуңа этәрә. Азларханов иптәшнең бәхетсезлеге читләтеп кенә миңа да килеп кагылды, хокук органнары тарафыннан тиз арада тотылып хөкем ителгән үтерүче-маньяк минем туганым—студент, безнең прокурорның булачак коллегасы гомеренә янады. Ышаныгыз, физик яктан зарар күрмәсә дә, яхшы беләм—ул гомере буена психик травма алды. Шуңа башка кешеләргә караганда, мин иптәш Азлархановның кайгысын күпкә яхшырак аңлыйм. Бәла артыннан бәла иярә дигәндәй, минем көтмәгәндә икенчесе дә күренде, тик мин бу фаҗига булмаган очракта да, шәхси коллекция белән туган хәл иртәме-соңгы өскә калкып чыкмый калмас иде дип саныйм. Менә шунда эшнең асылына якынлашабыз. Мин комсызлык, аның нинди битлекләр астына яшеренә алуы турында әйтергә телим. Элегрәк бюрода гадел булмаган юл белән йорт, машина, дача, ковер, бәллүр җыючыларны тикшерсәк, хәзер исә байлык туплауның тагын да үткенрәк формаларын очратабыз. Мине башкалабыздан килгән хөрмәтле һәм абруйлы белгечләрнең бәясе шаккатырды—йөз илле мең! Безнең крайдан прокурор гаиләсе тарафыннан җыелган сирәк керамика астрономик сан белән исәпләнә! Әле бездә бер генә ришвәтченең дә моның кадәр суммага җиткергәне юк иде.

Коллекция нинди юллар белән тупланганды̆р—белмим һәм белергә дә теләмим: пычракка керәсем килми, әмма дин тарафдары булмасам да, Балан мәчетеннән мөселманнарның изге саналган әйберләренә кул сузуны хупламыйм. Бу факт Азларханов иптәшнең коммунист буларак та, урындагы кеше буларак та дәрәҗәсенә суга. Бу—зур сәяси мәсьәлә һәм мин бюро моңа карата үзенең гадел бәясен бирер дип уйлыйм.

Комсызлыкка әйләнеп кайтсак... Файда, табыш алу белән иптәш Азларханов хатынының акылга сыймаслык мин-минлеге, дан-шөһрәт сөюе бергә кушылган, һәм минем белүемчә, шушы дан тирәсендә иптәш прокурор үзе дә купшыланып йөрүне бик ошатты. Ике тапкыр хатынын чит илгә озата баруын да мин партиядәге кеше өчен тыйнаксызлык дип саныйм. Менә бүген йөз илле мең дигән санны ишеткәч, ниһаять, бу ханымның суфый булып кылануына төшендем. Һәм ышанып шуны әйтә алам: аның бөтен максаты—данга омтылу, табыш артыннан куу булган, менә шушылар аны һәлакәткә алып килгән дә инде...

Чыгыш ясаучыларны моңарчы тыныч кына тыңлап утырган прокурор кинәт урыныннан сикереп торды.

—Тузга язмаган ялалар ягуыгызны туктатыгыз, иптәш Бикхуҗаев, һәм шакшы кулларыгыз белән хатыным исеменә үрелмәгез, юкса мин...—Ул, өстәл артыннан чыгып, үз-үзенә хисап бирмичә янаулы кыяфәттә Бикхуҗаевка таба атлады.

Өлкә комитетында мондый хәлне беренче тапкыр күргәнгә, Әнвәр Бикхуҗаевның абыйсы үзе дә сизмәстән чинап җибәрде. Әмирхан Даутовичны бүлмәдән култыклап алып чыктылар, һәм утырыш аңардан башка гына тәмамланды.

Бюро төштән соң башланды, ә ул кабул итү бүлмәсеннән чыкканда, эш көне күптән тәмамланган иде инде. Бушап калган коридорлар буйлап

баскычка юнәлгәндә юлында адәм заты очрамады. Паласлар җәелгән баскычлардан төшеп килгәндә, прокурорны кабат йөрәге тотты, ул баскыч басмасына утырып, авызына нитроглицерин капты. Утырышның тәмамланып килгәнен чамалап, үзендә көч табып аягына басты: дусларына да, дошманнарына да мондый мескен хәлдә күренәсе килмәде. Сак кына, мәрмәр баскычның култыксаларына ябыша-тотына, әкрен генә аска төште.

Инде язгы энгер куерган, һава сизелерлек салкынайткан, прокурор хәтта бөрешеп куйды, тик аның калтыравы тунудан булды микән? Ул ашыкмый гына бина каршындагы мәйдан аша үтеп, хезмәт транспорты тукталышына таба атлады. Соң булуга карамастан, машиналар шактый. Гадәттә, Әмирхан Даутович мәйданда күренүгә, аның машинасы кузгалып, каршысына килә торган иде, тик бу юлы «Волга»сы кабынырга ашыкмады. Ул эченнән генә: «Шофер да коллегалары белән бер сүздә, ахрысы»,—дип уйлап куйды. Якынрак килгәч, күзләре белән айкап чыкса да, ул үзенең машинасын тапмады, башка машина тәрәзәләреннән үзен күзәтүләрен тоеп, каушап калды. Борылып китәм дигәндә, ин кырыйда торган «Волга»дан өлкән яшьтәге шофер төште дә аның янына якынлашты. Ул моннан берничә еллар элек үзен йөрткән Усман аганы танып алды. Усман ага аның белән исәнләште дә ымлап үзенең машинасына чакырды һәм, уңайсызлануын яшермичә:

—Батып барган корабтан качкан күсе шикелле юкка чыкты. Сезнең авыр хәлдә калуыгыз, бүтән өлкә прокуроры булмасыгызны кайдандыр ишеткән ахры, бюрога керeп китүегезгә артыгыздан ук шылды...Хәзерге яшьләр исәпле, ә институтка кергәндә сезнең имзагыз куелган характеристика кирәк булды үзенә, читтән торып укый, имеш...—Усман ага ачуыннан тәкереп куйды.

Прокурор карт шоферга рәхмәт әйтеп, ярдәменнән баш тартты һәм җәяүләп кайтырга булды—тәпиләү аңарга файдага гына иде.

Апрельнең соңгы шимбәсе. Зур шәһәрнең иркен урамнарында тормыш кайный: кемнәрдер киного, паркка бара, кайсыларыдыр саф һава тансыклаган. Каршыга килүчеләрнең күпчеле аны белә, баш иеп исәнләшеп үтәләр һәм борылып артыннан карап калалар: Лариса Павловнаның үлеменнән соң шәһәрдә аның тарихын ишетмәгән берәрсе калды микән? Бары тик бюроның бүген чыгарачак карары турында гына белмиләр, ә үзе нинди нәтиҗәгә киләчәкләренә утырыш алдыннан ук төшенгән иде инде. Республика прокурорының төнге шылтыратуыннан соң, ул үзен салып таптыйсыларын чамалады, шуңа күрә артыгына өметләнмәде. Андый гаепләүләрдән соң кемне генә шундый җаваплы урында калдырырлар иде микән?

Бюрода үзен тыеп кала алмавына үкенмәде, чөнки Бикхуҗаевны башкача туктатып булмаячагын аңлады. Күрәсең, ул мона алдан әзерләнеп килгән һәм прокурорны чыгырыннан чыгару өчен зәһәрен аның иң авырткан җиренә—яраткан хатынының истәлеген пычратуга юнәлткән иде. Озакка, бәлки бөтенләйгәдер югалткан хезмәт урынына да әллә ни исе китмәде, тик көрәштә бернинди каршылыксыз оттыру җанына тиде. Авызын ачып сүз әйтергә дә ирек бирмәделәр, малай-шалай кебек күреп, аяк астына салып таптадылар. Шушы уе юлда да, өендә дә һич уеннан китмәде.

«Әгәр Бикхуҗаевлар «прокурор буларак абруен төшердек, хезмәт урыныннан колак кактырдык, хәзер ул безнең өчен бар ни, юк ни» дип уйлыйлар икән—бик нык ялгышалар,—дип фикер йөртте ул.—Бәлки мина дәрәҗәмне югалткан хәлдә намусымны аклавы җинелгәрәк туры килер. Һәм

аларның бу эшкә нокта куярга маташулары барып чыкмас».

Ут алынмаган буш, ятим өендә байтак кына ишекле-түрле йөргәннән соң, ул бакчасына чыкты. Бер-берсе белән узышып үскән агачларны караңгылык үз канаты астына алган. Прокурор, ялгызлыгын искәртеп торган өенә керәсе килмичә, бик озак ачык верандада басып торды; аның башында бары тик бер уй бөтерелде: бирелде. Көрәшсез-нисез бирелде.

Кинәт күз алдына паспортта Садыйков фамилиясен йөрткән Бикхуҗаевның бюродан өенә кайтуын, анда Сөен Бикхуҗаевтан башлап күпсанлы туганнарының аны зарыгып көтеп алуларын, карарны ишеткәч, өстәл тирәли утырышып, үзләренең өстен чыгуларыннан хозурланып бәйрәм итүләре килде; соң, үтерүчене яклап калу һәм өстәвенә прокурорның көлен күккә очыру уен-муен эш түгел бит. Бу аларның кланының җиңелмәс көчен күрсәтә түгелме?

Үз-үзләреннән канәгать Бикхуҗаевларның тантана итүләре шулкадәр ачык күренде ки, прокурор түзмәде, алдан ук башланган бәйрәмнәренә корт булып төшәргә уйлады.

Ул кабинетына керде дә телефон трубкасын күтәрде. Өй телефоннарына шылтыратса, башкалар алыр дип, юри өлкә комитетына тоташтырылганын җыйды. Ул уйлаганча килеп чыкты, чыбыкның теге очында Садыйковның үз-үзеннән канәгать тавышы ишетелде. Ашыга-ашыга чәйнәвеннән, прокурор аның өстәл янынннан кузгалып килүен, һәм, түземсезләнеп, үзенең бюрода компромиссыз чыгышы уңаеннан тәбрикләүләр көтүен аңлады.

—Бу—Азлархановж,—дигән тавышны ишетүгә, әле генә үзен күкнең җиденче катында тойган Садыйковның шатлыгы бер мизгелдә юкка чыгып, очкылык тота башлады.

—Иптәш Бикхуҗаев,—ул Садыйковка нык итеп үз фамилиясе белән дәште, тегесе исә каршы килеп маташмады.—Миңа калса, сез бәйрәмне иртәрәк башлагансыз. Бүген мин эш урынымны югалтканмын икән, ул әле суд карары белән килештем дигән сүз түгел. Мин хатынымны кем үтергәнен бик яхшы беләм һәм моны ачарга ярдәм итәр кешеләрем дә бар. Әгәр мин монда, республикада дөреслекне таба алмасам, илебезнең Генераль прокурорына кадәр барып җитәчәкмен. Һәм колагыгызга киртләгез: яраланган ерткыч сәламәтеннән куркынычрак. Мине ансат кына тезләндерә алмассыз, соңгы сулышыма кадәр көрәшәчәкмен...—Прокурор чыбыкның теге очындагы кешенең зур игътибар белән тыңлавын сизенде, һәм, мөгаен, йорт хуҗасының йөзе кинәт үзгәреп китүен күреп, барысы да аның янына җыелгандыр.

Күрәсең, ул дөрес фаразлады, Садыйков кинәт үзгәреп киткән тавышы белән:

—Ике генә минут сабыр итегез, трубкагызны куймагыз,—диде..—Микрофонны кулы белән каплап, үзен сырып алган туганнары белән киңәшләшеп алды ахры.

Берничә минуттан тәкъдиме әзер иде:

—Ике сәгатьтән мин сездә булам, безгә, һичшиксез, күзгә-күз очрашып сөйләшергә кирәк.

Прокурор сәгатенә күз төшерде: сәгать ун, димәк, үтерүченең туганы Әкрам Садыйков нәкъ төн уртасында Лахутидагы йортка килеп туктаячак.

Хуҗа кеше кухняга кереп, плитәгә чәйнек утыртты, бу ыгы-зыгылы шимбә көнендә бер касә чәй эчмәгәне исенә төште.

«Ярты ел җитмәгән, тагын ике сәгать кирәк булган аларга»,—дип уйлады ачулы прокурор. Нәрсә-нәрсә, әмма өстәл артындагыларның аппетитлары кимүенә ул шикләнмәде.

«Бу ике сәгать аларга ник кирәк булды икән?»—дип, төрлечә уйлап караса да, анык кына бер фикергә килә алмады. Шулай да бар адымнарын үлчәп, тикшереп атларга күнеккән бу кланга ике сәгать чынлап та кирәгенә ышана иде.

«Әкрам Садыйков үзе генә килер микән, әллә энесен дә ияртерме,ә бәлки ырунын бар ирләре жыелып килер?»—прокурор фикерләвен дәвам итте. Боларнын нәрсә эшләячәген алдан әйтеп булмый, шуна баш ватып торуның кирәге юк. Үзе генәме, әллә барысы бергәме, прокурор барысына да әзер, сабырлыгы тулып ташыды. Билгеле, бердәнбер шаһит капитан Чураев хәзерге минутта аның янында булса бик шәп булыр иде. Менә кемнең ярдәменә ышана ул! Анын уйларын укыйлармыни, нәкъ шушы вакытта Садыйковлар өендә дә сүз капитан Чураев турында бара, бар нәрсәгә кулы житкән Сөен Бикхужаевнын улын кулга алырга курыкмаган бу киребеткән кеше Азлархановнын бердәнбер терәге булуын барысы да анлыйлар иде.

Бернинди файдасызга ике сәгать үтеп тә китте...

## 7

Шәһәр курантлары төн уртасы житүен хәбәр иткәндә, йокыга талган Лахути буйлап уты сүндерелгән кара «Волга» тавыш-тынсыз гына шуышып килде дә прокурор капка төбендә туктады. Машина ишеге ачылып ябылды һәм тонык кына ут шәүләсе төшкән бакча юлынан берәү өйгә таба атлады. Үзе генә...

Капкадан верандага кадәр жәелгән бетон плитәләрдә ышанычлы адымнар тавышы ишетелде. Прокурор жинел генә атлап килгән бу кешенен Әкрам Садыйков булмавын чамалады. Сөен Бикхужаев та түгел, алар икесе дә гәүдәгә тазалар, центнердан артыкка тарталар, йөргәндә сулышларын гыжлатып алалар.

Өй хужасы төнге сәфәр белән килүченен каршына атлады. Көчле итеп яктыртылган алгы бүлмәдә утыз биш-утыз жиде яшьләрендәге купшы киемле яшь ир-ат басып тора, ун кулында кодлы өр-яна күн «дипломат». Әгәр прокурор төнге кунакны кичен урамда бәйрәмчә киенгән халык арасында очраткан булса, аны Мәскәүнеке дип уйлаган булыр иде.

—Хәерле кич,—диде таныш булмаган кеше һәм кискен хәрәкәт белән үзенең тыңлаусыз чәчләрен артка таба сыпырды, шул чакта анын нык беләзегендә Швейцариядә эшләнгән кыйммәтле, сирәк очрый торган әллә «Картье», әллә «Роллекс»диган алтын сәгать жемелдәп алды.

Хужа кеше сүзсез генә өйгә керергә ишарәләде. Ят кеше өйгә таба атлады да,туктап, ишектән башта хужаны үткәрде. «Сак кеше»,—дип бәя бирде Әмирхан Даутович.

Кабинетка үтүгә, чакыруны да көтеп тормыйча, ишеккә якын кәнәфигә урнашты, прокурор исә язу өстәле артына барып утырды.

Люстра төнге кунак утырган кресло өстенә туры килгәнгә, прокурор аны бик ачык күрде. Кунак моны чамалап алса да, кәнәфине күчереп тормады. Тыштан ул тыныч, тотнаклы, сабыр күренсә дә, Азлarханов анын көтелмәгән һәрнәрсәгә әзер булуын тоймый калмады.

—Мине Әкрам Садыйков дипме, яисә Сөен Бикхужаев дип саныйсызмы—барыбер, үзегезгә ничек унайлы, шулай кабул итегез, мин Гаилә исеменнән килдем,—дип башлады ул сүзен, аннары креслога жайлабрак утырды да тартырга рөхсәт сорады.—Безнен сөйләшү, иптәш прокурор, шактый озынга сузылыр,—дип өстәде һәм шунда ук тәмәкесен сүндерде дә көтмәгәндә:—Зинһар, минем кызыксынуымны кичерегез, тик әнгәмәне башлаганчы сынар күз белән булса да коллекциягезне карыймчы, анын турында бик күп ишеттем,—дип үтенде.—Кабат өлкә прокурорында кунак булу, гомумән

Урта Азиягә килеп чыгу мөмкинлеге булырмы, юкмы? Дөресен әйтим, мин Көнчыгышны яратмыйм, монда кешеләр бик астыртын, аларның кайбер эш-гамәлләрен бөтенләй аңлап булмый.—Кунак урыныннан торды...

Прокурор аның үтенечен болай бәяләде: димәк, кунак икенче бүлмәдән куркыныч янамавына ышанырга тели. Ул, берни сизмәгәндәй кыланып, аны залга чакырды һәм бүгенге очрашудан бу теле телгә йокмас кешедән күпне сыга алуына өмет итте.

Керамика белән кызыксынуы шул кадәрле генә булды күрәсең, бүлмәләрдә ул ике-өч минуттан артык тоткарланмады. Кабинетка әйләнеп кергәндә, тынычланган иде инде.

—Шушы чүлмәкләрне йөз илле мең дип бәяләделәрме?—диде ул, күнеле кайтып.—Ярый әле шул суммада тукталганнар, аның өчен соңгы елларда Лондон аукционында берничә танылган керамика коллекциясе Әнкара белән Порт-Сәетнеке белән чагыштырганда шактый кыйммәткә сатылган. Беләсезме, менә шушы коллекцияләрне хатыныгызның тупланмалары белән, аеруча соңгысы—Цюрихта күрсәтелгәне белән чагыштыралар һәм кайбер сәнгать белгечләре сезнекенә өстенлек бирәләр. Сүз дә юк, Мәскәүдәге кешеләр тырышканнар, тау кадәрле газеталарны актарып чыкканнар, чит ил газета-журналларында басылган мәкаләләрнең күчермәләрен алганнар. Аннары, Лондон аукционнары бәяләре буенча эш итәргә дигән идеяне дә алар бирде бит. Япон машиналары ярдәмендә коллекция йә аерым экспонатның якынча шактый түгәрәк бәяләре күрсәтелгән барлык мәкаләләрнең югары сыйфатлы күчермәләре алынган һәм шунда, янәшәсендә үк, русча тәрҗемәсе дә бирелгән. Бу документлар шактый җыелды һәм алар сезнең өстән язылган шикаятьләрнең һәрберсенә беркетеп барылды. Бичара белгечләр нишләсеннәр инде, без күрсәткән юл буенча китми чаралары булмады, югыйсә, аларны сезне яклауда, объектив булмауда гаепләрләр иде. Тагын шунысын әйтә алам: безнең берәр музей чүлмәкләрегезне алырга уйласа, меннән артыкка риза булмас иде. Нәрсә ул мең, аннан нинди янгыраш—җәмәгатьчелек фикере өчен ул нуль, шуңа мең безне канәгатьләндермәде. Ә йөз илле мең—менә бу ришвәт ичмасам, аның өчен теләсә кемне карага манарга була...

Прокурор аның бер сүзен читкә очырмый игътибар белән тыңлады, тегесе үзен шушы пычрак эшне башлап йөрүчеләрнең берсе итеп таныштырга теләде.

Тукта, Азлархановның бу адәмне кайдадыр очратканы бар бит, әйе-әйе, нык ихтыярлы тупасрак чырай, салкынлыгы бәрелеп торган кысынкы күзләр, сизелер-сизелмәс ак юллар сузылган чәч, текә маңгай—болар бар да таныш, тик кайда күрде соң ул аны: аеруча куркыныч җинаятьчеләр тупланган картотекадамы, әллә өлкәдәге колонияләрнең берсендә шәхси эшләр караганда берәр документтагы фотодамы? Һәм аның тәкәбберлеген киметә төшү өченме, әллә инде уйлаганын тикшерү максатыннанмы, соравын турыдан ярып бирде:

—Прокуратурадагы сейфны сез ачтыгызмы?

Әмма чакырылмаган кунак өчен бу сорау көтелмәгән булмады, ахры, ул кимсетелгән кыяфәт чыгарды:

—Юк, бу минем өлкә түгел, шеф. Югарырак алдырыгыз, мин ачкычлар белән түгел, баш белән эшлим.—Ул тагын тыңлаусыз чәчләрен артка таба сыпырып куйды.—Сейфыгызга килгәндә, аны җәза срогын монда тутыручы ачып бирде. Тик ул сезнең эш турында берни белми. Аңарга кабинет хуҗасы ачкычын югалткан, булышырга кирәк, дип әйтелде. Ә безне сейфтагы һәр район буенча алып барган амбар кенәгәләре кызыксындырды. Шулардан алынган мәгълүматлар бәрабәренә җаваплы кешеләр безгә сезне батыруда ярдәм иттеләр. Күрәсез, план барып чыкты. Районда суд шоп-шома гына

үтеп китте, Балан мәчете урнашкан Сардоба районындагылар да нык булыштылар. Ә инде альбомны бозган өчен гафу сорыйм, безнең башка чарабыз булмады. Сезнең ул куышыгызда төсле күчермә алырлык машина табылмады, Дини идарәне исә бары тик фотографиянең төп нөсхәсе белән генә ышандырып була.

—Сез ни өчен боларның барысын да миңа сөйлисез? Үзегезгә үзегез чокыр казыйсыз түгелме? Оешкан җинаятьчелек бездә каты җәзага тартыла, беләсездер.

Таныш түгел адәм мыскыллы көлде генә:

—Курыкмыйм, иптәш прокурор, курыкмыйм. Мин бит шуның өчен акча алам. «Оешкан җинаятьчелек», имеш...Бу сүзне ычкындырырга, ай-һай, ничек куркасыз. Хәтта халыкка җинаятьчеләр турында авыз ачарга да кыймыйсыз, үзегезне төрле уйдырмалар белән юатасыз: бездә юк, булырга мөмкин түгел, янәсе. Инде миңа бәлага дучар булган прокурорның үзе белән очрашырга язган икән, шунысын да әйтим: җинаятьчелек бездә гадәттә оешкан була, ул шундый шәп оештырыла, сез аны күз алдыгызга да китерә алмыйсыз, югыйсә, яхшырак көрәшер идегез. Сез миңа акыллы кеше, үзегезгә каршы аякланган төркемнән бер дә курыкмыйсызмыни? Оештыручылары кемнәр бит: Сөен Бикхуҗаев—Хезмәт Батыры, Югары Совет депутаты, колхоз рәисе; Әкрам Садыйков—өлкә комитеты бюросы члены, бик зур урындагы кеше, шулай ук депутат; өлкә милициясе башлыгы Иргашев, прокурор Исмәгыйлев һәм менә мин—профессиональ җинаятьче.

Сез намусын сатучылардан түгел, кем-кем, әмма без моны яхшы беләбез. Сезнең хөрмәткә лаеклы кеше икәнегезне, мөгаен, югары урындагылар да беләдер, ә шулай да иң кирәк чакта сезне ялгыз калдырдылар. Республика прокуроры да яклап сүз әйтмәде, хәтта бюрога да килмәде бит. Дөресен әйткәндә, планнар корганда, шундый шикле анонимкалар һәм демагогик чыгышлар белән генә өлкә комитеты прокурорын салып таптап булырына ышанмаган идем. Садыйков дөрес булган, ул, билгеле, сезнең мохитне яхшырак белә, ә безнең җинаятьчеләр дөньясында кешегә ансат кына яла ягу барып чыкмас иде. Сәер, сезнең монда әхлак турындагы төшенчәләр тәмам үзгәреп беткән.

—Әхлагыбызның нинди икәнен ачыклауны үзебезгә калдырыгыз, сезләп башка да ерып чыгарбыз. Барысы да сез уйлаганча начар димәс идем, яшь кеше. Ә сезнең берлек озакка бармас, безнең арада Иргашев, Бикхуҗаевлар кебекләр күп түгел, югыйсә, сез хәзер срок тутырмас идегез,—дип бүлдерде ул фәлсәфәгә бирелгән кунакны һәм, йөзе үзгәргәнне күреп, соңгы җөмләсенең аңа нык тәэсир иткәнен аңлады. Димәк, дөрес чамалаган булган...

—Азмы, күпме, ә шулай да тормышыгызны боздылар, карьерагызны җимерделәр. Җырыгыз җырланган, прокурор, сез оттырдыгыз. Менә нәрсә, әйдәгез сүз көрәштермик, чөнки без—капма-каршы фикер кешеләре, ярты сәгатьләп сөйләшәбез инде, ә эшкә керешкәнебез юк...

Прокурор исә кәнәфигә җайлы урнашкан адәмгә карап, республика прокуратурасында уза торган ябык киңәшмәләрне күңеленнән кичерде. Бу киңәшмәләрдә коллегалары үз крайларында һәм илдә оешкан җинаятьчелек белән хокук саклау органнарының бергә кушылуы турында ничә мәртәбәләр сүз кузгатып карадылар, тик аларны шунда ук туктаттылар йә китерелгән мисалларны уен-көлкегә алдылар. Каршында үзен бик иркен тоткан төнге сәфәр ясаучыны да Ростов йә Грозныйдан, Мәскәү йә Тбилисидан килгән «кунак» дип кистереп әйтә алмас иде. Ул әлеге хәлләр тәмамланганчы полковник Иргашев тарафыннан үзләренең өлкәсендә урнашкан

төрмәләрнең берсеннән вакытлыча чыгарылганга охшаган..

Шушы чакырылмаган кунакны тоткарлый алса иде ул! Тик прокурор моның буш хыял гына икәнен белә, әлбәттә. Беренчедән, аны, мөгаен, саклыйлардыр, иярчене иң кирәк мизгелдә янында булу өчен җәйге веранда күләгәсенә ышыкланып торырга мөмкин; икенчедән, җинаятьче, әлбәттә, коралланган. Әмирхан Даутович алгы бүлмәдә үк аның юка модалы кәчтүме астында сизелер-сизелмәс төртеп торган пистолетын чамалап алды. Ә иң мөһиме—ике инфаркт кичереп яңа тернәкләнеп килгән кеше типсә тимер өзәрлек, өстәвенә кансыз җинаятьчегә каршы тора аламыни? Пулядан йә булмаса каратэ, кунфу алымнарыннан—һичшиксез, ул аларны яхшы белә, нәкъ менә башкалардан үзен өстен сизү аны җинаять юлына этәргәндер—дөнья белән хушлашу ахмаклык булыр иде. Иң аянычы: бу фаҗига була калса, белмим, кайчан да бер ачылыр идеме; иртәнгә җинаятьче төрмәгә әйләнеп кайта һәм вәссәлам—кайсы акыллы башы үтерүчене төрмә рәшәткәсе артыннан эзләп йөрсен?

Кунак озынча пачкадан яңа сигарет чыгарып, кыйммәтле чакмадан ут элдерде.

—Башымны ташка орыйм, сезнең янга килүемнең сәбәбен барыбер белә алмыйсыз...

Телен ачарга мөмкинлек биреп, прокурор аны бүлдермәде.

—Кыска гына әйткәндә болай: сезгә менә шушы француз «дипломат»ын тапшырам, сүз уңаенда, хәзерге вакытта бу әйбер бик модалы санала. Тик үземә тапшырылган тыйнак кына йөкләмәне ачып салганчы Бикхуҗаевларның зур гаиләсе, хатыныгыз вафат булу сәбәпле, зур кайгыгызны уртаклашуын хәбәр итәргә тиешмен.

Йорт хуҗасының гаҗәпләнгән йөзен күреп, кунак тагын бер кат кабатлады:

—Әйе, әйе, ихлас күңелләреннән. Сез бит хатыныгызны махсус үтерделәр дип санамыйсыз, шулаймы?.. Бу фаҗигале дип санала торган очрак. Сезнең өчен дә, алар өчен дә... Язмыштан узмышлар юк. Сезнең зур югалтуыгызны да, Сөен Бикхуҗаев хәлен дә аңлыйм. Ул менә нәрсә ди: улын хөкем итсәләр дә, итмәсәләр дә прокурорның хатынын кире кайтарып булмый, шулай булгач тагын бер язмышны харап итү кирәк микән? Әхлаксызлык билгеле, тик моның җитди сәбәпләре бар. Бу якларда Сөен Бикхуҗаев билгеле бер хакимлеккә ия, күпләр югары урыннарга күтәрелүләре белән аңарга бурычлы. Ахыр чиктә Гаилә үзенең гаебен кире какмый бит, киресенчә, җаваплылык алырга әзер, әйтик, матди яктан. Шәхсән сезгә карата алар тискәре мөнәсәбәттә түгел, әгәр эшне яңадан карауны кузгатмаган булсагыз, әле дә үз урыныгызда утырыр идегез. Шулай итеп, урындыгыгыздан үз аркагызда колак кактыгыз булып чыга; нишлисең, уенның шарты шундый кискен: йә сез аларны, йә без сезне. Башкача булмый. Әгәр сез үз дигәнегезгә ирешкән булсагыз, полковник Иргашев белән прокурор Исмәгыйлевка җәзаның катысы эләккән булыр иде, уен бик тирәнгә китте, артка юл юк. Аннары, эчкерсезлегем өчен кичерегез, ике инфаркттан соң аякка басарсыз дип, берәүнең дә башына килмәде. Тагын бер тапкыр кабатлыйм, беркем дә сезне хезмәт урыныгыздан мәхрүм итәргә теләмәде, менә бу—шуның дәлиле. Таныш булмаган кеше идәндә торган куе кызыл «дипломат»ны алып тезенә куйды да тиз генә шифр җыйды. Җиңелчә генә чертләгән аваз чыгарып, капкачы үзлегеннән күтәрелә башлады һәм кунак ачык «дипломат»ны хуҗага таба борды.

—Монда төп-төгәл йөз мең, бу сезгә безнең аркада югалткан эш урыныгыз, хезмәт машинагыз, бушлай юлламалар, буфет һ.б. өчен түләү. Хезмәт хакында булачак үзгәрешләр дә, искиткеч бакчалы йортыгызны

югалту да—мөгаен, аны сездән алырлар—исәпкә алынды, күрдегезме инде үзсүзлелегегез нәрсәгә китереп житкерде...

Ул «дипломат»нын капкачын «шап»итеп япты да идәнгә куйды һәм аягы белән жинелчә генә прокурорга таба этәрде.

Прокурор сүзсез генә ботинкасынын очы белән «дипломат»ны кире төртеп жибәрде.

—Йөз менгә риза түгелме? Азсынасызмы? Анлыйм, андый урынны югалтсам мин лимон таләп итәр идем.

Прокурор лимоннын жаргонда миллион анлатканын белә һәм үз якларында яшерен миллионерлар барлыгыннан хәбәрдар иде.

—Миндә ачылык дәрәжәсе югары, шуна лимон ашарга ярамый, зиннәтле «дипломат»ыгыз белән йөз менегез дә кирәкми. Сезнен кебек, үземнен хезмәт урынымны беркайчан да акчалата бәяләгәнем булмады, юкка прокурор урынын югалтканга күз яшьләрен агыза дип уйлыйсыз. Хәер, дөресен әйтим, күп нәрсәгә күзем ачылган вакытта китүем кызганыч, хәзер мин башкачарак эш йөртер идем. Шәхси фажигам аркасында дөньяга күзем ачылды. Ахыр чиктә төркемдәшләрегез белән шуны анларга тырышыгыз: тормыштагы югалтуларнын барысын да акчага әйләндереп булмый...

Таныш булмаган кеше ерткычларча елмайды да кулларын чәбәкләде:

—Афәрин, прокурор, афәрин!

—Шамакайланмагыз!—дип кырт кисте прокурор.

—Ә мин кыланмыйм. Ни өчен үземне алкышламаска—мин яна гына бәхәстә егерме мен оттым. Анлатыйммы? «Дипломат» идеясе миннән чыкмады, аларга башта ук әйттем: акча алмаячак, кешесе ул түгел, дидем. Анын белән, ягъни сезнен белән була инде, башкачарак сөйләшергә кирәк, дидем, ачыктан-ачык әйтүем өчен кичерегез. Ә тегеләр көләләр, кем инде йөз меннән баш тартсын диләр. Менә шунда мин алар белән бәхәсләштем. Сезнен намуслы булуыгыз аркасында егерме мен эшләдем...

Прокурор, Бикхужаевлар илчесен бүлдереп:

—Икмәкне авырдан табасыз,—диде.—Мин кисәтеп куям: әгәр юлларыбыз кисешсә, ә аларнын иртәме-сонгы кисешүенә иманым камил, сезне кешеләр арасында яшәтмәс өчен бар көчемне куячакмын, чөнки сез—куркыныч кеше, шунын кадәрле куркыныч, сезнен кебекләргә бездә хәтта маддә дә юк.

Төнге кунак галстугын төзәтеп куйды да, елмая төшеп, жавап кайтарды:

—Сезнен рәхим-шәфкатегезгә беркайчан да өмет багланым булмады һәм анлыйм: без дошманнар, сезненчә әйткәндә, дошманнар лагеренын капма-каршы ягында торабыз. Әмма сәер тоелса да әйтим:үз-үзегезгә ышанычыгыз ошый мина. Беләсезме, хәзерге вакытта кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләр үзгәрә. Дөресен әйткәндә, чын дошманнар да калмады, мөгаен, сез дә мин генәдер, иптәш прокурор, дөресрәге элеккеге, шуна күрә, әйдәгез, бер-беребезгә хөрмәтле булыйк. Әнгәмәбез ахырында мина: «Хатынымны үтерү эшен башка кузгатмам»,—дигән вәгъдә бирсәгез иде.

—Монысы да сезнен идеяме?—дип сорады прокурор, чәнчеп.

—Әйе, минеке, үз сүзен сүз итүчеләрнекенә—аларны «радикаллар» дип атыйк—караганда акылга сыешлырак.

—«Радикаллар»ыгызнын планнары нindирәк инде?

—Ә менә монысын мин сезгә әйтә алмыйм, чит кешеләр сере. Тик шуны белегез, планнары коточкыч, хәтта үземә дә куркыныч булып китә. Башыгызны эшләтегез, прокурор, минем шартларны кабул итегез. Тартышта өстен чыга алмыйсыз—көчләрегез тигез түгел: рухи яктан да, матди яктан да. Вакыт Бикхужаевлар ягында. Өстәвенә һәр ясачаяк адымыгыз безгә билгеле, әнә, ярты ел элек уйланганнар бар да дөрескә чыкты. Кулда торасың, әлегә

кадәр бер мәртәбә дә ялгышканыбыз булмады. Без кул кушырып утырырга җыенмыйбыз. Кенәгәләрегезнең дә ярдәме искиткеч, хәзерге вакытта бик күп хөрмәтле кешеләр өчен сезне урыныгыздан алып ташлау кулай.

Аннары, нәрсәгә ирешмәкче буласыз? Сезнең бердәнбер мөмкинлегегез, дөресрәге, ярдәменә өметләнерлек һәм шаһит буларак таянырлык бердәнбер кешегез бар. Менә монысында аз гына борынга чиерттегез, Ташкентка күчереп өлгердегез, кызганыч, ә полковник Иргашевнын Чураевка карата планы шәп иде—тормышка гына ашыра алмады. Югыйсә, бу мөмкинлектән дә колак кага идегез. Яшереп тормыйм, без тау кадәрле эшне майтарып ташласак ташладык, әмма үтерүчеләрне шулай тиз тотарга Чураевка кем ярдәм иткәнен барыбер ачыкладык. Судтан соң капитаннын кем белән очрашуын да тәгаенләдек. Аларга өметләнмәсәгез дә була, үз вакытында фаш ителми калган кайбер гөнаһларын исләренә төшереп, аларны азрак куркытып алу җитте—авызлары томаланды. Тик менә Чураев белән генә кыенрак, аны куркытып та, сатып алып та булмый. Сезгә дә билгеледер, мөгаен, бервакыт ул качып йөргән берәүне эләктергән, ә тегенең янында акчасы менә бу «дипломат»тагыдан да күбрәк булган. Тоткын шул акчалар бәрабәренә үзен җибәрүен үтенгән, тик Чураев кире каккан.

Прокурор, әлбәттә, бу вакыйганы хәтерли, Чураев намусында өч үлем теркәлгән аеруча куркыныч рецидивистны тоткарлаган иде.

—Менә шулай...Чураев... Шымчы эше—куркыныч, анын белән көтелмәгән хәлләр булырга мөмкин, сез моны яхшы беләсез, прокурор, шулай бит? Милиция бигрәк тә җинаятьчеләрне эзләү бүлеге кешеләрен күбрәк югалта. Анын машинасындагы рациянен радиочакыруы белән эш ешлыгы безгә мәгълүм. Әйтик, капитан кич соң гына өенә кайтып барганда бер йорт янынннан үтеп бара, ди. Ә анда фотографияләре капитаннын түш кесәсендә йөргәннәр җыела, ди. Кыю һәм намуслы кеше буларак, ул алар белән очрашасы килү коткысын җинә алмый. Күптән эзләүдә саналган кешеләрне эләктерәсе килеп, саклык чараларын да оныта.

—Бәхет кемгә елмая, шул исән кала дисеңме?

—Юк,—дип, кунак башын чайкады.—Капитан исән калмаячак, чөнки тегеләрнен очрашу вакытында сакта торучысы, ыгы-зыгыдан файдаланып, аны атып үтерәчәк. Атышу кара-каршы барачак, шулай итеп, ул хәрби постында намус белән һәлак булачак һәм анын үлеме берәүдә дә шик тудырмаячак. Ничек, прокурор, эзлекле фикер йөртәмме? Әле бу планнын берничә варианты да бар. Чураев кебек башсыз кешене берәр карангы почмакта йә подъездда пуля яки пычак белән каршы алырга да була. Һәм сонгысы. Сез: Азат Ходайкулов бар бит әле, намусы уяныр да дөресен сөйләп бирер, дип әйтерсез. Сөйләмәячәк. Ни өченме? Чөнки суднын мәрхәмәтлелегенә өмете кечкенә, прокурорга кирәк булган дөреслек аны дулкынландырмый, аны бары тик бер нәрсә: ирекә чыккач тормышы ничек дәвам итәр—шул борчый. Үзенеке дә, авыру әнисенеке дә Бикхужаевларга бәйле.

Аннан сон ул капитан Чураев түгел бит, анардан гаиләгә курку-шом янамый. Тулы гарантия өчен бөтенләйгә дәшмәве кирәк була икән—ышаныгыз, дәшмәячәк. Ул күп катлы йорт төзелешендә өченче сменада эшли, йоклар-йокламас йөргән бер мәлендә—карыйсын—бичара монтаж чокырына очып төшкән була.

Сөйләшү бирелгән вакытыннан чыктымы, кунак нервланып, әледән-әле сәгатенә карый башлады.

—Хәзер, ышанам, сезнен вәгъдә дигән сүзегезнен ни бәрабәренә торуы башыгызга барып җиткәндер, ниһаять.

Прокурор башын игән хәлдә утыруын дәвам итте. Ул кланнын хәйләкәр планына берсүзсез ышанды, алар анын дәшмәвен ике гомергә

алыштырмакчы булалар. Ә үзләренекен итү өчен аларның теләсә нәрсәгә әзер булуларына Азлархановның шиге юк.

Чураевның гаиләсен, аның ике кечкенә баласын күз алдына китерде. Эркиннең үзе турында да уйланды: ышанычлы, турылыклы иптәш. Юк, ул алдына нинди генә максат куйса да, үз куллары белән аны һәм яңа гына унсигезен тутырган Азат Ходайкуловны үлемгә дучар итә алмас иде, юк.

Прокурор уе белән әле анда, әле монда ябышты, әмма ул билгесезлектә, аны селкенә алмаслык итеп китереп кысканнар иде.

«Бу адәм актыгына вәгъдә бирү—тегеләр алдында тезләнү, аларның дөреслеген тану...»—кунакның ашыгу-кабалануын сизмичә, прокурор ачынып фикер йөртте.

Шунда кинәт Бикхуҗаевлар илчесе, аның уйларын укыгандай:

—Мин сезне ирексезләп, беразтотнаксызлык күрсәттем, ахры, кичерегез. Әйдәгез, болай итик. Мин ялгызыгызны гына калдырам, безнең тәкъдим белән үзегезнең мөмкинлекләрегезне әйбәтләп тагын бер кат үлчәгез. Әгәр шартка күнәсез икән, нәкъ ярты сәгатьтән зал утын кабызырсыз. Юк икән инде, Аллаһы Тәгалә сезне ярдәменнән ташламасын, алга таба эш «радикаллар» кулына күчә.

—Ә сез үзегезне «либерал» дип саныйсызмы?

—Әйе. Бәхетегез, сезгә үзләре белән сөйләшергә туры килмәде,—дип, тиз генә «дипломат»ны эләктерде дә кабинеттан чыгып юк булды.

Төнге кунак җәйге верандадан капкага сузылган бетон сукмактан атлаганда, аңар тагын ике кешенең аяк тавышы өстәлгәнен хуҗа ачык ишетте.

Прокурор, башын иеп, шактый озак утырды. Кинәт аныкбер уйга килеп, телефонга ташланды. Берсенең трубкасын күтәрде, икенчесен—телефоннар эшләми иде.

Бу төндә беренче мәртәбә аны курку биләп алды. Соң аларның кыскарак һәм ышанычлырак башка вариантлары да булырга мөмкин, ләбаса...

Төнге кунак белән ике арадагы сөйләшүне хәтер иләге аша тагын бер кат үткәрде, вакыт-вакыт аңа әле булган хәлләр детективтан, чит илнекеннән өземтәләр кебек тоела, әгәр берәрсенә сөйләсән—чынга алмаслар иде, билләһи. Тик бар да чынбарлык—шунысы өркетә. Шушы коточкыч кешеләрнең баш булып йөрүләрендә аның да гаебе бар.

Урамнан әкрен кенә машина кычкыртканы ишетелде. Бу—аңа бирелгән вакытның чыгуын аңлата иде.

Прокурор авыр гына күтәрелде дә, чайкала-чайкала, залга үтте һәм бер генә секундка утны яндырып-сүндереп алды.

Ике машина берьюлы тавыш бирде дә, татлы йокыга чумган Лахутины сискәндереп, карангыга кереп югалды.

## БИШЕНЧЕ БҮЛЕК

### Айсберг

#### 1

Беренче майга каршы шушы төннән соң, прокурорның тормышы кинәт үзгәрде. Урынын югалтты, партия линиясе буенча каты шелтә алды. Әмма аны җәзаның кырыслыгы, гаделсезлеге түгел, ә Бикхуҗаевлар юллаган төнге илченең яшермичә, турыдан-туры сөйләп бирүе аягыннан екты. Ул бу елларда нинди дер үзе күзаллаган аерым, уйдырма дөньяда яшәгән булып чыга, ә шул арада катламнар барлыкка килгән, чәчәк аткан, прокурор исә аларны чамаламаган да икән. Монарчы үзен җирдә нык басып торган кешегә саный иде, тик чынбарлык ул күз алдына китергәнгә караганда

икенчерәк, күпкә карангырак икән. Ларисаның үлеменә кадәр прокурордан: үз өлкәндәге тормышны яхшы беләсенме, тәртиптә тотасыңмы? дип сорасалар, ул, мөгаен, бик нык үпкәләгән булыр иде. Ә хәзер белә: кәгазьләр, телефон, газеталар, җиңү рапортлары—менә тормышы шуннан гыйбарәт булган. Элеккеге урынында калган булса да, аның рухы төшәр иде—намуслы кешеләр өчен ышаныч сызыгыннан атлап чыгу эзсез калмый.

Аны прокуратурада калдырдылар, кайчандыр бу бинада иң беренче башлаган эш урынына күчерделәр. Көзен исә ул, нервлары таушалып, хастаханәгә эләкте һәм ике айлап ятып чыкты.

—Сез тормышыгыз өчен әһәмиятле ниндидер юнәлешләрне югалткансыз...—диде ана дәвалаучы табибы.

Өлкән яшьтәге табиб аның нервысы какшавын шәхси фаҗигасе нигезендә генә дип санаса да, диагнозны төгәл куйды. Әмма прокурор аңарга барыбер ахыргача ачылып бетә алмады.

Прокуратурада һәркем аңа аяк чалырга тырыша, монда ике яклы тормыш алып барыла кебек тоелды, авыруы да шуннан башланды, ахры. Серле катлам элеккечә яшерен кала бирде, ә калганнарына исә ышанычын югалтты. Утырышларда да коллегаларын элеккечә тыныч, ышанып тыңлый алмады; һәр чыгышның төбенә төшәргә, аларның сүзләре артында табыш-файдамы, яшерен исәп-хисапмы йә гаделлекме—нәрсә торганын аңларга тырышты. Ә элек почмакларда чыш-пыш килгәннәренә игътибар ителмәгән—кешеләрнең шәхси мәшәкатьләре беткәнмени, янәсе. Прокуратурага кем килә, кем белән аралашалар—анысына да исе китмәгән. Менә хәзер, авызы пешкәч кенә, элеккеге кул астындагыларның бар эше ниндидер серле очрашулардан, ябык ишек артында пышылдашулардан торгандыр сыман тоелды аңа. Әле бер ел элек кенә ул коллегаларының дус-ишләренә күз дә салмаган булган. Ә хәзер күреп тора: аларның күбесе кибет мөдирләре, директорлар белән авызга-авыз кешеләр. Аның уенча, прокуратура бинасын чакрым ераклыкта урап узарга тиешле бу адәмнәр, яшеренеп-нитеп тормый, үз машиналарында килеп тегеләрне алып китәләр йә ачыктан-ачык коридорда сөйләшеп торалар. Ничектер, прокуратурадагы иң яшь хезмәткәрләрнең дә «Жигули»ларда җилдерүләренә дә әһәмият ителмәгән. Аларга караганда хезмәт хакын өч мәртәбә артык алса да, алар Лариса белән очын очка ялгап яшиләр иде. Дөрес, беразын коллекциягә, альбом һәм китапларга тоттылар. Машина Ларисаның эшендә уңайлыклар тудырса да, «Жигули» алу турында телгә дә кертkәннәре булмады..

Ә туйларга һәм башка шундый тантаналарга чакырулар? Кемнәргә? Бу бәйләнешләрне яшереп тә маташмадылар, киресенчә, иртәгесен бик горурланып кемнәрдә булулары, биш йөз кешелек итеп әзерләнгән бай өстәл артында утырулары, кемнәр нинди зиннәтле бүләкләр алып килүләре турында һәр почмак саен авыз суын корытып сөйләп йөрделәр. Коллегаларының исен китәргән кунакчыл хуҗа, баксаң-күрсәң, йөз егерме тәңкә хезмәт хакына эшләүче гади бер склад мөдире булып чыга.

Суд оешмасы хезмәткәрләренең һөнәри этикалары турында сүз кузгаткалап караган чаклары булды, кая ул—шунда ук көлкегә алдылар:

—Менә, кабинетыгызны алыштыргач, ничек сайрый башладыгыз? Ә бер кат өстәрәк утырганда нигә тавышыгыз чыкмады?..

Күнеле белән коллегаларыннан шикләнмәскә тырышты ул, әмма шуларның кайсыдыр Иргашевка сейфны ачарга, кәгазьләрендә актарынырга булышкан бит, кемдер Сардоба районында булган командировка вакытларының төгәл датасын эзләп табышкан. Кем белә: берәр коллегасы Бикхуҗаевлар эшендә очны очка ялгау өчен юрист буларак киңәшләрен биреп, судны тизләтергә ярдәм иткәндер. Боларны уйлап, күрәсең, аның

нервлары кыл кебек тартылган булгандыр, коллегалары белән бер сөйләшүдә ул ычкынып китте һәм нәтиҗәдә психоневрологик хастаханәгә эләкте. Кайчандыр хәрби госпиталь булган бу хастаханә партия өлкә комитеты бинасы белән бергә торгызылган булган, шунлыктан монда да бик матур паркка нигез салынган. Палаталарның тәрәзәләре имәннәр утыртылган аллеяга карап тора. Меньяшәр имәннәрдән асфальт сукмакка тып та тып чикләвекләр коела. Ул бер кешелек биек түшәмле, якты палатада ята. Бу бүлмә тынычландыру көченә ия, ахрысы. Элеккеге осталар биналарны гасырлар буе саклансыннар дип кенә түгел, ә сараймы ул, театрмы йә госпитальме—серен, жаен белеп төзегәннәр.

—Мина калса, мондагы диварлардан да шәфкатьлелек, мәрхәмәтлелек бөркелеп тора,—диде ул хастаханәнең баш табибына. Соңгы елларда еш дәваланырга туры килде ана, шуна сүзләрен уйлап әйтте.

Аларда элегрәк булгалаган баш табиб Зоя Алексеевна Ковалева ихлас күңеленнән аның хәленә керде. Хастаханәдә кырыс режим куелган, әмма ике атна үттеме икән, прокурорның үз көн тәртибе барлыкка килде. Быелгы көз җылы килде, явым-төшемнәр юк, шуна ул озаклап бакчада йөрде, имән чикләвекләре коелган сукмактан атлаганда күңеленә тынычлык иңүен сизде. Һәр көнне бакчаның әле бер, әле икенче ягына килеп чыга, яшерен почмакларның матурлыгына карап соклана, аннары берәр беседкага кереп утыра да жәен Монтениның «Литературные памятники» сериясендә чыккан өчтомлык «Опытов» китабын кулына ала.

Прокурор хастаханәдә, мөгаен, өч-дүрт атнадан артык тоткарланмаган булыр иде, тик баш табиб, Әмирхан Даутовичның Лахутидагы йортын алырга дигән карар чыгарганнарын ишетте. Тормышында тагын бер көтелмәгән текә үзгәреш авыруның психикасына ничек тәэсир итәсен белмәгәнгә, Ковалева прокурорны хастаханәдә булдыра алганча озаккарак калдырырга тырышты. Йорт мәсьәләсенең тәмам хәл ителгәнен белгәннән соң, табибә акрын-акрын гына аны әзерли башлады: жае чыккан саен, кичерәк, унайлы фатирда үзеңне ышанычлырак хис итәчәксен, дип әйтә килде. Тамчы тама-тама ташны тишкәндәй, прокурор да бу фикер белән килеште: чыннан да, Ларисасын хәтерләтеп торган Лахутидагы йорттан баш тартырга кирәктер.

Пациентын жәлләп, аның сәламәтлеген һәм психикасын кайгыртып, баш табиб аңарга үзе теләп йорттан баш тартуы турында гариза язарга киңәш итте, һәм ул дәваланган арада шәһәр башкарма комитеты аша торак мәсьәләсен хәл итәргә вәгъдә бирде; ул прокурорга бер бүлмәле фатир бүлгәннәрен белә иде инде. Лахутидагы йортыннан баш тартып гариза язганда, Әмирхан Даутовичның алдына үзеннән-үзе: Лариса Павловнаның коллекциясен нишләтергә? дигән сорау килеп басты.

Альбом һәм каталогларны гына калдырып, коллекциянең үзен урындагы крайны өйрәнү музеена бушлай бирергә әзер иде Азлархановс.

Тик тупланманы музейга тапшырганда тоткарлык килеп чыкты... Нотариуста расланган бүләк язуында коллекциянең йөз илле мен торганлыгын күрсәтмәвен үтенделәр, янәсе музей балансына шундый зур сумманы алырга туры киләчәк.

Прокурор исә, белгечләрнең нәтиҗәсенә таянып, сумманы күрсәтүне таләп итте, шулай итеп эш вакытлыча тукталып калды. Музей директоры коллекциягә бәя куюны җирле сәнгать белгечләренә тапшырырга тәкъдим ясады. Озакламый хастаханәгә яңа белешмә китерделәр, анда коллекция бер мең үндүрт сум да алтмыш ике тиенгә бәяләнгән иде.

Прокурор сүз әйтерлек хәлдә түгел иде, ул бик озак кәгазьгә текәлеп утырды. Бәлки ул бюроны, анда яңгыраган коточкыч зур сумманы исенә

төшергәндер, ә бәлки тиененә кадәр төгәл әйтеп биргән төнге кунакны хәтереннән үткәргәндер...Башын күтәреп, музей директоры белән янәшә торган баш табибка күз төшереп алгач, шушы бәя белән килешәм дип, имзасын сырлады.

Музей коллекцияне үз саклау урынына күчерүгә, Зоя Алексеевна прокурорга торак алыштыру мәсьәләсенең хәл ителүен һәм тиз арада шунда күчәргә кирәклеген әйтте. Яңа урынга күчү мәшәкатьләрен коллегалары үз өстенә алуларын җиткерде, гәрчә эшләр башкача тора иде. Иргашев Лахутига милиция взводы алып килде, ут чәчеп торган яшь егетләр ике сәгать үттеме-юкмы, өй эчендәге кирәк-яракларны прокурорның яңа микрорайондагы квартирасына күчереп тә куйдылар. Милиционерларны хуҗа йортының гадилеге, ярлылыгы таң калдырды; шушы ук егетләр язын полковник Иргашевка өлкә үзәгенә күчәргә ярдәм иткәннәр иде, ай-һай, бик авырга туры килгән иде ул чакта!

Фатир алыштыру буенча авыруда шик тумасын дип, Зоя Алексеевна аны хастаханәдә тагын ике атналап яткырды. Шушы вакыт эчендә прокурорны ераккарак җибәрү өчен, неврологик санаторийга юллама юнәтү максаты белән кайларда гына булмады. Үзәктән алу уе барып чыкмады, янәсе прокурор хәзер номенклатур хезмәткәр саналмый икән; тырыша торгач, Таҗикстан тауларында урнашкан җирле Оби-Гарм санаториена юллама эләктерә алды. Табибә буларак, ул нәкъ менә хәзер Әмирхан Даутовичка урын алмаштыруның кирәклеген аңлый иде. Әле шәһәрдә, прокурорның йортын һәм коллекциясен тартып алганнар икән, дигән имеш-мимешләр дәвам итә, һәркем бу хәбәрләрне булдыра алганча төрләндерә, ишеткән очракта, Азлархановның авыру йөрәге моны ничек кабул итә—билгесез, шуңа аның хәзергәерактарак булуы хәерле. Яңа фатирында бер төн кунганнан соң, прокурор санаторийга китеп барды...

## 2

Ничектер шулай килеп чыкты: прокурорның үз гомерендә бер тапкыр ни тауларны, ни диңгезне күргәне булмады. Ә монда менә сиңа мә! дигәндәй, бер ел эчендә язмыш җилләре аны язын Ялта якларына илтеп ташласа, көз ахырында Таҗикстан тауларына алып менде. Һәм берсе дә үз теләге белән түгел—тормыш кушуы буенча. Бервакыт үзәге бик өзелгән чагында: «Югалтулар елы,—дип сыкранган иде.—Хатынымны югалттым, өйсез калдым. Бакчамнан колак кактым. Эшемне, намуслы исемемне югалттым... Коллекцияне, ачык һавада урнашкан музейны ... Сәламәтлегемне...»

Тик кеше бервакытта да өметен өзми, аны тормышта нииндидер ышаныч тота... Ул елгы көз, гаҗәпкә, озын, җылы килде. Гиссар сыртындагы текә тау битләрендә куе булып үскән агачлар әле яфракларын коярга өлгермәгән, алар көз-рәссамның пумаласы ярдәмендә сарылы-кызыллы төсләргә манылып, тирә-юньгә нур чәчеп утыралар. Җиләк-җимеш агачлары да уңышлардан сыгылып тора, өлгергән алма, груша, айва, хөрмә исләреннән баш әйләнә. Кичләрен тауларда сизелерлек суыта, шуңа пионер вакытларны хәтерләтеп, учаклар тергезәләр. Прокурор, чапанга төренеп, сәгатьләр буе ялкын телләре биешкәнен карап утырырга ярата.

Көндезен озаклап санаторий тирәсендә йөри, хәтта кайбер көннәрдә төшке ашны да үткәреп җибәрә, тик үкенми, сонлап булса да, табигать белән аралашудан җанына шифа ала. Кайвакытта башына төрле уйлар килеп китә: әгәр шәһәрне, прокуратураны ташлап, бөтенләйгә монда калса? Берәр эш табылмый калмас иде әле.

Тик соңгы елда югалтулары күп булды шул, никадәр генә күңеленнән куарга тырышса да, тоз эләккән яра сыман, җанында сулкылдап тора. Бик

әрнегән көннәрнең берсендә, көндәлек сәйраны вакытында башына: ник әле үзе, гаиләсе белән булган хәлләр турында республика прокурорына язмаска, дигән уй килде. Тауларда аның яратып өлгергән почмагы бар иде—еллар һәм жилләр тау токымын шулкадәр эшкәрткән, менә дигән язу өстәле белән кәнәфи ясап куйган. Ул соңгы вакытларда менә шушында китаплар укырга йә уйларына чумып, тын гына утырырга иярәшеп китте. Уйлаган ниятен ахырына житкерергә теләп, ул атна буе таш өстәл артында башыннан кичкәннәрне калын дәфтәргә теркәде. Хатынының шау-шу куптарган коллекциясен янарак кына мең сумга бәяләүләре, аны үз теләге белән музейга тапшыруы турында язарга да онытмады. Дәфтәргә бер-бер артлы йөз мең салынган «дипломат», төнге кунак, аның дуслары—полковник Иргашев, прокурор Исмәгыйлев, депутат Бикхужаевлар турындагы юллар тезелде. Анардан капитан Чураев белән тоткын Азат Ходайкуловның гомерен хәвеф-хәтәрдән саклавын үтенде.

Калын дәфтәрне Ташкентка кыйммәтле бандероль итеп жибәргәннән соң, аның жаны бушанып калды, күңеле күтәрелде. Теге вакытта, Беренче май алдыннан, Бикхужаевлар кланының кырыс шартларына күнеп, ул килешергә мәжбүр булды һәм шул адымы әлегә кадәр анарга тынычлык бирмәде, жанын көйдерде. Менә, ниһаять, ярты еллап узганнан соң, ул үзендә кабат көрәш башларлык көч таба алды.

Прокурорның чын күңелдән ачынып язылган язмасы күрше республикадан исән-имин Ташкентка барып житеп, республика прокурорының канцеляриясенә килеп ирешә. Бәхетенә, дәфтәр аны яхшы белгән һәм хөрмәт иткән кеше кулына эләкте, тегесе укый башлагач, тыела алмыйча ахырына кадәр танышып чыкты. Соңгы битне ябып куюга, шунда ук өлкә прокуратурасына шалтыратты. Трубканы кайчандыр полковник Иргашевка Әмирхан Даутовичның сейфын ачарга ярдәм иткән кеше күтәрде.

—Мин прокурор белән элемтәгә керә аламмы? Анардан кеше әйтеп кеше ышанмаслык гажәеп сәер хат алдым.

Тегесе жавабында аптырап калмады:

—Ничек, сәер дисезме? Соң, психушкадан тагын нинди хат килсен инде...

Элемтәнең теге очындагы тавыш өзелеп торды.

—Ничек психушкадан?

—Әйе, кызганыч, чып-чын психушкадан. Аның ялгызын гына авыр хәлдәгеләр палатасында өч ай тирәсе яткырдылар, ә хәзер ераккарак—тауларга жибәрделәр.

Әңгәмә тормышта очрый торган үзгәрешләр, әлерәк кенә бу якларда данлыклы булган прокурорның кайгылы язмышы хакында дәвам итте...

Канцелярия башлыгы сөйләшү тәмамланганнан соң бик озак аптырашта утырды. «Язмыш, бер карасаң, гажәеп сәер һәм куркыныч, нәрсә күрәсеңне алдан белеп булмый—бер ел эчендә менә дигән кешене сындырып, тормышын пыран-заран китерделәр». Шулай да һөнәри гадәте алдан чыкты: ышану бер нәрсә, ә менә тикшерү, һичшиксез, кирәк. Озакка сузмыйча неврологик диспансер белән элемтәгә керде. Кызганыч, Әмирхан Даутовичның хастаханәдән чыгып, дәвалануын тауларда дәвам итүе расланды. Дәфтәрне нишләтергә дигәндәй, бер тын уйланып торды да, вакытлыча өстәленең аскы тартмасына салып куйды. Ике айлап үткәчме, исенә төшеп, дәфтәрне архивка тапшырыйм дисә, аның юкка чыгуы беленде.

Ә өлкә шәһәрендәге Иргашев кешесе исә канцелярия башлыгын шулай ансат кына төп башына утыртуыннан канәгать иде. Аннары, уңышыннан канатланып, коридорга атылып чыкты да, сагышлы кыяфәт чыгарып, беренче очраган хезмәткәргә: янәсе, әле генә Ташкенттан шалтыратып,

ни өчен психик авыруларны прокуратурада тотасыз, дип искәрттеләр, диде. Һәм прокуратура буйлап имеш-мимеш, гайбәтләрнең яна дулкыны китте...

### 3

Оби-Гармнан прокурор Яңа ел алдыннан кайтып төште. Инде икенче Яңа елны Ларисадан башка каршы ала: узганында реанимация палатасында аунаса, монысында яна буш фатирда. Ике вакыйга бергә туры килсә дә, җанында бәйрәмгә урын юк иде. Күз алдында бәхетле көннәре калыкты: бу вакытта Ларисасы белән бакчаларында, тирә-яктагы балаларны куандырып, зәңгәр чыршыларын бизиләр иде. Башында бер генә секундка:«Лахутидагы яна хуҗалар чыршыны бизәделәр микән?»—дигән уй чагылып узды һәм шунда ук онытылды да—борчу-мәшәкатьләр баштан ашкан иде. Әле әйбер-каралары Лахутидан килгән килеш таралып ята. Яна өенә телефон кертелмәгән. Бәлки кемдер аның сәламәтлеге белән кызыксынган, уңышлы ел теләп тәбрикләгәндер. Күршеләре кемдер—аларны да белми. Житмәсә, телевизоры да күрсәтми, монда көчле антенна кирәк икән. Ә аның хәтта бүлмә антеннасы да юк—барысы да Лахутида калды. Бердәнбер юанычы шул булды: төн уртасына әйбер-караны урнаштырып, фатирын ипкә салды. Жирле курантлар төнге уникене сукканда, ул кухнясында әзерләгән тыйнак кына өстәл янында утыра һәм күңеленнән: «1980 нче ел соңгы ике елга караганда уңышлырак һәм бәхетлерәк булсын»,—дип тели иде.

Тик теләкләре чынга ашмады: янасы да, аннан соң килгәннәре дә шәфкатьле, мәрхәмәтле булмады... Ул Оби-Гармнан кайтканда, Ташкент прокурорны эшеннән азат итәргә кушкан, дигән имеш-мимеш шәһәрне аркылысын буйга гизгән вакытлар иде. Хәтта хастаханәдән Әмирхан Даутовичка хокук саклау органнарында эшләү тыела дигән кәгазь алырга да маташып карадылар. Тик Зоя Алексеевна каты торды: кадрлар бүлегенең елдам башлыгына, андый нерв какшаулар, кайгы-хәсрәтләр кичергән прокурорда гына түгел, теләсә кемдә булырга мөмкин икәнен бик тиз аңлатты.

Прокуратурада ул җәйгә кадәр эшләде, әмма тирә-юнендәге киеренке шартларга түзә алмады—китәргә карар кылды. Өстәвенә, теләсә кайсы әллә кайчангы үпкәләрен искә алып элеккеге таләпчән прокурорның желегенә төштеләр. Бәлки шулай җанын ашаулары яна житәкчелеккә кирәк булгандыр.

Ул заводка эшкә урнашты. Кечерәк кенә заводта юристконсультант эше аның өчен кулай күренде. Тик бер ел уздымы-юкмы, күңелсезлекләр башланды: чөнки житештерү технологияләре, сату, үзкыйммәт һәм продукциягә планлы сарыф итүләргә төшенеп житкән иде.

Житештерү бик гади—әйберләр ассортименты дистә еллар үзгәрми, бары тик үз эшенә битараф кеше генә эшнең асылын сизми калыр иде, мөгаен. Аңлап алгач, ул хәтта югалып калды: яна эшендә анардан бары тик бер нәрсә—предприятие мәнфәгатьләрен яклау гына таләп ителде. Прокурор фикерләвенчә, ул мәнфәгатьләр дәүләт һәм кулланучы ихтыяҗларына каршы килеп кенә калмый, дөресен әйткәндә, еш кына зыян китерә иделәр. Үзенең яна житәкчелегенә шуларны аңлатырга теләде ул, предприятие, дәүләт һәм кулланучыга файдалы булсын өчен үзгәртеп кору кирәклеген дәлилләп күрсәтте. Тик аны тыңларга да, аңларга да теләүче табылмады, әле алай гына да түгел, аның артыннан ишек ябылуга, бармакларын чигә тирәсендә әйләндерделәр: менә акылдан язган, үз-үзен премиядән колак кактыра, янәсе. Чираттагы зур гаугадан соң, ул китәргә мәҗбүр булды : гамәлдән чыгару актына кул куярга теләмәде.

Яна эш тиз генә табылмады... Газапланды, өзгәләнде, шунлыктан еш кына хастаханәгә Зоя Алексеевна янына кереп чыкты. Табибә үзенең танышлары аша аны шәһәр читендәге кирпеч заводына урнаштырды. Бу эш ана тагын да авыргарак туры килде: завод җитәкчелеге белән шул ук мәшәкатьләр, шул ук фикер каршылыклары, әле яңалары да өстәлде...

Заводта эшчеләрнең яртысыннан артыгы—вакытыннан алда азат ителгән элекке хөкем ителүчеләр. Алар калган срокны заводның кайнар цехларында эшләп тутырырга ризалык биргәннәр. Һәм юрист буларак, ул монда ачыктан-ачык закон бозу очракларын күреп алды.Хөкем ителүчеләр төрмәне сөргенгә алыштыру өчен барысына да риза, тик кайнар һәм куркыныч цехларда эшләргә ни теләкләре, ни осталыклары юк иде. Бу социалистик предприятиедә эш сәер куелган: мәсәлән, анарга еш кына йә мастерны, йә технологны, йә учетчик, кладовщикны алмаштырырга туры килә—эшкә килүчеләргә караганда китүчеләр күбрәк, шуна житешмәгән хезмәткәрләрне срогыннан алда иреккә чыгарылганнар белән тутырырга туры килә... Берәр мәҗарага тармаган йә бәхетсезлек очрагы булмый калган берәр тыныч атна булды микән? Эшкә урнашуының икенче көнендә үк анын элекке өлкә прокуроры булуы беркемгә дә сер түгел иде инде, бу исә хәлне катлауландырды гына: тормышка, язмышка ачулы, йончыган кешеләрнең бу һөнәр кешеләренә карата үз фикерләре шул...

Зоя Алексеевна Азлархановка яна эш урыны эзләргә кереште. Тик кая гына мөрәҗәгать итмәсен, һәркайда йә ягымлы, йә салкын гына кире бордылар, югыйсә, тәҗрибәле юристлар кирәклеге мәгълүм иде.

—Яшерен сүз куешканнар,—диде ул, ачынып.

Бервакыт шулай эштән сон калырга туры килде—яндыру миче сафтан чыкты һәм җитәкчелек тулысы белән ремонт эшләрендә катнашты. Эшчеләрне ни хезмәт хакы, ни житештерүчәнлек, ни сыйфат—берсе дә кызыксындырмый, аларга тизрәк көн үтсен, әнә, түрәләрнең башы авыртсын, янәсе. Заводта эшләр туктаса да, алар өчен барыбер—уртача эш хакы килеп тора. Шулай итеп, эштән сонлап чыгу өстенә тукталышта та хәйран озак тоткарланырга туры килде: хәрәкәт графигында билгеләнгәнчә һәр ун минуттан килеп җитәсе автобуслар никтер күренмәде. Прокурор булып эшләгәндә, кирпеч заводы кебек предприятиеләр тукталышына автобуслар сәгатькә бер килә дисәләр, ул, мөгаен, ышанмаган булыр иде : очраклы хәлдер, буяуларны куерталардыр, дип уйлар иде.

Теге апрель төненнән сон, Бикхуҗаевлар илчесе артыннан ук сыкрарга тотынган җан борчуына завод мәшәкатьләре, эшчеләрнең күз күгәртеп сәгатьләр буе автобус көтүләре дә өстәлде. Болар бит барысы да прокуратура күзәтүе астында булырга тиешле нәрсәләр: нәкъ менә үзе—прокурор—халык ихтыяҗларын якларга тиешле кеше иде бит.

Шунадыр, хокук өлкәсендә башлаган теоретик хезмәтен дәвам итү теләге беренче тапкыр кирпеч заводында эшләгәндә уянгандыр. Юк, хәзер анын докторлык, йә булмаса башка фәнни дәрәҗәгә исе китмәде, ул бары тик сонгы өч еллык тәҗрибәсен гомумиләштерергә генә теләде.

Почта тартмасыннан газеталарга ияреп хат чыкты. Берәүдән дә хат көтмәгәнгә гаҗәпләнеп калды. Конвертта кире адрес та күрсәтелмәгән. Башына килгән беренче уе—Бикхуҗаевлар тагын ни белән куандырган икән?—әмма ялгышты. Хат анонимка булса да, прокурорга яхшылык теләүче кешедән булып чыкты. Ул мона бер яктан куанса, икенче яктан кәефе төште. Конверт эчендә газеталан кисеп алынган кисемтә белән машинкада басылган кыска гына язу иде. Кайчандыр үзе еш басканга, прокуратура машинкасын шунда ук танып алды: «Ф» хәрефенен бер түгәрәге җитешми иде. Хат җибәрүче прокурорның авыр хәлдә калуын белә. Тик өлкәдә анарга үзенә яраклы эш

табу мөмкинлеге юк, чөнки куралмаучылары, Азлархановнерв авырулы дип, тирә-якка гайбәт таратканнар. Шуңа аны бер җиргә дә алырга теләмиләр икән. Һәм соңыннан газетадан алынган кисемтәдәге белдерүгә күз салырга кушкан. «Консерв заводына тиз арада тәҗрибәле юристконсульт кирәк. Түләү эш башыннан, торак мәйдан бирелә». Хат язучы аны шунда тәкъдим итүләре, заводта прокурорны көтеп торулары турында хәбәр иткән.

Ул, кулындагы хатны йомарлап, озак утырды, чыннан да, ике инфаркт кичереп, үпкәсе кабарганнан сон, кызу цехларда тузан эчендә эшләрлек сәламәтлек калмаган; кайчакларда хәле китә һәм менә-менә кайнар кирпеч төялгән вагонеткага авар да башка аягына күтәрелә алмас төсле тоелган көннәре аз булмады. Әзер продукцияләр складытерриториясен көненә өчәр ураганда, ничек туры килде шулай өелгән кирпеч өеме өстенә ишелер кебек, ә андый очраклар булмый тормый—бәхетсезлек очрагы диләр дә вәссәлам. Аннан соң, бар, гаепләне эзләп кара: әгәр кемдер синең башыңа авыррак әйбер белән кундырырга уйласа, вакыты да, җайлы урыны да табыла, тузан болыты эченнән берни күренми, иске вагонеткаларның ыңгырашуы һәм чиелдавы астында тавышың үзеңнән ерак китми.

Аның монда эләгүенә сөенеп туялмаган Бикхуҗаевларның тегермәненә су коеп, шушы эшкә ябышып ятудан ни мәгънә?

Иртән завод идарәсеннән күрше өлкәгә шалтыратты. Сөйләшү тоныннан, чынлап та, аны монда көткәннәрен аңлады. Димәк, кемдер аның өчен тырышкан. Күчү белән бәйле мәшәкатьләр дә тиз хәл ителде: көнен генә әйтсен, консерв заводы машинасы юл уңаенда үз продукциясен төяп килә һәм прокурорны әйбер-карасы белән алып китә. Шулай килештеләр дә.

Әмирхан Даутович китү турында гаризасын язарга ашыкты, бер көн үтүгә, исәп-хисап ясады, дүшәмбегә инде завод машинасын көтәсе генә калды.

Ял көне китапларын барлап, кирәк-яракларын тутырды да зиратка Ларисасы белән хушлашырга китте.

Аңа бертуган Григоряннар ясаган һәйкәл-таш ошады. Вәгъдәләрендә тордылар: кабер ташы гына димәссең, чын скульпторлар кулы сизелеп тора—тот та бирәр күргәзмәгә куй, ихластан башкарылган хезмәт. Бронзадан коелган чардуганы алар эскизы буенча эшләнде. Зират туфрагында агачлар әйбәт тамырлана. Күр, әнә чардуган тирәли утыртылган тупыллар һәм имәннәр ничек күтәрелеп киткәннәр, ә роза куаклары исә янәшәдәге каберләргә кадәр үрелгәннәр. Прокурор биргә еш, һәр ял саен диярлек килде, кабер өстен тәртиптә тотты. Ә бүген менә хушлаша...

Зират тавыннан төшеп килгәндә, эңгер-меңгер куерды. Шулай булса да, юл уңаенда Лариса белән бергәләп иң бәхетле ун елын уздырган йорты, күз карасыдай саклап үстергән бакчасы белән хушлашыр өчен Лахутига сугылырга булды. Соңгы елларда Зоя Алексеевна киңәше белән өе турында сүз кату түгел, хәтта уйлау теләге дә булмады.

Кем яши икән анда хәзер?

Лахутига борылуга, баскан урынында катып калды : куаклар—тере стена юкка чыккан. Аларны төбе-тамыры белән йолкып атканнар да тимер-бетон койма бастырып куйганнар.

«Биш катлы йортны панельсез калдырырлык булгач, күрәсең, зур түрә яшидер»,—дигән уй телеп үтте аның башын.

Элеккеге хуҗа, ишегалдына күз саласы килеп, йорт тирәсен әллә ничә кат ураса да теләгенә ирешә алмады. Һәрвакыт ачык торган яшел капканы кара төскә буялган алагаем зур тимер капкага алмаштырганнар. Ни коймада, ни капкада бер ярык тапмассың—ышанычлы, нык, гасырлар буе торырлык иткәннәр. Күрше йорт янында торган буш мичкәне тәгәрәтеп койма буена алып килде. Ишегалды утларын бетермәгәннәр, сукмак

кырыйлатып тезелгән яктырткычларның кайберләре сүрән генә яктырта. Прокурор үз ишегалдын танымады: тәбәнәк агачлардан жилләр искән. Ә бит аларны Лариса белән икәүләшеп кайлардан гына сораткмадылар, алар бик авырдан тамыр җәйделәр. Зәңгәр кафель белән каплатылган бассейн да, чирәмлекләр дә юкка чыккан. Хәтта ишегалды почмагындагы җәйге чәлләләрдә киң ябалдашлары белән чәчәкләргә күләгә ясаган мәгърур имәнне дә кискәннәр. Кайсы якка күз салма: түтәлләр дә түтәлләр, яна хуҗа үз тәртибен урнаштырган.

Өйнең бар җирендә ут балкый, төбенә кадәр ачылган тәрәзәләр аша көй ургыла.

Ул: «Мөгаен, телевизор карыйлардыр,—дип фаразлады да соңгы тапкыр ишегалдына күзләрен йөртеп чыкты.—Якты дөньядан тимер-бетон койма артына кереп яшеренгән бу адәм кем икән, сорыйсы булыр».

Әмма нәкъ шул вакытта веранданың гөлт итеп кабынган уты яктысында буйлы-буйлы пижама кигән таныш сын күренде. Прокурор башта үз күзләренә үзе ышанмады: булмас, ялгыш күрәмдер, дип уйлады, тик тегенең боерулы тавыш белән өйдәгеләрнең берсенә самовар чыгарырга кушуын ишетүгә, шиге калмады. Әйе, бу ул—полковник Иргашев иде.

## 4

Әгәр теге кичтә «Лидо»да элеккеге коллегалары белән очрашкан булса, сөйләшү озакка сузылган булыр иде.

Прокурор үз язмышыннан зарланырга яратмады, әмма, Лариса турында сөйли башласа, теләсә кемдә кызгану, хәленә керү хисләре уянмый калмас иде. Хәер, читкә кагылганнар, җиңелгәннәр башка төрле хисләр уятмый дадыр, нишлисең кеше психологиясе шулай корылган инде, шуңа ул элеккеге танышлары белән очрашмау җаен карады. Төнге кунак дөрес әйткән: хәзер Бикхуҗаевлар чоры һәм ул күпме генә талпынмасын—гаделлеккә ирешә алмаячак. Илдәге вазгыятьне үзгәртеп кенә, гаделлеккә өмет итеп була.

Кичләрен Буденный урамы буйлап йөргәндә, ул башка рестораннарга кермәскә булды—берәү белән дә очрашасы килмәде. Үз тормышын янабаштан күзаллап чыгуы аның күңелен тынычландырып җибәрде, юридик тикшерүләре буенча хезмәтенең кешеләргә кирәклеген тагын бер кат тойды.

Ашыгырга кирәклеген дә аңлады—әледән-әле йөрәге үзен сиздереп тора. Ашыгуның тагын бер сәбәбе бар. Ул прокурор постын калдырып, башка бик күпләр шикелле яшәү рәвешенә күчкәч, шуны сизде: илдә Бикхуҗаевлар кебекләр шактый үрчегән икән—ресторааннар көн-төн тулы, котырынкы эчү мәҗлесләре гөрли, зурдан кубкан кәрт уеннары, әдәп-әхлакны читләтеп үтү—гомумән, ата улны, ана кызны белми диләрме әле?

Атна үтте, икенчесе, ул эшенә йотылды. «Лидо» ресторанына барыр юлны онытса да—Буденный урамы буйлап кичке сәйранын дәвам итте.

Тик салмак кына аккан тормышын үзгәртеп җибәргән көн килде.

Кичен өенә кайтып керүгә, артыннан ук диярлек ишектә кыңгырау чыңлады. Вакыт шактый соң, көтәр кешесе юк—бу шәһәрдә беркем белән аралашмады, шуңа аптырап калды. Шулай да барып, ишекне ачты. Баскыч мәйданчыгында икәү басып тора, ярым караңгылыкта ул аларның күптән түгел «Лидо»да утырганда, янәшә өстәл артыннан баш селкеп сәлам бирүчеләр икәнен абайлады.

—Хәерле кич, Әмирхан Даутович,—диде төнге кунаклар.—Турыгыздан үтеп бара идек, утыгызны күрдек тә кереп чыгарга булдык. Каршы килмисезме?

Кырык тирәсендәге бу ир-атлар белән йөзгә-йөз очрашкач төшенде—ул

аларны белми иде. Элекке прокурор төнге кунакларга сөенмәде дә, куркып, каушап та калмады. Югалтасын ул югалтты инде, шуңа кунакларга өйгә үтәргә ымлады.

Бүлмәгә кергәч, алар үзләре белән таныштырдылар. Зәңгәр күзле, озынрак буйлысы Артур Александрович Шубарин, ә карарак кыбырсыгы Икрам Мәхмүтович Фәйзиев икән. Прокурор тәкъдим итсә дә, тегеләр нигәдер утырырга ашыкмадылар. Артур Александрович бүлмәне күзләре белән айкап чыкты да:

—Бик тыйнак яшисез икән, прокурор...—диде сүз башларга теләгәндәй, тик Азлярханов дәшмәде.—Йөз меңнән баш тартуыгызга үкенмисезме?

Ул, мөгаен, турыдан бәреп хуҗаны аптырашта калдырмакчы булгандыр, әмма прокурорны хәзер берни белән дә гаҗәпләндереп булмый иде инде, шуңа ул салкын гына:

—Юк, үкенмим...—дип җавап кайтарды һәм, көлемсерәп:—Минем тормышым турында тагын ниләр беләсез?—дип сорады.

Кунак хуҗаны кызыксындыра алуына канәгать иде.

—Күпне. Ни мәктәптә, ни институтта берәүнең дә биографиясен сезнеке кадәр өйрәнгәнем булмагандыр, чын әгәр...

Өй хуҗасы сөйләшүгә кушылып китте:

—Нинди хөрмәт белән ?

—Сабыр итегез, вакыты житкәч, барысын да белерсез. Бер генә нәрсәне әйтә алам, прокурор...Сезгә шулай дип мөрәҗәгать итсәм, каршы килмисезме?Тормыш юлыгызны үз ихтыярым белән өйрәндем һәм яшермим...тирән хөрмәт белән. Сезнең белән дуслашырбыз дип ышанам, һәрхәлдә безнең теләгебез шундый.

Прокурор аның тел төбен аңлап житкермәде, тик кунакның баштан ук үз ягына аударырга тырышуы шикләндерде. Юк, болар аның элеккеге коллегалары да, партия йә совет аппараты хезмәткәрләре түгел. Әмма кемнәр—һич башына китерә алмады.

Шубарин тизрәк эшкә күчәргә теләде, ахры:

—Без хатыныгызның башына житкән кешене беләбез. Сезгә Әнвәр Бикхуҗаевның җинаять эшләнгән районда узган елдан прокурор булып эшләвен дә житкерәбез. Сезнең турыда барысын да беләбез дигәнгә ышандыру өчен сүзне Икрамга бирәм.

Күзе уйнаклап торган кара тутлы хәрәкәтчән Фәйзиев күн папканы ачып кәгазьләр алды.

—Шулай итеп... Азлярханов Әмирхан Даутович, 1933 нче елда Себердә туган. Балалар йортында тәрбияләнгән, әти-әтиләре юристлар, 1937 нче елда репрессиягә эләккәннәр. Дүрт ел Тын океанда хәрби-диңгез флотында хезмәт иткән. Туган шәһәрендә кызыл дипломга университетны, Мәскәүдә аспирантураны тәмамлаган. Өйләнгән. Хатыны—Лариса Павловна Турганова, сәнгать белгече, Шәрык керамикасыннан шәхси коллекция туплаган, күргәзмәсе берничә тапкыр чит илдә күрсәтелгән. 1978 нче елда...

Прокурор кара тутлыны кул ишарәсе белән туктатты—укыйсы күп иде әле. Үзе турында инәсеннән җебенә кадәр белүләренә шиге калмады.

—Нәрсәгә бу сезгә,—диде ул арыган тавыш белән.—Бу хәлемдә минем белән кызыксынучы бардыр дип уйламыйм,котлы таратуның мәгънәсен күрмим...

Шубарин ашыкмый гына бүлдерде:

—Без котлы таратучылар түгел. Һәм дөрес әйтәсез, хәзер сезнең турыда уйлаган кеше юктыр, чөнки кәнәфи ияләре генә игътибар үзәгендә. Тик, зинһар, безне филантроплар дип кабул итмәгез, безнең максат—башка, тормышыгыз яхшы якка үзгәрергә мөмкин. Ә биографиягезне жентекле өйрәнүгә килгәндә, моның үз сәбәпләре бар, соңрак төшенерсез һәм дәгъва

белдермәссез дип ышанам. Без үз дөньябызның бер читен ачарга уйлыйбыз, шуна үзебезне куркыныч астына куймабызмы дип шикләнәбез.

Прокурор чакырылмаган кунакны бүлдерде:

—Ачыграк әйткәндә?

—Юк, әлегә ярамый. Анысы сездән хезмәттәшлек итүгә ризалык алгач.

—Анламыйм, миннән сезгә ни кирәк?

—Каударланмагыз, прокурор, эш бик житди. Мин жирле сәнәгатьтән. Кыскасы, безгә юристконсультант кирәк.

—Юристконсультант?—Элекке прокурор гажәпләнде.—Хәзер безнен агай-эне белән буа буарлык ләбаса. Шулмы проблемагыз?

—Әле нинди!—Кунак авыр сулап куйды, прокурорның төшенә алмавына шаккатып анлатырга булды:—Безгә бит юристның теләсә кайсы кирәкми. Юридик яктан да, тормышта да зур тәжрибәсе булганы кирәк. Өстәвенә кануннарны белеп, анлап эш иткәне, хакимият коридорларын, Мәскәүгә юлны яхшы белгәне. Тирән белемле, ихтирам һәм ышаныч казанырлык яшьтә булуы шарт. Гомумән, башы һәм характеры булган кеше кирәк. Сезнен досьегыз, прокурор, менә шуна бик жентекле өйрәнелде... Дөресен әйтик, сезнен белән бәйләнү безне куркыныч астына куя. Әмма уртак фикергә килә алсак—һичшиксез отачакбыз: сезнен юридик тәжрибәгез, элемтәләрегез безнен өчен бәяләп бетергесез файдалы булачак.

—Шулай да әйтсәгез иде: үзегезне куркыныч астына куярга нәрсә мәжбүр итте?—Прокурор төнге кунакларның ни теләвенә һаман төшенә алмады.

Кунак, әйтерсен бу сорауны көтеп торган, уйлап-нитеп тормый жавап кайтарды:

—Логика, хөрмәтле прокурор, логика... һәм тормышыгызда килеп туган хәлләр.

—Логикагызга төшенмәдем, төгәлрәк булмыйммы?

—Яхшы, әгәр бик теләсәгез. Мин сезнен прокурорга хас сыйфатларыгызны югалтмавыгызга бик шат. Без юкка гына сезнен анкета мәгълүматларыгыз белән танышмадык. Ә логикага килгәндә... Безгә калса, дәүләт идеягезгә дип әйтикме, бурычыгызга дипме—сездә ничек әйтеләдер,—тугрылыклы булуыгызны беркайчан да бәяләмәде. Әйтик, әти-әниегезне дә. Алар эзсезнисез юкка чыктылар, үзегез исә ятим үстегез. Хатыныгызны үтерделәр, өегезне тартып алдылар, эшсез калдырдылар, намуслы исемегезне салып таптадылар, сәламәтлегегезне бетерделәр...Үтерүче һәм анын яклаучылары ирektә, алай гына да түгел, жылы урыннарда рәхәт чигәләр. Сезнен дәүләткә карата үз карашларыгыз булырга тиештер инде. Бикхужаевлар тәкъдим иткән йөз меннән баш тартуыгыз да бездә хөрмәт уятты.

Бу әдәпсез нотыктан сон, прокурор ишеккә күрсәтергә омтылды, тик сонгы мизгелдә аны нәрсәдер тотып калды. Бәлки язмыш ана сонга калып булса да жәмгыять алдында гаебен юарга сонгы мөмкинлекне бирәдер? Кем белә...Чакырылмаган кунакларны куалап чыгарырга өлгерер, анын өчен баш ватасы юк.

Урынлыдырмы, әллә урынсызмы, хәтеренә бер акыллы хужалыкчының ун еллап башы бурычтан чыкмый таркалып барган бер предприятиене аякка бастыруы килеп төште. Бернинди документсыз, дәүләт төзү оешмаларыннан башка гына ремонт базасы һәм автохужалык өчен жылытылган гаражлар төзегәне өчен жавапка тартылды ул. Гәрчә астыртын максатлар куймаса да, канун бозылган. Шул хужалыкчы бервакыт анарга, ачынып:

—Бездә эшләмәгән өчен түгел, киресенчә, эшләгән өчен хөкем итәләр,—дигән иде.

Бу очракта да шулай: кунакларга ишеккә төртеп күрсәтү дөрес булыр

иде, әмма тыелып ахырына кадәр тыңлап бетерергә кирәк: ул бит әле эшнең асылын, үзенә нинди роль бирелгәнен белми. Логика мәсьәләсенә килгәндә, икесе дә, мөгаен, үз фикерләрендә калырлар. Төнге кунакларга: Бикхуҗаевлар, Иргашевларны шәхсән үзем Совет хакимияте, партия, дәүләт белән бервакытта да янәшә куймадым дисә, барыбер аңламаслар иде. Ә әти-әниләренә килгәндә... Аларның фаҗигасе гомуми фаҗиганең бер чаткысы гына, менә хәзерге кебек, аның белән булган хәлне шәхси бәла дип санап булмый, бу заманда ул үзен зыян күрүчеләрнең берсе генә дип саный. Ниһаять, башына барып житте—аны нииндидер зур масштабтагы предприятиегә китереп тыкмакчы булалар, һәм бу эш, аның аңлавынча, айсбергка тиң: өске һәм аскы өлешләрдән тора, төп өлеше, су астындагысы, океан төбендәге кебек караңгы, һәм аерым юридик түбә таләп итә. Димәк, бу Шубарин яшерен икътисад белән эш итүче совет миллионерлары дигән яңа дулкынның вәкиле булырга да мөмкин. Үз теләген белән андый синдикат кочагына килеп керү, ай-һай,—куркыныч, житмәсә алардагы кырыс кануннар... Ул болардан хәбәрдар иде. Ул да түгел, башында икенче уй калыкты: «Яшь чагымда ук гомеремне гаделлек өчен көрәшкә багышлыйм дип ант иттем, тик бердәнбер көнне канунга да, хокук саклау органнарына да кирәгем калмады. Бәлки гомеремне куркыныч астына кую бәрабәренә соңгы кабат үз антыма тугрылыклы калыргадыр?»

Шушы уе ярсыган күнелен урынына утыртты. Эченнән генә төнге кунак белән килеште, шуңа берәр сүзен ишетми калмыйм дигәндәй, бар игътибарын җигеп, тыңларга кереште.

Ул хәтта сорау да бирде—Шубарин анда килешүме, әллә шик яшеренгәнме икәнен аера алмады:

—Мәскәүгә барулар...хакимият коридорлары,—дидегез. Сезнеңчә, мин андый авырлыкларны күтәрә аламмы? Ике инфарктым белән авырту үпкәләрем үзләрен гел сиздереп торалар. Минем мөмкинлекләремә артык югары бәя куймыйсызмы?

Кунак, өстеннән авыр йөк төшкәндәй, шаркылдап көлеп җибәрде.

—Бу ике оятсыз килеп керделәр дә бар мәшәкатьләрен минем өскә аударырга маташалар дип, әлегә кадәр безне куып чыгармавыгызга аптырыйм. Борчылмагыз, сәламәтлегегез турында белештек, сак булырбыз дип ышандырам. Эшегезгә килгәндә, рәсми төстә булыр, сезгә беркайчан да, беркайда да сәламәтлегегезгә зыян китерерлек итмәбез. Сезнең бурыч—аеруча әһәмиятле йөкләмәләрдә илче һәм юридик киңәшче булу. Бөтен вак-төяге турында бүген сөйләшмәбез дип уйлыйм, иң мөһиме—ризалык бирүегез кирәк. Ә Мәскәү һәм башка шәһәрләргә сәфәрләр, билгеле, булачак. Анда да проблемалар тумас дип саныйм...безнең кешеләр кулыгызга чемоданыгызны да тоттырмаслар. Бүгенгә эшлекле сөйләшүләрне тәмамлыйк та безнең берләшүне юып алыйк, шулаймы?

Прокурор югалып калды.

—Минем чәем генә бар, анысы да әзербайҗанныкы, икенче сортлы.

Шуны гына көткәндәй, әңгәмәгә кара тутлы кушылды:

—Борчылмагыз, прокурор, сезнең спартаннарча яшәвегезне һәм мөмкинлекләрегезне белеп, анысын да күз алдында тоттык...—Ул ишегалдына караган тәрәзәне ачты да кемгәдер ым какты.

Бер-ике минут уздымы—юкмы, ишектә кыңгырау шалтырады. Теге вакытта «Лидо»да күргән официант икән. Ике кулында ашъяулык белән капланган ике кәрзин. Житез Икрам бер кәрзинне элэктерергә дә өлгерде. Официант хуҗаны тыенкы гына сәламләде дә бүлмәгә үтте, күрәсең, мондый кучмә хезмәт күрсәтүе беренче тапкыр гына түгелдер. Алар Икрам белән тиз генә өстәлне уртага күчереп куйдылар, официант кәрзиннән

крахмалланган чытыр ак эскәтер алып җәйде дә ресторannan алып килгән тәлинкә, чәркәләрне тезеп чыкты. Аннан сон, кәрзиннәрен тотып, хуҗа рөхсәте белән кухняга кереп югалды.

Озак та үтмәде, кухнядан тәмле исләр бөркелде. Табаларда нәрсәдер чыжлаган, жылынган арада официант тавыш-тынсыз гына өстәлгә кабымлыклар, яшеллек, «Боржоми»ларны урнаштырды. Прокурор «Боржоми»ны соңгы тапкыр биш ел элек өлкә комитеты буфетында эчкәнен хәтерләде. Шубарин өстәл тирәсендәге ыгы-зыгыга игътибар итми Лариса Павловнаның стенага эленгән фотографиясе каршында басып торуында булды.

—Күркәм хатын иде. Талантлы. Миндә аның альбомнары саклана.

Артур Александровичның үзеннән сораулар көткәнен аңласа да, прокурор дәшмәде. Шулвакыт кыздырылган бүдәнәләр белән гөмбәләр салынган, өсте яшел үләннәр белән бизәлгән зур коштабак күтәреп официант килеп керде. Ул аны өстәл уртасына куйды да сораулы карашын Шубаринга төбәде. Тегесенең уе башкада идеме, уйлап-нитеп тормый гына:

—Рәхмәт, Адик, китә аласын, Ашот өенә кайтарып куяр,—диде.

Официант шунда ук саубуллашып чыгып китте. Аның артыннан ишек ябылуга, Артур Александрович өстәл янына чакырды. Ул кайда да үзен хуҗаларча тотарга күнеккән иде, күрәсең.

Прокурорның каршы килүенә карамастан, аның чәркәсенә дә коньяк агызды.

—Үзара аңлаша алуыбыз һәм уңышлар өчен,—төнге кунакның беренче тосты әнә шундый булды. Прокурор да аларга кушылып уртлап куйды. Шулай да «Дипломат» дигән чех сырасыннан баш тартмады, бик рәхәтләнеп, мактый-мактый, бер бокалны бушатты.

Кара тутлыга җитә калды:

—Бер-ике тартма «Хольстена» кертеп чыгармын, эсседә аннан да шәбрәк эчемлек юк,—дип әйтеп куйды.

Озак утырдылар, әмма эш турында башка сүз кузгатмадылар, дөрес, Икрам берничә тапкыр ниндидер эшкә кагылышлы консультация алмакчы булып авызын ачкан иде, Артур Александрович әңгәмәне иплэп кенә икенче якка борып җибәрде.

Шубарин чит илләрдә, шул исәптән Японидә дә булган икән, прокурор белән андагы тормыш һәм гадәтләр турында фикерләрен уртаклаштылар.

Иртәгесен төш вакытында «Лидо»да очрашырга сүз куешып саубуллашканда, төн уртасы авышкан иде инде.

Прокурор, кунаклар киткәннән соң, бик озак иртәгедән яна этабы башланырга охшаган тормышы турында уйланып утырды. Артур Александрович белән әңгәмәсен, Икрамның сирәк-мирәк репликаларын янәдән бер тапкыр башыннан кичерде.

«Сезне үз эшләребезгә катнаштырып, үзебезне куркыныч астына куюыбызны аңлыйбыз»,—дигәннәре нәрсә аңлата икән?

Бары бер нәрсә ачык: ул иртәгә тотынасы эш зур масштаблы, җитди, шуңа тәвәккәлләгәннәр, күрәсең. Бу эшкә ныклап кереп киткәнче, үзенә күз-колак булачакларын да чамалады. Билгеле, хуҗа кеше үз эшенә артык кешене катнаштырмаска тырыша, әмма телиме-теләмиме, юрист белән киңәшләшмичә кала алмый. Никадәр генә куркыныч тоелмасын, аның каршы килмәскә кыюлыгы җитте, нишлисең, башкача хәле юк, язмыш аны юрист буларак та, кеше буларак та тагын бер кат сынарга уйлады, ахры.

Шубарин әлегә аңа нинди таләпләр куелачагы турында ым какмаса да, прокурор үзе эшләп киткән заводларныкыннан аермасы юктыр дип саный. Яшерен трест хуҗалары да, предприятие директорлары да бары бер

нәрсәне—үз фирмасының ихтыяжларын яклауны таләп итә.

Прокурор, ниһаять, тынычланды һәм йокларга ятты—аның өчен иртәгәге көн дә жинелләрдән булырга охшамаган.

## 5

Прокурор «Лидо» ресторанына нәкъ билгеләнгән вакытка килеп житте. Ишек төбендә кичәге официант каршы алып, аны өстәл янына озатып куйды. Шубарин көтмәгәндә икенче бер ишектән килеп керде. Кичә төнлә утыруның эзе дә күренми: жыйнак, пөхтә, үзен кулда тота белүчеләргә охшаган. Зал инде тулып килә, прокурор бик күпләрнең карашы аның табындашына төбәлгәнен сизеп, тоеп утырды, тик тегесе генә аларны күрмәмешкә салышты.

—Ничек, кичәге карар үз көчендә каламы? Бернинди ирексезләү юк, мин эшкә үз теләкләре белән алынганнарын хуплыйм,—диде һәм инициативаны үз кулына алу гадәтенә тугры калып, бокалларны «Боржоми» белән тутырып куйды.

—Юк, кире уйламадым,—дип җавап бирде прокурор уйчан гына.—Сез дөрес әйтәсез, картлык әллә кайда, таулар артында түгел, тик мин әлегә аны каршыларга әзер түгел икәнмен. Фәкать бер сорау—сездә мин Кырымда, мәсәлән, Ялтада бәләкәй генә өйлек эшли аламмы? Бу—мина табиблар тәкъдим иткән урын.

—Кечкенәгә генә түгел, хәзер анда ялга киткән генераллар яши торганына өмет итә аласыз,—дип ышандырды Шубарин.—Үзем дә Кырымга, Ялтага гашыйк кеше буларак, рәхәтләнеп булышырга әзермен, киләчәктә кунакка барыр урын булыр. Бәлки, кайчан да булса бу эшләрдән туеп, үзем дә күршетирәгездән берәр нәрсә юнәтермен. Барысы да үзегездән тора, кабатлап булса да әйтим: безгә тәжрибәгез, белемегез, элеккеге элемтәләрегез бик тә кирәк. Әйдәгез, тынычлап кына тамак ялгап алыйк та, аннары мина—номерга менәрбез, эш турында шунда сөйләшербез.

Өстәл яныннан кузгалганда, прокурор сак кына:

—Ишек янында утырган кызыл күлмәкле егеткә игътибар итегез әле, зинһар. Мина калса, ул махсус безнең өстәлне күзәтерлек урын сайлаган, күзе сездә генә,—диде.

Артур Александрович ул күрсәткән якка борылып карамады, көлемсерәп җавап кайтарды:

—Мин ялгышмаганмын, прокурор, ничек, дары савытында дары бар әле, диләрме? Сез хаклы, ул миннән күз дә алмый. Шулай булырга тиеш тә—ул бит минем тән сакчысы.

Азлархановның аптырап калуын күреп, шеф буласы кеше көлеп жибәрде:

—Әйе,әйе, тән сакчысы, нигә гаҗәпләндегез? Сезнеке дә булачак, бер шәп кешене күз унында тотабыз, бер-ике атнадан килеп чыгар. Ә Ашотка килгәндә, дуслашырсыз дип уйлыйм, ышанычы егет, ана таянырга була.

Аның номеры өченче катның коридор башында икән. Бүлмәгә кергәндә, прокурор авыр имән ишектәге ике яшерен биккә игътибар итте, өлкә прокуратурасындагы аның кабинетына да шундый йозаклар куелган иде.

Ике бүлмәле «люкс» карап торышка әллә ни тәэсир калдырмый: гарнитур тыгызлап торган кечкенә генә йокы бүлмәсе дә артык зур булмаган зал, соңгысы, мөгаен, хуҗасы өчен кабинет һәм кабул итү бүлмәсе ролен үтидер. Тавыш-тынсыз жилләткеч эшләп тора, шуңадыр бүлмәдә рәхәт, салкынча һава. Өй мохите сизелеп тора, димәк, монда күптәннән яши.

Прокурор як-ягына карангалады, күзенә «Шарп» телевизоры белән аның янына куелган видеоприставка чалынды. Номер хуҗасы, прокурорның сораулы карашын тотып:

—Әйе, өй киносы,—дип раслады.—Шәп фильмнар күп, мәсәлән, Копполаның «Крестный отец» ы кебекләр, кызганыч, карарга вакыт кына юк. Ә вакыт ягыннан сез тыныч булыгыз, рәхәтләнеп карый аласыз, теләсәгез, системаны үз номерыгызга күчерерләр, әйтермен.

Прокурор аңа сораулы караш ташлады.

—Әйе, дөрес ишеттегез, үз номерыгызга. Сүз уңаенда аз гына алга сикердем. Без болай хәл иттек: сезнен торагыгыз ни безгә, ни үзегезгә туры килми. Башка шәһәрләрдәге кебек монда да бер бүлмәлеләргә ихтыяҗ зур икән, шуңа гостиницадан ерак түгел, күрше кварталдан гына ике бүлмәлене белештек.Үзем барып күрдем, сезгә дә ошар дип уйлыйм. Фатир ремонтка мохтаҗ булмаса да, шәһәрдә осталар барлыгыннан файдаланып, аз-маз яңартуны кирәк таптык. Бер-ике сәгатьтән Икрам белән барып карап кайтырсыз, әлегә кайбер эшләрне хәл итеп бетерик. Ике айлап сез миңа көн дә кирәк булачаксыз: хәл итәсе мәсьәләләр күп җыелды. Черемушкадагы фатирыгызны бушатырбыз, ә Красиндагысында әлегә ремонт дәвам итәр, шуңа күрә әлегә бер кат югары нәкъ минеке кебек үк номерда яшәп торырсыз. Бүген йә булмаса иртәгә үк кунакханәгә күчәргә кирәк булыр.

Үзенә бирелгән күрсәтмәләрне ишетеп, прокурор ирексездән көлемсерәп куйды. Номер хуҗасы моңа шунда ук игътибар итте:

—Мин нәрсәнедер дөрес әйтмәдем мәллә?

—Ремонт, дүртенче катта «люкс...» Сез минем финанс мөмкинлекләрен артык югары бәялисез түгелме, Артур Александрович?

Шубарин көлеп җибәрде:

—Рәхәт сезнең белән, прокурор. Беләбез, мөмкинлекләрегезне беләбез. Без элеккеге җитәкчеләрегез кебек түгел: кешене эшкә дәшеп, аннан файда күткәндә, башта аның үзе турында кайгыртабыз. Девизыбыз да—кайгырту нинди, эше шундый. Шунаргадыр, тәвәккәллек сораганын белә торып, безгә бик теләп киләләр...

Ул, үрелеп, язу өстәленең ачык тартмасыннан бер төргәк акча алды да прокурорга сузды.

—Менә сезгә тота торырга. Җитмәсә, тартынмагыз, сорагыз. Кабатлап әйтәм, мин филантроп түгел, һәрбер эшлекле кеше сыман, мин дә акча саный беләм. Тик шуны белегез: сезнең хезмәтегез бик югары бәяләнәчәк, шуңа күпме телисез, шуның кадәрне алдан алаласыз. Классикадан исегездә калгандыр: элек Россиядә хезмәт хакын бирәр ел алдан алып булган, бездә дә шундый ук система—тик бар кеше өчен дә түгел, билгеле.

Прокурор бер төргәк иллелекне кесәсенә салып куйды. Пиджак җиңнәренең кыршылуын күреп, номер хуҗасы нәрсәнедер исенә төшерде:

—Һәм соңгысы, төзүчеләр белән очрашканнан соң, Фәйзиев белән күрше өлкәнең сәүдә базасына китәрсез, төшке аш алдыннан шылтыраттылар: бик күп товар килгән, сезне анда көтәләр. Кием-салымнарны инәсеннән җебенә кадәр яңасына алмаштырыгыз. Ничек әле, киеменә карап каршы алалар, акылыңа карап озаталар диләрме? Бу—мин уйлап чыгарган нәрсә түгел.

Ул тагын нәрсәдер әйтмәкче булып авызын ачкан иде, шәһәрара телефон шылтырады. Чыбыкның теге очындагы кеше озаклап нидер сөйләде, Шубарин да ара-тирә прокурорга аңлаешсыз репликалар кыстыргалады, тик бу сөйләшүне ошатмавы йөзендә ярылып ята иде. Ниһаять, түземлеге төкәндеме:

—Көтегез, бүген килермен,—диде дә трубканы оясына ыргытты.

Артур Александрович бүлмә буйлап әйләнеп килде, йокы бүлмәсенә сугылды һәм аннан чыкканда үзен кулга алып, элеккечә тынычланып, сабырланып калган иде.

—Планнарны өзгәннәрен яратмыйм. Менә бүген сезнең белән эш турында сөйләшмәкче идем—булмады, берсекөнгә кала инде, ашыгу-кабалануны җенем сөйми. Мин хәзер үк Ташкентка китәм. Ә сез әйбәтләп урнаша, шәхси эшләрегезне рәткә сала торыгыз.—Өстәлдән ачкыч алып бирде,—Дүртенче катта, карагыз да күченегез.—Ул тынып торды.—Саубуллашканчы тагын бер генә нәрсәне әйтим... Кичә монысы турында сүз кузгатасым килмәде, эшкә үз теләгегез белән килүегезне көттем.—Ул туп-туры прокурорның күзләренә карады.—Безнең белән хезмәттәшлек итү өчен сездә тагын бер сәбәп бар, уйлавымча, анысы акчадан да мөһимрәк. Менә шул, хәзер сездә кем беләндер исәп-хисапны өзү мөмкинлеге бар... Бикхуҗаевларга да кулыбыз житәр, тик аз гына вакыт бирегез. Ә хәзергә хуш иттек.

Ул номердан чыкканда, коридор тәрәзәсе янында, теге кызыл күлмәкле егет тәмәке тартып тора иде. Прокурорны күргәч, төпчеген ташлады да, елмаеп, аның каршына атлады. Тик Азлархановн, аны күрмәмешкә салышып, дүртенче кат баскычына юнәлде.

Фәйзиев белән күрше өлкәдән төн канатын җәйгәч кенә әйләнеп кайттылар. Авыр, тыгыз көн булганга, көндәлек сәйраны да казага калды. Аруы чигенә җиткән, хәтта сатып алып кайткан әйбер-карасына күз дә саласы итмәде, тартма, төргәк, пакетлар шунда, алгы бүлмәдә таралып калды—иртәгә барыбер кунакханәгә күченәсе.

Икрам тәкъдименнән дә баш тартты: бердән, «Лидо»га барырлык хәле калмаган, икенчедән, ялгызы гына калып, тагын бер мәртәбә барысын да башыннан үткәзәсе килде. Димәк, яңа хуҗалары аның ярдәменә, элемтәләренә исәп тота, юмартлыклары да, торак мәсьәләсен тиз хәл итүләре дә тизрәк үз эшләренә тартып кертү максатыннан.

Артур Александрович исәп-хисап ясау мөмкинлеге булыр дип нәрсәдән чыгып әйтте икән? Кызыксындыру өчен генәме? Ә бәлки үзенен дә кайчандыр Бикхуҗаевлар кланы белән юлы кисешкән булгандыр да прокурорны бергәләп үч алырга чакыруыдыр? Гаҗәп, әле генә кайтам да урынга авам дигән кешенең төн йокысы качты. Аптырагач, торды да плитәгә чәйнеген утыртты, аннары төнге кунактан калган яхшы чәйне пешерде. Чәй янында уйлавы да рәхәт. Юк, хәзер ул үткәнендә казынмады, уйлары киләчәккә төбәлгән иде. Хәзер ул тормышны өлкә прокуроры булып эшләгәндәгегә караганда әйбәтрәк беләм, дип саный. Бүген ул яшерен синдикат белән хезмәттәшлек итәргә ризалык бирде. Ни өченме? Чөнки күптән инде артельчылар, цехчылар, яшерен икътисад хуҗаларының көч туплавы, аларның йогынтысы турында сигналлар алынса да, югарыдагылар оешкан җинаятьчелек, наркомания, фахишәлек, канунның криминал белән кушылуы турында сүз чыгуга кул селтәгән шикелле, ул да бу хәбәрләргә ышанмады.

«Бездә моның булуы мөмкин түгел», «Бездә андый җинаятьләр өчен сәбәпләр юк,»—дигән демагогик фразаларга алданып, тормышның асылына төшенеп җитмәвен менә хәзер генә аңлады.

Ничек аңламаска, әле эшенә тотынмаган, аз-маз таныш Артур Александровичның нинди көчле йогынтылы кеше икәнен бер күрүдә сизеп алды. Әнә бит, тәрәзәчек каршында дүртенче каттагы номер турында тел тибрәтүгә, кизүнең йөзе май кояшына охшап калды.

Фатирын алмаштыру хакында ЖЭКка бер шылтырату җитте, читтән торып тиз генә хәл итеп тә куйдылар.

Сәүдә базасында исә тылсымлы «ачкыч»—Шубарин фамилиясен ишетүгә, директор үзе складтан складка йөртеп, иң яшерен почмакларындагы дефицит әйберләрне чыгарып салды. Җәмгыятьнең хокукларын, иминлеген,

тынычлыгын саклыйсы кеше үз вакытында шундыйларны күрә белмәгәч, тормышны аңлыйм дип әйтә аламы, йә?

Менә хәзер нәрсә эшләсен белә: җәмгыяткә ябышкан шушы яман шешләрне кубарып атарга, Бикхуҗаевлар кланының элемтәләрен өзгәләп бетерергә һәм яшертен икътисадның серле дөньясын ачып, аның башындагыларны чиста суга чыгарырга тиеш. Билгеле, прокурорны Шубарин синдикатына Бикхуҗаевлардан үч алу теләге генә этәрде дисәк, ялгыш булыр, алар өстеннән тагын да көчлерәк клан идарә иткәнен аңлаган иде инде. Тәҗрибәсе һәм интуициясенә таянып, ул Шубарин кулы белән тагын да ераккарак һәм биеккәрәк сузылырга мөмкин булуына төшенде.

Дөрес, Әмирхан Даутович бу ниятенең куркыныч якларын күрми-сизми түгел. Бикхуҗаевлар бер нәрсә алдында туктап калмаганны, күләдәгеләр турында уйлыйсы да юк. Шунда ук күз алдына самбо буенча илнең элеккеге чемпионы Ашот килеп басты: боерсыннар гына—хәзер жиренә житкерәчәк...

«Бүреләр белән яшәсән—бүре кебек уларсын». Әлегә кадәр борчыган сорауларына җавап кебек, бу мәкаль нәкъ вакытында исенә төште: ышанычка кереп, синдикатның алыштыргысыз кешесенә әйләнергә, әйе, шулай эшләргә!

Бу карар прокурорның кәефен күтәреп җибәрде. Ул төргәк һәм тартмаларны таратып ташлады һәм ун минутлар үттеме, гардеробның шадраланган көзгесендә озын буйлы, зәвык белән киенгән ир-ат сурәте пәйда булды. Аның өстендә ачык соры тройка костюм, көмеш төсендәге күлмәгенә күк төсендәге галстугы килешеп тора, ә аякларында—модалы саналган итальян ботинкалары. «Әйе, бу тип, мөгаен, «күләдәгеләргә» якынрактыр, аны үз кешеләре кебек кабул итәрләр»,—дип, үз кыяфәтеннән риза калды һәм йокларга җыенды.

Икенче көнне беренче тапкыр чәйханә юлын читләтеп, «Лидо»га юл тотты. Ул залга килеп кергәндә, Фәйзиев анда иде инде. Адикның чакыруын көтеп тә тормыйча, ышанычлы адымнар белән өстәл янына юнәлде.

Аның:»Хәерле иртә»,—диюенә, Икрам югалып калды, иртүк килер дип уйламаган иде, күрәсең.

—Ай-яй, киенеп тә куйгансыз, әллә шәһәр башкарма комитетына юл тотасызмы?—дип кызыксынгандай итте.

—Юк, шеф үзешчәнлеккә рөхсәт бирмәде.

—Әйе, ул аны яратмый,—дип раслады Икрам.

Иртәнге аш вакытында да тынычлык килмәде, башында бөтерелгән уйларыннан арына алмады прокурор. Фәйзиев белән ике арада булган сөйләшү, кыска-кыска репликалардан шуны аңлады: Икрам бу эштә икенче кеше булса да, барлык мөһим карарларны Шубарин берүзе кабул итә һәм үзенең ярдәмчесенә планнарның барысын да ачып салмый шикелле. Димәк, урынбасарын кысрыклап, дәрәҗәле урынга омтыла дигюләреннән курыкмыйча, ана, һичшиксез, хәбәрләр чыганагына елышырга кирәк. Мондый даирәдә үзеңне никадәр комсыз, тупас-дорфа тотасың, шулкадәр тиз ышаныч казанасың—монысын ул тәгаен белә. Шуңа күрә, иртәнге аштан соң, үзенең бары тик Шубаринга гына буйсынуын аңлаткандай:

—Зинһар, телевизор белән видеомагнитофонны минем бүлмәгә менгерттерегез әле. Шеф миңа берничә фильм тәкъдим иткән иде, үзе кайткач, аларны карарга вакытым калмас дип уйлыйм. Ә хәзергә яңа фатирыма—төзүчеләр янына сугылам. Мин шулай да алгы бүлмәмне агач белән тышлатуны кулайрак күрәм,—диде дә сүзенең тәмамланганын белдереп, урыныннан торды.

Фәйзиев үзен ничек тотарга белми югалып калды:

—Ничек телисез, шулай эшләгез. Фатир сезнеке. Ә видик мәсьәләсендә хәзер үк әмер бирермен. Дөрес әйтәсез, хужа кайткач, кино турында уйларга вакыт калмас, җилкәгезгә бик күп эшләр өелде.

Рестораннан чыкканда, прокурорның кәефе күтәренке иде. Шулай булмыйча—кечкенә генә булса да җиңү яулады бит! Димәк, сайлаган юлы дөрес. Кинәт «Лидо»ның фикуслар һәм пальмалар белән бизәлгән иркен холлының көзгеле стенасында Факир сурәтен күреп алды. Сурик Мирзоян кемнедер көтә иде ахры, прокурорга күзе төшсә дә, тиз генә абайламады, ә аннары инде тегесе ишеккә житкәндә, ук кебек залга атылды: мөгаен, Икрамны кисәтергә теләгәндер инде.

Ул килеп кергәндә фатирында эш кайный иде: бүлмәнен берсендә такта идән өстенә паркет җәяләр, ә ванна һәм кухняда слесарьлар мәш килеп сантехниканы алмаштыра.

Прокурор әле кичә генә шеф кулыннан бер төргәк акча алгач: »Мина нәрсәгә аның кадәр акча, нишләтермен аларны?»—дип уйлаган иде. Тик сәүдә базасыннан әйләнеп чыкканда, төргәкнен яртысыннан артыгы бушаганын күрде. Үзенә көчләп диярлек таккан бер күн плащ кына мен тәнкә торсын әле. Тик хәзер кичәге туздыруыннан канәгать тә калды бугай: акчаны унга-сулга таратуын сиздереп, араны якынайтмагае. Хәер, плащы да үзенә үлчәп текәннәр диярсен, өстендә тап-таман утыра.

Яңа ниятләр аны көтелмәгән уйларга этәрде, һәм ул ашыкмыйча, җәяүләп кенә мебель кибетенә юл тотты.

Соңгы елларда төзелгән кибетләр кебек монысы да өлкә потребкооперациясенә карый. Шаккатмалы: бик кыска гына арада биниһая зур кибетләр, берсеннән-берсе баерак ресторан-кафеларны ничек төзеп бетерәләр икән? Менә шул кооператорлардан сәламәтлек саклау органнары һәм мәгариф белән тәҗрибә уртаклашуларын сорарга иде, югыйсә, яңа төзелгән биналары сәүдә, гомумтуклану предприятиеләренеке белән чагыштырганда ташка үлчим.

Кибетнең эче дә тышына туры килеп тора. Дөресен әйткәндә, җиһаз кибетенә соңгы тапкыр моннан унбиш еллар элек кергән иде бугай. Анда да Лариса Лахутидагы яңа йортларына Германиядән кайткан йокы гарнитуры карарга ирексезләп диярлек алып барды. Хәер, ул җыелманы бик ошатсалар да, барыбер алырга туры килмәде. Җиһазга дигән акчалары музейга кереп киткәнен сизми дә калдылар. Ике караватт алдылар да шунын белән вәссәлам: башка бу темага әйләнеп кайтмадылар...

Кибеттәге агач материалының муллыгына, төрлелегенә шаккатып: «Бүген җырлар гына түгел, җиһазлар да үзгә икән»,—дип уйлап куйды ирексездән. Кибет бик иркен, һәртөрле гарнитурлар, кухня җиһазы, көзгеләр, коверлар—интерьерга ярашлы итеп тезеп куелганнар, күнеленә хуш килгәнен сат та ал, әйе, дизайнерлар кулы тигәне сизелеп тора. Әмма аның исен китәргәне—бәяләр булды. Теге вакытта Лариса белән кызыгып калган гарнитур, әле дә бик яхшы хәтерли, җиде йөз сум тора иде. Хәзер ул бәягә язу өстәле генә, йә булмаса ике кәнәфи алырга мөмкин икән, әле алары да төрле бәядә: мәсәлән кәнәфинең биш йөзлеге дә, җиде йөзлеге дә бар. Башка бәяләргә дә күз төшерәсе итте, әһә, йокы гарнитуры ике меңнән уналты меңгә кадәр, кухняныкы алты йөз—ике мең, ә бүлмәнеке биш меңнән башлана. «Бу бәяләр кемнәр өчен икән соң?—дип уйлап куйды прокурор.—Бар кеше дә Шубаринда хезмәттә түгел, зур-зур акчаларны бирәр ел алдан алып куя алмый».

Әйтерең юк, җиһаз да, бәяләре дә тан калдырырлык, әле шунысына да игътибар итте: аның күзе төшкән әйберләрнең барысы да чит илнекеләр. Иркен залны айкап йөргәндә башында бер генә уй иде: ничек булса да

күбрәк акча туздырырга. Шулай да ундүрт меңлек венгр йокы гарнитуры—«Чаба» ны да, унике меңлек «Сибилла»дигән бүлмәнекен дә, кухня өчен биш меңлек швед гарнитуры «Викинг»ны да аласы килмәде. Куен дәфтәренә ниндидер билгеләр ясаганнан соң, ул чыгу юлына борылды.

Икенче көнне төшке аштан соң, Феллининың «Репетиция оркестра»сын карап утырганда, кемдер ишек шакыды.

Прокурор «пауза»га басып, теләр-теләмәс кенә ишекне ачты һәм Шубаринны күреп алды.

—Комачауладым, ахры,—диде кунак, экранда катып калган сурәтне күреп.

—Юк-юк, сез нәрсә, узыгыз, зинһар. Өй киносының рәхәте дә шунда, теләсә кайсы вакытта туктатып һәм карап була...

—Сез яңа мохиткә мин уйлаганнан да тизрәк ияләшәсез,—Шубарин елмайды.—Төзүчеләрне дә кызулаткансыз, җиһазларны да кайгырта башлагансыз.

Ул дөрес чамалаган, аның һәр адымын күзәтеп торалар. Мөгаен, Фәйзиев та прокурорның кәефе күтәренке булуы турында сүз катмый калмагандыр. Шубаринның сүзләрен раслагандай, куен дәфтәрен чыгарды да кибеттә тутырылган битен ертып кунакка сузды.

Шубарин кызыксынып укый башлады:

1. «Лувр» (Югославия) бүлмә гарнитуры—5400 сум.

2. Йокы гарнитуры «Рижане» (Румыния)—2900.

3. Кухняныкы, «Комфорт (Югославия)—1700.

Барысы—10 мең сум.

Шубарин, йөзендәге елмаюын сүндермичә:

-Шә-әп, аппетитыгызны әйтәм,—дип куйды.

—Шуңа күрә бүген үк үз вазифаларыма тотынырга әзермен,—дип шаяртуга борды прокурор.

—Бүген үк булмас, атна ахыры булгач, сейфтан документларны алып тормаган идем. Өстәвенә бер-ике сәгатьтән Икрам белән күрше өлкәгә туйга китәбез. Теге сез барган сәүдә базасы директоры кызын кияүгә бирә, булачак кияве—крайда билгеле кешенең улы.

—Сез үзегез Шәрык туйларына мөкиббән кешеме, әллә бару мәҗбүриме? Яңа гына юлдан кайттыгыз ләбаса,—диде прокурор, аның хәленә кереп.

—Әйе, нәкъ өстенә бастыгыз, мин туйларны, бигрәк тә шау-шулы мәҗлесләрне яратмыйм. Бүгенге кичемне рәхәтләнеп сезнең белән үз номерымда гына үткәрер идем, Адик та өстәлне туйныкыннан ким әзерләмәс иде, тик мин, һичшиксез, анда булырга тиешмен. Урта Азиядә шактый еллар яшәгән кеше буларак, аңлыйсыздыр дип беләм: андый чараларда өлешчә эшләр һәм язмышлар да хәл ителә. Әмма бу юлысы эшләрем күп түгел, яңгынга әверелмәсен дип, нәни генә учакка су сибәсем бар, шуңа Ташкенттән эт сыман арып-талып кайтсам да бармый кала алмыйм. Ә сезгә Феллини белән вакытыгызны күңелле генә үткәрүегезне телим.—Ул ишеккә борылды.

Бусагада тукталып, нәрсәнедер исенә төшергәндәй итенде дә:

—Сез бүген үк эшкә керешергә әзер, дидегез бугай?—дип сорады.

—Әйе, «Репетиция оркестра»ны башка вакытка калдырырга әзер.

Шубарин уйланган кыяфәт чыгарып торды да, ниндидер карар кабул иткәндәй, кулын селтәде:

—Үзебезнең оркестрның репетициясен башларга вакыт. Җыеныр өчен ике сәгать вакыт сезгә. Искиткеч шәп костюм да алгансыз икән, Икрам әйтте. Туйга өчәү бергә барабыз.—Прокурорның аптыравы йөзенә чыкканын күреп кабатлады:—Әйе, әйе, туйга, эшкә түгел... «Язгы көн елны туйдыра», онытмагыз.Безнең эшлекле телгә әйләндергәндә бу мәкаль

ничек янгырыйдыр, анысын тәгаен генә әйтә алмыйм, әмма хәлебез якынча шулай... Нәкъ ике сәгатьтән мина—кәтәм.

Прокурорга җыенудан башка чара калмады.

—Менә бит, тышкы кыяфәтегезгә карап, ай-яй, эшләре унышлы бара икән бу кешенең диярлек булган,—дип каршылады аны Артур Александрович билгеләнгән сәгатьтә.—Үзегезне ышанычлы итеп тотарга киңәш итәм. Тормышыгызда, әйтерсең, коточкыч вакыйгалар булмаган, сез сынмагансыз, янадан үз биеклегегездә дип белсеннәр. Әгәр инде кемдер сез безнең тирәдә түгел, киресенчә, без сезнең янда дип уйлый икән, анысы тагын да яхшырак. Аңлашылдымы?

Бу комбинаторның тагын нинди мөгез чыгарырга җыенуына төшенмәсә дә, ул:

—Тырышырмын,—дип вәгъдә бирде.

Урамда машина көтеп тора иде. Шәһәрдән шоссега чыгуга, Ашот магнитофон кабызырга теләде, әмма янәшәсендә утырган шефы аны туктатты. Шунда магнитофон янындагы телефон трубкасына күзе төшкән прокурор, гаҗәпләнеп:

—Телефон, машинагызда телефон?—дип сорады.

—Әйе, японныкы, йөз километр радиусында тота. Өегездә ремонтлар төгәлләнеп, чит-ят кешеләр китеп беткәч, сезгә дә куярлар, теләсә кайсы вакытта—машинада бараммы мин, номердамы—ялгарлар. Тик белегез: мондый элемтә турында бик азлар гына хәбәрдар.

Юлда әллә ни сөйләшмәделәр, ара-тирә алышкан репликалар, кыска фразаларны прокурор бик үк аңлап житкермәсә дә кабатлап сорамады. Туйда үзенә нинди роль бирелгән икән—бар уе шуны ачыкларга тырышу булды.

Шубарин, бәлки, ашыгыч кабул кылган бу ниятенә инде үкенәдер, дигән уй башына килеп китте дә Азлархан янәдән үз дөньясына чумды: өлкә прокуроры булганда туйларга, күңел ачу чараларына бик сирәк йөрде ул. Шунадыр, баштарак чакырулар еш булса да, соңыннан дәшүдән бөтенләй туктадылар. Менә хәзер машинада барганда гына аның башына барып житте: сәүдә базасы директоры туйга сайланган кешеләр даирәсе генә җыела дигән иде бит. «Бу туйда Шубаринның мине кемгә күрсәтәсе килә икән соң? Әллә кемнедер шаккатырырга уйлыймы, янәсе мин урынымны югалтсам да, акчалы булып янадан аякка басканмын». Ул сүзсез баруларына бер яктан куанды да, чөнки шунысына төшенде: монда нәрсәдер бар, шуна башында чуалган уйларны тәртипкә саласы, нинди дер вариантлар уйлап куясы бар.

Ә бәлки ул Бикхуҗаевларны куркытырга телидер? Күрәсезме, янәсе, мин кем белән! Юлыгыздан алып ташланган прокурор элеккеге хәленә кайтты һәм көрәшергә әзер икәнен белдерү өчен үзе сезнең өнегезгә килде.

Аның фикерләрен укыгандай, Шубарин сорап куйды:

—Сез андагы өлкә прокуроры Халитов белән танышмы?

—Әйе.

—Үзара мөнәсәбәтләрегез ни тирәдә иде, хәзер ничек, сезнең белән исәпләшәме?

—Кайчандыр анарга минем ярдәмем тигәләде. Кыен хәлдә калганда да киңәшкә минем янга килде. Исәпләшә дип уйлыйм.

—Анысы яхшы, юкка гына Феллинидан аермаганмын икән.

«Халитов, Халитов...Гадел Шәрипович...»—күпме генә тырышмасын, бу фамилия белән бәйләнешле гауга-фәләнне исенә төшерә алмады. Башкалар шикелле анарга да өстән гел басым ясап торуга карамастан, Халитов теләсә кем кубызына бии торганнардан түгел иде. Хәер, хәзергесен кем

белә, аларның соңгы җиде елда очрашканнары булмады, ә җиде елда җиде төрлегә үзгәрергә мөмкин.

«Гадел Шәрипович, Гадел Шәрипович...»—дип кабатлады ул эченнән генә. Шубарин нигә аның турында сүз кузгатты икән? Нинди планнары бар, Халитовтан ни тели сон ул? Үз-үзенә күпме генә сораулар яудырма, дөрес җавабын табып булмас—әлегә яна хуҗасының уй-ниятләре аның өчен кара урман кебек. Шулай да болайрак түгел микән: бу уенда катнашырга ана әле иртәрәк, димәк, кырыйда әзер булып торачак. Нишләмәк кирәк—артка юл юк.

Еракта өлкә үзәге тирәсендәге бистәләр шәйләнде. Уен башланырга ярты сәгатьләп калып бара. Ул, фикерләрен бер ноктага туплау өчен, күзләрен йомды да башын урындык аркасына терәде.

Тик уйлары белән ялгыз калырга язмаган икән, тынлыкны Шубаринның тавышы өзде:

—Ә хәзер мине игътибар белән тынлагыз. Безне бу якларда бик яхшы беләләр, бигрәк тә соңгы елларда. Шуңа безнең компаниядә булуыгызны искәрми калмаслар. Хәер, ялгыз килеп керсәгез дә, шәйләми калмаслар иде. Сезнең бурыч: аягыгызда нык басып торуыгызны күрсәтәсез, элеккеге танышларыгыз җәмгыятьтәге урыныгызны кайтарырга әзер дип уйласын. Кайда эшләвегез белән кызыксынсалар, артык детальләренә кагылмый, җирле сәнәгать идарәсендә, дип җавап бирегез. Аннары, әгәр Халитов сезнең белән очрашудан качмаса, минем белән таныштырырсыз. Күптәннән очрашу җаен эзләп йөрим, минемчә, бүген иң кулай вакыт. Ә калганнарын—кем белән очрашырга, мөнәсәбәтләрне яңартырга икәнен туй барышында әйтермен. Борчылмагыз, рәхәтләнеп күңел ачыгыз. Шунысын да искәртим: дошманнарыгыз да булуы ихтимал, шуңа мин сезне ике-өч кеше белән таныштырырмын, алар сезнең элек күз күргән кешеләрегез дә булырга мөмкин—аптырап калмагыз. Болар Бикхуҗаевлар белән пычакка-пычак кешеләр, нәрсәнедер бүлешә алмыйлар. Сезнең бу кешеләр белән элемтәгез сизелми калмас, монысын ышандырып әйтәм.

Бераз уйланып торганнан соң өстәде:

—Хәер, миңа калса, Бикхуҗаевлар белән исәп-хисап ясарга үзегезнең дә мөмкинлегегез булачак.Тик, минем уйлавымча, сез дан-шөһрәт сөючеләрдән түгел, Бикхуҗаевларның башына прокурор җитте дип шаулауларын теләмисездер. Җиңүне башкаларга калдырыйк, минем өчен, мәсәлән, һәрвакыт нәтиҗә беренче урында,—дип, сөйләшүне томанлы фраза белән тәмамлады.

—Килеп җиттек!

Машина яшеллеккә күмелеп утырган шәхси йортлар урнашкан тыкрыкка борылды. Бакчалар буена, кысылышып, машиналар тезелеп киткән, номерларына караганда кунаклар төрле өлкәләрдән җыелган булырга охшаган. Ашот машинасын капка төбенә үк китереп туктатты. Җирле гадәт буенча тимер капка төбендә агачлар күләгәсе астына өсталләр тезгәннәр. Килүчеләрне йорт хуҗасы Җаббаров каршы алып тора. Шубаринның «Волга»сын күргә, база директоры кунакларын калдырып, машина янына ашыкты.

Кунак кәләшнең әтисе белән кочаклашып күреште һәм компания исеменнән дип, калын гына конверт тапшырды. Аннары аның колагына нидер пышылдады да прокурор белән таныштырды.

Шубаринны ярты сүздән аңларга күнеккән Җаббаров прокурорны култыклап ишегалдына—җыелып торган кунаклар янына алып керде. Компаньоннары исә, дәрәҗәле зур кунакны озата барган кебек, аның янәшәсеннән атладылар.

Ишегалды берьюлы алты йөз-җиде йөз кунакны кабул итәрлек иркен иде. Шәһәрнең бик сирәк скверы гына Жаббаров ишегалды белән ярыша алырлык: мондагы пөхтәлек, тәртип, мөгаен, бер бакчачы гына моның кадәр эшне майтара алмас.

Ишегалдының урта бер җирендә зур фонтан балкып тора—мәрмәренә караганда, ул туйга яңартылган, ахры. Фонтан яныннан төрле тарафка кызыл ком сибелгән сукмаклар киткән. Түрдәрәк, бөтерелеп үскән үсемлекләр ышыгында җәйге кухня урнашкан; аның каршында ике урында тимер чыбыкларда бәрән түшкәләре кыздыралар, алардан чыккан тәмле ис бакчадагы башка исләрне күмеп киткән. Берничә урында корылган чәчәкле чатырлар астында өстәлләр әзерләгәннәр. Хуҗа кунакларны үзләре өчен билгеләнгән урынга кадәр озатты да кабат капкага ашыкты. Бар да үз эшендә: колакчалар элгән яшь егетләр соңгы кат микрофон һәм көчәйткечләрне тикшерәләр, шароварлар киеп алган көяз яшь кызлар кунакларга минераль су белән пепси-кола тәкъдим итәләр. Бу йортта мондый сандагы кунакларны беренче генә каршылаулары түгел икәне сизелеп тора. Фонтан янындагы кызыл ковер капланган калкулыкта музыкантлар уен коралларын көйлиләр. Кай тарафка бакма—бәйрәм рухы: тегеннән дә, моннан да көлү тавышлары, күптән күрешмәгән дус, танышларның аһ-уһ килүләре ишетелә.

Прокурор тыныч кына әйләнә-тирәдәге ыгы-зыгыны күзәтте; тәҗрибәле кеше буларак, Жаббаровның аларга аеруча дустанә мөнәсәбәт күрсәтүе күпләрне бу якка борылып карарга мәҗбүр иткәнен күнеле белән тойды. Шубарин һәм Фәйзиевне күпчелеге белә, таный, әмма күрше өлкә прокурорына шулкадәрле игътибар күрсәтелүенә төшенә алмый аптырап калулары сизелеп тора. Яннарыннан үткәндә, ул колак чите белән генә: «Азлархановӏ...Азлархановӏ...Азлархановӏ...» дип пышылдашуларын да ишетеп калды.

Инде аны бар да таныды һәм—ничек күтәрелә алган, монда, иләк аша сайлап җыелган кунаклар янына ничек килеп эләккән—хәзер шул турыда баш ваталар. Аннарына килүгә, бу өчәү туктаган чатыр янына килә башладылар. Дөрес, башта Шубарин һәм Фәйзиевнең таныш-белеш, дуслары килеп күреште, ә тегеләре исә һәрберсен прокурор белән таныштыра бардылар. Озакламый аны белгәннәр дә табылды. Тик ул аларның кайберләрен йөзгә күреп белсә дә, кем икәннәрен хәтерли алмады, чөнки күбесе—күрше өлкәләрдән иде. «Димәк, Бикхуҗаевлар да килеп чыгарга мөмкин»,—дип уйлады ул, әмма әлегә алар гаиләсеннән берәү дә күзгә чалынмады.

Артур Александровичның йөзе канәгать күренә, мөгаен, эченнән генә, прокурорны туйга алып килүенә куана, ахры.

Прокурор үзенә куелган бурычны онытмады—Халитов белән күрешергә. Аның бу уңышыннан күп нәрсә торырга мөмкин, шефының ышанычын казану, мәсәлән. Әлегә эшләр Шубарин теләгәнчә бара. Ә нәтиҗәсе менә бүген күренергә тиеш.

Кинәт аның башына гади генә бер чагыштыру килде: әгәр ул Халитов урынында булса, чәчәкләргә күмелеп утырган бу бай йортка, туйга килер идеме? Прокурор булмаган кешенең күзенә дә мондый муллыкның кайдан килүе мәгълүм ләбаса. Җавабын да үзе тапты: әгәр Галел Шәрипович элеккечә канун сагында торучы булса, монда ике аягының берсен дә атларга тиеш түгел. Әмма шефы Халитовны монда очратырга исәпләде, кем-кем, Шубарин вакытын суга салучылардан түгел, йөз егерме километр җирдән пылау ашап, ярым-ялангач биюче кызларны күзәтер өчен генә килеп йөрмәс иде. Димәк, ул Халитовның буласын төгәл белә. Озак баш ватарга туры килмәде, кунакларны өстәл янына чакырдылар. Нәкъ шул вакыт Шубарин янына бер кеше килеп, нидер пышылдады.

Шеф тавышын күтәрми генә:

—Менә көткән кешебез дә килеп житте,—диде, вакыйгага ачыклык кертергә теләде:—Халитов нишләр икән?

Әгәр прокурор Халитовны махсус көтеп тормаса, мөгаен, аны танымаган булыр иде: күрешми торган жиде елда ул тазарган, чал чәчләре арткан. Ишек алдына ул хужа белән бергә туйга килгән дуслары янәшәсендә килеп керде.

Әмирхан Даутович алар аралашкан чактагыдан шактый үзгәргән булса да, Халитов аны таныды. Тегесе күзенә кереп тормаса да, ул шунда ук төркем эчендәге элекке коллегасын шәйләп алды. Прокурорның карашы жете, әле дә үзенә тарта торган иде шул. Халитовны тирә-юньдәгеләр үз өстәлләренә чакырып торсалар да, ул прокурор янына ашыкты.

—Кемне күрәм мин!—диде дә кочаклап алды.—Нинди жилләр белән, Әмирхан Даутович? Хәер, ахырдан сөйләрсез. Сезне исән-имин, сау-сәламәт күрүемә...—арткарак чигенеп, беркавым баштан-аяк күз йөртеп чыкты да елмаеп өстәде:—һәм унышлы алга таба баруыгызга шатмын. Шунда ук шәйләп алдым, туктале, минәйтәм, безнең ерак почмакларга мондый көяз кешене нинди жилләр ташлады икән дим. Карыйм—сез! Менә сиңа могжиза, чынлап әйтәм! Жаббаров: бүләк ясыйм, туйда элекке дустың белән күрештерәм, дигән иде, тик кем киләсен әйтмәде.—Хужага борылып:—Ялгышмагансың, Әмирхан Даутович миңа бик күп яхшылыклар эшләгән кеше, чын дус. Сөендергәнең өчен рәхмәт. Күптән очрашканыбыз юк, әйдә, син безне бер өстәл артына утырт инде...—Һәм үзе белән килгәннәргә күз дә салмыйча, коллегасын кочаклап, кызыл чатыр янына юнәлде.

Артур Александрович очрашуны читтән генә күзәтсә дә, барысын да күреп, ишетеп торды. Өстәл артында да Халитовның янәшәсендә утырып, теләсә кайсы минутта сөйләшүгә кушылып китәргә әзер торса да, артыгын кыланмады.

Өстәл тирәли урнашуга, фонтан янындагы калкулыкта музыка уйнап жибәрде—шулай итеп, туй башланды. Әңгәмә белән һәвәсләнеп, ике прокурор, дөрес, берсе—элеккеге, әйләнә-тирәдә барган вакыйгаларга исләре китмәде, үзләрен дә бүлдерергә кыймадылар—Шубарин мөмкинлек бирмәде. Каршыларында утырган Икрам бокалларны күзәтте, кабымлыклар тәкъдим итте. Тәлинкәләргә яшелләкләр өстәде. Прокурор терелеп житмәвен сылтау итеп, коньяклы рюмкага иренен генә тидереп куйды, ә коллегасы, эчтән нидер яндыргандай, бер тостны да калдырмады. Салган берсен бушата барды.

Яшьләрне котларга дип, микрофон янына Гадел Шәриповичны да чакырдылар. Яшьләрне тәбрикләгәннән соң, ул бүген үзенең икеләтә бәхетле булуы, туйда күптәнге дусты Азлярханов Әмирхан Даутовичны очратуы турында әйтте, аны дуслары арасында сәламәт һәм шат күрүенә куанычын белдерде. Кунаклар баштагы котлау сүзләрен колак яныннан гына үткәрсәләр, соңгы жөмләләренә кучкәндә барысының да игътибарлы карашы аңарга төбәлгән иде.

Озак та үтмәде, республикада танылган биюченең чыгышын тәкъдим иттеләр һәм табын яңы бердән тынып калды. Биюче өчен махсус бик зур ковер жәйделәр, микрофоннан аның кемдер туйга салган бүләк икәнен житкерергә дә онытмадылар. Шәрык туйларында биюченең роле нинди икәнен Урта Азиядә яшәүчеләр генә белә; көй яңгырауга күбесе, бигрәк тә ир-атлар, бию мәйданчыгына ашыктылар. Шубарин Икрамны озакка югалмаска дип кисәтер өчен авызын ачканда, тегесеннән жилләр искән иде инде. Фәйзиев театрал йә футбол жанатарлары кебек туйларга мөкиббән китүчеләрдән, шуңа да тирә-яктагы бер генә туйны калдырмый иде.

Гадәттә бар нәрсәне җиде кат үлчәп, бер кат кисәргә яраткан Фәйзиев, туй турында сүз чыкса, маньякка әйләнә дә кала; улының әле булмаган туена кунаклар санын меңнән ким итмәскә дигән хыял белән янып, исемнәре билгеле кешеләрнең туйларына йөрү белән бергә аларга шактый бүселгән конверт тоттыра һәм кайчан да булса үзен дә шулай зурларлар дип ышана.

Өстәвенә Икрам дан-шөһрәт яратучылардан, үз исеме атаклы биюче, җырчылар исеме янәшәсендә искә алынсын өчен ниләр генә эшләми. Гадәттә шәрык туйларына чакырылган җырчы-биючеләргә хуҗа кеше түли, әмма кунаклар арасыннан да бүләк бирүчеләр табыла. Кавказлылар туенда соңыннан ул акчалар яңа өйләнешүче парларга тапшырылса, монда исә башкаручының үзендә кала. Шуңарга бу якларда халыкка танылган җырчы-биючеләр шактый мал-мөлкәтле саналалар. Туйларда акча «марафон»ында Фәйзиевтән өстен чыгучылар булмый диярлек, шунлыктан мәҗлес хакында сүз кузгалганда аның исеме ишетелми калмый.

Шубарин баштарак аның бу гадәте белән көрәшеп карады, әмма барып чыкмаслыгын аңлагач—кулын селтәде. Урынбасарының шик астына алынган рекламасы кайчакларда файда да китергәли.

Икрам исә шефын Шәрыкны аңламауда битәрли, киләчәге өчен акча салуын аңлатып карый, тик Шубарин европалыларга хас гадәтенчә төпле җавап кайтара:

—Әгәр чыгарып салганыңны җыеп алган көненә кадәр яши алсам—миннән сиңа ун мең!..

## 6

Хәзерге һәм элеккеге прокурорны, шулай ук Артур Александровичны туйга үз «мерседес»ында килеп төшкән данлыклы биюче Санобар да кызыксындыра алмады—үзләренеке үзәктә иде. Алар иркен ишегалдын урап килергә булдылар. Гадел Шәриповичның беренче килүе икән, ә Шубаринның монда элек тә булгалаганы бар. Ул аларга арык буена барырга тәкъдим итте. Прокурор коллегасын култыклап алды да, әкрен генә сөйләшә-сөйләшә, сукмак буйлап киттеләр.

Өстәл артында утырганда Шубарин Гадел Шәриповичның артык күп эчүенә игътибар итте, шуңа Азлархановка кузгалыр алдыннан:

—Исереп беткәнче сөйләшүне минем тарафка күчерсәгез иде,—дип пышылдарга өлгерде.

Прокурор уңайлы вакытны эзләгән арада, Халитов үзе турыдан-туры:

—Дустым, сезгә кем ярдәм кулы сузды? Ишетүемчә, сезнең хәлләр бик мөшкел иде шикелле?—дип сорады.

Шушыннан да ипле чак булмасын чамалап, прокурор туктады һәм:

—Менә ул кеше—Артур Александрович...—дип, шефына ишарәләде.

Аларның артларында торган Шубарин, шуны гына көткәндәй, ялт итеп яннарына килеп басты. Тик Халитов Шубаринны искәрмичә кайтарып сорады:

—Шушы гангстермы? Акула? Хәер, мин сезнең башка юлыгыз, башка тәкъдимнәр булмавын аңлыйм. Ә менә мине һәм аның ятьмәсенә эләккән башкаларны бирәр вакыт кем дә булса аңлармы икән? Хәзер аңа тартым йә булмаса сезнең Бикхуҗаевлар шикелләләр, ай-һай, күп үрчеделәр, безнең якларда гына түгел, ил буенча шулай... Шубарин булышты дисез инде?

Юк, Халитов алар уйлаганча исерек түгел иде.

—Әйе, ул. Таныш булыгыз, Гадел Шәрипович. Хәзер минем юллар аныкы белән кушылды.

Артур Александрович Халитовның соңгы сүзләрен ишетмәгәндәй, үзен тиешенчә тотып, кулын сузды. Әкрен, әмма төпле итеп:

—Минем уйлавымча, элеккеге дустыгызның безгә карата дәгъвасы юк, җирле сәнагатьтә аның киләчәге өметле дип ышанам. Бәлки әле, аны безнең тармакның министры буларак күрербез. Әгәр бу эшегезне калдырырга уйласагыз белеп торыгыз: бездә сезнең өчен кайчан теләсәгез, шунда кызыклы эш табылачак.

—Ай-яй, җинел генә каптырмакчы, кабахәт!—Халитовның йөзе каралып чыкты.—Барысын да үз кубызына биетмәкче. Сигезаяк диярсең, капшавычларын бар якка таратып салган. Мин аның нәрсә теләвен бик яхшы аңлыйм—Әхрәров өчен тырыша. Башта үтенә, кире каксам, янарга тотыначак, ниндидер чаралар күрергә... Шулай бит, Шубарин? Минем өстән хәйран материал җыйгансыңдыр инде?—Прокурор исе китмәгән кыяфәт чыгарса да, Азлархановның аның эчке киеренкелеген сизми калмады.

—Ялгышасыз,—дип каршы төште Шубарин.—Сез хисле кеше, шуңа буяуларны куертасыз. Гангстер... Акула... Сигезаяк... Җитди кеше сүзләре түгел. Чыннан да, мин сезнең белән Әхрәров хакында сөйләшмәкче идем. Әгәр иртәгә ярты сәгать вакытыгызны кызганмасагыз, минем турында да, коллегаларым турында—менә аларның берсе хөрмәтле Әмирхан Даутович яныгызда—фикерегез үзгәрәчәк.

Халитов кулы белән чикләвек агачы астындагы урындыкка күрсәтте дә:

—Утырыйк әле, бүген нишләптер арып торам, диде.—Кабул итәргә дисез инде. Яхшы, иртәгә кичкырын килеп карагыз. Сезнең яклаучыларыгыз, дөресрәге әрәмтамакларыгыз авыз ачарга да ирек бирми башладылар, тәмам камап алдылар.

Тик тыныч кына утырырга язмаган икән, аны прокуратура кизүе эзләп табып, бик тиз арада Ташкент белән элемтәгә керүен сорады. Халитов коллегасын кочаклап саубуллашты да Шубаринга иртәгә булачак очрашу турында искәртеп, тиз генә китеп барды.

Шубарин башын урындыкның аркасына терәп уйга чумды, хәтта берара янында утырган прокурорны да онытып җибәрде. Исенә килсә, әлегә кадәр аңарга карата яхшы мөнәсәбәттә булган юристның икеләнеп калуын сизде.

Дөрестән дә, элеккеге прокурор сагаеп калды. Ул үзен киек-җәнлекләрнең игътибарын тарту өчен куелган алдавыч хәлендә сизде һәм эче поша башлады. Шубарин исә, аның уйларын укыгандай:

—Башыгызга нинди кайгы төште?—дип сорады.—Ходай хакы өчен, дустыгызны шикле эшләргә тартам дип уйлый күрмәгез. Ул үз юлын күптән—өч ел элек сайлады инде, сезнең алда кәмит уйнап маташкан була. Һәрвакыттагыча: бурыч, намус һәм акчалы мул тормыш—кайсын сайларга? Аңардан мина нәрсә кирәклеген кайтканда әйтермен, искә төшерерсез әле. Ә хәзергә без үз бурычыбызны җиренә җиткереп үтәдек дисәк тә була, рәхәтләнеп күңел ачыйк.

Кызып алган кунаклар Санобар биегән мәйданчыкны сырып алганнар. Прокурорның колагына берничә тапкыр көчле музыка астында кычкырган, сызгырган тавышлар арасыннан Фәйзиевнең ярсулы көлгәне чалынып китте.

Санобар, мөгаен, бик яхшы биидер, чөнки соклanudan аһ-ваһ килүчеләр кулыннан акчаларын эләктерергә өлгерми хәтта. Билгеле, ул бигрәк тә шәмәхә һәм яшел акчалы куллар янында, тегеләрнең һушын алырлык хәрәкәтләр ясап, тоткарланырга тырыша.

Алар үзе биегәндәй очынган-канатланган Икрамны күзәттеләр. Санобар ике тапкыр аңа да ягымлы елмаюын бүләк итеп, үзенең ин унышлы, иң матур хәрәкәтен башкарды. Икрамнын кулындагы иллелекләр төргәге сизелерлек юкарган иде инде. Бу исә Санобардан сон чыгыш ясаячак башка биюче, җырчыларнын йөзенә күләгә салган, чөнки алары да урынбасарнын юмартлыгына өмет итәләр иде.

Артур Александрович Икрамга ишарә ясарга тырышса да, тегесен кадаклап куйганнармыни, Санобардан күзләрен аера алмый.

—Фәйзиев бүген безнең өчен юк,—диде ул, елмаеп, һәм көтмәгәндә:—Әйдәгез, хөрмәтле прокурор, булмаса, кузгалыйк әле без,—дип тәкъдим итте.—Үз эшебезне эшләдек, калганы безгә кирәкми.

Ул җавап бирергә ашыкмады. Бәлки Бикхуҗаевлар килеп чыгар? Шәрык туйлары иртәнгә кадәр сузылганын яхшы белә, әнә бит кунаклар әле дә килә, тагын да соңарганнарын сыгылып торган өстәлләре көтеп тора.

Шубарин, янә анын уен сизгәндәй:

—Сезнең Сөен Бикхуҗаев йә ир туганы Әкрам Садыйков белән очрашасы килгәнегезне күреп торам. Тик, кызганыч, кәефегезне кырырга туры килә : алар бүген күренмәсләр дип беләм,—дип куйды.

Сүзен расларга теләп, кәчтүм кесәсеннән пөхтә итеп бөкләнгән дәфтәр бите чыгарды да прокурорга сузды. Анда нечкә фломастер белән ашык-пошык: «Бикхуҗаевлар булмаячак», дип язылган иде.

—Әйе-әйе, бу чынлап та шулай,—дип раслады Шубарин.

—Яхшы, ә урынбасарыгызны нишләтәбез?

—Анын таныш-белешләре буа буарлык, иртәгә берәрсе китереп китәр әле. Ашыга төшик.—Ул күзләре белән шоферны эзләде.

Аларның сөйләшүен тынлап торган диярсен, Ашот ялт итеп килеп тә чыкты, әкрен генә:

—Мин монда, шеф,—диде.

—Сиздермичә генә машинаны икенче урамга алып чык та безне көтеп тор.

Шубарин үзенең тән сакчысы белән сөйләшкән арада, прокурор эченнән генә Фәйзиевнең монда калуына сөенде, бәлки юлда нәрсәнедер ачыклый алыр. Томаннан арынырга вакыт.

*Ахыры киләсе санда*



Мөхәммәт
Мирза

## ГАЗӘЛЛӘР, РОБАГЫЙЛАР...

* * *

Хикмәтле вә кодрәтле бу замана,
Үз дигәнчә итә—кая карама...

Асты-өскә килде бөтен дөньяның
Күзең йомып-ачып алган арада...

Булмагандай юкка чыкты таулары...
Таш кыялар пәйда булды далада...

Үзгәрделәр, бәндәләрне күр әнә:
Кемдер бөлә, кемдер байый—дан ала.

Әдәп, әхлак, йола—барсы буталып,
Төс үзгәртте танып булмас чамада...

Үзгәрмәде шәт бердәнбер тәхетле,
Бәхетлеләр туенда ул—тамада.

***

Хаким тартты колын кырыс хөкемгә.
Чаларып чыкты чигәсе бер көндә...

Хатадан халимы Хода бәндәсе?—
Фәрештә түгел лабаса бер кем дә...

Чирәм үсте сукмагына, юлына,
Читләштеләр: хәлен белми бер кемдә.

Бизенделәр сәбәп итеп ни барын,
Булмаса да бер сәбәбе өркергә...

Мөхәммәт МИРЗА (1953)—*шагыйрь, «Турайгыр», «Таң суы», «Адәм баласы» (татар, рус, төрек, инглиз телләрендә бишьюллыклар) һ. б. китаплар авторы. Казанда яши.*

Диделәр.—Ул,—дип, хәбәрдар һәр эштән,
Ярлыкау йә хөкем—аның иркендә...

Тәкъдирендә мескеннән мескен гавам—
Үз шәүләсеннән шүрләгән ил-көндә.

***

Югалганмы, булмаганмы чамасы,
Нәфсен чигендерерлек юк чарасы...

Шөһрәт, данга килә бик ураласы.
Тар түшенә тагын ниләр тагасы?..

Бимазалап бүләк даулый бичара.
Ни дә булса кирәк уйлап табасы...

Булгач, булгач берәгәйле булсын,—дип,
Көн-төн башын вата, ди ил агасы...

Юкса, ни бирсәң чирканмыйча хәтта
Шайтан авызына кереп аласы...

Төшенерме Адәмнең бу баласы:
Хәтердә бер гыйбрәт булып каласын?..

***

Йөз адымнан тиен күзен алган укка
Ауда, яуда аңар тиң елгырлар юк та...

Дарья кичкән, кыя менгән бер тында ул,
Аргамакта очып кергән янган утка...

Ал бирмәгән алышларда, орышларда
Бил бирмәгән алып бөтен Урда-Йортта...

Даң-шөһрәте таралган бар кыйтгаларга
Ханның аяусыз сакчысы булып та.

Ул бер үзе тора дип йөз яранына,
Хан шагыйрь-вәзирен җибәргән куып та.

Шуннан сүтелгән дәүләте... И Мирза,
Кемгә хаҗәт риваять бу меңъеллыкта?!

***

Дөньясы киң, киң булса да, күп сыймаучысы,
Сые сыгылып торса да, юк сыйлаучысы.

Малын кая качырырга күп юллаучысы,
Мохтаҗ учына салырга юк уйлаучысы...

Ялга ятлар ярларына күп юлаучысы,
Илендә ярык тагарак—юк сылаучысы...

Айны бүлеп яталар ди—күп Ай аучысы,
Айдан айга җитмәгәнне юк аяучысы.

Туеп сикергәнне күреп—күп тыймаучысы,
Кулы кычытканы күп тә, юк кыйнаучысы.

Йөз елдан ниләр буласын күп юраучысы,
Бүген ник шундый хәлдә мин—юк сораучысы?!

***

Без дә сызгырып әчердек атларны...
Ат барда ал чыгармадык ятларны.

Ни кыйммәте затлы зыялыгының,
Морзалар саклый алмады атларын...

Инде ятлар кулындагы корал без:
Аямыйбыз кая, кемгә атканны...

Яуларында алдан чабып ятларның,
Яуладык яуланмас солтанатларны.

Җиргә тигезләп җилләргә тараттык
Таралмас тоелган каганатларны.

Бездәй атсыз яучабар бармы тагы?
Без бер валчыгы зыялы затларның...

***

Кичер, газәл, рөхсәтсез килеп керсәм.
Син гүзәлне тупасланып «э»рәнҗетсәм...

Гашыйкларның бәхет яше тамган төшкә
Табанымның тузанлы эзен төшерсәм.

Итәгемә «яреп» кергән зәһәр җилгә
Гөлләреңнең ал иреннәрен өшетсәм...

Назга сусаган җаннарның бәлзәменә
Явызларның имансыз сүлен төшертсәм...

Хәтта синең йөз аклыгын яклыйм,—диеп,
Иблис-шайтанны тәкрарлау сүзен кертсәм...

Вәгъдә—иман, ышан гүзәллек бакчасы,
Бер былбылың булырмын, әгәр кичерсәң...

## Робагыйлар

***

Агач башын җил борыр һәр тарафка.
Адәм башын сүз борыр һәр тарафка..
Җаһил сүздән кубарыла җил-давыл,
Җан-иманың инаныр кай тарафка?!.

***

Шөкер, кемнәрдәндер алып бүләсе юк,
Шөкер, кемнән булса алып түләсе юк...

Шөкер, гомер күзләремдә теземә төшеп,
Ходайдан ары һичкемгә түнәсе юк...

***

Язылмаган кануннар бар—безгә түгел,
Үтәлмичә калулар бар—бездән түгел...
Бер сәбәпсез Себерләргә сөрелгәннәр...—
Сакла, Раббым, беркемгә дә без жәл түгел..

Вакыт агышын тоярсың—тыялмассың,
Ярларын буып куярсың—боралмассың...
Галәмнәрнең серләренә төшенеп тә
Дөньялыкта ике гомер торалмассың...

***

Беләм, бердәнберең түгеллегемне,
Белә белгәннән җан күпме теленде...
Беләм; мин бердәнбер сугаручыңмын
Сусап сулыккан күңелең гөлеңне...

***

Болай гына айры кавем кебек сез,
Ә чынында бер тамчы су кебек сез...
Мин-минлекме, ятка ярыйм диепме,
Чит-ят булып кыланасыз кебек сез...

***

Ярны ярга тоташтырган—кешеләр,
Ярдан ярны аерган да—кешеләр.
Ташу саен чигенә бара ярлар,
Ярлар ерагайса нишләр кешеләр?!

***

Татар башын саныйлар ди тагы да,
Өлкән туган батты кара кайгыга:
Баш санын булыр кечрәйтеп, тарайтып,
Җанын ничек иманыннан аерырга?

***

Бердәнбер буласың килә—беләбез,
И, бичара, дип, кызганып көләбез...
Уйлап баксаң, күлерлек түгел хәлләр:
Бердәнберләр кубәйгәнгә бөләбез...

***

Ялганны дөрес дип сөйли беләсең...
Тыңлап торганны чөеңә эләсең...
Өреп каба өйрәнмәсләр шул бер дә,
Авызлары пешкән саен көләсең...

***

Кагыйдәсез уеннарны күп кордың...
Күзгә карап кулларга күз тоттырдың...
Уйный-уйный бар көндәшеңне кырдың...
Бердәнбер калдың—барыбер оттырдың...

***

Гәрчә чакырса дус, туган, һәр чакта
Син әүвәле максатларын ачыкла...
Хан, бәкләрдән калган кыргый җан кыю—
Хәнҗәр тыгып кунагына кочакта...

***

Дус, туганнар, кодалар, кодачалар—
Берсеннән берсе әйбәтрәк ич алар...
Бәбкәләре—нарасый бичаралар:
Пип-пип, бир-бир,—дип авызын ачалар.

***

Өлеш—урталай бүлүдән башлана.
Көмеш—асылташ куюдан кашлана...
Асылташка авыр ташлар басылган...
Өлешең-көмешең бирмә башкага...

***

Кем иделәр, кем булдылар—кара син...
Кайсыннан нинди гыйбрәтләр аласы?..
Ник мәңгегә килгәндәй кыйланасы—
Барыбыз да хәтер булып каласы...

***

Бәйдәге көчек бик хәтәр күренә,
Бәргәләнә-бәргәләнә өренә...
Ычкынса бу тешләр дә өзәр дисең,
Ул койрыгын кысып кача өненә...

***

Ел тәүлеге бәйдә тора—өреп тора,
Кемнәр ничек көнен күрә—күреп тора...
Малын саклый—тугры колы хуҗасының
Өреп тора, әмма бүре йөреп тора...

***

Аңарга ятлар тәгаме татлырак...
Бар да ялтыраган кадәр затлырак...
Ялтырап торучы кызылга кызыккан
Бәндә дигәнең бүген беркатлырак...

***

Мең дә беренче мәртәбә эндәшәм,
И бәндәм, синең белән киңәшләшәм...
Бу дөнья өч көнлек димә һичкайчан...
Җаның мәңге яши күчеп янәшә...

Рашат
Низами

# СӘЙДӘШНЕҢ СОҢГЫ ЕЛЫ

КЫЙССА

**Сәхнәдән—төрмәгә!..**

«Тинчуринны төнлә алып киткәннәр!»

Аяз көнне яшен сукканнан да хәтәррәк бу хәбәр Салих Сәйдәшевне аягыннан ега язды. Ничек? Ни өчен? Гаебе нәрсәдә? Күкрәп торган, яшәүне шашып яратучы, күзләрендә иман булган, иҗаттан башка яши алмаучы кырык яшьлек Кәрим Тинчуринны кулга алсыннар диген! Әле узган ел гына иҗат эшчәнлегенең 25 еллыгын хөкүмәт дәрәҗәсендә зурлап бәйрәм иткәннәр иде. Ау мылтыгы да бүләк иттеләр үзенә. Бу мылтык хәзер аның үзенә каршы төбәлде микәнни?..

«Халык дошманы», имеш... Кемнәр, ни өчен уйлап чыгарды икән бу әшәке, чеп-чи ялган сүзләрне? Халык тикле халыкның дошманы була димени? Булса да булыр фәкать җаһилләр, сатлык җаннар гына... «Халык дошманы» дигән сүзне актарып чыгарганчыга кадәр ничек матур итеп, иҗдиһат белән яшәп яталар иде ләбаса...

Илдә нindидер дәҗҗал купты! Бу афәтне, иблис дигән ерткычны кемнәр, ни өчен уятты? Сәйдәш бу сорауларга җавап табарлык хәлдә түгел иде.

Аны инде бер тапкыр куркытып алдылар түгелме соң? Милләтчелектә гаепләп, совет властена каршы агитация алып барган дигән сылтау белән, 1929 ел ахырында җизнәсе Шиһаб Әхмәровны кулга алдылар. Янәсе, кредит бирү җәмгыятендә идарә әгъзасы буларак, аз җирле татар крестьяннарын Иделнең уңъяк ярына күчереп утырту, Кызыл Байрак авылын тергезү эшләрендә төп оештыручылардан берсе булган ул. Әтисе урынына калган кешедән, унике яшьлек Салихны кулларыннан тотып Тукай тикле Тукай каршына алып килгән, гомере буе татар хәятына, аның туган халкының мәгърифәтенә, мәдәниятенә армый-талмый хезмәт итеп яшәгән җизнәсеннән ничек инде «дошман» ясап булсын икән?!. Күз алдына китерә алмаслык гайре табигый хәлдер бу. Репрессияләр шаукымы тукталырмы дигәндә генә...

Инде менә икенче тапкыр Сәйдәшнең күңеленә, иманына, язмышына чәнечкеле чукмар белән кизәнәләр.

Тинчуринны кулга алуларның сәбәбе—имеш, ул, туган-тумачаларын үз тирәсенә җыеп, дәүләт театрын үз монополиясенә әйләндергән... Имеш, ак офицер хатынын, генерал киленен үзенең театрына сыендырган. Янәсе, аның үз хатыны Заһидә Тинчуринаның әтисе патша заманында

*Ахыры. Башы 1нче санда.*

«действительный статский советник» булган һәм башкалар...

Кәрим Тинчуринмы халык дошманы? Юк, мен тапкыр юк!.. Әмма НКВД кешеләре өчен сыныкка сылтау табулар берни түгел, ахрысы.

Ничек болай бу? Без кабызган утларны сүндерергә теләүче дошманнар бар микәнни, Кәрим ага Тинчурин?..

Авыр уйлардан Сәйдәшнең йөрәге кубарыла, пәрә-пәрә килә иде бу минутларда. Аның үзенә дә кара козгынның канат җилләре килеп кагылмасмы берзаманны?.. Аның җаны-тәне ватылган иде.

Ике сәгать буе фатирында ишекле-түрле йөренде, газапланды шулай. Җаны уйнаклады. Ишек шакыдылар, берәүгә дә ишек ачмады. Хәзерге вакытта ялгызлык аның иң әйбәт юлдашы иде.

Берничә көннән соң колагына азмы-күпме хәбәрләр килеп ишетелде ишетелүен... Ләкин болар—вакыт хәтереннән бер бөртек тамчы гына иде...

***

...Иртәгә—Кәрим Тинчуриннның туган көне. Хатыны Заһидә белән табын әзерләүдә мәш кайнаган чаклары аларның. Төнлә белән берзаман каты гына итеп ишек шакыдылар... Төн уртасында кемнәр булыр бу? Алдын-артын уйлап та тормастан, ишек ачтылар.

Анда... НКВД киемнәре формасыннан басып торган өч-дүрт кешенең шәүләсе пәйда булды.

—Менә ордер. Кулга алу кәгазе. Сез кем буласыз?

—Кәрим Тинчурин.

—Бик яхшы. Кулларыгызны аркан куеп, артка борылыгыз. Селкенмәскә!

Офицер киемендәге бу кешенең фәрманы бик катгый иде. Кулыннан пистолетын төшермәде.

—Ау мылтыгы кайда? Хәзер үк урынын күрсәтегез!

Ау мылтыгы пүнәтәйләр карамагына күчте.

—Бер тапкыр да атып карарга өлгермәдем,—диде Тинчурин, гаҗизләнеп.

—Дөрес эшләгәнсез. Без сезне советка каршы мылтык күтәрүдән коткарабыз, контр!

Аннары үзенең яраннарына ым какты:

—Тикшеренүне дәвам итегез!

Тегеләр, ризыкка ташланган таракандай, өстәл-тумбочкаларны, китап киштәләрен ду-чат килеп актарырга керештеләр. Тинчуринның күз карасыдай кулъязмалары идәнгә чәчелде... Дагалы күнитекләр астында ул язган әсәрләр ертыла, таптала, елый... Язылып яткан пьесасының битләре әнә шундый хәлдә капчыкка тутырыла. Бер-бер хаталану, ялгыш түгел микән бу?.. Юк, ерткыч бүре сыман, Тинчуринның иҗат хәзинәсенә рәхимсез ташлана болар!..

Антиквар кибетеннән сатып алган чынаяк савытлар, германский фотоаппаратлар да икенче бер капчыкка кереп чумды. Өйнең астын-өскә китереп тентүләрдән соң матрас мамыгы һәм мендәр йоннары, тапталган кәгазь кисәкләре генә өелеп калды. Болар бик ашыктылар, ахрысы. Хатыны Заһидә Тинчурина иренең «Мәрҗәннәр» дигән папкасын көч-хәл белән яшереп-саклап кала алды.

Кәрим Тинчуринны аста «кара козгын» машинасы көтеп тора икән. Икенче көнне дүрт хәрби килеп, аның бөтен китапханәсен, калган байлыгын, мебельләрен төяп, каядыр алып киталәр. Боларын драматург бөтенләй белмичә дә кала.

Тинчурин Кремль астындагы хибесханәгә якасы чигүле ак күлмәктән килеп кергән иде. Хәзер инде ул күп юуудан сизрәгән, таушалган төрмә күлмәгеннән. Сорау алулар башлана.

Кылычтай юка борыны өстенә көмеш кысалы күзлек атландырган тикшерүче аны бик кырыс кабул итте.

—Син кем? Исем-фамилияң?

—Драматург Кәрим Тинчурин...

—Булды. Боларын беләбез. Иң яхшысы, син советка каршы эшләрең турында сөйлә... Кара аны, яшермичә!..

—Минем советларга каршы берни эшләгәнем булмады һәм булмаячак та!

—Пафос болар! Суган суфые булма. Хатының—дворяннар токымыннан. Кулак малае син, үзең дә шул якка авышкансың. Миңа фәкать дөресен сөйлә. Үзеңә җиңеллек булыр.

—Мин җиңеллек эзләмим. Мин дөресен сөйлим.

—Алайса, әйт. Җидегәнчеләр, солтангалиевчеләр белән бәйләнешең күптәннәнме?

—Минем кендегем бары театрга бәйләнгән.

—Әһ-һә! Шулай шул. «Хикмәтле доклад» исемле пьесаңда син, системаны үзгәртергә кирәк, дигән сүзләрне алга сөрәсең. Бу—Сталинга, социализмга каршы сүз. Настоящий контр син, белдеңме! Гаяз Исхакыйның койрыклары!!!

Сөйләшү татар телендә бара иде. Сержант Гатин, татарча белүе белән масаеп, нәфрәтләнеп һаман саен һөҗүмгә күчте:

—Син, гражданин Тинчурин, иң яхшысы—гаебеңне вакытында таны, миңа эш-мәшәкать калдырма. Юкса...

Әйтеп бетермәде, ләкин тикшерүченең явызлыгы йөзенә ташып чыккан. Ул үзенә кирәкле җавапны көтә. Тинчуринның җавабы катгый иде:

—Мин берниндә контрреволюцион оешмада тормадым. Әсәрләремдә кайбер хаталар, ялгышлар бармы? Сез хата тапкан әсәрләрнең барысы да диярлек революциягә кадәр язылган. Сез ул әсәрләрне үзегез укып чыктыгызмы соң?

—Сорауларны мин бирәм!!!

—Мин бит үз пьесаларымда һәрвакыт ярлы халык ягында. Мин бит байлардан, буржуйлардан һәрвакыт көләм. Башка халыкларны пьесада мыскыл иткәнменме? Әзрәк булгандыр, монысын кире кага алмыйм...

—Болары вак мәсьәлә. Ә менә син ак эммигрант Гаяз Исхакый белән хат алышкансың. Болар безнең кулда бар.

—Хат алышуның ни гаебе бар?

—Гаеп шунда: Исхакый—советларның кан дошманы. Без аңа үсәргә, дошман үрчетергә хут бирмәбез... Син аның энесе Хәсән Исхакый белән бәйләнештә торасың. Япон шпионнарына илне сатасыз. Без моңа бик каты итеп нокта куячакбыз. Аңлыйсыңмы, канлы нокта!..

Тоткыннарны кыйнаудан тәм тапкан, «Болар мине сагыначак әле»,— дип масая торган Гатиннан тиз генә котылып булмаячагын аңлады Тинчурин.

Шуна да карамастан, үзенә ясалма рәвештә өелгән бөтен гаепләрне, уйдырмаларны һаман саен кире кага килде. Көннәрнең берендә тикшерүче түзмәде, соңгы сүзен ярып салды:

—Ярый. Әллә кем булырга тырышасың, Тинчурин! Мин сине иртәгә Склетов кулына тапшырам. Кушаматы—Палач. Ул синең телеңне бик тиз ачтырыр! Менә күрерсең... Тукта! Тагын бер сорау калган икән әле... Данлы композитор Салих Сәйдәшев та сезнең төркемдәме?

—Минем берниндә төркемдә катнашканым булмады. Салих Сәйдәшевкә килсәк, ул бит музыкант, композитор. Көйләр, җырлар яза. Музыкага

муеннан баткан. Сәясәткә анын бернинди катнашы юк...

—Ай-һай, телгә шомаргансын. Ләкин бу сүзләрне беркетмәгә язып куясы булыр...

Кул күтәреп караса да, гренадер гәүдәле Тинчурин каршында әлегә Гатин бернинди унышка ирешә алмады. Көнчелектән ачуы кабарды анын.

—Сез алдашасыз!—диде ул жикеренеп.—Мин сездән дөресен сөйләүне таләп итәм, гражданин Тинчурин!.. Хәзергә ин жинел жәза—«стойка»га куям. Көне буе аякта басып торачаксың. Инде шуннан сон да анламасаң, сине Склетов көтеп тора. Ул—үз эшенең мастеры...

Икенче көнне Тинчуринны Склетов янына кертеп ташладылар. Ул—мәгарәдән үрмәләп чыккан гаҗәеп бер әзмәвергә охшаган иде. Чукмардай йомры беләкләр. Жилкәсеннән үсеп чыккан баганадай таза муены тап-такыр итеп кырылган башына тоташкан. Әйе, палач дисәң дә палач бу!..

Әзмәвер күп сөйләшеп тормады. «Юк», дигән сүзне ишетү белән, бер селтәнүдә Кәрим дигән данлы егетне идәнгә сугып екты. «Гаебенне таныйсынмы?», «Кул куясынмы?» Шушы ике сорауга унай жавап ишетмәдеме, көрәктәй кулларын әшәке эшкә жикте. Измә итеп, вәхшиләрчә кыйнап ташлый иде ул үзенең бернинди коралсыз тоткыннарын. Бер-ике көн дигәндә Кәримнең карарлыгы калмаган иде... Аягында көчкә басып тора. Гәүдәсе таш кебек авырайды. Аяк астындагы идән менә-менә авышып китәм дигәндә дә ул диварга тотынып исән калырга тырышты...

«Сез үзегез халык дошманнары!»—дип кычкырасы килде анын. Ләкин монын бик кыйммәткә төшәсен чамалап, канлы тешләрен гарьлек белән идәнгә төкерде...

***

Бу хәлләрнең чын дөресе, айлар-еллар узгач кына, «дворян» кызы буларак типкедә йөргән, өйсез-йортсыз калган Заһидә Тинчуринага һәм канатсыз калган Салих Сәйдәшевкә тамчылап, өтек-өтек кенә барып ирешге. Күбесе—озын колаклар, чыбыксыз телефон аша.

Дөресен әйткәндә, Сәйдәш ут эчендә калды. Ул нишләргә, кемгә таянырга тиеш хәзер? Дөньянын асты-өскә килде шикелле. Дөньяны шом, әләк басты. СССР дигән зур илдә халык хәзер үз күләгәсеннән үзе куркып яшәгән хәлендә...

Һәркайда «кара исемлек» төзелгән. Кемнең ни әйткәнен, ничек сулыш алганына хәтле бар яктан тикшереп торалар. Әле кичә генә дус, табындаш булып яшәп яткан бәндәләр бүген инде бер-берсен сата, палач балтасы астына жибәрә. Бер генә киек-жанвар да үз туганын үзе ашамый. Ә кешеләр әнә нишли...

«Халык дошманы» Кәрим Тинчуринны чын-чынлап яклаучы табылмады бугай. 1929 елны Ялтада Галимжан Ибраһимов янында булганнарны да кырып-себереп өтерменгә жыя башладылар. Композитор Салих Сәйдәшев «кара исемлек»тә бармы-юкмы—ул моны анык кына белми. Камалыштагы ерткыч кебек яшәргә туры килер микәнни? Бунтарь Такташ әнә вакытында үлеп өлгерде булса кирәк, юкса анардан «халык дошманы» ясау бу мөртәтләр өчен сукыр бер тиенгә дә тормас иде. Юньле читекче дә була алмастай алласызлар, сугымчылар илнең түренә кереп оялаган түгелме?

Дөрес булса, СССР композиторлар союзы председателе Тихон Хренников әллә Сталин янына кергән, әллә телефоннан гына сөйләшкәннәр, ди. Янәсе, ул юлбашчыга әйткән, ди:

—Зинһар, композиторларга тия күрмәсеннәр. Алар фәкать музыка язалар, алар сәясәт эшеннән ерак торалар.

Чынлап та, халкына хезмәт иткән, чын халыкчан жырлар язган

композитор ничек инде шул халыкның дошманы булыр икән?

Кызганыч, Кәрим Тинчуринның данлы әсәрләре репертуардан, сәхнәдән төшеп калды. Аларның сулышына «табу» дигән йөгән киертелгән. Алай гынамы, халык дошманының хатыны совет йортында яшәргә тиеш түгел дип, Заһидә Тинчуринаны өеннән урамга куып чыгарганнар әнә. Ә инде Тинчуринның НКВД куштаннары алып киткән кулъязма папкалары исән микән, әллә көл итеп күккә очырылганмы? Ике олауга сыйган китапханәсе, затлы сувенирлары, сигез германский фотоаппараты кая китте дә кемнәр кулына күчте икән?..

Сәйдәшнең уена бер фетнә фикер кереп оялады: «Болар үзләре контр түгел микән соң?» Ләкин моны кычкырып әйтергә ярамый иде.

Эченнән генә болай дип әйткәне дә булмады түгел: «И әтием Жамалетдин! Ярый әле крестьян токымыннан булгансың. Юкса улыңны җәһәннәм капкасына бик тиз илтеп тыгарлар иде...»

## Зур Кызыл урамы буйлап...

Өйдә чакта ул үзен кайчак читлектә кебек хис итә. Нәрсәдер җитми. Һавамы? Иркенлекме? Кешеләрме? Бөтенесе бергә укмашкан булса кирәк. Мондый чакта—урамга, урамга!..

Флигельнең тимер рәшәткәле кечкенә капкасына якынайды. Аркылы-торкылы итеп, квадрат рәвешендә ясалган бу рәшәткәләр ана ничектер төрмә тәрәзәсендәге тимер каплагычны хәтерләтә иде. Өтермә. Таш капчык. Хибесханә. Бу яман йортка халык әнә шулай әллә ничә исем уйлап тапкан. Төрмә диварларында һәр кешегә бер кирпеч әзерләп куелган, дип тә әйтәләр халыкта. Булыр, булыр. Кәрим Тинчуринны, Фәтхи Бурнашны, тагын-тагын әллә ничаклы адәм затларын үзенә упты бит бу кыямәт йорты!

Дуслары бер хәбәрсез югалгач, тирә-юнь бушап калды, олы дөньяның бер чите кителде шикелле. Яшәүнең кызыгын, түмен тояр өчен үзендә өр-яңа көчләр табарга кирәк хәзер. «Нинди илдә яшим мин?» дигән сораулар күңелдә еш калкынып куя. Ә эшем кешеләре, куштаннар тормыш агышына шулкадәр бирелгәннәр, «Без кая барабыз?»—дип сорарга вакытлары да, теләкләре дә юк аларның...

Урамга! Урамга чыгып, күңелнең ерак почмакларын да, бөялеп яткан уй-фикерләрне дә хет бераз җилгәреп кайтырга кирәк.

Аны тагын Горький урамы көтеп тора иде. Ничәмә-ничә тапкырлар гизә инде ул шушы урамны! Йорт почмакларына урысчалатып «улица Максима Горького» дип язылган язылуын, ләкин асылда Сәйдәш урамы бит бу: җәяү йөреп, ул шунда гомеренең күпме өлешен уздырды, өеннән чыкса яисә өенә кайтса-керсә дә—һаман шул урам... Кекин йортындагы хәрчәүнәгә халык та юкка гына «Сәйдәш ханәсе» дигән исемне кушмагандыр...

Кабан күленең аргы ягында завод торбалары шәйләнә. Күктәге томансу һаваны ертып, сабын заводы ягыннан төтен баганалары күтәрелә. Мәчет манарасы күгендә сары ай җемелди, күгәрченнәр бөтерелә. Чиркәү гөмбәзләре тирәсендә, гадәттәгечә—чәүкә-каргалар өере...

Урамнарның исә үз көе, үз җыры, үзенә хас тыелгысыз тормышы... Сәйдәш—табигатьтәге бихисап авазлардан, урам-мәйданда кайнашкан кешеләр сөйләшеннән, аларның монсу яки көләч йөзеннән хакыйкать тавышын ишетергә һәм аңларга күптәннән өйрәнгән композитор. Тулы канлы, камил музыка бары шулай туа дөньяга. Сәйдәшнең тәне дә, җаны да урам хәрәкәтенә кушылып китте, андагы авазларга иярде...

Ашыкмый гына Гоголь һәм Карл Маркс урамнарын узды.

Астарак, шәһәр үзәгендә Куйбышев мәйданы, Бауман урамы... Гаҗәп:

бу кешеләрнең Казан каласына ни катнашы бар икән? Тимер юл вокзалы тирәсендәге бер урамга Сакко-Венцетти дигән исемябыштырганнар. Боларының кем икәнен белүче бар микән? Нигә татарның борынгы, тарихи каласына татар исемнәре кушмыйлар? Сәер, бик сәер...

Сәйдәш Зур Кызыл урамга аяк басты. Хет ичмасам монысының исеме татарча янгырый. Кулларын артка куеп, шушы урам буйлап атлап баруында ул ниндидер символик мәгънә күрде. Кызылармеец Сәйдәш... Аннары ул, зур театрның зур сәхнәсендә, үзенең үлмәс моңнарын яңгыратты... Татар дәүләт академия театры белән Мәскәү, Ленинград, Оренбург, Әстерхан һәм Идел буе шәһәрләрендә гастрольләрдә йөрде... Урта Азия республикаларында, Уфа, Оренбург шәһәрләрендә иҗади концертлар бирде... Гөлләр янгыры булып ана һәркайда алкышлар яуды... Сәйдәш үзенең күп кенә замандашлары белән, мәдәният урамының зурысыннан, кызылыннан атлады. Революциягә, газиз халкына хезмәт итте ләбаса. Әмма аны хәзер ныклап аңлаучы бармы соң?

Иҗатының иң парлак чагында аның канатын кистеләр! Кәрим Тинчуринның данлы пьесалары сәхнәдән алып ташланды. Шуның белән бергә, Салих Сәйдәшевнең дә бик күп җырларына тыю, «табу» салынды. Гонорар акчасына юллар киселде. Оркестрны куып тараттылар. Театрда 30 елдан артык дәвам иткән дуслык, хезмәттәшлек еракта калды. Сәхнәдә чәчәк бүләк итсәләр, тәкъдир исә ана хәзер билчән суза түгелме?..

Ходай адәм балаларына ике иң олы нәрсәне бүләк иткән—берсе гомер, икенчесе Ватан. Хакыйкать шуны әйтә: әгәр гомерең булмаса, бу дөньяда берни майтара алмыйсың. Әгәр Ватаның булмаса, кылган эш-гамәлләреңнең кыйммәте тузан бөртеге хәтле генә. Зур талантның бер көнлек әсәрләр язарга хакы юк! Шөкер, халык мәхәббәте, аның кодрәти энергиясе Сәйдәшкә әле дә булса яшәргә, сынап төшмәскә көч бирә.

Сәйдәш Зур Кызыл урам буйлап атлый. Революциягә кадәр салынган борынгы йортлар да күп биредә. Борынгылык төсмерләре әллә каян күзгә бәрелеп тора... Әнә, өч катлы таш йортның аскы тәрәзәләренә тимердән үреп ясалган каплавычлар беркетеп куелган. Күрче, челтәрләп эшләнгән шушы каплавычларда нота билгеләренә охшаш бизәкләр дә чекерәеп тора! Биш сызыклы ноталар алдына куела торган нота ачкычына тартым бормалы-әйләнмәле сурәтләрне төсмерләү дә кыен түгел...

Боларны ясаучы тимер остасының күңелендә композиторлык куәсе посып яткандыр, мөгаен. Фантазиясе мулдан уйнаган аның... Тәрәзәләр—өйнең күзләре Чү! Яран гөлләре тезелеп утырган тәрәзәнең ак пәрдәсе селкенеп куйды... Кемнәр яши икән биредә? Бәхетле кешеләрме, әллә замана михнәтен йотып утыручылармы... Әйтү кыен, бөтен нәрсә—бер Ходай кулында.

Тәрәзә пәрдәсе ачылгач та анда яшь кенә бер чибәр кызның аксыл-сылу йөзе күренеп китте. Бәхетле бул, яшь кыз! Теләк шул сина...

Сәйдәш Зур Кызыл урам буйлап Казан суына таба атлый.

Кәрим Тинчурин турында уйламый калган көне бар микән аның? Йөрәгенең керсез почмагында һаман ул. Тинчуриннан башка Сәйдәш юк. Һәм киресенчә: Сәйдәштән башка Тинчурин да юк. Бу—аның сүзләре түгел. Моны бүтәннәр әйтер иде. Баш режиссер—бөтен театрны, коллективны, сәхнәне, спектакльне бәйләп торучы көмеш чылбыр, алтын бөҗра! Алар икесе дә дуслыкларына беркайчан күләгә төшермәделәр.

Сәйдәштән сорамыйлар дисеңме:

—Нишләп синдә элеккеге иҗат дәрте юк?

—Ни өчен синдә утызынчы еллардагы активлык күренми?

Андыйларга, моңсу елмаеп:

—Кәрим Тинчуриннар житми мина!..—дип җавап бирә Сәйдәш.

Гавәмнең төрлесен, инсаннарның яхшысын да, яманын да байтак күрде ул. Яхшылар күп, әмма монафыйкъ, шымчы, икейөзле бәндәләр дә житәрлек бу тормышта. Юкса һәр кешедә кызыл кан ага, ә нигә мәкер кара була икән?

Тормышны хәзер бигрәк тә дәртсез, монсыз адәмнәр басты. Андыйлар Сәйдәшкә юлдаш та, мондаш та түгел!

Тормыштагы уен кагыйдәләре усал, рәхимсез. Бөтен кешене бертөсле уйларга өйрәтү, кулда һәркайсын йөгәнләп тотар өчен Казанда да Композиторлар союзы төзеделәр әнә. Һәммәсе, флюгер сыман, шунын рәисенә йөз белән борылдылар, ләббәйкә торалар. Жәмгыятьнен чисталыгы, әхлагы өчен барган көрәшнең беркайчан туктаганы юк. Анын табигый сафлыгын күктәге көчләрнең катнашы белән генә үзгәртеп була, мөгаен. Бу олуг миссия, сәнгать чынбарлыгы ин әүвәле чиратта музыка жилкәсенә төшә. Бирелә сәнгать әһеленнән чиста кул, зирәк талант сорала...

Сәйдәшнең таланты көчлерәк балкыган саен Казан көчекләре дәртләнебрәк өрә башлады! Алар балтыр итен түгел, йөрәк итен тешлиләр... Гажәп: каян килә икән күнелендә кинә, куенында таш йөртүчеләр?

Ә хәзер бармы соң анын дуслары? Бар, билгеле. Фронтовик шагыйрьләрдән Мөхәммәт Садри, Мәхмүт Хөсәен... Профессор Гыйлем Камай, Мөхәммәт Гайнуллиннар гаиләсе... Журналист Исмәгыйль Усманов... Урамда ялгыз йөрүләр шактый жайсыз-унайсыз ана. Еракган ук танып алалар. Эндәшәләр. Чакыралар... Ярый әле «тукран эчәрлек кенә» дигән эчке кагыйдәсенә хыянәт итми. Чакыручылар арасында таныш түгел кешеләр дә очрап куя. Бәлки, «подставной» берәр агент-мазарлардыр ул. Андыйлар Сәйдәшне исертергә, фаш итәргә тырышалар булса кирәк. Менә шуна да ул «Черек күл», Дзержинский урамнары тирәсенә якын бармаска тырыша.

Яхшы кешеләр, якын дуслары өчен Сәйдәшнең күнеле генә түгел, яшәп яткан фатир ишеге дә һәрвакыт шәрран ачык булды. Кыен хәлдә калганнарны коткару яисә үз фатирына сыендыру дигәндә ана куш инде. Артистка Галия Кайбицкая берзаман ире белән аерылышты. Балам белән торыр урыным юк дип, 1929 елны Казаннан Әстерхан татар театрына китеп бармакчы ул. Аны бу хата гамәленнән Сәйдәш туктатып калды: ачуланды, жибәрмибез, диде. Фатирындагы ике бүлмәсенең берсен ана биреп, үзе Тинчурин өенә вакытлыча килеп урнашты. Сугыштан сонгы елларда яшь артист Шәүкәт Биктимеровның яшь гаиләсен үзенә «прописка»га керергә рөхсәт бирде. Ә менә йортсыз-жирсез калган артист Ибраһим Гафурга почмак бирүе үз башына тукмак булып төште!.. Хатынсыз да, фатирсыз да калды Сәйдәш! «Хатынымны кияүгә бирдем әле»,—дип, юк-бар гайбәтчеләрнең авызын томалаудан бүтән чара калмады.

Икенче хатыны Сафия, шулай итеп, ижат кешесенең күнелен-рухын анламады. Анын кайчагында шаярып-көлеп: «Билдән түбән мин үземә дә ышанмыйм»,—дигән сүзләре раска туры килде... Чеп-чи хыянәт! 1943 елда аерылыштылар. Олы улы Нәүфәлгә 14 яшь, кече улы Эмиль алтынчы яшенә кереп бара иде.

Өсте-өстенә борчулар, фажигаләр килеп кенә торды Сәйдәш дигән ир-егеткә! Язмыш ана һичбер кызгану күрсәтмәде. Мәктәптә тәнәфес вакытында, авыр имән ишеккә башы бәрелеп, Эмиль улы хастаханәдә үлеп китте. Музыкада, пианино уйнауда искиткеч талантлы бала иде! Махсус музыка мәктәбенә йөргән дәресләре әнә шулай ярты юлда киселеп калды бәгырьнең...

1946 елны медальләр тагып сугыштан кайткан Альфред абыйсын ничек

яратып кочаклаган иде ул! «Мина пистолет алып кайттыңмы?»—дип, аны көн саен аптырата иде, кәбәм... Насыйп булмаса, бәхетенне тәкъдир кулыннан талашып тартып алып булмый икән шул!

Тормыш, рояльдәге клавишлар кебек, ак һәм кара полосалардан тора. Һәр яңа тумыш көн иске-москы вә чүплекләр арасыннан үсеп, күтәрелеп чыга. Шигърияттә, музыкада да шулайдыр бу. Ә менә мон дигән нәрсә ахыр чиктә барыбер яктылыкка манчылган була...

Ялгызлык. Эшсез, акчасыз калу... Болар Сәйдәшнең яраланучан йөрәгенә тирән эз сызды. Газеталар: без зур адымнар белән социализмга барыбыз, дип мактана. Ләкин кемнәрдер кикереп баеганда, кемнәрдер ач-ялангач утырганда моның поты бер тиен ләбаса! Барысын да югарыда утырган чиновниклар, «әшнәлек» көче хәл итә.

Кеше белән әрепләшүне, үпкәләп йөрүләрне белмәде Сәйдәш. Никадәр сабыр, тыныч холыклы кеше, шулай да үз гомерендә бер тапкыр «бәйдән» ычкынганы булды аның... Шул инде, акчасызлык харап итте. Ат гомере буе эшли әнә, өстенә кияренә чикмәне дә юк бичараның. Сәйдәш тә шул көнгә калып бара түгелме?

Тотты да филармония директоры Хәйсин янына керде. «Акча юк!»—дип кырт кисә бу. Юмалап та, ялынып та карады Сәйдәш, ахырда кычкырып торып җибәрде:

—Хәзер үк акча бир! Нәрсә, мин ачтан үләргә тиешмени?!.

Менә шулай итеп, ул чакта бераз акча төште аның кулына.

Дуслары янында Сәйдәш: «Мине кырык җирдә кырык самавыр күтәп тора»,—дип кабатларга яратса да, чынлыкта исә аның күңелендә—тирән яшеренеп яткан рәнҗү, ачыну, чарасызлык...

## Гармунчы егет «Москвич»ны иярли...

Кекин йортындагы хәрчәүнә яныннан тыныч-мәшәкатьсез генә узып китәрмен дигән иде...

Юк, барып чыкмады. Җәйге көн булганлыктан, аның ишек-тәрәзәләре шыр ачык һәм эчтән кемдер берәүнең венский гармунда уйнаганы ишетелә иде. Сәйдәш тукталды, көй-авазларына колак салды. Кемдер гармунда аның «Хуш, авылым» көен башкара... Калын тавышлы берәү җырга кушылып китә...

Уникe телле венский гармунның тавышы бик тә таныш иде. Теге... сыра заводында имән кисмәкләр ясаучы Сәлимнең гармуны түгелме соң бу? Нәкъ шул! Вятка ягыннан алып кайтылган бу гармунда Сәйдәшнең берничә тапкыр уйнап караганы да булды. Балта остасы Сәлим янына, сырадан авыз итәргә дип, артист һәм язучы дуслары белән кергән чаклары да бер тапкыр гына булмагандыр.

Ишектән керү белән сәхнә шикеллерәк бер почмакта утырган гармунчы егетне күреп алды. Унҗиде-унсигез яшьләр тирәсендә булыр. Куе чәчле, чуендай кара тәнле егетнең алдында шешә шикелле нәрсәкәй һәм тәлинкә тулы кабымлыклар да күренә иде.

Ир затлары өстәл артында мәйханә килә. Аларның күбесе—утны-суны кичкән, сугыштан кайткан фронтовиклар. Шәраб яки аракы эчүдән бер дә тайчанып тормый алар, хәтта мулдан да җибәргәлиләр. Нилектән? Сугыштан ияреп кайткан борчу-хәсрәтләрен стаканга салып эчүләреме? Яу кырында ятып калган полкташлары хөрмәтенә дә рюмканы каплыйлар. Герман җиреннән әсирлектән кайткан, инде кайтып та ил эчендәге репрессияләргә эләккән дусларын искә алалармы?.. «Тегене уйна! Моны уйна...»—дип, егет алдындагы подноска акча ташлыйлар...

Алар Сәйдәшне аягүрә басып сәламләделәр.

—Туктагыз. Бу егетне миңа бирегез!—диде дә аны үзе янына чакырды. Урамга, өрәңге агачлары янындагы эскәмиягә чыгып утырдылар. Сәйдәшнең тавышы җитди:

—Нишләп утырасың син анда... ирләр белән аракы эчеп?..

—Юк, абый, «Морс» бит ул, баллы су...

—Алайса ярый. Мавыгып китә күрмә... Сәлим малаемы син?

—Әйе, «Кара малай» дип тә йөртәләр үземне.

—Заманында әтиең белән дуслар идек... Исемең ничек?

—Илдус.

—Бик яхшы. Ә мин Салих абыең булам. Сәйдәшев.

—Шулай дип сизгән идем аны. Дөрескә чыкты!—дип шатланды егет.

—Бирedә беренче тапкырмы син?

—Әйе, диярлек була. Акча өчен инде. Гаилә, дарулар өчен уйныйм. Әнинең йөрәге авырта...

Танышу дәвам итте. Шоферлыкка укыган. «Россовхозснаб»та машина йөртә, ягулык ташый икән ул. «Улым»,—дип эндәшкәч, күнеле нечкәрүдән күзләренә яшь бәреп чыкты аның. Әтисе вафатыннан соң бу ягымлы җылы сүзне беренче тапкыр ишетүе булды, ахрысы.

Иртәгә шимбә көн. Киткәндә иртәгә сәгать 11гә театр каршына килергә кушты аңа Сәйдәш.

—Килештекме. Сәгать унбергә үзем дә чыгып җитәрмен.

Икенче көнне Сәйдәш, флигельнең ишегалдына чыккач, пиджагының эчке кесәсеннән чылбырлы сәгатен тартып чыгарды. Нәкъ унбер тулып килә. Капканы ачып урамга аяк баскач та театр ягына карады. «Кара малай» дигәнең шунда, тимер ишекләр төбендә таптанып тора иде.

—Молодец! Төгәл егет икәнсең,—дип мактады ул аны...—Театр директорының шоферы бик нык авырып киткән. Яңа кеше эзли ул. Сиңе тәкъдим итмәкче булам.

—Эшкә? Театрга? Минем белемем юк бит.

—Руль артына дигән таныклыгың, праваң бар. Чын документ. Калганына кайгырма. Шоферга фәлсәфә кирәкми,—диде Сәйдәш, ягымлы көлемсерәп.—Киттек, кирәбез. Мин синең хакта әтиең урынына кайгыртырга тиешмен.

Касса кырыендагы имән ишекне ачып керделәр дә директор бүлмәсенә уздылар.

—«Москвич»ны йөртә беләсеңме?—дип төпченде хуҗа, егетнең документларын тикшергән арада.

«Беләм», «Йөртәм», «Ярар» дигән сүзләре ышаныч уятырлык иде. Икенче көнне үк Илдус руль артына утырды. Кибет-базар юлларын айкап, театр өчен кирәк-яраклар ташып та өлгерде. «Шәп снабженец чыгачак монардан»,—дип шатланды директор.

Сирәк кенә, йомышы чыкканда, Сәйдәш тә аның җинел машинасына утыра. Әле беркөн шулай «Кольцо»га кадәр бергә бардылар. Матбугат йортына керәсем бар дип, Бауман урамында төшеп калды. Барган шәпкә танышы очрады. Мөтәшагыйрь. Кулында гәҗит. Исәнләшергә дә онытып, кул аркасы белән гәҗиткә суга-суга сөйләнде:

—Менә, күпме яңа орденчылар... Монда нигә синең исемең юк, Салих абый?

Сәйдәш тыныч кына, гаҗәпләнергә урын калдырмыйча:

—Ник булмасын! Минем Салих Сәйдәшев дигән исемем бар...—дип җавап кайтарды.

Мин сине эшкә урнаштырдым, диеп борчымады ул Тукайның Карахмәте

сыман «кара малай»ны. Киресенчә, күрешкән-исәнләшкән чакта Иллус атлы шофер егет: «Салих абый, барасы жирен юкмы?»—дип үзе күбрәк сораштыра иде.

—Консерваториягә,—ди Сәйдәш. Бүтән сүз әйтми. Арткы утыргычка кереп утыра. Гадәтенчә, кулын егетнен жилкәсенә куеп, «киттек» дигәнне белдерә. Сөйләшми, егетнең игътибарын алмаска тырыша. Хәер, Иллус үзе дә күп сөйләшә торганнардан түгел. Чәй эчкәндә, ачылып китеп, сөйләгәне булды: алты-жиде яшеннән үк гармунда уйнарга өйрәнгән икән. Жырларга да яратам, дигәч, тавышын тынлап карады. Табигать бүләкләгән чып-чын тенор тавышы! Ләкин егеткә машинасыннан гайре, берни дә, бернинди дан да кирәк түгел...

Әйләнеп кайткач, театр буфетына кереп чәй эчтеләр. Сәйдәш ана үзе белән булган бер хәлне сөйләп бирде:

—Менә шушында булды бу. Театрда эшләгән чагым. Бездә бит теге башта—артистларнын киенә торган бүлмәсе. «Егетләр, буфетка барып киләсем бар, йомышларыгыз юкмы?»—дигәч, сакаурак бер артист: «Салих дус, мә, шушы өч тәнкәгә өч перәлек алып кер әле»,—диде. Әйләнеп килдем. «Йә булдымы?»—ди теге. «Менә булды»,—дип өч перәннекне аңа суздым. « Бу нәрсә, шаяртуынмы?»—ди. «Сон,—мин әйтәм,—үзең сораган өч перәлек. Менә сдачасы». « Мин синнән өч перәннек түгел, өч перәлек дидем бит»,—дип үпкәләде. Ул мина өч сумлыгын өч «берлек»кә ваклатырга кушкан икән ләбаса! Шулай итеп, өч перәннекне үземә кимерергә туры килде...

Сәйдәш кесәсеннән «Первомайский» дигән кызыл-матур тышлы папирос тартмасын тартып чыгарды. Шунысы яхшы, егет тәмәке тартуга хирес түгел иде.

Урамга чыккач, Сәйдәш аны фатирына чакырды. Иллус Чайковскийнын стенада эленеп торган портретына бик озаклап карап торды. Бүлмәдәге искерәк диван, урындыклар, өстәл, тумбочкаларны бер кат күздән кичерде. Шундый данлы композиторнын гадәти бер шартларда яшәвенә исе китте бугай анын. Күпне күргән, инде искерә төшкән пианинога, андагы шәмдәлгә, яшел бәрхет өстендә яткан дирижер таякчыгына мөкиббән китеп карады.

—Салих абый, талчыбыктан сезгә әнә шундыйрак бер таякчык ясап бирсәм, каршы килмәссезме? Лак белән буяп та жибәрермен...

—Яса, улым, яса! Истәлеккә булыр.

Пианинода халык көйләрен уйнап күрсәткәннән сон, ишегалды як тәрәзәдән анын машинасына керергә жыенганын карап торды. Ләкин ишегалдындагы машинасына кереп утырырга өлгермәде егет, әллә каян гына кара плащлы, кара эшләпәле икәү килеп чыкты. Икесе ике яктан култыклап алдылар да, жилтерәтеп диярлек, театр ягына өстерәделәр. «Тегеләр»... Тегеләр тагын килеп житкән, козгыннар! Нигә шул чакта чыгып, егетне араламады Сәйдәш?! Хәер, чыгып, ни майтара алыр иде икән ул? Көчленеке замана...

Икенче көнне күрешкәндә сөйләде Иллус. Аны бөтереп алганнар да, артына тибә-тибә, театрның авыр имән ишекләре арасына китереп кысканнар:

—Тиз бул, сөйлә! Нинди сүзләр әйтте ул сиңа?Ниләр сөйләштегез?..

Егет куркып калмаган, коелып та төшмәгән:

—Сөйләшмәдек. «Немой» бит ул. Күп сөйләшми.

—Алдашма! Дөресен әйт безгә!

—Дөресен әйтәм. Пианинода уйнап күрсәтте.

—Анысын ишеттек. Стоп! Кемнәрне телгә алды ул? Совет властен

сүктеме?..

—Юк. Шоферга фәлсәфә кирәк түгел, диде.

—Ул сине мыскыл иткән. Ә син аны якламакчы буласың!.. Кара аны, дөресен сөйләмәсәң, телеңне бик тиз ачтырырбыз...

Тавышка ярый әле ардминистратор чыгып өлгергән:

—Нишләтәсез безнең шофер егетне?!

Тегеләргә шыпырт кына чыгып таюдан бүтән чара калмаган. Мондый хәл Илдус белән ике-өч тапкыр булган икән.

Эх, кара җаннар! Тырнак астыннан, юк, кешенең күңел сараеннан кер эзлиләр... Әйе, Сәйдәш кебек «асыл кош»ны бер-бер гаеп табып, тәпиеннән эләктерсәләрме?.. Самавырчы малай булып йөргән сержанттан—лейтенант погонына кадәр күтәрелү берни түгел аларга... Композиторның өченче хатыны Асия Казакова—татар байлары нәселеннән. Сыйнфый дошман кызы. Сәйдәшнең Тинчурин, Бурнаш белән бәйләнеше кайбер допрос кәгазьләрендә уелып калгандыр. Менә шушы «салам»га тотынмакчы бу ике кара эшләпә...

Әлеге хәлләр 1953 елның җәендә булган иде. Хәзергә ул-бу күренми, тындылар, ахрысы.

Алдагы елны Илдус Совет Армиясе сафларына китеп барды. Озатканда Сәйдәшнең сүзе-киңәше шул булды:

—Кешеләр белән кәпрәеп, борын чөеп сөйләшүдән ерак бул. Сынатмаска тырыш. Бәхетле көннәрең алда синең...

## Чаллыяр. Сугыштан бер кайтаваз...

Аларны, бер төркем әдәбият-сәнгать әһелләрен, Алабуга шәһәренә мактаулы кунак итеп чакырдылар. Сәбәбе бик күркәм—бу борынгы калада педагогия институты ачыласы икән.

1954 елның 8 маенда, «Вера Засулич» дигән ак пароходка утырып, Иделне һәм гүзәл Каманы кичтеләр. Менә палубадан композиторлар Сәйдәшев һәм Ключарев, шагыйрьләр Әхмәт Исхак һәм Әнвәр Давыдов, җырчы Мәрьям Рахманкулова төшеп килә. Кунакларны пристаньда шәһәр җәмәгатьчелеге каршылый. Чаллыдан махсус килгән улы Альфред һәм аның хатыны Сәйдәшнең пристань идәненә аяк басканын көтәләр. Ирләрчә кочаклашу! Ничә елдан соң сагынычлы күрешү...

Зур тантана хөрмәтенә бәйрәм концерты. Кичен банкет. Икенче көнне Сәйдәшне кичке якта җиңел машина белән Чаллыяр бистәсенә—Альфред улының гаиләсенә илтеп куялар.

Казан университетын тәмамлаган Альфредны юллама белән Чаллыярга судья итеп эшкә җибәргәннәр иде. Нинди куаныч: түрбакчалы, берничә бүлмәле агач йорт биргәннәр үзенә. Баскыч төбеннән күтәрелгән болдырның түбәсе шәрыкъ стилендә, гөмбәзләп ясалган. Кичен—пилмән шулпасы, үләннәр кушып ясалган чәй. Гаиләдә—өч бала: Валерик, Светлана, Әлфия. Биш-алты яшьлек Валерик балалар бакчасына йөри, калган ике яшь баланы килененең әнисе бага икән. Баласыз өй—чәчәксез болын, дигәннәр. Хактыр бу.

Озак сөйләшеп утырдылар. Соң ятылган иде.

...Иртәгесен Сәйдәшне түрбакчадагы кошлар серенадасы уятты! Чут-чут киләләр, бәгырькәйләрем, осталык ярышына чыгып басканнар диярсең... Кызык: аларның авазлары Идел буе урманнарындагы кошларныкына охшаган да, охшамаган да кебек. Ачык тәрәзәдән акация һәм сиреньнәрнең хуш исе саркылып кергән иде. Чыгып карады, чынлап та шулай: сиреньнәр төн эчендә күбекләнеп чәчәк аткан!

«Көтелгән кунак килде!»—дип ягымлы, җылы каршыладылар аны кичә.

Бала-чагалар «яңа» абыйны, дөресрәге, бабаларын баштарак читтән карап торсалар, аннары инде куенына ук елыштылар. Валерик исә: «Мин иртәгә бакчага бармыйм, бабам белән йөрим. Юкса урамда адаша ул»—дип, ана тагын да ныграк сырышты.

Бүген йорт эче шактый бушап калган—Альфред ниндидер мөһим бер судта зур бер эшне тикшерүдә катнаша икән. Хатыны Вера—рус теле һәм әдәбияты укытучысы—чыгарылыш класснын житәкчесе, анын да вакыты кысанга охшаган. Күз тимәсен, улынын жәмәгате, Вера дигән килен, чыннан да, тотанаклы, ипле, ышанычлы күренә. Гаилә ныклыгына ни житә сон! Сәйдәш дигән ир заты моны үз тәжрибәсеннән яхшы белә...

Тынлык. Йомшак жилнең агач яфраклары арасыннан кыштыр-кыштыр узып киткәненә хәтле ишетелә. Өй түрендәге зифа ак каен үзебезчә, саф татарча жырлый әнә. Түтәлләрдә—чәчәк балкышы! Шунда куна-куна бал кортларының безелдәве колакны иркәли. Жыйнак кына шушы бакча—үзе бер симфоник поэма сыман! Фани дөньяда яшәп яткан һәркайсынын моң-музыкага кагылышы, катнашы бар—моны исбатлап торасы юк.

Сәйдәшнең жаны да, тәне дә истирәхәт кичерә иде бу минутларда.

Агачлар күләгәсе үзара этешми-төртешми генә жиргә төшеп яткан... Кояшның күләгәсе була алмый, ә менә төннәрен айның саргылт күләгәсе йорт түбәләренә, рәшәткә өсләренә төшеп кунаклый. Тылсымлы шушы өрфия эчендә Валясы белән утырганнарны оныту мөмкинме сон!..

Ә менә музыканың күләгәсе буламы? Була. Ләкин бары тик театрда, анын да тамаша залында, диварларнын ярымкараңгы ялангач стеналарында. Оркестр авазларынын дулкыны тамашачы күңеленә барып житкәнче иң элек ике як диварларга килеп бәрелә. Моны аңлатып булмый, моны бары тоярга гына мөмкин.

Иртән торып ишегалдына, бакчага чыккан саен Сәйдәш бер ялгызак сурәткә караш ташлый. Такталардан коршалган койманың теге башында, аргы ягында корыган карама агачы аягүрә басып тора әнә... Зәңгәр күкнең ашъяулык тиклем бер почмагында анын корыган ялангач ботаклары туктап калган яшен тармакларын, оеп калган музыка кыйтгасын хәтерләтә. Теләсә ничек аңла һәм аңлат син бу сурәтне, телсез авазларны... Шушы ноктада ниндидер язмышлар, тәкъдир тамгалары кисешә кебек...

Сәйдәшнең ябыга төшкәнен, төннәрен йөткергәләп алуын күрмиләр-сизмиләр дисеңме... Анын теләгәнчә ял итәргә мохтажлыгын аңладылар, мөмкин кадәр тынычта калдырырга тырыштылар. Альфред улынын әйткән сүзләре һаман колак төбендә:

—Кадерле әтиебез син. Хет бер атна, хет ун атна яшә бездә! Сине бирегә беркем борчымас, әти...

Жанга, тәнгә, күңелгә тынычлык бирердәй сүзләр иде бу. Кычкырып-шаулап йөрмәгәч, Салих Сәйдәшев дигән композиторның Чаллыярда яшәп, ял итеп ятуын баштагы көннәрдә, чынлап та, беркем белмәде диярлек. Ләкин... без капчыкта ятмас, дигән борынгылар. Хәлләр нәкъ шулай килеп чыкты да берзаман. Өч көн уздымы-юкмы, Сәйдәш янына, ул яшәп яткан йортка берәмләп тә, төркемләп тә халык агыла башлады. Укытучылар, суд-прокуратура хезмәткәрләре, хәбәрчеләр, гади кешеләр һәм колхозчылар... Хәтта күрше авыллардан да ерак араны якын итеп килеп чыгучылар табылды.

Киң карашлы, киң күңелле Сәйдәш халыкның бу мәхәббәтен, рәхмәтен ничек инде кире каксын да, «халык мәхәббәте лауреаты» дигән исемнән ничек баш тартсын икән! Һәркайсын жылы-ягымлы кабул итте, аларның сүзләрен, гозерләрен, моң-зарларын тыңлады, шатлыкларын бүлеште.

Сәйдәш холык-табигате белән аралашудан кача, ераклаша торганнардан

түгел. Шулай итеп, ял итү вә ялгызлык рәхәте кичерүләр кешеләр белән аралашу, сөйләшү сәгатьләренә дә барып ялганды.

Көннәрнең берендә ана:

—Сукыр гармунчы килгән. Сине ишегалдында көтә,—диделәр.

Чыкса, ишегалды эскәмиясендә, чыннан да, бер кулына артыш таяк тоткан, икенче кулы белән тез башындагы тальян гармунын кочаклаган, мосафир кыяфәтле, утыз-кырык яшьләр тирәсендәге Хода бәндәсе утыра иде. Кара күзлектән. Бите җөй-җөй яра эзләре белән капланган. Аны озата йөрүче малай булса кирәк, кырыенда сәләмәрәк киемле бер үсмер басып тора.

Гармунын сак кына итеп эскәмия читенәрәк куйды да:

—Әссәләмүгаләйкүм, Салих абый!—дип бик ышанычлы мәкамдә исәнләште ул һәм үзе белән таныштырды.—Шәйхетдин атлы кешемен. Элек мәктәптә җыр һәм рәсем дәресләре укыттым. Сугышта танкист идем...

Китте сөйләп, китте сөйләп... Күренеп тора: аралашуга сусаган ул, газиз башыннан кичкәннәрне сөйләп-тугарылып, күнелендә яткан истәлекләрен бушатасы, уртаклашасы килә аның.

Гармун качмас, иң элек утлар-сулар кичкән тома сукыр фронтовикның сөйләгәннәрен бүлдерми генә диярлек тыңларга туры килде.

—Сугышка кадәр сезнең җырларны тыңлап үстек без, Салих абый! Егерме дүртенче елгылар без. 1942 елны җыеп алып киттеләр. Сугышка киткәндә сезнең «Хуш, авылым»ны кат-кат җырладык. Соңгысында прәме күздән яшьләр килде... Колхозда трактор ярдәмчесе булып та эшләдем. Шуңадыр, танкистлыкка укыттылар мине. Курск дугасына эләктем. Мактану булмасын, нибучь, маршал Рокоссовскийның үзен күргән кеше мин!.. Безнең яшел ботаклар белән маскировать ителгән танкларны карап йөрде ул урманда. Кул биреп үк күрешмәде анысы, вакыты да булмагандыр, вак-төяк командир ише генә түгел бит...

Сәйдәшнең тыңлавына куанып, дәвам итте:

—Дугада, ай-яй, каты барды сугышлар! Танкка танк бәрелгән тимер чыңнары, снаряд шартлаулары әле дә колагымда чыңлый. Сезнең «Совет Армиясе маршы» чыңнары белән кердем сугышка... Фашистның «Фердинанд» дигән нәмәрсәкәйләре белән маңгайга-маңгай килдек! Менә шунда минем танкка ут капты... Төтендә, ут-ялкында буылып калдым... Кем, ничек коткаргандыр, хәтерләмим дә. Аңыма килгәндә, бинтларга чорналып, хәрби госпитальдә ята идем... Яшисе килү көчле булгандыр инде, Ходайның рәхмәте белән исән калдым. Сугышта йөргәндә гармунымны үлеп сагына идем! Шул да коткарды бугай мине...

Тынып калды, куллары белән гармунын капшады.

—Сезнең рөхсәт белән берәр көй уйнап китсәм дигән идем, Салих абый!..

—Әйе, ут-дәрьяларын кичкәнсең икән, Шәйхетдин энем... Уйна, эчтәге сагышларны тышка чыгарыйк булмаса.

Күпне күргән гармунга охшаган бу. Каешы һәм мехлары кыршыла төшкән. Почмак калайлары, киресенчә, җилкәдә күп йөри-йөри тәмам шомарып-ялтырап беткән. Уң як яңагында кайчандыр кечерәк кенә көзгесе дә булган моның, мөгаен, ватылгандыр—ул урында көзгенең уч төбе чаклы эзе генә сакланып калган.

Менә гармун каешын җилкәсенә элде, үзе генә белгән тыйнак аккордларны эзләп тапты. Тупас, ләкин йөгереклеген югалтмаган бармаклары белән тальянының көмеш телләренә кагылды. Сукыр гармунчы «Уел» көен уйный иде. Көй уңаена иреннәрен бер ачып, бер кысып куя. Түзмәде, карлыкканрак тавыш белән җырның азагына үзе дә кушылды:

Егет тә генә кеше һич кайгырмас,
Газиз башы аның сау булса.

Яна заманнарда яшәп яткан Сәйдәш көчле рухлы бу гармунчының Тукай заманындагы җырны шулай оста уйнавына һәм җырлый белүенә таң калды. Күрче, шушы моңлы-сагышлы җырга, үзенең уйнавына ул кояш һәм ай нурларын кертергә тырыша иде. Халык дигән сүз—буш сүз түгел. Әнә шулай җырны—моңны сөйгән Шәйхетдиннәре бер моның белән генә чикләнми бит аның...

Бу очрашуның тәэсире озакка житәрлек иде. Сукыр гармунчының сөйләгәннәре, комарланып уйнавы кичкә кадәр күңеленнән китмәде. Китәсе көннәр якынайгангамы, бүгенге кич гаҗәеп дәрәҗәдә матур моңлы, галибанә иде.

...Батып баручы түм-түгәрәк кояш кура җиләге төсенә кергән. Көндез аның нурлары күк гөмбәзенә арфа кылларыдай тартылган иде. Ул кыллар каядыр китеп югалган. Литавра тәлинкәсенә охшап калган кызыл кояш тирәсендә хәзер утлы шәфакъ тузаннары гына төсмерләнә. Күгелҗем урман өстендәге шушы кинлекләргә күктән әллә ниткән моңлы-сагышлы музыка агылып төшә сыман... Табигатьтә бер көннең үлеп, икенче көннең кабат уяныргa дип йокыга талган, кисешкән мәле... Кеше гомерләре дә шулай булса икән ул. Юк, кеше мәңгелек йокыга талса, ул инде бүтәнчә уянмый, аның кылган гамәлләре тарихта, исәннәр күңелендә яши башлый...

Йомры түтәлдә үсеп утырган розалар тагын да кызгылтрак булып күзгә күренде. Кырыйдагы бер чәчкә төймәсеннән сынар таҗ яфракчасы җиргә өзелеп төште. Гап-гади шушы күренеш Сәйдәшкә могҗизалы тәэсир итте, чөнки бу тормыш гөләбеннән бик иртә өзелеп калган Валя-Валентинасын хәтерләтә иде... Чү, тагын икенчесе өзелеп, үлән арасына тирбәлеп төште. Монысы нинди фал, монысын ни-нәрсә дип юрарга? Үзенең уйларын куарга теләп урыныннан кузгалган гына иде, аны чәйгә дәштеләр.

Бүген өтеп-өтеп көнозын кояш кыздырган иде. Юкка булмаган икән...

Кояш батып, караңгылык төшәр-төшмәс дигәндә әллә каян гына җил кузгалды, болытлар үтәли куерды.

Дөньяда патшалар да идарә итә алмый торган кодрәти бер нәрсә бар: ул—табигать. Аның язылмаган үз кануннары. Менә бу яңгыр болытларын кирәк чакта чакыртып та китерә алмыйсың, аларны куып җибәрү дә кулдан килә торган эш түгел. Яңгыр, яңгыр!.. Болытларны дөбердәтеп гүя атлар көтүе узды. Күкләрне тутырып яшен яшьнәде! Озак та үтмәстән, чиләкләп яңгыр коя башлады. Тылсымлы пәрдә булып, тәрәзә пыялаларын яңгыр суы томалап алды... Андагы яңгыр тамчылары балык күзедәй елтырый иде. Алар, тора-бара нота билгеләренә әверелеп, акрын гына аска таба тәгәриләр...

Бу яңгыр, янартып-сафландырып, Сәйдәшнең күңеленә дә ява иде кебек. Шушы яңгыр эзләреннән ул иртәгә үзенең даңлы-шаңлы Казанына китеп барачак лабаса...

***

Кояшлы-айлы, моңлы, чыклы һәм сандугачлы көннәр артта калды. Саубуллашканда әйткән сүзләрен, кинәйтә төшеп, инде үзалдына кабатлады:

—Сау бул, Чаллыяр! Сау булыгыз, улым, кызым һәм оныкларым! Без әле очрашырбыз...

## Килеп җитте моңсу көзләр...

Соңгы вакытларда Сәйдәш өй хуҗалыгы эшләренә әлләни игътибар итми башлады. Бүген хәтта урын-жирен дә иренеп, теләр-теләмәс кенә җыештырды. Кабартам дип куллары белән мендәргә суккалаган иде, салам очыдай тырпаеп, аның бер почмагыннан каз каурые бармагын чәнчеп алды. Зыян юк, клавишларга кагылам дисәң, чәнчә бармакның роле шунын хәтле генә...

Кухняга дип узган чакта коридор идәненең такталары, карт кешенең сөякләредәй, башмак астында моңсыз гына шыгырдап калды. Чәйнек капкачының шылтыравында да көнелне юатырдай яна авазлар юк иде.

Һаман да урам, дуслары-танышлары үзенә ныграк тарта аны.

Җәйнең соңгы җиле исеп, август үзенең вазифаларын сентябрь аена тапшырды инде. Тротуарда берән-сәрән сары яфраклар күренә. Таш шәһәрдә әбиләр чуагының тәме-ләззәте сизелми, көзгә дә бәрелеп тормый. Менә хәзер авылда, табигать хозурында булсаң иде! Әйдә, хыяллан, Сәйдәш, хыялланудан бөлмисең дә, баемыйсың да...

Күңелнең бер кылы тын гына, кабаланмый гына шуны искәртеп тора: Сәйдәшкә быел бәхет яки бәхетсезлек яный кебек. Моны аңлап-аңлатып бирү өчен көрәзәче булу кирәктер...

Әллә ниткән булып чыкты бу 1954 елның җәе! Чыбыксыз телефон, яшерен юллар аша: 22 июльдә Төркиянең Әнкара шәһәрендә мөһаҗир әдип Гаяз Исхакый вафат, дигән хәбәр Казан каласына килеп ирешә. Газеталар бу хакта әйтергә бер кәлимә сүз тапмадылар, халыкка кәррә чаклы да хәбәр салмадылар, билгеле. Олуглардан да олуг Гаяз Исхакый, шулай итеп, мәңге онытылыр микәнни?

Ул бит ак патша зинданыннан да исән-аман килеш чыккан кеше. Салихның өлкән җизнәсе Насретдинны да, амнистия сылтавы белән, Кремльнең Кирпеч асты төрмәсеннән бик тиз азат иттеләр теге чакта. Патша төрмәләре дә болай ук җанкыяр булмаган, ахрысы. Фашистларның Моабит төрмәсен кичкән җәлилчеләрне дә акладылар хәтта. Ә менә Тинчурин, Бурнашлар кая китеп югалды, ник алардан бернинди хәбәр юк—бу хакта сөйләшергә, сорашырга да куркалар. Амнистия булырмы киләчәктә, яисә совет төрмәсендә билгесез югалганнарның язмышлары кайчан ачыкланыр икән соң?

Борчыла Сәйдәш, Ходай биргән җаны һаман да шулай уйнаклый. Йөрәгенең саф җирендә алар—исән, яшиләр, сагындыралар, кайчакны төшкә дә керәләр...

Менә шушы хәсрәтле уйлар көймәсендә тирбәлеп, дустының өенә килеп җиткәнен сизми дә калды Сәйдәш. Кыңгырау төймәсенә баскач, ишек артында Исмәгыйль Усмановның дустанә ачык йөзе пәйда булды:

—О-о, Салих абый! Рәхим итеп...

—Исәнме, дустым! Менә сина утырмага килдем әле. Сездә күңелем ял итә минем.

Көтеп кенә торгандай, ак самавыр кайнаган иде. Өф-өф итеп, тәмләп озаклап чәй эчтеләр. Төшке ашка да ерак калмаган иде. Аннары Сәйдәш, гадәттәгечә, акрын гына таныш пианино янына утырды. Назлап сыйпаган сыман итеп, бармакларын клавишлар өстеннән йөгертеп узды да экспромтлар уйнарга кереште. Алар, киңәйгәннән-киңәя барып, бүлмәне тутырды. Кояш нурларына тотынып, тәрәзә аша каядыр күккә китеп югалдылар. Кинәт бу авазлар гаммасына ниндидер шомлы, сикәлтәле мотив кушылып китте!.. Аккордлар дулый, көчәя барган чакта күкнең бәллүр көзгесе челпәрәмә килеп ватылды сыман...

Исмәгыйль куркынып калды:

—Салих абый, бер-бер нәрсә булмагандыр ич?

—Юк, дустым, хафаланма. Просто... синең янда жиңеләеп, бушанып киттем мин...

Ул тагын урамда. Урамнар гизеп йөргән Сәйдәш шәһәр өчен бармы, юкмы хәзер? Аяклары үзеннән-үзе Ленин бакчасына таба атлады. Трамвай тәгәрмәчләренең тимер рельслар өстеннән авыр өстерәлеп, вакыт-вакыт чинап барулары шәһәр манзарасына үзенчә бер жанлылык өсти кебек.

Халыкчан бакча бу. Берәүләр эскәмиягә кара-каршы атланып шахматта көч сынаша. Икенче бер почмакта дәртләнеп домино сугалар. Борынгы акча, иске монета алмашучыларның да рәсми булмаган үз биләмәсе бар. Сыра, хәмер эчә торган жирдән чыгып килүчеләр күзгә чалына... Үзенең атаклы маршы өчен СССР Оборона наркомы Климент Ефримович Ворошиловтан исемле сәгать алган композитор кабакта сыра чөмереп утырсамы?.. Бу инде кемнәр өчендер—«чәйнәр» ризык, гайбәт сагызы. Менә шуңа да Сәйдәш хәзер андый почмаклардан ерак булырга тырыша.

Кемдер юкә агачының кәүсәсенә сыерчык оясы ясап элгән әнә. Бушап калган ояга чыпчыклар хужа: керәләр-чыгалар, кыска койрыкларын сикертеп үзләренчә кайнашкан булалар. Юкә, өрәнге агачыннан коелган берән-сәрән яфраклар өзелеп төшми, гүя, күзгә моң булып күктән тамалар...

Кемнең, кайсысының сагышы көчлерәк бүген: Табигатьнекеме, Сәйдәшнекеме?

Сәйдәш өчен тормышындагы иң зур, иң әһәмиятле вакыйгалар вакытның теге як өлешендә, кояшлы ягында бүленеп калды түгелме? Күңелендә кояш тотылган чаклар азмы булды аның! Искә төшерә башласаң, йөрәге телгәләнә. Аның жанын гарипләргә, музыкасына тышау салырга теләүчеләр әле хәзер дә юк түгел. Ләкин чын музыка беркайчан да артка чигенүне белми. Ул вакытлыча йә югалып торырга, читкә тибәрәләр икән, заман арбасыннан вакытлыча төшеп калырга да мөмкин. Бары шулай, бүтәнчә була алмый.

Власть башында утыручыларның ышанычын яулап, алар белән «әшнәлек» корып яши белгәннәр рәхәт кичә бүген. Обком секретаре Батыев кебекләргә—сүзләре, көндәшләренә «тешләре» үтә. Композиторлар союзында терәк булырдай дуслары калмады диярлек. Алар бар да казна һәм жәмәгать эше белән мәшгуль. Акча килеп торырдай жылы урыннары бар. Хет берничә ай гонорар хисабына гына яшәп карасын иде алар, белерләр иде көймә төбенә ничек итеп су кергәнен...

Сәйдәшкә менә сигезенче ел инде югарыдан эш тәкъдим итүче юк. Хәер, ул үзе дә, эшләпәсен салып, кемнеңдер каршысына тезләнеп килә торганнардан түгел. Яшерен үпкә, ачу, гарьлек саклау—шулай ук аның кабилиятенә хас килми.

Заманында икенче гильдия сәүдәгәр саналган Мөхәммәтжан Казаковның кызы Асиягә өйләнүе тормышларын азмы-күпме жайлап жибәргән иде. Маяга калдырган акчалар тора-бара шикәрдәй эреде дә юкка чыкты.

Дөньяның иләк ягын да, күн ягын да күп күрде Сәйдәш. Төптән уйлап карасаң, музыканың хрусталь сараенда тау чаклы эшләр башкарып өлгергән ич ул. Боларны санап кына чыкканда да сөлге буе исемлек барлыкка килер иде. Йөзләгән жырлар, марш һәм арияләр, пьеса һәм драмаларга музыкаль бизәлешләр... Соңгы елларда Сәйдәш ижаты сүнде, сүрәнәйде, дип лаф оручылар нык ялгышалар. Фәтхи Бурнашның «Югалган шатлык» либреттосына опера яза башлаган иде, мәгълүм сәбәпләр аркасында ул өзелеп калды. 1952 елда Гамир Насыйриның «Кадерле минутлар» драмасына Сәйдәшев музыка язды, аның премьерасы уңыш белән узды. 1954 ел. Гата

Нуруллин. «Вөждан». Театрның соравы буенча бу пьесага да музыкаль бизәлешне, җырларны Сәйдәшев иҗат итте. Тик кызганыч: май аенда булган премьераны Сәйдәш үзе күрмичә калды—Алабуга һәм Чаллыярда ял иткән чагы иде аның. Кайткач, истәлеккә дип, кулына бер данә афиша тоттырдылар.

Якын дусты Мөхәммәт Садри әлерәк кенә «Ак күгәрчен» дигән пьесасына либретто тәмамлады. Сәйдәш аның беренче күренешенә увертюра язып та өлгерде инде. Культура министрлыгы белән килешү төзеп, саллы гына гонорар алды. Кызганыч: авырып китүе сәбәпле, бу эше дә өзелде. Ак күгәрчен сәхнәләргә кадәр күтәрелеп оча алмады!

Сәйдәшнең тормышында әнә шундый «кызганыч»лар нишләптер күбәеп китте шул. Ул—тормышында да, иҗатында да югалту һәм фаҗигаләрне күп кичергән кеше. Язмышның ләүхел-мәхфүз тактасына шулай язылган, күрәсең. Ләкин Сәйдәш үзенең кайгы-хәсрәтләре турында кешеләргә сөйләргә беркайчан яратмады, үзен юмор хисеннән дә мәхрүм итмәде.

Шулай бервакыт милиция частена ниндидер концерт белән киттеләр. Килеп җиткәч кенә кайсынындыр исенә төште: баянны алырга онытканнар икән... Ике милиционер, театрның партком секретаре Баян Гыйззәтне урталарына алып, китеп баралар.

—Баянны да алып киттеләр,—ди Сәйдәш, уфтанып.

Аның бу сүзен җитдигә алалар. Театр халкы пошаманга төшә, чышын-пышын сөйләшүләр дә күбәя. Сугыштан соң бит бу,ниләр булмас диген. Икенче көнне иртән, нәкъ шул хакта сөйләшеп торганда, Баян Гыйззәт эшкә килгәч, барысы да шакката:

—Ничек... Сине җибәрделәрмени? Кичә сине алып киткәннәр иде бит...—диләр беравыздан. Шулчак Сәйдәш, ике кулын сузып:

—Исәнме, Баян, сине чыгардылар да мени?—дип сораган булды.

—Каян?—ди Баян, гаҗәпләнеп.

—Милициядән!—ди Сәйдәш.—Имеш, сине ике милиционер алып киткән, диделәр ич.

Эшнең нәрсәдә икәнен аңлап, артистлар рәхәтләнеп бер көлде ул чакта. Бу гамәле өчен Сәйдәш соңыннан үкенеп тә куйды. Чөнки әлеге шомлы шаяртудан һәркемнең күнелендә юшкын да утырып калган иде...

Ирләр компаниясендә уен-көлкенең тынып торган чагы сирәк була. Нәрсә-нәрсә, әмма Сәйдәш күпертеп, арттырып, чама хисен югалтып сөйләүчеләрне: «Шаяртма!» дип, шушы яраткан сүзе белән туктата да белә. Зыялы зат буларак, ул беркайчан «кечкенә» кеше булып яшәмәде.

Сәйдәш үзенең көйләрен бер дә интекмичә язды диярлек. Шагыйрь Мөхәммәт Садри «Совет Татарстаны» газетасында эшли. Алар редакция бүлмәсендә яисә Сәйдәшнең фатирында еш күрешәләр. Берсендә яңа шигырен күтәреп килгән ул. Сәйдәш аны тыңлады, шигырьне үзе дә беркат укып чыкты. Пианино каршына килеп утырды да бераздан өр-яңа көй уйный башлады. Аннан соң, борылып елмайды да:

—Булды бит бу!.. Ярыймы соң?—дип сорады.

—Ничек шулай тиз?..—дип гаҗәпләнде Садри.

—Көйләр миңа үзләре килә, мин аларны эзләп йөрмим.

—Вәт гаҗәп!—дип тел шартлатты Садри.—Бөек рәссам Пикассо да нәкъ шулайрак әйткән...

Көннәрнең берендә газета редакциясенә килеп кергәч, Мөхәммәт Садри аның кулына машинкада басылган бер бит кәгазь тоттырды.

—Менә, каләмдәшебез Муса Җәлилнең «Җырларым» дигән шигыре бу. Дөресрәге, шигырь-васыяте. Син моны үзеңә ал әле, уйланмый калмассын дип беләм...

Шигырьнең беренче юллары ук Сәйдәшнең бәгырен көйдереп алгандай итте:

Жырларым, сез шытып йөрәгемдә,
Ил кырында чәчәк атыгыз!
Күпме булса сездә көч һәм ялкын,
Шул кадәрле жирдә хаккыгыз!..

Төрмә газапларын кичкән, үлгәндә дә елмаеп, аягүрә басып үлә белгән батыр йөрәкле Муса Жәлилнең язмышын, шигырьдәге утлы-кайнар сүзләрне бөтен тәне-вөжданы аша үткәреп, төне буе газапланып чыкты, әллә ничә тапкыр урынынннан кубарылып, пианиносы каршына иелде. Кайнарланды, салкынчарак өй эче эссе булып китте. Моң-сагыш, көчле рух белән сугарылган, яшәү һәм көрәшкә дан жырлаган «Жырларым»ның музыкасы, реквием әнә шулай—тынгысыз газаплар эчендә туды. Шагыйрьнең васыятенә Сәйдәш йөрәгенең парә-парә килгән кисәкләрен дә, сугышка каршы ләгънәт ору мелодияләрен дә, үзенең васыятен дә кушып жибәрә алды булса кирәк. Үзенә шулай тоелды.

Жырның кайнарлык, оран авазлары бөркелеп торган нотасы таң алдында тулысынча әзер иде.

Артык киеренкелектән нервалары бирештеме, тирән кичерешләр йөрәгенә каптымы әллә—Сәйдәш, эчке бер авыртудан бөгәрләнеп, клавишлар өстенә капланды. «Үтәр, үтәр... булгалый...»—дип, үзен эчтән генә тынычландырырга тырышты.

Чынлап та, үтеп бара әнә...

Уйласаң, гомер дә үтеп бара лабаса!..

Сәнгать корбаннар сорый, дигән бер акыл иясе. Асылда ул үзен, гомерен сәнгатькә корбан итте түгелме? Бәхетле булдымы соң Сәйдәш? Сәгадәткә ирештеме ул... Әлеге сорауга өзеп кенә жавап бирү дә читен. Бу тормышта сагыш белән шатлык гел бергә, янәшә, житәкләшеп йөриләр—моны ул тәгаен яхшы белә.

Кешенең, бигрәк тә хатын-кыз затларының чәчәк вакыты узып китәргә мөмкин. Ә менә чын сәнгать әсәренең, Музаның гомере вакыт белән чикләнми. Тарих шаһит: күпме талант ияләренең даһи музыкасы гасырдан-гасырга күчеп яши, меңнәр-миллионнар йөрәген дулкынлатып, жылытып, алдагы көрәшләргә рухландырып тора.

Шәхси тормышында Сәйдәш әлләни хаталар ясамады кебек. Булганнары да—язмыш шаяруы белән. Ә менә ижатында... кайтарып булмаслык хата эшләде бугай ул. Бигрәк тә театрда эшләгән чагында туктаусыз язды да язды... Язганнарының күбесен оныта барды... Үзенең музыкасын яттан белгәнгә һәм яхшы хәтерләгәнгә күрә, күбесенә партитура һәм аранжировка ясап тормады, вакыты да чамалы иде. Спектакльләр сәхнәдән төшүгә, аларның күбесе ничектер югалган булып чыкты. Тәжрибәсезлек, үз ижатына карата гамьсезлек галәмәте бу. Аның күпме көйләре-язмалары әнә шулай юкка чыкты, яисә радиокомитет бүлмәләрендә тузан жыеп ята. Тинчуринның пьесалары тыелгач, Сәйдәшнең дә күп кенә жырлары үзеннән-үзе эфирдан, сәхнәдән коелып калды. Кайбер акыллы титибашлар аны, янгын куркынычын сәбәп итеп, кырга алып чыгып яндырмасалар ярый да бит... Хәер, Ибраһимовны, Тинчуринны, Бурнашларны югалту янәшәсендә—болар чүп кенә.

Ялтада чакта Галимжан Ибраһимов: «Эш белән үч алыр вакыт...»—дигән иде. Замананың кара афәтләре әдипнең үзеннән үч алды. Композитор Сәйдәшнең сазында житмеш жиде кыл бар иде... «Жырларым»ны язганда

соңгы кылда уйнавы түгел идеме аның? Соңгы вакытларда хәле начарая төште, бу хакта беркемгә сөйләгәне, зарланганы гына юк. Тукай әйткәнчә, «бетте көч, сынды кылыч...» дияр чаклар житеп киләме әллә? Юк-юк, аның җегәре әле сүбхәналла, музыкасы да йокы симертү турында уйламый. Күптән түгел ноталар белән «Балалар җырлары» дигән китабы чыгу да аның күңеленә бәлзәм булып тамды.

Больница юлының ни икәнен дә белмәгән Сәйдәш табибларга барырга атлыгып тормый. Тукай соңгы елларында аспирин белән генә торган, диләр. Сәйдәш аспирин дигәннең «а» хәрефен дә үзенә якын китермәде, аны үзе белән кесәсендә йөртмәде. Бары тик апасының улы Үзбәк Әхмәров кына аны хастаханәдә тикшерүдә ятарга күндерә алды. Үзбәк атлы, елтыр күзле бу малайны, муенына атландырып, сабый чагында еш уйната иде бит ул. Хәзерендә әнә—шәһәрнең исемле врачы, ничек инде аны тыңламыйсың!

***

...Партактивның махсус клиникасында үпкә авырулары буенча белгечләр һәм Сәйдәшнең Оренбург елларыннан ук якын танышы, профессор М. Фәйзуллин, рентген тасмаларын тикшергәч, нәтиҗә чыгаралар. Беренчел диагноз: «сул як үпкәсендә сусыл шеш». Хастаханәдә бераз ятып дәвалангач, алга таба дәвалау ысулын сайлау һәм ахыргача тикшерену мәсьәләсе калкып чыкты. «Бер дә борчылма, иң яхшысы Мәскәү»,—диделәр. Медицина фәннәр академиясенең Вишневский исемендәге хирургия институтына бару өчен кулына юллама тоттырдылар. Чигенер урын калмаган иде.

Мәскәүгә бару көнен көтеп яшәүләр—иртәгә һава торышы ничек булыр, яңгыр яуармы-юкмы? дигән шикелләрәк бер нәрсә иде. Тәкъдир шулай кушамы аны: инде икенче тапкыр Сәйдәшне, кыстый-кыстый, Мәскәүгә таба юллыйлар. Аның бер дә барасы килеп тормый. Мәскәүдә укып йөргән елларында да өстенә ишелердәй булып басып торган таш йортларын, кысан урамнарын күңеле кабул итмәде. «Мин Казанны яратам, аннан башка яши алмыйм»—дип әйтүе буш сүз түгел. Ул бит Казаныннан бик сирәк чыгып китә: сәяхәткәме, гастрольләргәме—анда да фәкать дуслары белән йөри. Уен эшмени—ул хәзер әнә япа-ялгызлыкка, билгесезлек кочагына барып керергә тиеш.

Моңсу күзләргә менә шушы моңсулык, билгесезлек тә килеп өстәлде.

Әнә шулай каршылыклы халәт эчләрендә кәтә торгач, китәр көне дә килеп җитте. Озатырга, саубуллашырга дип, фатирына туган-тумача һәм иң якын дуслары җыйналган иде. Моңаерга урын калдырмыйча, шаян сүзгә, уен-көлкегә дә җай табалар. Юл алдыннан дип, берәр чәркәне тотып куярга да онытмадылар. Озата килүчеләр үзләрен уңайсыз хис итмәсен дип, якты-тыныч карашы, тыенкы елмаюы, әчке бер җыйнаклыгы белән Сәйдәш табынга ямь, мәдәт бирергә тырышты.

Шагыйрь Мөхәммәт Садри табында утырганнардан бөтенесенең теләген әйтеп сала белде:

—Казаныңны ятим итеп, башкалада озак йөремә, Салих дус! Юлларың уң булсын, фәрештәләрнең «амин» дигән чагына туры килсен. Хатлар яз, без ул хатларда синең кул җылысын да, йөрәк җылысын да тоярбыз, иншалла. Тормыш бик катлаулы, Чиста калыр өчен безгә дингез кебек горур булырга, үз-үзеңә ышанырга, дусларыңа таянырга кирәк. Әйдә, Салих абый, күтәрик... Җырланмаган әле безнең җыр!..

Дулкынлана Сәйдәш. Бу ихлас сүзләрне ишетү—рәхәт тә, моңсу да аның өчен. Менә шул чакта ул урыныннан күтәрелде дә пианиносы янына килеп утырды. Күңеле һәм күз карашы еракка, еракка төбәлгән иде аның. Йөрәгендә чылтырап аккан чишмә суыдай билгесез моңнар чыңлый... Менә

монарчы беркем дә ишетмәгән экспромтларын уйный башлады... Аклы-каралы клавишлар арасыннан әле ак күгәрченнәр, әле уктай атылган кара карлыгачлар очыра!.. Бу моннарга Иделнең зәңгәр кинлекләре, киртләч-киртләч ярлар, Кызыл Байракның иртәнге томаннары, Чаллыярдагы сирень исләре, яңгыр шавы—боларның һәммәсе, һәммәсе дә төсле авазлар гаммасы булып сыйган-сыешкан иде...

Бу гаҗәеп музыка йортның ишегалдына, урамга, шәһәр өсләренә ташып чыкты, болытларны сискәндерде. Әйтерсең, Сәйдәш Казанында соңгы концерт бирә! Юк, концертның дәвамы булачак—соңгы якты аккордлар әнә шуны аңлата...

Сәйдәшне, хатыны Асия Казакованы, дусларын тышта автобус көтеп тора. «Кара малай» Илдус, әллә ашыктырып, әллә гудок биргәндәй итепме, машинаның сигналын да кычкырта!

Хәерле сәгатьтә булсын!

Тимер юл вокзалына таба кузгалдылар...

Мәскәү шифаханәсе: яшәү яки үлем...

Беренче сәгатьләрдән үк шуны аңлады Сәйдәш: саулыгының кадерен бел, больница хәлләренә төшмә дә төшмә икән!

Гомер булмаганны, төрле анализларын алырга дип, бер бүлмәдән икенчесенә, өченчесенә йөрттеләр. Баштарак дүрт кешелек бүлмәдә яшәде. Бер атна үттеме-юкмы, аны аерым палатага күчерделәр. Бу эш читтән кемнеңдер катнашы белән эшләнде булса кирәк, ләкин Сәйдәш моның артында кем кулы торганын бөтенләй белмичә калды. Шунысы шатландыра—дәвалау шартлары яхшы, ак халатлы врачлар да итагатьле һәм кайгыртучан иделәр.

Композиторны Алипов дигән профессор карады, хәлләрен сорашты. Рентген мәшәкатьләре үткәннән соң әйтте:

—Әйе, сезнең сул як үпкәгездә сусыл шеш бар. Вакыты җиткәч, операция ясарбыз,—диде.

Сәйдәш бу сүзләрне, башын акрын гына селки төшеп, тыныч күңел белән тыңлады. Ходай, яраткан кешемә сынаулар җибәрермен, дигән бит. Казан пациенты бу сынауларга барлык җисме белән әзер иде. Японнарның үлемнән курыкмау, гадәттән тыш хәлләргә тыныч карый белү фәлсәфәсен ишеткәне бар иде аның. Ә шулай да бу хәбәр аңа яшәү бәхете, яшәү кадере турында ныклап искәртте кебек.

Палатаның ап-ак түшәме һәм стеналары күңелгә азмы-күпме тынычлык сирпи. Хәтта ике ишекле тумбочка өстенә дә ак эскәтер җәелгән. Ике урындык. Кергән-чыккан врачлар озак тормый, болар—килгән-мазар кешеләр өченгә тәгаенләп куелган булса кирәк.

Хәл белергә килүче кунаклар, чыннан да, озак көттермәде. Гадәти, игезәк көннәрнең берендә ишектә иңнәренә ак халат элгән икәү күренде. Уколдан соң ятып торган чагы иде, Сәйдәш урыныннан тормак булды, йөзе яктырып китте:

—Нинди профессорлар керә икән?—дип шаяртты ул.

Әхмәт Фәйзи белән Габдрахман Минский җылы итеп күрештеләр, хәлен сораштылар. «Тегеләй итмә, болай итмә... Тыныч ят, сиңа күп йөрергә ярамый...» кебек киңәшләрен яудыра башладылар. Сәйдәш, кәефенең әйбәт икәнлеген расларга теләп, янә дә көлемсерәп җавап кайтарды:

—Әйтәм ич, ялгышмаганмын... Сез чынлап та профессорга тиң икәнсез. Алар да әнә шундый киңәшне бирергә яраталар... Йә, сөйләгез, Казанда ни хәлләр бар?

Авыру янына керүчеләргә, сүзләр-сораулар белән ялыктырмас өчен, биш-ун минутлык кына рөхсәт бирелә иде. Кыска гына очрашу. Ләкин

ялгыз диярлек яткан, төрле-төрле уйга, истәлекләргә баткан кеше өчен бу—күңел бәйрәме, килер көнгә ышанычыңны ныгыта торган жылы, шифалы бер очрашу иде.

Башкаланың клиникасы зур, халык бик күп. Төрле телләрдә сөйләшүләренә, төс-кыяфәтләренә караганда, чит ил кешеләре дә бар биредә. Күрче, үз аягың белән нык басып урамнарны гизгән чакта бер дә уйламыйсың икән... Әйтерсең, бөтен кеше—яше-карты да, егетләр-кызлар да—таза, сәламәт, жир жимертеп йөриләр, эшкә-хезмәткә батканнар. Ә монда... авыру өстенә авыру, палата-коридор саен Ходайның чирле бәндәләре. Алар арасында, операциядән соң бинтка уралып, көзге яфрак сыман саргайганнары да, аксакка калып, таяк ярдәмендә йөрүчеләре дә байтак. Илдәге халыкның яртысы чирле дип уйларсың, валлаһи! Тәмләп сөйләшеп утырырлык кеше генә юк.

7 ноябрь дә килеп житте.

Октябрь революциясенең 37 еллыгы.

Бәйрәмнең шау-шусыз гына төсмерләре шифаханәдә дә сизелә. Парадный ишекләр ягына урак-чүкечле кызыл әләм элгәннәр. Аралашып, дуслашып өлгергән авырулар бер-берсен бүгенге бәйрәм белән котлый. Кемнәрдер хат язу, гәжит уку белән мәшгуль.

Сәгать ун. Менә хәзер Кызыл мәйданда хәрбиләрнең тынлы оркестры күкләрне тетрәтәдер! Мәйдан ташларын чыкырдатып, хәрби техника, саф-саф тезелгән колонналар ташкыны агыладыр...

Казанның Ирек мәйданы күз алдына килеп басты. Анда да шундыйрак хәлләр, бәйрәм тамашасы, билгеле. Сәйдәшнең Кызыл Армия маршын уйнамый калмаслар. Ул моңа шикләнми. Заманында Мәскәүнең Кызыл мәйданында, Бөек Ватан сугышының төрле фронтларында яңгыраган бу марш нишләп әле тормыш сәхнәсеннән төшеп калсын икән?! Ялкынлы, сугышчан һәм жинүчән батыр авазлар һәркемнең күңеленә канат куя, яшьләргә һәм көрәшергә дәртләндерә... Литавралар чыңлаганда гүя энже бөртекләре чәчелеп китә дә, трубалар уйнаганда, әйтерсең лә алар яңадан бер ноктага, үзәккә жыйналалар. Бу маршның мәңгелектән, гасырлар төпкеленнән күтәрелеп чыкканын, аның триумфаль адымнар белән киләчәккә барасын композиторның үзеннән дә ныграк аңлаучы бар микән?..

Тукта, Сәйдәш, хисләргә артык бирелмә. Һәммәсе сиңа: тынычлык кирәк, ял кирәк, дип кабатлап, кисәтеп тора лабаса.

Казанда дуслары, күрше-тирә белән ничек итеп Октябрь бәйрәмен зурлаулары, табында утырулары кинәт исенә төште. Чү, истә калса да калыр икән: берсендә бәйрәмгә күршесе Хәким Сәлимжановның өч-дүрт яшьлек улы Марсельнең туган көне дә бик табигый кушылып киткән иде. Моңа гажәпләнәсе юк: малайның туган көне—7 ноябрь... Марсель атлы бу егеткә бүген егерме яшь тулды дигән сүз. Ул һаман да фехтование белән җенләнә микән, әллә әтисенең эзенә кайтып төшәрме?.. Сәйдәшнең улы Альфред әнә һөнәре буенча юрист, әмма пианинода уйный, үзе әйтмешли, үзе өчен генә кайчакны көйләр дә язгалый...

Улы Альфред, аның гаиләсе өчен жаны тыныч аның. Күрде ич: бик тату, аңлашып яшиләр, өч бала үстерәләр. Үзендә һәрчак елмаерлык көч тапкан Сәйдәш шушы урында үзалдына елмаеп куйды. Сәгыйть Кашап дигән бер танышын күргәч, ул:

—Нигә кашың жимерек? Әллә авырыйсыңмы?—дип сораган иде.

—Авыртмыйм ла... Хатын әрли. Иртә гауга, кич гауга. Саласың, ди.

—Сәгыйть, синең яшь балаң бармы әле?

—Бар.

—Жылакмы?

—Жылак, кәнишне.

—Алайса, син хатынына чи усак утыны кайтарып аудар!

—Нигә?

—Нигә икәнен үзең белерсең. Хатынны өч нәрсә картайта: исерек ир, жылак бала, чи утын. Картайган хатын күп сөйләшә алмый ул!

Һәй, Сәйдәшнең үзенең дә шундыйрак хәлгә төшкәне булды ич... Бервакытны Шәриф Камалның өенә килеп керде ул. Язу өстәле янында матур гына сөйләшеп утырганда, күзе өстәл өстендәге көллек савытына төште. Мәрмәр ташыннан ясалган бу көллек кырыена авызын зур ачкан карга сыны да беркетелгән иде. Игътибарлап, сәерсенеп каргага күпмедер карап торганнан соң:

—Шәриф абый, чыгарып ат әле бу козгыныңны, күңелгә тия,—диде.

—Нигә?—дип гаҗәпләнде өлкән әдип.—Бик кызык карга бит.

—Ул минем хатынга охшаган,—диде Сәйдәш.—Хатын да шушы козгындай авызын иләмсез ача да һәркөн: ак-ча-а, ак-ча-а, дип кычкыра...

Валя-Валентина белән исән-сау гомер кичерсәләр, тормышы болай ук килеп чыкмас иде аның. Валя һаман да төшләренә кереп әрнетә йә сөендерә аны. Ак күлмәктән, җәйге җиңел камыш эшләпәдән тын гына каршына йөзеп килә. Күп сөйләшми, син кайларда йөрисең дигәндәй, бары текәлеп карап тора. Иркәләргә дип кочаклап алам дигәндә генә... каядыр офыкларга китеп эри, югала! Нишләтәсең, төш дигән нәрсәнең дәвамы кеше ихтыярында түгел.

Туганнары, дуслары, танышлары—барысы да күз алдында. Тик алар белән сөйләшеп кенә булмый.

Кыска гына гомерендә күпме югалтулар кичерде Сәйдәш! Беренче хатыны Валя бала тапканнан соң мәңгелеккә өзелде, бәгырь... Өч-дүрт яшьлек улы Рәләф, кинәт чирләп китеп, кулында җан бирде... Каһәр суккан ишек! Мәктәбендә шуңа бәрелеп, сигез яшьлек улы Эмиль дә больницада вафат булды. Нинди талантлы бала иде ул! Пианинода уйнар иде, 1нче номерлы музыка мәктәбенә укырга йөрер иде... Иң якын дусты Тинчуринның эзсез-нисез югалуы... Монысы искә төшкәндә дә йөрәге пычак белән кискәндәй йөзгә, меңгә телгәләнә.

Бер кеше өчен бик күп түгелме соң болар? Йөрәге әле дә ничек түзеп торды икән бу хәтле газапка, тетрәнүләргә? Йә, әйтегез: тормыш нигә гел югалтулардан тора, кем уйлап чыгарган моны?..

Улы Эмильгә бәйле бер вакыйганы һич онытасы юк аның. Театрда «Наемщик»ны куярга дәртләнеп йөргән чаклары. Әллә ничекләр итсә дә, Сәйдәшнең Батыржан ариясе һич барып чыкмый, меңнәтерә! Репетицияләр тулы канлы барсын өчен режиссер да, җырчы артистлар да ашыктыра. Композитор үзе дә борчыла. Аны, берничә көнгә бикләп, «арестовать» итеп тә карадылар. Юк, барып чыкмый гына теге ария дигәнең... Бер яшьлек улы Эмильнең тәпи басып, чук-чук атлап киткәнен дүрт күз белән көткән чаклары иде. Шулвакыт хатыны Сафия телефоннан шалтыратып сөенче алды:

—Улыбыз Эмиль тәпи йөреп китте!

Менә шул чакта утыз сигез яшьлек Сәйдәшнең тәненә дәрт йөгерде, күңеленә илһамлы очкыннар тамды да инде! Шул минутларда кемдер аның колагына Батыржан ариясен җырлый башлады сыман... Сәйдәшнең кулында очланган, ике төстәге ике башлы карандаш иде. Тотынды нота тамгаларын тезәргә... Ашыгу-кабалануданмы, карандашның зәңгәр төстәге очы сынды. Очларга вакыт юк, әйләндереп куйды да кызыл башы белән язарга керește...

Ниһаять, җыр тәмам.

—Ачыгыз!—дип кычкырды ул, ишекне каты гына дөбердәтеп. Сонрак исә: «Минем ике төстәге карандаш белән язылган нотам кайдадыр булырга тиеш»,—дип искә алса да, бу язманың бүтәнчә кулына әйләнеп кайтканы булмады.

Көннәр акрын гына уза тора.

Абруйлы врачлардан торган консилиум да операция ясарга кирәклегенә фәтва бирде. Инде гажәпләнеп, яхшыга өметләнеп тә композитор операция вакытын көтеп ята.

Шулай итеп, аңа—кылдай нечкә, кылычтай үткен пычак өстеннән узарга туры килер микәнни? «Горбәттә үләргә язмаган мина»,—дип, ирония белән елмаерга тырышты. Хирург пычагы... Ни әйтсән дә, анын эше-тырышлыгы ике нәтиҗәнең берсе белән тәмамлана: ул сина яки тормыш бүләк итә, яки һәлакәт... Язмышның нота дәфтәренә сур быргысынын ничек уйнаячагы язылганмы?..

Соңгы вакытларда күзенә йокы керми башлагач, Сәйдәш мона каршы үзенчә бер «хәйлә» дә уйлап тапты. Йоклар алдыннан күзләрен нык итеп йома да анын хыялында, күз алдында ап-ак кына куян баласы пәйда була. Менә шуның ялтыр колакларын, алсу төстәге күзләрен терелтеп, йомры-йомшак аркасыннан сыйпагандай итә торгач, керфекләренен ничек итеп йомылганын сизми дә кала...

Кичә туганнарына, дусты Мөхәммәт Садрига хатлар язып салды. Икенче көнне аны операция бүлмәсенә алып кереп киттеләр. Баштарак операция инструментларының шалтор-шолтыр килгән авазларын ишетеп ятты! Наркоздан соңниләр булды—калганын ул еракта калган томанлы төш итеп кенә хәтерли...

***

Уянып күзләрен ачканда бөтен тирә-юнь энгер-менгер эчендә йөзә иде. Аннары—ап-ак тынлык...

Бүлмә эче акырынлап яктыра төште. Бүлмәнең ишек-тәрәзәләре, түшәм-диварлары ачык төсмерләнде. Ышанасы килми: операция уңышлы узган!

Казанга, туганнарына Мәскәүдән телеграмма очты: «Операция уңышлы үтте. Барысы да әйбәт бара».

Бер-ике көн узды микән, Сәйдәш яткан бүлмәгә акрын-акрын атлап Гази Кашшаф килеп керде.

—Котлыйм үзенне, Салих туган! Операция ясаган профессор белән сөйләштек. Бөтенесе әйбәт, тәртиптә, диде. Берничә көннән Казанга алып кайтырга мөмкин булачагын да әйтте. Поезд белән кайтырга кинәш итә. Яран төзәлгәнгә кадәр бераз көтәргә туры киләчәк, билгеле.

Анын бу сүзләре Сәйдәшнең йөрәгенә терек суы, бәлзәм булып тамды, ике бите буйлап шатлык тамчылары тәгәрәде. Курыкмыйча дөрес эшләгән ул, менә бит—бар да әйбәт бара...

Казан хәлләрен сорашканда Сәйдәш хәтта шаярту сүзләре табарга да өлгерде. Анын өчен кояшлы көннәр, тормышның яңа авазлары өр-яңадан башланырга тора түгелме?

## Көтелмәгән һәлакәт...

Бүген—16 декабрь.

Яна елга ике атна калды дигән сүз.

Казанга кайтабыз! Поезд белән... Гази Кашшаф аны әнә шундый сүзләр белән баштанаяк сөендерде. Операция ясаган профессор Алипов

та: «Барысы да уңышлы үтте. Инде яраларың төзәлсен, сабыр ит»,—дип гел юатып тора.

Казанына кайту аның өчен бер могҗиза булачак. Туганнары, иң якын дуслары белән табын артында Яңа елны каршылау... Монысы инде—шатлык өстенә шатлык булачак... Менә шундый насыйпларын һәм төкле аягын белән кил син, 1955 елның Яңа елы!

Бер яктан, нинди шатлык—аны уйлыйлар, аны кайгырталар, аның өчен җан аталар. Икенче яктан, тәне күкрәк турысыннан жем-жем итеп тора, сызлана, аяклары хәзергә авырдан атлый. Ярый, монысы да үтәр, үтәр әле берзаман...

Операция алдыннан Сәйдәш үз-үзенә сораулар биргән иде:

—Син ни өчен яшисең?

Үзенең соравына үзе үк җавап та бирде:

—Халкым өчен, аның киләчәге өчен. Мин бары музыкага табынам.

—Синең өчен дөреслек нәрсә ул?

—Ихлас яшәү. Халкыңа һәм сәнгатькә хезмәт итү.

—Синең дошманнарың бармы?

—Юк. Көнчеләр һәм бәйләнчек кешеләр генә бар дөньяда.

Иртән уяну белән ул беравык менә шуларны уйлап ятты. Кичәге көннәр белән алдагысын бер-берсенә ялгарга, янәшә куярга тырышты. Халәте шундый.Операциядән соң булуга карамастан, күз тимәсен, дәрт тә бар, дәрман да бар шикелле.

Әкрен генә таң атып килә бугай. Тоныкбер яктылык, палата диварларына сыенып, әкрен генә каядыр шуыша, үрмәли төсле. Бирелә—Сәйдәш янында гел диярлек утырган, ана су яки дарулар биреп торган хатыны Асия Казакова кичә туганнары янына кайтып киткән иде. Сәйдәш ялгызы бүген. Үзенә еш кузгалырга ярамаслыгын аңласа да, ике кулы белән таянып, аягына басты. Кирәк, шулай кирәк иде...

Һаман да шул оялчанлыгы аркасында кыенсынып, чит кешеләрдән ярдәм сорарга читенсенеп, ул аягына торып басты. Акрын гына атлап китте...

Чү! Карават почмагына бәрелеп, аягы кинәт таяныр ноктасын югалтты. Ике кулын җәеп, карават тимеренә тотынырга да өлгермәде, Сәйдәшнең гәүдәсе чарасыздан идәнгә авып төште... Ярасының җөйләре сүтелде бугай—көрәнсу пижамасына кан табы бәреп чыкты...

Аның күз алдында әнгер-мәнгер биешә башлады, колагына томанлы авазлар ташып керде...

Вакыт төшенчәсе югалды, дөнья каядыр еракка—артка чигенде кебек...

Ап-ак төстәге куян баласы хәтеренә саркып керде. Тик ул кан төсенә—шәфәкъ алсулыгына буялган иде.

Чынмы бу? Әллә саташулы төш кенәме?

Үлем! Кайда синең рәхимсез тырнакларың?! Яшәү үзе дә—кырыс, рәхимсез бер нәрсә. Кешене тән һәм рух газапларыннан фәкать үлем генә коткарырга мөмкин. Ә барыбер яшисе килә! Ләкин, кояшка күзләреңне тутырып карый алмаган кебек, үлемгә дә туры текәлеп карау мөмкин түгел...

Күкләрдән төшкән әҗәл үзенең үлем чалгысын аның баш очында уйнатмак була! Тукта, Вакыт! Ходайның сөеп җибәргән баласын яшәү белән үлем сызыгыннан аралап кал... Бу синең көчеңнән киләдер...

Сәйдәш, ярым аңсыз хәлдә дә, әҗәлнең дәһшәтле чалгысын аның сөякчел кулларыннан бәреп төшерергә тели!

Ниһаять, Сәйдәш аркасы белән караватта калакланып ята. Тәне хәлсез. Аяк-куллары исә гер сыман авыр.

Сүзсез генә газаплануы күпмегә баргандыр, бераздан ул үзенең кулларында шәфкать туташының иреннәрен, кайнар күз яшьләрен тойды... Бар көче белән елмаерга тырышты... Зур дөнья аңардан һаман да акрын-акрын гына еракка чигенә кебек.

Дөньяның кыл уртасында нинди дер бушлык пәйда булды шикелле. Гәүдәсе, диңгез төбенә баткан кургашын кебек, аска тарта... Ә җаны— вулканнар атылган ерак офыкка таба йөзә...

Иреннәре пышылдап кына: «Минем исемем үземнән бәхетлерәк»,—дигән сүзләрне кабатлады. Берсен-берсе куышып, әллә чынбарлык манзарасы, әллә фантастик сурәтләр чылбыры әйләнеште.

Ул нинди дер билгесезлеккә, тирән чоңгылга кереп чумды шикелле... Һавада газаплы музыка авазлары эленеп калды.

Композитор Сәйдәш яткан карават турысында, дөресрәге, күкнең ничәнчедер катында мәңгелек моң аурасы пәйда булды... Әлеге моң Сәйдәшнең үлмәс җанын җир һәм күкләр белән тоташтырды шикелле...

Сәйдәшнең каршы торыр көче калмаган иде. Җаны күккә ашты.

Аның күк йөздәй зәңгәр күзләре мәңгелеккә йомылды.

***

Яшәү, үлем һәм мәңгелек. Алар өчесе дә берьюлы килде аңа.

Ул Аллаһының, югары көчләрнең барлыгына ышанып үлде. Музыка— аның өчен күкләр белән сөйләшү бәхете, кешеләргә әйтер сүзенең бер чагылышы иде.

Социализм төзергә ашкынган җәмгыять үзенең хәлиткеч ноктасында— тарих тәлинкәләрендә тирбәлә: кайсы якка барабыз, кайсы як басар? Сәйдәш әнә шундый тетрәнүләр, үзгәрешләр елында мәңгелеккә ашты.

Музыкада ул, гүя, үзенең киләчәген эзләде һәм тапты.

Киләчәкнең капкалары Аңа ачык иде.

## Сәйдәш белән хушлашу

Композиторның күзләре мәңгелеккә йомылса да, яшәү-мәгыйшәт хәрәкәте мең төрле мәшәкатьләре белән дәвам итә. Әлмисактан килгән туу-үлем йолаларының тормыш арбасыннан төшеп калганы юк.

...Куе танда, әле төнге караңгылык таралып та өлгермәгән бер мәлдә, Чаллыярда яшәп яткан улы Альфред Сәйдәшевнең тәрәзәсен кагалар. «Операция уңышлы үтте» дигән юанычлы хәбәрдән соң тагын нинди яңалык-мазар булырга мөмкин?

Район советы кәнсәсендә кизү торучы хатын икән. Кабаланып һаман тәрәз кага:

—«Срочно!» дигәннәр... Альфред Салихович, сезне Казанга, обкомның үзенә чакыралар!..

Композиторның өлкән улы баштарак ни уйларга да белмәде. Ашык-пошык җыенды да беренче очраган авто белән Казан каласына чапты. Обкомда иртәнге зур җыелыш икән. КПСС өлкә комитетының беренче секретарен байтак көтәргә туры килде аңа. Сәркатип кызга рәхмәт, ерактан килгән кунакка шикәрле чәй белән печенье тәкъдим итеп өлгерде...

Ягымлы каршыласа да, секретарьның талканы коры иде, ашыктырды, сүзне бик кыска тотты:

—Хәзер үк Мәскәүгә китәсез!..—Уфтанулы сулап куйды.—Әтиегез вафат... Минем катгый наказ шул—Мәскәүдә калдырмаска, композиторны фәкать үзебезнең Казанда күмәчәкбез! Сораулар, сораулар юкмы?

Көтелмәгән бу хәбәрдән Альфредның күз аллары караңгыланды. Мондый

чакта нинди сораулар булырга мөмкин ди?.. Кинәш-табыш итү өчен тизрәк Әхмәровлар гаиләсенә ашыкты. Колагында исә һаман бер үк сүзләр чыңлый иде: «Сөекле әтисе... вафат...» Дөресме бу, ялгыш хәбәр генә түгелме?

Бер сәгать дигәндә туганы Үзбәк Әхмәров белән Мәскәү поездына утырдылар. Поезд тәгәрмәчләре бер үк сүзләрне рельсларга туктаусыз чүкеп барды:

—Әтисе вафат... Композитор Сәйдәш вафат...

Шушы күңелсез уйлар агымында вагон тәрәзәсе аша урман ешлыклары, электр баганалары, кар түбәле станцияләрнең эреле-ваклы бинлары чайкала. Нидер сизеп, гүя, алар да әлеге тоташ агым ятьмәсендә тыпырчыналар, кая барып бәрелергә белмичә әле бер, әле икенче якка ташланалар...

Кешенең тәне-гәүдәсе бүген бар, иртәгә юк.

Мәскәүләргә поезд белән, үз аягы белән китеп барган Салих Сәйдәшевнең табутын, махсус самолет белән Казанга кайтару өчен, аэропортка китерәләр. Кагыйдәләр кырыс, карышып-бәхәсләшеп торырга берниндн чара юк: табутны бары багаж рәвешендә генә тапшырырга кушалар. Озатышырга килгән Әхмәт Фәйзи, шул квитанция белән кассага барып, «багаж» бәясен түләргә мәҗбүр. Бары шуннан соң гына мәрхүмнең табутын самолетның бер почмагына урнаштыралар.

Фәйзи акча каян тапкандыр, күпме түләгәндер—моны белүче юк. Аэродромның ташкурчак хезмәткәрләре дә, Мәскәү үзе дә Сәйдәш дигән якты шәхеснең татар музыкасы, татар халкы өчен «күпме бәя» торганын абайламый калгандыр, билгеле.

***

Ниһаять, Казан аэропорты.

Бурап-буранлап кар ява! Менә шушы тоташ агым эченнән, карасу-коңгырт болытлардай кубарылып, тере ташкын каршыга агылып чыга. Болар—Сәйдәшнең табутын алып кайтучы самолетны каршыларга дип килгән халык төркеме икән...

1954 ел. 19 декабрь. Сәгать көндезге 10.

Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының түр залына, биеккә—барлык кеше күрерлек итеп, композиторның кара каймалы кызыл табуты куелган. Бихисап чәчәкләр дингезендә күмелеп, Моң Бәгыре ята. Әле кайчан гына Казан урамнары буйлап йөргән Сәйдәшнең гәүдәсен матәм мөнбәренә яткырып салганнар. Минут саен алмашынып, беләкләренә кызыл тасма бәйләгән композиторлар, әдипләр, җәмәгатьчелек һәм хөкүмәт вәкилләре матәм сагында тора. Югалту ачысын тагын да көчәйтеп, күңел төпкелләренә кадәр үткәзеп, кайсыдыр почмактан сызып-сызып кына «Тәфтиләү» моңнары агыла. Заһид Хәбибуллин, скрипкасын үксетеп-елатып, остазы һәм җан дусты белән әнә шулай хушлаша. Өске каттан исә Фәйзи Биккинин «Хуш, авылым» көен концерт гармунында башкара...

Матәм башыннарак көтелмәгән бер «аңлашылмаучылык» та килеп чыга әле. Обком вәкилләреннән яшь кенә бер иптәш, процессия эшенә катнашасы килеп, мәрхүмнең югары дәүләт бүләкләрен чыгарырга тәкъдим ясый. Янәшәсендә диярлек басып торган шагыйрь Мөхәммәт Садри ана каршы чәчрәп чыга:

—Ә сезнең аларны биргәнегез булдымы соң?!.

Обком вәкиле буларак килгән, композиторның иҗатыннан да, язмышыннан да бөтенләй бихәбәр бу иптәш шундук телен тешли.

Казан халкы, төрле төбәкләрдән, төрле район һәм авыллардан килүчеләр ике көн буена сөекле композиторы белән хушлаша. Аны озатырга килүчеләр арасында кайсы гына милләт вәкилләре юк—татарлар, урыслар, чувашлар,

яһүдләр, украин, белоруслар... Шәһәрнең янәшәдәге Гоголь һәм Маркс урамнары ике көн буена озын чиратлардан бушап тормый. Зиратка озатасы көнне исә халык урамнарның ике ягына рәт-рәт, дивар булып баскан. Зиратка таба якынайган саен бу ташкын кинәя, арта, көчәя, урамнарга сыймый башлый. Мөмкин булмаганлыктан, ул көнне автобус, трамвай һәм троллейбуслар йөрүдән туктый.

Сәйдәшне күмү-озату мәрасиме халык җыенына әверелә, күкләрне кул җитмәстәй моң белән тутыра. Казан тарихында кайчандыр фәкать Тукайны, Такташны мәңгелек туфрагына әнә шулай озатканнар...

Халык баш хәрефтән языла торган Бәгырь белән хушлаша.

Менә әтисе янәшәсеннән колакчын бүрек, пальто кигән җиде-сигез яшьлек малай атлап бара һәм сорый:

—Әти, бу яхшы абыйга һәйкәл куячаклармы?

Чигә чәчләре чалара төшкән әтисе сүзен өздереп, ышанычлы төстә әйтә:

—Әйе, улым, һичшиксез, куячаклар. Берничә елдан соң без синең белән Казанга тагын килербез. Композиторның шәһәр уртасындагы һәйкәленә хөрмәт билгесе итеп чәчәкләр салырбыз!

Халык ташкынына ияреп, театрдан алып зират эргәсенә кадәр тынлы ике оркестр юл буе матәм музыкасын уйный. Яна татар бистәсе зираты. Яңа казылган кабер янына үтеп керешле түгел. Дарчин төсендәге куе кызыл туфрак бүген нинди зур моң иясен үзенең куенына аласын белде микән?.. Табутны кадерләп кенә, сак кына кулдан-кулга тапшыралар. Хушлашу сүзләре әйтелеп беткәннән соң халык телсез-өнсез рәвештә оеп кала. Үзенең сөекле композиторына фәкать тынлык белән хөрмәтен белдерә. Ул көнне театрның җыештыручылары фойеда һәм ишек төпләрендә бер генә тәмәке төпчеге дә тапмыйлар...

Аның кабере каршында күпме инсаннар яхшы һәм гадел булырга дип күңеленнән генә ант эчә. Композиторның үлеме җәмгыятьтәге таза-сәламәт көчләрне аякка бастыра, сафландыра. Әлеге көчләрне хәрәкәткә китерүнең чыганагы—тормышка, табигатькә, кешеләргә карата сәгадәтле сөю, Сәйдәштән күчкән үзгә бер мәхәббәт. Мөлдерәмә андый мәхәббәт Сәйдәшнең күңеленнән җыр, моң, музыка булып ташый иде. Сәйдәшкә, аның музыкасына булган мәхәббәт халыкны берләштерә, руханә туплый, алга дәшә.

Үлем—яңадан яши башлау, халык күңеленә күчә баруның башы гына. Сәйдәшне соңгы юлга меңнәр озатты. Ләкин ул барыбер кешеләр арасында калды.

Композитор—вакыт, заман, юлында очраган көндәшләре белән дуэльгә чыкты. Адәм кыяфәтле шайтаннар белән көрәш алып бару җиңелдән түгел. Ул—туып һәм гомер итеп яшәүнең көчен, бөеклеген бер расласа, инде үлеп һәм гүргә кереп әлеге хакыйкатьнең чынлыгын икенче кат раслады. Сәйдәш болай да халыкның үз улы, газиз бер баласы иде. Үлеме һәм моңнары белән ул мизгел эчендә үзе халыкка әверелә.

Ул—татарның җанын, изелгән рухын уятырга җибәрелгән фәрештә иде. Шуңа да аны күз күрмәгәнчә кадерләп, хөрмәтләп күмделәр, елап хушлаштылар. Сәйдәшнең үткәне, бүгенгесе, киләчәге—бербөтен булып, тамырланып халык бәгыренә тоташкан. Аның җыры, моңнары безне яшәргә һәм хезмәт-иҗтиһатка чакыра.

Кем яисә кемнәр күрсәтмә биргәндер, ләкин халык мәхәббәте фонында үтә ямьсез, аяныч бер хәл килеп чыга: Сәйдәшне күмгәндә, ул ана лаек түгел дип, хушлашудан кинохроника төшерергә дип килгән төркемне кире борып җибәрәләр. Цивилизацияле, үзен-үзе хөрмәт иткән илләрдә мондый

хәлгә юл куелмас иде, әлбәттә.

Композитор васыятен язып калдырмаган. Ләкин ул, бәхеткә күрә, Моабит тоткыны Муса Җәлилнең «Җырларым» шигыренә соңгы көен, соңгы аһәңнәрен язып өлгерде. Бу җыр—көчле рухлы ике шәхеснең җиңелмәс байрагы! Сугышка, гаделсезлеккә каршы нәфрәт белән язылган җыр-бомба! Татар шагыйре һәм татар композиторы—алар икесе дә үзләренең гомер финишына васыять булырдай әнә шундый көчле, аһәңле сәнгать әсәре белән килеп җиттеләр. Бу җыр «Без яшибез, без җиңелмәс халык!»—дип музыка телендә набат суга, чаң кага...

Тормышында күп кенә бәхетләрдән мәхрүм Сәйдәш үзе әнә кешеләргә шатлык-бәхет, көрәш дәрте, илһам өләшә! Бу—аның фидакарьлеге.

Композиторның тормыш һәм иҗат юлында, судан кинәт калкынып чыккандай, гел диярлек Нәҗип Җиһанов фигурасы калкып чыга!.. Ул—Татарстан композиторлар союзы рәисе, Казан консерваториясе ректоры, хөкүмәтнең күп кенә орден-медальләренә һәм мактаулы исемнәргә ия кеше. Кыскасы, музыка дөньясында үзе теләгәнчә яшәр һәм эшләр өчен аның кулына зур мөмкинлекләр, хакимият дилбегәсе тапшырылган. Коеп куйган җитәкче. Бәхәс чыкса, чәүкә карганы яклар, ди. Вазифасы буенча түбән баскычта торганнарның күбесе Җиһанов ягына авыша.

Төрле куштаннар, яраннар тарафыннан һәм, әлбәттә, обком түрәләре күрсәтмәсе белән, Сәйдәшнең милли халыкчан иҗатына Бөек Ватан сугышына кадәр үк күпмедер дәрәҗәдә «табу» салына. Тыштан караганда соңгы елларда аның Җиһанов белән аралары җайлы, ипле генә кебек. Сәйдәш исеменә Җиһанов начар сүзләр әйтми әйтүен. Рәсми тантаналарда ул кайчакны аңа мөлаем мөнәсәбәт күрсәтә, беркатлы тыңлаучылардан алкышлар да яудыра. Ләкин болар асылда—чын ихластан түгел, нибары рольгә керү, битлек киеп уйнарга тырышу. Яшертен яткан аскы агым исә бүтәнчәрәк юллардан ээ яра...

Мисаллармы? Берничәсенә генә тукталыйк булмаса. Композиторның театр һәм радиодагы архивы таркатыла, югалтуга дучар ителә. Аның музыкасы язылган тасмаларны Казансу буена алып төшеп яндыралар. (Эш бүлмәсендә янгын чыгу куркынычы бар, янәсе). Музыка белгече, профессор Мәхмүт Нигъмәтҗановка берзаманны Мәскәү музыка буенча аспирантура ачарга рөхсәт бирә. Моны ишетеп алган Нәҗип Җиһанов шалтыратып аңа болай ди:

—Сәйдәшне өйрәнү өчен аспирант алырга җыенасың, диләр. Кандидатлык диссертациясе түгел, аның өчен диплом эше дә бик тамандыр...

Үз заманының «ханы» С. Батыев, Сәйдәш вафатына сигез ел узганнан соң, зиннәтле кабинетында утырган килеш кенә композиторның исемен «мәңгеләштерү»гә үзеннән өлеш кертә: ягъни Казанның Пелатән төрмәсе тирәсендәге иң ямьсез-тар-пычрак бер урамга Сәйдәшев исемен бирәләр. Композиторның иң якын иҗади дусларыннан К. Тинчурин һәм Ф. Бурнаш кыйналган, газап чиккән, бер хәбәрсез юкка чыккан шушы шомлы төрмә тирәсен сайлап алу, билгеле ки, күрәләтә кылынган яман вә әхлаксыз гамәл.

Батыев моны беркем белән, бигрәк тә Композиторлар союзы рәисе белән киңәшләшми генә үзбелдекләнеп, ай-һай, эшләр иде микән?.. Ике түрә арасындагы әшнәлек «җимеше», искә төшерсәң, әле дә булса күпләрнең җанын-йөрәген әрнетеп тора!

Ялганны, хакимият ныгытмаларын музыка белән генә җимереп буламы? Була икән шул! Салих Сәйдәшев үлмәс иҗаты белән әнә шуны раслады. Сәйдәш рухы, акрынлап булса да, хакимият башында утырганнарның намусын уята алды. Еллар үтә торгач, композитор иҗатына баш иючеләрнең туктаусыз таләп итүе нәтиҗәсендә, Казаныбызның кыл уртасында

Сәйдәшкә, ниһаять, һәйкәл куелды. Башкалабызның яна төзелгән Зур концерт залына Салих Сәйдәшев исеме бирелде. Болар—соңлап булса да дөреслек тантанасының җиңүе иде.

Безнең табаннар астында күпме генә тапталмасын, Җир—барыбер бөек! Шуның шикелле, Сәйдәшне күпме генә таптарга һәм тапларга тырышмасыннар, ул—барыбер бөек...

Үлем—исән чагында танылу тапмаган һәм кыерсытылып яшәгән талантлар өчен Аллаһының иң зур бүләге. Сәйдәш үзенең вакытсыз үлеме белән җәмгыятьнең бер хатасын да төзәтте: күпләр сафланды, тәүбәгә килде, хәтта мүкләнә башлаган түрәләрнең дә күнел һәм маңгай күзләре ачылды.

Ике дөреслек була алмый. Хакыйкать берәү генә булган шикелле, Сәйдәш тә—берәү генә һәм бердәнбер. Татарның моң хәятында, музыкабыз тарихында ул һәрвакыт Беренче булып калачак. Моңа еллар шаһит. Ул яктылыкның караңгыны җиңәсенә ышанды, үзенең музыкасы белән безгә әнә шул хакта сөйләде...

Салих Сәйдәшев дигән шәхес турында бик күпләр әйтеп яки язып калдырган. Менә шуларның барысыннан да иң мөһим сүзләрне, үзәк тамырын сөзеп-сыгып алсаң, композиторга карата мондый төп бәя килеп чыгар иде: «Ул гаҗәеп затлы, ачык һәм саф күңелле, нурлы-иманлы кеше».

Тарих, тормыш шуны раслый: дөнья—полководецларның кылыч чыңын түгел, бөек композиторларның музыкасын тыңлап-ишетеп яши, шуның дулкынында алга бара.

Татар хәятында Тукай, Җәлил, Сәйдәш—өч йолдыз... Алар сөйгән халкы өчен соңгы сулышларына кадәр хезмәт иттеләр, көрәш утында яндылар. Алар өчесе дә чын мәгънәсендә азатлык җырчысы иделәр. Кешенең өч нәрсәгә—иреккә, мәхәббәткә, үлемгә генә хакы бар. Бу сүзләр аларның өчесенә дә тулысынча тәңгәл килә иде.

Әйе, 1954 ел—Сәйдәшнең соңгы елы дип, аның кабер ташына һәм тарих битләренә генә уелып язылган. Ә инде мең авазлы тормышта Маэстроның соңгы елы берничек тә була алмый, чөнки ул калдырган моңнар—мәңгелек! Бер татар шагыйре әйтмешли, Сәйдәш кар-бураннар аша үзенең кара роялен тартып бара. Бурлак сыман. Ә вакытның мәңгелек җамыннан, чайкалып, үлемсез моңнар түгелә...

Бәр, барабан!
Ела, скрипка!
Син, музыка, алга бар шулай.
Нигә безне еллар эргәсендә
Сагыш капкалары каршылай?
Бу—Сәйдәштән калган моңсулыктыр,
Эзәрлекләп килә еллардан.
Мәхәббәт һәм нәфрәт түгеләдер
Мең авазлы нечкә кыллардан...

Әйе, Салих Сәйдәшев өчен киләчәкнең алтын капкалары мәңге ачык. Сәйдәш дәвам итә, үзенең сөекле халкы белән яңа гасыр михрабына таба атлый...

*1999—2009 еллар.*
*Олы Мишә—Казан—Олы Бәрәзә.*

Әхмәт
Гадел



## Табигатькә—сөю җырым...

### I

Урманнарым-тауларым.
Җәнлекләрем—ауларым!
Азмы сезгә яудырдым мин
Күз нурларын—яуладым!

Сез яшәттегез мине,
Бирдегез торыр өйне.
Бүләк иттегез ут-хис:
Буламы яшәү сөйми?

Һәр үләндә җан күрәм,
Һәр чәчәктә көн күрәм.
Һәр агач җанга хәким,
Мин—сезсез үксез-ятим.

Урманнарым-тауларым,
Җәйрәп яткан кырларым,
Күлләрем-болыннарым,
Куышкан колыннарым...

Һәй, минем көтүләрем!
Хәстәрләп йөртүләрем.
Көянтә-чиләк биетеп,
Җан сөйгәннең шәфәкъ буйлап
Чишмәгә үтүләре;
Шул мизгелне күңелемнең
Сабырсыз көтүләре!

Мин урман-тау баласы.
Монда мине бу туфракка,
Бу кочакка аласы—
Җирнең асыл куенына
Хәзинәдәй яшерәсе,
Тамыр итеп саласы!

Әхмәт ГАДЕЛ (1942) – *шагыйрь, прозаик, публицист; дистәгә якын китап («Чам», «Яшьлек урамы», «Чал кылган җыры» һ. б.) авторы. Казанда яши.*

**Без яшәтербез сезне:**
**Һич онытмагыз безне.**
**Ядкәр булсын атыбыз,**
**Сездә безнең хакыбыз.**

**Җилгә яфрак таратып,**
**Кышны-җәйне яратып,**
**Каршылап гөлле язны,**
**Уятып күлне, сазны—**
**Дога кылырсыз, күккә**
**Күтәреп аккош-казны.**

**Урманнарым-тауларым,**
**Үлмәсләрем-сауларым,**
**Мәгыйшәтнең мәшәкатен**
**Эчегезгә каууладым:**
**Күпме сагыш йоттыгыз,**
**Мине ап-пакь тоттыгыз,**
**Арбадыгыз җанымны,**
**Сак иттегез аңымны,**
**Гөлләр белән бизәлгән**
**Сез—яшел бишегемдер,**
**Җилләр—бишек силәсе!**
**Күпме кайгы күрсәк тә,**
**Сездән—шатлык киләсе!**
**Урманнарым-тауларым,**
**Мәңге үлмәс җырларым,**
**Мин киткәч тә чиертерсез**
**Минем сазның кылларын!**

**Күтәрегез җилләрдә,**
**Күрсәтегез илләргә.**
**Күкләр дә укыр рәхмәт,**
**Җирдә ишетер Әхмәт,**

**Хәзергедәй ятлар ул**
**Сезнең моңлы җырларны:**
**Сез мине саклагандай,**
**Сезне мәңге саклар ул!**

**2**

**Ачам күңел ишеген,**
**Уз күңелем түренә.**
**Син бик яхшы кешесең;**
**Күзләреңнән күренә.**

**Әгәр, кунак, кермәсәң,**
**Тормышымны күрмәсәң,**
**Уйларымны бүлмәсәң,**
**Кайдан килер куаныч?!**

**Килче, кил, булып дустым,**
**Сый-хөрмәтем үземдә:**
**Чәй белән вакыт узсын,**
**Ике күзем—йөземдәй.**

**Сүзем—бал зур кунакка:**
**Игелек бу торакта!**
**Димә:—«Яши еракта»,—**
**Ачам күңел ишеген,**
**Уз күңелем түренә.**
**Син бик яхшы кешесең,**
**Күзләреңнән күренә.**

**Син бик яхшы кешесең,**
**Күрәм, сөя беләсең...**
**Тукта! Нигә әле син,**
**Шатлыктанмы, көләсең?!**

**Тукта! Нигә әле син**
**Көлә-көлә киләсең?!**

Миңа моңсу иде бик,
Ә син бик шат икәнсең!

Күпме еллар, булып кош,
Көзге күктә суздың моң...
Чү! Йә, нигә кердең дә
Басып торасың тып-тын?!

Үт түремә, туганым,
Кер кальбемә, җан-ярым?
Син-шатлыкка кушылып,
Эреп акты моң-зарым.

Күпме тотты беләктән,
Кисте сагыш—йөрәктән,
Күпме ярды—турады...

Бездәгедәй тугрылык,
Бердәмлек һич булмады.

Син дә мин! Без бербөтен!
Син дә мин! Күпме көттем!..
Күпме көтте урман-тау...
Көттереп җанны өттең...

Без икәү—ике кунак,
Син миндә, ә мин—синдә.
Язгандыр бергә булмак
Безләргә гомер—илдә...

Язгандыр бергә булмак.
Юк аерылу, юк фиракъ!
Сөйгәнем, назлы иркәм,
Юлыбыз озын-ерак...

3

Син сер, дисең, син сер, дисең—серле йомгак,
Үткәнемә юлларымны җуйдым, дисең.
Чиксез диңгез, очы юк тау, соңы юк юл:
Китмәс итеп серле чикләр уйдың, дисең.

Син үзең дә серле сандык түгелме соң?
Күпме еллар тырышсам да ача алмыйм.
Хәзинәңне үзем белән алып кына,
Сихереңнән—татлы төштән кача алмыйм.

Гөлдән сылу, кайдан индең, әсир иттең?
Күз нурларың кочып алды йөрәгемне!...
Мин юк идем бу дөньяда... Хасил иттең...
Син үзең дә Кодрәтленең бүләгеме?!

Янә җанны минем төрә якты хисем,
Татлы уйлар ала сарып вөҗүдемне.
Синең төсең, синең җылы нурлы исем
Назлап коча һәм тибрәтә күңелемне.

Урман-таулар арасында тик син вә мин,
Җир һәм күкне бөтен итә ак болытлар,
Җаным имин, булыйк имин, Раббем, имин!
Безнең хистә ак күгәрчен—хак саулык бар.

Бу дөньяда булмый икән сөю, без кем?!
Урман-таулар, сихри күлләр—хыялмы соң?
Уйлыйк: тагын, син булмасаң, дөнья ни ул?
Кеше—Кеше, ягъни инсан буламы соң?!

*2009. Иске Казан.*



Ленар
Шәех

## БЕР КӨЛӘЧӘК ӘЛЕ КОЯШ ТА...

* * *

*(Габдулла Тукай яшәгән «Болгар» кунакханәсенә мәрсия )*

**Хуш, исән бул, Тукаемның**
**Җанын саклаган бина.**
**Ятимне—бөек шагыйрьне**
**Кире какмаган бина.**

**Йөрәктәге тирән ярам**
**Бәлкем, бер төзәлер дә...**
**Тик кем генә җөрьәт итте**
**Сиңа кул күтәрергә!?**

**Кем уйлаган шагыйрь хакы**
**Булыр бары чүп диеп:**
**Тукай өчен—изге бина**
**Артык диеп, күп диеп?!**

**Ятим җанын дәваларга**
**Ул сиңа ишек каккан.**
**Тукайның әнисе бит син,**
**Ул синдә оя тапкан!**

**Якты бүлмәләр эчендә**
**Күпме шигырь тугандыр...**
**Акшарланган диварларны**
**Илаһи моң югандыр.**

**Хуш, исән бул, Тукаемны**
**Үз иткән изге бина.**
**Дога кылырга теләсәм,**
**Мин килә алмыйм сиңа...**

Ленар ШӘЕХ (1982)—*шагыйрь, публицист; «Авылдан килгән мендәр», «Дүртенче кат... Бишенче кат...», «Керпе ничек энәле булган?» исемле китаплар авторы. Казанда яши.*

Син юк инде, изге «Болгар»...—
Милләтем, бу нишләвең?..
Сине уятырга теләп,
Иренемне тешләвем...

## Ага-базар

Ага-базар, ага базар,
Гүя утлы таба-базар...
Әби-карчык күп йон язар,
Оек бәйләр, ак шәл бәйләр,
Үтәр язлар, үтәр җәйләр...
Ә хатыннар ак май язар,
Сөт өстедән әйрән сыгар—
Ап-ак икмәк, кымыз чыгар!..
Карт бабайлар тәнен язар,
Арба ясар, чана ясар,
Итек тегәр, ката басар...
Ә ир-атлар канын язар,
Тимер чүкер, кылыч ясар—
Мичен ябар, мичен ачар...
Ямь-яшь кызлар сөю язар,
Мендәр эшләр, чигү чигәр—
Аһ, уңганнар!.. Нинди чибәр!..
Яшь егетләр сөяк язар,
Ат чаптырыр, колын карар,
Ары чабар, бире чабар...
Сәүдәгәргә бәхет язар,
Бәрхет, ситса, ефәк кенә,
Гүя йомшак түшәк кенә...
Пешкән җимеш, кипкән җимеш,
Аша юып, шушы килеш.
Яңа күлмәк, яңа ыштан—
Кисәң, яза күрмә һуштан.

Ага-Базар, ага базар...
Иске базар, яңа базар.
Алыш-биреш, сату-алу,
Учка алтын, көмеш салу.
—Бер алтынга...
—Унбиш көмеш...
—Ярый, алам шушы килеш...—
Ыгы-зыгы, сатулашу,
Шау-шу гына, татулашу...

Һәр көн саен ага базар...
Тарихчылар тарих язар...
Киләчәккә соң ни язар?..
Ага-Базар, ага базар...

* * *

Борылам да карыйм үткәннәргә—
Нәрсә калган дисең, нәрсә калган?..
Кемдер анда мине талбишектән
Җылы, назлы кулларына алган.

Борылам да карыйм үткәннәргә—
Нәни малай уй-йокыга талган.
Яфрак кадәр генә учларына
Йолдыз нурын, ай яктысын салган.

Борылам да карыйм үткәннәргә—
Үсмер малай чаба урамнардан.
Әле генә җәйгән ташлы комнан,
Әле генә яуган ап-ак кардан...

Борылам да карыйм үткәннәргә—
Егет бара серле томаннардан...
Аңа карап, юлның чатларында
Җылы куллар яулык болгап калган.

Борылам да карыйм үткәннәргә—
Ә үткәннәр уй-йокыга талган.
Чабып барам яңа яуган кардан...—
Нидер калган анда, кемдер калган...

* * *

Мин ышанам: бер киләчәк әле,
Бер көләчәк әле кояш та.
Шат нурларын бөркиячәк әле
Бар дөньяга, җиргә ул башта.

Кайгыларны бер юачак әле,
Бер туачак алсу таңы да.
Болытларны ул куачак әле
Ак офыкның чиксез ярына.

Мин ышанам: бер киләчәк әле,
Бер көләчәк әле безнең көн.
Җанга җылы бөркеләчәк әле,
Барлык җаннар булып бербөтен.

Әйе, шулай, өметләнәм әле,
Көн бетмәгән әле безгә дә.
Кояш нурын киметмәгән әле,
Болытларны кире эзләмә!

Мин ышанам: бер киләчәк әле,
Бер көләчәк әле язмыш та.
Бөтенесе бер күрәчәк әле,
Изрәп-оеп татлы сагышта...

* * *

Эх, бер мәл рәхәтләндереп
Шигырь язасы килә!
Кәгазь буйлап каләмемне
Шыгырдатасы килә!

Эссе көнне сискәндереп,
Яңгырын яудырасы,
Йә булмаса, кар көртләрен
Чиләгә аударасы!..

Нәни генә күлләвекне,
Эх, дулкынландырасы...
Эсседән туң йөрәкләрне
Ялкында яндырасы!..

Барлык кайгы-борчуларны
Иделдә агызасы,
Моңсу көннең уртасына
Шаян нур тамызасы!..

...Эх, бер мәл талгын вакытны
Бер тизләтәсе килә,
Бар дөньясын, каләм белән,
Мең үзгәртәсе килә!
Мең үзгәртәсе килә!..

* * *

Урам тулы бомж этләр, бомж кошлар,
Алар ничек төн үткәрер, ничек кышлар?

Хәер эстәп утыралар тукталышта.
Каурыйлары һәм йоннары лычма, лычма!

Кем ни бирә, риза булып йөри алар,
Әкрен генә койрыкларын сөйри алар.

Күпләр бүген күңелләрен бикләгәндер,
Мәрхәмәтле җаннар әле бетмәгәндер...

Зур йөрәкләр, киң күңелләр кая калды?..
Яшәешне салкын тынлык камап алды,

Боз катырды тәрәзләргә, кояш үтми,
Игелек йомгагын никтер беркем сүтми...

Урам тулы бомж кошлар, бомж этләр...
Кемнәргәдер якын алар, кемгә—читләр...

Һәрнәрсәгә була ахыр, була чикләр.
Болай барса, Ходай үзе Җирне бикләр!..

* * *

Яз бавының очы югалган,
Эзләп карыйм микән Уралдан?..
Йолдызларның нуры кимегән,
Эзләп карыйм микән Иделдән?..
Карурманның шомы сүрелгән,
Сорап карыйм микән бүредән?..—
Җидегән чишмә ага тамчылап,
Ал шәфәкътан яңа таң сорап...

* * *

Безгә кадәр яшәгәннәр,
Бездән соң да яшәрләр.
Дөнья туктаусыз картая,
Дөнья һаман яшәрә.

Пушкинны күргән наратлар[1]
Иелгән җиргә таба—
Ике йөз ел уен эшме?—
Вакыт чаба да чаба...

Урал тавы авыр сулый—
Ул да иңеп барамы?..
Алда билгесезлек ята,
Киләчәк кап-караңгы.

Искелеккә алмаш—яңа,
Картлыкка—яшьлек атлый.
Кояш кына бу галәмдә
Никтер буын яңартмый.

Үткәннәрне себерәбез
Һәм чүплеккә түгәбез.
Җан асрарлык акчабыз бар,
Нәни генә түбәбез.

Җимерәбез... Киләчәктән
Нәрсә диеп дәшәрләр?—
Безгә кадәр яшәгәннәр,
Бездән соң да яшәрләр!..

[1] Пушкиннарның Михайловское биләмәсендәге нарат аллеясы турында сүз бара.



Алмаз Хәмзин

# КЫРЫК СИГЕЗ КИЛО

ХИКӘЯ

Төшкә таба көн сүрәнләнә төште. Озак та үтмәде, инде ничә көн буе кызып төссезләнгән һава дымсуланып китте. Әллә каян гына җыелган болытлар күк йөзен каплап алды һәм ... келтерәп янгыр ява башлады.

Сәрви карчык үтил складын бикләп, тиз генә өенә йөгерде. Кибәргә элгән керләре ишек алдында калган иде.

«Шактый каты явар, ахрысы, өлгерә алсам ярар иде»,—дип өзгәләнде ул һәм бер күккә, бер алдына карап, эре янгыр тамчылары астында турыга бәрде. Ике ара якын гына, адымлап чутласаң, йөздән генә артыр. Менә инде ул капкага да килеп бәрелде, этеп, төртеп карады, бикле булып чыкты. Тик аны бикләгәнен хәтерләми. Әйе шул, иртәдән бирле склад ишегеннән капкасына карап утырды, килүче-китүче сизелмәде. Нишләргә инде? Астан керсен микән?

Ул капка астындагы аркылы тактаны суырып алырга маташты. Булмады.

Байтак кына җәфалангач, үзенең инде тирләп тә, чыланып та манма су икәнен абайлап алды.

«Ача алмам тиз генә, булмас,—дип кире складына йөгерде.—Кибәрләр әле, көн озын!»

Байтак утырырга туры килде аңа ышыкта. Бер көчәеп, бер әкренәеп яуды да яуды. Жылы янгыр, рәхәт янгыр...

Чыр-чу килеп, аяк киемнәрен кулларына тотып ялан тәпиле балалар йөгерешеп үтте. Әнә, куе яфраклы тал астында, яңгырдан ышыкланып, ап-ак күлмәкле ике кыз утыра. Ачык склад ишегеннән бөтенесе күренә Сәрви

Алмаз ХӘМЗИН (1947)—*язучы, җырчы; күпсанлы популяр җырлар, «Озак яшисегез килсә» исемле китап авторы. Казанда яши.*

карчыкка. Анын да шулар кебек яшь чаклары бар иде. Сылу, чибәр, алма кебек иде бит. Бер кайгысыз, мәшәкатьсез көннәре кая сон анын?..

Чүәкләрен салып, яшел чирәм өсләреннән йөгереп үтәсе, кочакларын җәеп, онытылып су коенасы, су чәчрәтәсе, коеп яуган җылы яңгыр астында калып чыланасы, йомшак тамчылардан назланасы килде. Беразга гына булса да мизгелгә генә яшьлеккә кайтып, тагын бер мәртәбә чәчәкләрне үртисе, Зөя суларына ятып чәчләр үрәсе иде.

«Ярый әле син бар, хыялым! Син—минем канатым, җилпим исә—кайтам туган якка, кунсам инде—утырам шушы карангы складта»,—дип чүпрәк өемнәре өстенә җайлабрак урнашты да, сырган бишмәт эчендә йокымсырап китте. Күз алдына әлеге ике кызнын ак күлмәге чалынды, әле су өстендә кояш нурлары уйнаган кебек булды һәм шул су кинәт кинәеп, шаулап аккан зур елгага әверелде. Еракта, нокта кадәр генә ак әйбер очына. Менә ул якыная. Күбәләк түгелме? Әйе, әйе, ап-ак күбәләк. Ул һаман килә, ул кеше кебек көлә-көлә канатларын җилпи. Менә инде узып та бара! Кинәт ул өермә ясады, эчендә бөтерелде-бөтерелде дә ак күлмәкле кызга әйләнде, комлы сөзәк ярдан алга йөгерде. Кем булды бу? Үзе түгелме сон? Әйе шул, җилбәзәк кыз—Сәрви!

Менә ул Зөя ярлары буйлап йөгерә, су эчәргә төшкән атларны, казларны өркетеп үтә. Өскә күтәрелә, әрәмәлек арасында югала. Ул юри егыла, куе үләндә ауный, кычкыра-кычкыра көлә. «Ачуыгыз киләме?.. Ачуыгыз киләме?.. Ул матур, ул авылда, юк, авылда гына түгел, бөтен Тау ягында ин чибәр кыз! И-ше-тә-сез-ме!.. Карагыз әле, карагыз, күпме чәчәк бу аланда! Нинди матурлар! Юк, араларында ин матуры мин! Мин, мин! Шулаймы, тал? Әйтегез, болытлар! Ин матур чәчәк бу аланда мин бит?!»

Зәңгәр күктә ак мендәрләр кебек салмак кына болытлар агыла. Алар ана: «С-и-и-н!»—дип җавап бирәләр кебек. Ул күкрәгенә чәчәкләр җыя, очып-очып аларны күккә чөя. «Мин! Мин—ин гүзәле!..»

Күнелендә туган рәхәт тойгылардан ул күзен ачты, складта гына утыруына төшенгәч, көрсенеп куйды.

Кая сон ул рәхәт вакытлар, җәннәт көннәр? Әкияттәгедәй яшьлегем кайда минем? дип күгәргән тупас иреннәре ярым пышылдап, дерелдәп куйды. Әй, ул вакытлар, бәгырьләрен телгәләгән заманнар...

Авыл табигате ямьле дә инде, җанга якын. Сукмак буйларын һаман да тигәнәк, читән кырыйларын кычыткан баса торгандыр. Мәрьям тыкрыгыннан төшкәч, Зөя аркылы озын басма һаман бар микән? Ындыр артындагы алачыктан ишетелгән чүкеч тавышлары хәзер бер мон булып колагымда чыңлый. Нигә элек яратмадым икән шунын чынгылдавын? Йөрәгемне бертуктаусыз чүкеч белән кыйныйлар төсле иде. Безнен әтинен таш амбары булган ул алачык. Шау-шулы вакытларда кулак диган булып талап чыкканнар.

И әтием, кай җирләрдә ятып калган икән синен гәүдәләрен? Син исән булсан, болай булыр идеме минем язмышым?!

Хәер, ул ни эшли алган булыр иде инде? Бөтен дөньясы каршы иде бит ул чакта безгә. Ә кызынның буш башында җилләр шаулый, күнелендә сәмруг кошлары очкан инде. Сөбханалла, хәйран гына яшәп ятам бит әле менә! дип карчыкларча тискәре уйлап куйды ул кисәк. Йортым бар, Аллага шөкер, эшлим әле, пенсиясе килә, кеше кулына калганым юк, калырга язмасын! Йортым агач, иске булса да эчләре шәһәр фатирыннан калышмый. Стеналарын Вьетнам обое белән тигезләп ябыштырган, шау чәчәк арасында утырам. Кышын миченә бер ягып җибәрсән, тәүлек буе май эчендә йөзеп йөргән кебек. Урамга караган дүрт тәрәзәмнен пәрдәләрен генә күрсән дә, «аh» итәрсен! Алагаем зур ике келәмне йә стенага эләм, йә

идәнгә җәеп рәхәтләнеп ауныйм. Зөя чирәмнәрен бер кырыйда торсын! Ике айга бер «Газым бетте, китереп ыргытсагызчы, җаным,»—дип автоматтан яки яшелчә кибетеннән шалтыратсам, шул җитә. Газ баллонының самавыр кәмфәркәсе кебек капкачы эченә берлегенне тыгып куясың да, шуның белән эш бетә. Газ таратучыларның йөзе акчаны күрү белән балкып китә, йөгереп кенә йөриләр« Апа, сиңа шыплап тутырганны калдырабыз, менә, сайлап алдык»,—дигән булалар. Шулай итмәсәң, бер айга да җитми кайчагында, тыны чыгып бетә. Хәзерге вакытта акча бөтенесен эшли. Бигрәк тә аракы яшәсен! Бер яртыга гомерен бирергә торган кешеләр буа буарлык бит хәзер. Әнә Гаиф күрше: «Сәрви апа, утыныңны турыйсы юкмы?» дип кенә тора. Нәрсә кирәген беләм инде мин аңа. Электр пычкысы белән керә дә, үтилдән җыелган әрҗә, такта кисәкләрен турап та бирә. Менә сиңа бер яртылык эш. Шул коры-сарыны ягып җып-җылыда кыш үткәреп чыгам бит әле.

Кырын ятып телевизор карыйсын кем уйлаган аны ул вакытларда. Шушындый тормышка каршы торганбыз бит ә?! Театр, кино карап ятабыз бит диванда җәелеп! Никадәр гыйбрәтле хәлләр күрсәтәләр!

Ә менә «Зәңгәр шәл»дә муллалардан көлү артыграк. Алай дисәң, безнең авыл мулласының да өч хатыны булган түгелме соң? Хәер, аларның ул вакытта ни эшләп йөргәннәрен, ни кыланганнарын кем белгән? Менә яшьләрнең уен-җырлары дөрес. Шулай кич-кырын чишмә буена җыелырлар иде. Икешәр рәт тезелешеп, кулга-кул тотышып, түгәрәк ясап, җырларлар, гармунга типтереп биерләр иде.

Аның белән егетләр нигә йөрмәде икән? Хәер, ул—сәер кыз, ул—кулак калдыгы, аксөяк, эш сөймәс, кеше сөймәс булып үскән. Әйе, ул чәчәкләр үртәп үсте. Тузганаклар тузгытып, аның ак өермәсен куып йөрергә ярата иде. Аның яшьлеге тузганак кебек. Кулга алмас борын таралырга торган ак бүреген өреп, һава дулкынында очкан тузганак серкәседәй яшьлеге очты аның. Тау ягы кырларыннан, урманнардан, офыклардан узып, еракларга очты. Ак яшьлеге очты, чиксез киңлекләрдә агылып йөреп түбән төште, башка иңкүлекләргә кунды һәм анда үскән матур, утлы чәчәккә әверелде. Ләкин ул чәчәк үзен чәнчеде, ул котылырга теләп чәбәләнде, өзгәләнде, ниһаять, ычкынды. Котылуына сөенеп бер ышыкта хәл алды.

Көтмәгәндә коеп яңгыр яварга тотынды. Аның күп санлы тамчылары көчле ташкын ясап бу ышыкка да ургылып керде. Ул чыланды, тузганак серкәсенең ак күлмәге җебеп, пычранды, ул төпкә батты. Ә төптә, җирнең җылы сулышын сизеп, аңа елышты, йомшак юрганына күмелеп ятты. Ташкын китте, ул аны югалтты. Офыктан биеккә күтәрелгән кояшның ягымлы нурлары аны эзләп тапты, тәнен җылытты. Ул да кояшны, зәңгәр күкне күрергә теләгәндәй җирнең юрганын ачты, куллары, аяклары белән өскә үрмәләде, яктылыкка калыкты.

Хыялларына бирелеп байтак оеп утырган Сәрви җәһәт кенә сикереп торды. Ишек төбенә ургылып килгән һәм килеп җитәрәк склад астына юл ясап өлгергән яңгыр ташкыны әллә кайларга алып киткән бит аны... Чыннан да, кысылып калган чыбыкка ниндидер мамык бөртеге ябышкан, аны яңгыр тамчылары талый, аска таба төртеп төшермәкче була. Ул кычкыра, ярдәм сорый кебек. Сәрви карчык каткан буыннарын турайтып, калтыранган кулы белән мамыкны алды да, нәрсәнедер белергә, танырга теләгәндәй, җентекләп актарырга кереште. «Юк, бу тузганак түгел икән,»—дип уйлапмы, юеш мамыкны бер читкә, корырак почмакка ташлады.

Башы әйләнәме соң? Әйе шул, җинелчә генә башы шаулый икән. Әллә теше сызлыймы? Әллә баш шуңа чынлыймы икән? Алдырып атасы бер-ике теш калды, шулар йөдәтә инде. Аларын да алдырсам, ясалма авыз гына куйдырасы кала. Бу алтын тешләре дә туйдырды. Ризыкның бер тәме юк,

билләһи, әллә чәйнәп ашыйм, әллә болай гына йотам. Кан басымын да даими түгел диләр. Ничек бертөсле булсын инде ул. Тимер дә күгәрә. Рәхәт кенә яшәп ята дип беләләр бугай, яшәрсен бу балалар белән!..

Ул хәлсезләнеп, тагын да ныграк башы әйләнмәсен дип, складның калай стенасына сөялеп торды. Күзләрен йомып бу шаукымның үткәнен көтте һәм бераздан чүпрәк капчыкларын, мендәрләрен як-ягына төрткәләп, кабарткан кебек йомшартып өстенә утырды.

«Нәрсә эшләдем соң әле мин бу араларда? Картайдым бугай... Болай бер дә булмый торган иде. Җитмешнең өске ягында шул инде хәзер. Әй, гомерләр...

Әнә үзем кебек йортым да, капкасы да... Ир кеше кулы тими шул аларга, ир кеше кулы. Үткән ел гына буяткан идем югыйсә, кыекларына кадәр. Икесе ике төсле булмасын дидем, капкасы да яшел төстә. Каен агачлары арасында гөл кебек утыра иде бит әле үткән ел. Әле бер генә кыш чыктык, әйтерсең лә гомер буе кеше кулы тимәгән ул такталарга. Буяулары ярылып-яргаланып, купшакланып, төссезләнеп элеккеге иске хәленә кайткан.

«Бик яхшы буяу, ал, Сәрви апа!»—дип үгетли-үгетли бирде бит әле шуны Таифә.—Башкага түгел, үземә дип калдырганы»,—дия-дия кибетнең артына качырып чыгарып җибәргән булды.

Нәфсесен сузып килмәсме әле үзе минем янга, банка өсләре, чит ил порошоклары сорап. «Хозяйственный магазин»ның башлыгы дип тормам, суланып каткан порошоклар тыгып җибәрермен. Мин дә тәмле телләнә беләм. Сүз эзләп кешегә кергәнем юк. Бик кәефемә туры килмәсә, кире борып та җибәрергә күп сорамам. Аның белән бала чукындырасым юк. Буяусыз да торырмын әле. Бүтән кибетләр дә бетмәгән. Әле бу тирәләрне сүтәләр икән дигән хәбәрләр дә йөри. Ремонт ясап расходланасы юк. Түбәсен дә буятмыйм, көтеп торсын. Ай, әйбәт тә булыр иде сүтсәләр. Берүземә аерым бүлмә бирсәләр, котылыр идем...

Аның күңеле тулды. Калтыранып әйтелгән соңгы сүзләреннән соң йомшак күз яшьләре менә чыгам, менә тамам дип, салынып төшкән күз кабакларында бераз туктап, бүселеп торды да, коелып төште. Ул аларны тыймады. Күрер кеше юк, ул үзе генә. Бер рәхәтләнеп елый алганы да юк.

Сәрви бишмәтен ике кулы белән тәненә тыгызлабрак тартып куйды, алгарак иелде. Бәз халатына тамган күз яшьләренең ничек сеңеп югалганнарын бик озак карап торды.

Нигә соң әле болай жебеп утыра, кем аны мәҗбүр иткән балавыз сыгарга? Аның хәтәррәк вакытларда да күз яше чыгарганы булмады ләбаса... Нишләде соң әле ул бүген?

«Сүтсеннәр иде тизрәк, бакчасын да кызганмыйм, пенсиям үземә җитеп барыр иде әле. Нәфеснең чиге юк! Тамак тук булсын, кеше төсле яшим дип үләргә вакыт җиткәнче көчәнергә димәгән, җитәр! Начальник: «Әллә пенсия акчасына гына яшәп ятарга уйлыйсыңмы, Сәрвитти, ашыкма! Менә яңа склад салырга уйлап торабыз, рәхәтләнеп эшләрсең!»—дигән була. Миндәй карчыктан нинди эш инде? Хәер, минем кебекләр генә эшләмәсә, бу консервы калаенда утырырга, чүпрәк-чапрак, тимер-томыр, калдык-постык җыярга кем килсен. Яңасын төзесәләр, кешесе бәлки табылыр...

«Юк, юк, җаным, рәхмәт тәмле сүзең өчен, олылап сөйләшеп торуың өчен бик рәхмәт»,—дигән иде ул ана.—Ял итәм, бик көтеп алган ялым, рәхмәт. Нервыларымны рәтлисем бар, ату бернигә ярамый башлады. Югыйсә бетерәләр мине болар. Вакытсыз гүргә илтеп тыгалар»,—дип соңгы сүзләрен авыз эченнән генә мыгырдады.

Син бигрәк бәгыремне ашыйсың, Зәйгүрә! Үзем сайлап кушкан исемен үзем яратмыйм. Әйтү түгел, искә дә аласым килми, билләһи. Киләсенне

белсәм, күңелем кителә башлый, гәүдәнне күрсәм, коелып төшәм, калтыранам. Гөнаһ шомлыгы бит. Күрәсем дә килми. Аждаһа, билләһи! Йә, шуңа ни әйтерсең?

Янәмәсе, мин әтисен җәберләп, кимсетеп, изеп яшәгәнмен. Аны кол шикелле итеп тотканмын. Алтын-көмеш җыйганмын, өйгә хрусталь ташыганмын. Мин кешеләрне алдаганмын, имеш. Киемнәренең, тамагына кергән ризыгының каян килгәнен белми ул. «Ташыма, урлама!»—дип әйтүе җиңел. Тормыш син уйлаганча гына бармый. Төрле чаклар була. Алдагысын күрә белергә кирәк!

«Әнә, күрше-күлән сиңа бармак төртеп күрсәтә, имеш. Төртсен, аларныкын тартып алмыйм. Яши-яши аңларсың әле. Колагыңда ялтыр-йолтыр алтын алкалар, бармагыңда төрле төстәге серле кашлы йөзекләр балкыгач, үзгәрерсең әле. Башка төрле сайрарсың! Күрербез! Алтын-көмешнең тылсымын белмисең әле син!»—шулай дигән иде ул, Зәйгүрәсе җиткән кыз булып үсеп килгәндә...

Чыннан да үзгәрде Зәйгүрә. Ләкин бу хәтле үк зәһәр булып үзгәрәсен Сәрви башына да китермәгән иде.

Үз балам бит, үз балам! Кемнең шулай булганы, мондый хәлгә төшкәне бар? Соңгы сулышым: «Миңа хәзер җан бирәм», дисә дә авызыма бер тамчы су салмаячак бит ул. Врач инде, шул, дару сорасаң «Дөмек!»—дияр. Миннән калмас, мин яшисен яшәгән, миңа син ни кырырсың икән бу дөньяда? Синең дә балаң бар, үзеңнең дә рәхмәт ишетәсең килер. Әмма, көтмә! Ишетмәссең син аны! Алма агачыннан ерак төшми, бел! Синең рәхмәтең миңа шушы булса, аның рәхмәте сиңа тагы да ачырак булыр әле. Миңа язмыш өч пот тоз ашатты. Ә сиңа күбрәк эләгер ул...

Сәрвинең тамагына тозлы төер килеп тыгылды. Борчулары, хәсрәтләре, барлык газаплары тулып укмашкан төер. Күңел төере. Ул зурайганнан зурая барып, алагаем шарга әверелде, авырттырды, тырнады. Әле генә үпкә катыш тиргәү, ачу тулы хәлдә кызышып утырган Сәрвинең тәненә салкын тир бөркелде. Атылып чыккан яшь бөртекләре җыерчыклы бит өстендәге тир тамчылары белән кушылып аска тәгәрәде, иреннәрен әчеттерде. Сәрви ашыгып-кабаланып төкерегән йотты, йөзен чытып быгырдап куйды. Аннан калтыранган куллары белән күзен сөртергә керешә. Үзе һаман бертуктаусыз кабатлады: «Күрмәгәненне күрсәтер әле сиңа кызың. Андыйлар инде күптән эшләп ашый белә, бот күтәреп: «Ашарга пештеме?»—дип акырып кына ятмый.

Тузанлы тимер-томыр, чүпрәк-чапрак өемнәре арасында үзалдына сөйләнеп, чыгырыннан чыгып утырды да утырды ул. Ә инде авылыннан качып киткәндәге хәлне искә төшергәч, тагын да ныграк ярсыды: «Юк, юк, берегезне дә күрәсем килми, бе-ре-гез-не дә. Әнине дә, Зәйгүрәне дә. Газапламагыз мине! Миңа моннан, муеннан, тәмам гарык булдым. Чәнчелеп китсен дөньягыз, йә Алла»...

Ул саташып, тыз-быз, үзен-үзе белештермичә склад буйлап йөрергә тотынды. Шифр түбәгә шаулап яуган яңгыр һәм әле генә исеп куйган җил ярым караңгы чүпрәк складын дөбердәтеп, тау куышында төрле җанварлар чинаганын, еланнар ысылдаганын хәтерләтте.

«Качам, китәм еракка, бөтенләйгә. Эшләмәячәкмен, үлсәм дә бүтән эшләмәячәкмен, мәңге»...

Ул яшьлеге белән буталды, саташты, әллә ниләр кыланды. «Атсалар да!» Кисәк аяк астында аунап яткан янчек сары самавырга абынып, иске паласлар өеменә барып төште. Тора алмый чүпрәкләр белән әүмәкләште, арага әнисеме килеп буталды, чәбәләнеп аннан арынды, аны куды. Ул китте. Ул томаннар арасына кереп югалды. Куллары сузылган, тузган

чәчләре белән йөзе капланган иде. Үзе бертуктаусыз кабатлый: »Нишләвен бу, кызым, нишләвен?! Китмә, таш-ла-ма-а-а!»

Урамда, склад янында гына, сулы чокырга батып ниндидер машина көчәнә, алга-артка атынып, гүли. Идән астында чылтырап гөрләвек агышы ишетелә. Складның ерагырак почмагында, карангыда, күселәр бугай—чыйныйлар. Ояларына су төшкән, күрәсен.

«Өнемме бу, төшемме?»—дип Сәрви карчык үзен үзе капшап карады. Сөйләнә-сөйләнә егылган урыныннан торды. Таптанып, әфсен-тәфсенен укыды. Ачык ишеккә карады—янгыр һаман ява икән әле.

Ул чагында да менә шулай янгыр яуды. Төне буе яуды. Ләкин ямьсез янгыр иде ул. Көзге янгыр кебек җилләп, бер туктаган булып, бер коеп, алдап. Чыланып хәлсезләнгән тал ботакларының тәрәзәгә кагуын бик озак күзәтеп ятты Сәрви ул төнне. Асылынып тал очларына хәтле төшкән сөйрәлеп баручы шыксыз болытларны үтеп, иртәнге яктылык нурлары беленүгә ул ишек алдына чыкты. Янгыр һаман сибәли. Өйдәгеләр йоклый иде. Көрәк алды да, бердәнбер тикшерелмәгән җирне—сарай базын актарырга керешге. «Кайда гына булырга мөмкин сон ул?»...

Бар бит ул, бар! Өйдә юк, түбәләрнең тикшерелмәгән җире калмады. Мунчаны әйләндереп кенә ыргытмады. Ындыр артларындагы, су буендагы агач, багана төпләрен жентекләп капшап узды. «Кая күмелгән, кая?»

Башы чатный, бер ноктага бәреп, зенгелдәп тора. Сорау саен мен билгесезлек. Ул ярсып базның әле бер, әле икенче почмагына атылды. Каян туры килде, шунда казынды. Казыды да казыды. Бераздан көрәге нәрсәгәдер тиеп шыгырдады түгелме? Ул шыкырдау бөтен тәненә таралды, ниндидер бөҗәк-кырмыскалар күлмәге эченнән йөгереп үтте. Бите, бөтен тәне янды. Ул хәлсезләнеп янә сыгылып төште. Бераз хәл алды да, шашып, салкын үзле балчыкны кулы белән казырга кереште. «Менә ул, менә ул, жан көеге!»

Базнын карангыланып китүен һәм өстенә кара шәүлә каплануын сизсә дә, ул ашыкты. Томырылып төшкән гәүдәгә шашкан, котырынган эт шикелле тешләрен шыгырдатып, тырнакларын киереп ябышты. Ынгырашу, тарткалашу, дөм карангыда әүмәкләшү күтәрелгән тузан белән буталды. Зиһен мидән генә түгел, баздан ук чыгып качты. Үткен тырнаклар белән сыдырылган ул шәүләнең бите коточкыч хәлдә. Туфракта әвәләнеп, инде бераз күнегеп килгән карангылык арасында куллары белән битен каплап улый, юк, ул елый, нидер үтенә, аңа таба кулларын сузып, ялвара: «Нишләвен бу, кызым, нишләвен?»—дип бертуктаусыз, өнсез кабатлый иде. Күпме еллар үтеп бер ташламады аны шушы караш, гел искә төште, гомере буе җанын телде, ээзәрлекләде. Көн карангылана башласа да, җил котырынып баганалар уласа да, дөбердәп янгыр килсә дә ул үтил складында утырып калырга курка иде. Тимер склад сәер капчыгына, каранғы базга әверелгән кебек, төрле җиренә яшеренеп сөйләшкән тавышлар ишетелә башлый, әллә нинди шома кыллы кара җанварлар ялт итеп үтеп китә, түр почмагында куркыныч кыяфәттә утлы күзләр пәйда була. Кисәк аяк асты убылыр да ул каранғы базга егылып төшәр, ә анда аны һаман әнисе шул соңгы сүзләрен кабатлый-кабатлый, кулларын сузып көтеп торадыр кебек.

Умырылган күлмәк итәгенә чүлмәген төреп чыгып качканнан бирле кайтканы булмады Сәрвинен. Көннәр, айлар, еллар—шулар белән гомер үтә торды. Кеше язмышында ясалган авыр җәрәхәтләр вакыт дигән нәрсә белән буталып тигезләнә, яки башка яңа яралар белән каплана икән. Тик ул онытылды дигәч тә яналары өстәлгәннән соң кабат уянып, өздереп сызлап куя. Эндәшмисең, ынгырашмыйсың, түзәсен. Шулай яңа авыртуларны

сыкранмыйча, күрсәтмичә эчтән үткәреп җибәрергә тырышасың. Ә ул һаман җыела, туплана икән.

Әнисенең соңгы көннәре хакында ул сеңлесе Тәслимәдән белде. Акылдан шашкан икән, мәрхүмә.

«Урының оҗмахта булсын, кайтып бер уч туган җир туфрагы да сала алмадым шул каберенә, әнием, бәгърем»,—дип елады Сәрви Тәслимә алдында. Килештереп елады, үксеп-үксеп, күз яшьләре белән. Ләкин аның авылына кайтыр юллары киселгән шул, ялганмаслык булып, мәңгегә өзелгән. Тәслимә исә әнисен җирләгәч Казанга килеп эшкә кергән. Бөтен дөньяны куптарып Сәрвине эзләткән. Тапкан. Аның да Казанда яшәвен белгәч, янәмәсе, бик сөенгән. Шуннан ары әниләре турында бер-берсенә һичкайчан да сүз кузгатмадылар, алар аны оныттылар...

«Яңгыр ява да ява... Бүген туктамас, ахрысы,»—дигән уңайдан монда килеп төпләнүләрен уйлап алды Сәрви карчык. Күпме ят-җир күрергә, юл йөрергә насыйп булды ана. Тормыш үзенекен итте, ничек кирәк шулай бөкте, сыкты. Сәрви мәхәббәт өләшеп йөрүдән туйды, яхшы чакта, үзе әйтмешли, артык соңга калганчы, кияүгә дә чыкты. Паровоз йөртүче Ясәвине эләктермәсә, белмим, кайларга алып киткән булыр иде әле аны тормыш юллары?!.

Ясәви юаш кеше булып чыкты. Алар Казанда йорт салдылар. Һаман да шул йорт әле ул. Бераздан кызлары туды. Исемен «Зәйгүрә» дип куштылар. Ясәви гаиләдә анда-монда бер күренеп, песи кебек кенә йөри бирде, күп нәрсәгә катышмады. Сәрви эшләсә эшләде, эшләмәсә эшкә урнаш дип кыстамады. Сәрви алтын-көмеш юнәлтү белән шөгыльләнде, бәллүр савыт-саба белән кызыксынды, бөтенләй таралып бетә язган байлыгын тулыландыра башлады. Ире хезмәтенә байтак җыйды ул хәзинәләрне. Менә бу алагаем колак алкасы да шул вакытта алып калган әйбер. Эшкә киеп йөри торган йөзеген тагын бер кат капшап, барлады. Суконный базарыннан ярты бәягә алган иде аны. Кашлы. Кашы зәңгәрсу төстә. Күзе яхшырак күргән вакытта караштырып, хыялларга чумып утыра торган иде дә бит, картайгач ярылып тупасланган бармаклары белән әллә ни сизеп тә булмый шул.

Әй ул заманнар... Бер генә дә вакытым юк иде, бер генә дә. Әле монда чабам, әле тегендә. Әле монысына керәм, әле тегесенә: килешәм, ызгышам, сатулашам. Дога ятлап утырырга вакыт булдымени миңа?—дип үз-үзен аклап куйды.—Юк, юк, мина рәхәт тәтемәде. Бала карасынмы?.. Сугыш еллары... Бер пот ипи—мең алтын дигәндәй, тик ята торган вакытлар идемени? Борчулар, хәсрәтләр белән сугыш үткәнне дә сизмәде. Юк, юк, рәхәт тәтемәде миңа, юк, юк...

Ишек төбенә чүп тыгылып җыелган суга тамчылар төшә. Алар куык ясап дулкыннар җәя, көлтә кебек өскә күтәрелә дә як-якка сибелә, вак-вак тамчылары өстән тәгәрәп бара, энҗе бөртекләре диярсең, аннан югалалар.

Сәрви калай чәй банкасына салып ышанычлы җиргә яшергән энҗе-мәрҗәннәрен кайтып карамакчы булыпмы, ишектән башын чыгарып өскә карады, сибәли икән дип чүпрәк үлчи торган шактый зур үлчәүгә күчеп утырды. Тагын алтыннары белән буталып, уйлары аны әллә кайларга алып китте. Зәйгүрәгә биргән алкаларын, йөзекләрен, муенсаларын янә бер кат күз алдыннан кичерде. Ялтырауларына кадәр хәтерендә. Ана биргән кебек алтыннарны табарсың хәзер бар! Бәяләре күтәрелеп кенә тора. Әгәр үткән ел Тәслимә кием шкафыннан челтәрле муенсаны һәм сурәт төшерелгән бер балдакны урламаган булса, сигезенче классын тәмамлагач, шуларның берәрсен Юзаннага бүләк итәрмен дигән иде. Һичбер нәрсәне яшереп калып булмый. Актарырга гына торалар. Бер сүз әйтергә ярамый Тәслимәсенә дә,

Юзаннасына да, Зәйгүрәсенә бигрәк тә. Акаеп кына карый, нурсыз күзләре белән айкап кына ала Зәйгүрә. Имеш, аларның да өлеше бар. Акыртып талыйлар, билләһи. Зәйгүрәсе беркөнне: «Минем Юзочкама бер алканы җәллисең, үзең бирмәсәң, колагыңдагын өзеп алам»,—дип куркытып маташа. Булыр аннан. Колаксыз калырсың, Алла сакласын!

Укучы балага ниткән алка тагын, мәктәптә күрсәләр, ни әйтерләр? Инде болай да башыннан аягына кадәр мин алган кием. Ана тегенди-мондый гына, простой әйбер дә кирәк түгел бит әле, кыйбатлысы булсын, чит илнеке. Гәүдәсе гәүдә түгел ичмасам, озын сыйрак. Бу яшьтән үк шундый озын кыз була ди мени?!. Кайларда гына буталып шундый колга ир кешене туры китерде икән Зәйгүрә? Хәер, җылы якларда төрлесе бардыр. Ярый әле кара төстәгесе туры килмәгән. Ел саен диңгезгә ял итәргә китә, имеш. Саф һава, тозлы су, имеш. Таулар, пальмалар, кызыклы очрашулар... Төрле кешеләр... Имеш, «Син нәрсә аңлыйсың сон!» Беләбез без аларны һәм кызыклы очрашуларны. Әниең инде бу эштә песи ялаган кеше, акыл өйрәтмә! Имеш, ел буе эшләп бик каты арый. Бездән туйган, бездән ял итеп кайта. Бездән туйсан—килмә! Берәү дә сине монда сөйрәп китерми, үзең акаеп килеп житәсең. Эшләп армыйсың син, жанкисәккәем—ялкау син! Кемнәрнен генә башын интектерәсеңдер, бер бәладер инде начальникларына.

«Мине Дмитрий Федорович гел мактап кына тора»,—дигән була. Дмитрий Федорович мактар ул, менә авыруларың бер дә мактамый, зарланалар ди шул, бәгырькәем.

Кайда торганыңны, кайда эшләгәнеңне әйтми йөрсән дә беләбез, барын да беләбез. Килеп йөрерләр дип куркасыңмы әллә, килмәбез—курыкма! Монда килеп акаюларын да бик житкән. Атна арасында өендә ни эшләп ятуын мине бер дә кызыксындырмый, пычагыма да кирәк түгел алар мина. Базарга барсам да күреп кайтам мин ул мыеклыларны. Эшендә дә жаен тапкансыңдыр әле. Бардыр әле анда да берәрсе. Дмитрий Федоровичын юкка гына мактамас!

И, балалар, белмисез кадеремне, белмисез! Житмәсә, бу хәсрәте-Юзаннасы теңкәмне корта, эчем авырта ди дә укырга бармый. Барма, соңыннан йөрерсең менә минем кебек житмешне узгач та үтил складында чүпрәк жыеп. Бөтен дөньяга исемең таралыр, данлыклы булырсың. Хәзер мине «Үтил Сәрвие» дип кенә йөртәләр. Эте-бете белә. Син дә «Үтил Юзаннасы» булырсың. Кара син аны, ашамаган була. Акча бир ана имеш көн саен. Тамагына капмыйча, әбисенең керер тишеген калдырмыйча сүгеп, пыр тузынып мәктәбенә китте. Әллә нигә психы котыра шуның иртән укуга китәр алдыннан. Син—күсе, син—«Плюшкин,» дип (анысы кемдер тагын?) кыздырылган колбаса белән йомырканы өстәлгә каплады. «Если на юг барырга акча бирмәсән, ашамыйм дип әйттем ич мин сина», ди. «Әбиең акча бирсә, мин сине на юг алып барам» дип зур апасы үрти икән. Зур апасы әйбәт... Син беләсеңме кем: «ты—вор, ты—паразитка общества!» дип тагын әллә ниләр тезеп китә. Әби кешегә килешеп бетми торган, теләсә кайда кунып йөрүче хатыннарга гына әйтелә торган сүзләр. Бөтенесен ишетеп бетермәде әле ул чагында. Һәркем үз сүзен туглый торды. Сәрвине чыгырыннан бер чыгарсаң, мәктәбенә барыр әле... Укытучыларыңның барысына да әйтер кем икәнлегеңне. Мондый укучы була димени. Эт баласы, хайваннан туган нәмәрсә. Исемең дә кеше исеме түгел бит синең—елан токымы. Анаң гомер буе бәгыремне ашады, хәзер икәүләп тотындыгызмы? Тәслимә котырта моны, билләһи, шул гына котырта. Һаман үч саклый, онытмаган. Әкрен генә маташа, астыртын, ай-яй астыртын. Өлеш даулый. Ачуын баса. Әйттем ич, югалттым мин аларны, югалттым. Ышанмасаң ышанма! Баланы котыртып ачуыңны алма! Кеше

баласына тыгылып, ялагайланып йөрисең. Имеш, ул да үстерә аны, ул да карый. Үзеңнекен үстерәләр аны. Күбәләк кебек бер чәчәктән икенчесенә кунып йөреп, кысыр калдың. Пенсиянне ал да тик ят! Кара син аны, үз акчасын кассага салып бара, ә көньякка барырга дигәндә әбиеңнән сора имеш! Хәйләкәр! Үз бүлмәсе, үз көе, суы-ние үзендә, шунда гына яшәп ятасы. Талашасы-нитәсе юк. Юк, көн саен монда килә.

Менә шул шимбә якынлашса, кулыннан бөтен эше төшә Сәрвинең. Юзаннаның да коты чыга, ә Тәслимә бөтенләй кача. Чөнки Зәйгүрә килә ул көнне. Ул килгәндә өй чиста, һавасы саф, тәм-томы пешерелгән булырга тиеш. Килер дә кырын ятып китап укыр. Бер кул эше тотмас, ертык-тишекне түгел, төймәсен дә такмый, менә шул!

Кем торсын аның белән, кем тора алсын! Ел ярым түзеп торган ире дә квартиры-ние белән ташлап качты бит ул аждаһаны. Дөрес итте, бала чүпрәкләренә батканчы вакытында ычкынып өлгерде.

Мингерәп йөрде Сәрви атналар буе. Менә тагын шимбә житте.

Аңа өендә кешеләр җыйнала башлагандыр кебек булып китте. Яшен яшьнәп, күк күкрәү колагына Зәйгүрәнең тавышы булып ишетелде. Сәрви чымырдап куйды. Ашыгып башын як-якка чайкады, исәрләнүеннән котылырга маташты, күз алдында әллә каян гына хасил булган томанлы кешеләрне куллары белән куды. Алар беркавымга югалып тордылар.

«Акылдан шашам, ахрысы, мин бу складта»...

Ул кибеткә кереп ипиләр, сөтләр алып кайтасы барын исенә төшерде. Туктый да белмәде яңгыры. Сонга калдыра, кибетләр төшке ялга ябылганчы туктаса ярар иде. Хәер, офыкта бер чите күренә бугай күренүен. Бөтен нәрсә, бөтен эш Сәрви өстендә ич. Ипи алып кайтучы да юк. Кая инде ул, утын, бакча дигән сүзләрне кузгатып та булмый. Барысын да үзен табасың, килеп корсак тутыра гына беләләр. Тапканны пешереп тә ашый белмиләр бит. Гел Сәрвигә салыналар. Ничек авыр табылганын белмиләр шул ризыкның, кирәк-яракның...

Дөньяның барлык мәшәкатьләрен берүзенә калдырып китте шул Ясәвие. Соңыннан гына аңлады аны Сәрви, соңыннан гына. Иң зур алтыны, иң кадерлесе ул булган икән. Күпме газап, күпме хәсрәт калдырган ул аңа. Ә үзе, ничек аның юлына очраган булса, шулай эзсез генә китеп барды бу дөньядан. Буйга житкән бәйсез, сансыз кызы белән утырып калды Сәрви. Күпме байлыгын салды шул кызына, күпме расход чыгарып укытты бит шуны. Кеше булсын диде. Бәясе кыйбат ул кызның, кыйбат, ай, кыйбат!

Ире исән вакытта юньләп эшләмәгән Сәрви чүпрәк җыя торган складка эшкә урнашты. Иллене узгач, хезмәт кенәгәсе ачтырды. Бик кимсенеп эшләде. Түзде, аннары—күнде. Эшеннән җай таба башлады. Чутлашканда оста кыланды. Китерелгән чүпрәк-чапрак, кәгазь, сөяк, тимер-томыр өчен әйберләтә чутлашу кертелгәч, дәрәҗәсе күтәрелде, дуслары артты. Ул бигрәк тә кибеттәге сатучылар белән ныграк аралашырга тырышты. Чит илнең кер юу порошоклары, банка капкачлары һәм башка кирәк-яраклар блатны арттырды.

Зәйгүрә өчле-тугызлыга институтны тәмамлап, диплом алды. Укыганда ук сылу гәүдәсе тупасланып, буянып-сөртенеп йөргән битләре төссезләнеп калды. Күзенең нуры бетте.

Өйгә кайтмыйча, әллә кайларда йөрү галәмәтләрең болар, дип ачулана торган иде аны Сәрви көзгә каршында уфтанып утырганда. Эшең булмасын анда, кайчанниләр кыланып йөрдең дип синнән сораган кеше юк бит әле. Дөмексәң дә бетәрлек түгел гөнаһларын. Элеккеләре дә, хәзергесе дә. Кубәйгәннән күбәя, өстәлә генә бара. Арткы яктан көне-төне капчык-капчык әйбер ташыйсың.

Ашасыннар, кеше арасында ким-хур яшәмәсеннәр өчен тырышам дип әйтеп кара Зәйгүрәгә...

Үз балаң бит, үз балаң. Кешедән нинди рәхәт күрәсең. Хәер, әнә күрше карчыгы ишетми дә, юньләп күрми дә, ә квартирантлары кадерләп кенә тоталар үзен. Утынын, суын ташып кына торалар. Бергә ашыйлар ди. Ә монда: алтышар, сигезәр чиләк су китерәсең, керләрен юасың... Җәелеп ята да китап укудан арынмый. Нәрсә, бер дә язмыйлар микәнни шул китапларында үзе төсләләр турында? Бигрәк культурный инде. Культурныйлыгы аркасында балага шундый исем кушкансың да инде син. Лүзия дә түгел бит, ичмасам—Юзанна..

Ярапый, бүген килмәсен иде. Ялын—ял, йокын—йокы, эшен—эш түгел ул килсә. Әллә Юзаннага акча бирергәме? Тәслимәсе белән китсеннәр шул дингезләренә, укуы бетә ич инде. Зәйгүрәсе дә ычкыныр, ул каламы соң? Бергә йөрмәс ул алар белән, аерым китәр әле, менә күрерсең! Китсеннәр, рәхәтләнеп калыр идем.

Шул чакны капкадан зонтик тоткан Тәслимә килеп чыкты. Бер кулында теге зур сумкасы.

Ничек? Чыкмыйча шушы вакытка кадәр өйдә ятты микәнни? Нигә соң әле ул капканы ача алмый маташканда тәрәзәне генә шакымаган?... Тәслимә өйдә булган бит! Керләрне җыеп алырга башына килде микән? Юктыр... Берәр нәрсә эзләп, актарып яткандыр әле. Тагын нәрсә чәлде икән?

Ул уйлап бетергәнче Тәслимә килеп тә җитте.

—Лимонын белән бераз чүпрәнне алдым, кайткач утырып, иркенләп чәй эчәрмен. Камыр да куям. Зәйгүрә килгәнче китим.

—Ярый, сау бул, Тәслимә! Икенче килгәндә үткән атнада урлап киткән заем кәгазьләрен алып кил әле!—дип авызын гына ачмакчы иде, урам чатында, борылыштан Зәйгүрә килеп чыкты.

Кисәк чигәләре сулкылдап тибә башлады. Дерелдәгән керфекләре арасыннан чак кына күренеп калган дөнья атынып китте һәм ул әнисенең канлы бите, алтын-көмешләре, чүпрәк-чапраклары белән буталып, урыныннан кузгалган җир белән әйләнергә тотынды. Нindидер яктылыкта Зәйгүрә пәйда булды. Иреннәре кыймылдый, ул аны ачулана түгелме? Ә, юк, ул кулын болгый, кемнәрнедер чакыра, ул кешеләр җыя, ул хәзер барысын да әйтәчәк. «Кешеләр, менә күрегез, менә ул әнисен.»...

Ул котылырга теләп, янәшәдә калкынып торган Тәслимәгә кулларын сузарга теләде, ләкин тегесе: «Кирәк түгел, кит, кит!»—дип дөм караңгыга чумды. Нindидер мизгелдән соң яктылык тагын барлыкка килде. Зәйгүрә һаман аның турыда сөйлиме?... Ул аңа төртеп күрсәтә, ә Тәслимә башын чайкап: «Әйе, әйе, шулай булды»,—дип Зәйгүрәнең сүзләрен җөпләп тора сыман. Сәрви акланырга ымсынды, ләкин нәрсәдер әйтергә теләгән мәрмәр төсле иреннәре очында соңгы сүзе, аңлашылмыйча, эленеп калды. Хәлсез гәүдәсе чүпрәк-чапрак өелгән түгәрәк тәрәзәле үлчәүгә янтаеп төште.

Үлчәү угы, ризасызлык белән бераз уйнаклап торды да, кырык сигез кило тирәсендә туктап калды.



Рәмилә
Майорова

# КАЯ БОЛАЙ ЯРСЫЙ ӘЛЕ КҮҢЕЛ?..

***

**Тамырларым буйлап кан йөгерә—**
**Җан-фәрманга чаба тилереп.**
**Йөрәк капкаларын ачып-яба,**
**Күзәнәкләр кала илереп.**
**Кая болай ярсый әле күңел,**
**Яшь-яшь йөрәк кая талпына?**
**...Бастым төсле менә, кулым җәеп,**
**Яшәешнең сере алдына.**

***

**Нигә кирәк болай дөрләп яну**
**Мең хисләрдән көеп, газапланып?**
**Егыласым беләм. Әмма барыбер**
**Очыйм әле—очыйм канатланып!**

***

**Кеше—җирдә атлап йөри торган**
**Бер уенчык курчак.**
**Җанын саклап азапланмый, әмма**
**Югалтудан курка.**
**Үләр өчен яши дөньясында,**
**Мизгелләрне санап.**
**Үтә көне—ике юл чатында**
**Үз язмышын сайлап.**
**Гөнаһ җыеп яшәгәнче, әллә**
**Яхшыракмы үлем?**
**...Бу сүзләрдән кәефләнгән шайтан**
**Читтән тора көлеп...**

Рәмилә МАЙОРОВА—*яшь шагыйрә, КДУ студенты; «Сөю хәбәре» исемле китап авторы. Казанда яши.*

***

Матур бүләк биргән кебек,
Төреп биргән җанны тәнгә
Илаһи зат. Бәлки кемдер
Сәерсенер мондый хәлгә.

Конфет кебек төреп биргән!
Алганда да әрчеп алыр.
...Ялтыравык кәгазь-тәнең
Бу фани дөньяда калыр.

## Көчсез каләм

Фикерләр кайный йөрәктә,
Белдерергә сүз тапмыйм.
Уйларымны төзәтәм дә,
Янәдән сөртеп ташлыйм,
Яктылыкка чыгаралмыйм.
Күңелдә ак хис саклыйм.
...Яраланган хыялымны
Газраилләрдән яклыйм.
Хыял үлсә, үлә теләк,
Өметең сүнә элек...
Шуны аңлау ачысы да
Йөрәкне ала телеп:
Гаделсез тормыш каршында
Чарасыз ялгыз адәм.
...Көчсез булуын белсә дә
Һаман да тынмый каләм.

## Кемдер шакый

Йөрәгемә кемдер шакый...
Нигә дип керми икән?
«Ишек бикле түгел» иде,
Әллә ул белми микән?

Күңелем теләгән кеше
Булса әгәр бу кунак,
Чыгып та алыр идем лә
Елмаеп, ике куллап!

...Йозаксыз, тын йөрәгемә
Кемдер шакый да китә.
Ә күңел шат. Ул үзенчә
Нидер сизгәндәй итә...

Камил
Кәримов

# КҮРШЕ АВЫЛ КЫЗЫ

БӘЯН

Тавышсыз-тынсыз гына көймә килеп туктады, ишкәкчесе—Мөдәррис. Ләйсәнә белән минем арка терәшеп утырганны күргәч, көймә эчендә үрә катты.

—Кочаклашып утырасыгыз килгәч, шыпырт кына югаласыгыз калган, бөтен лагерьга сөрән салдырып, кеше куркытып...

Теге ярга чыкканда ишкәкләрне үземә алдым. Мөдәррис Ләйсәнә янына елышып көймә борынына утырды. Үзебез бер сүз дәшмибез—ләм-мим.

—Фотоаппаратны алган булсам, үзегезне фотога төшерәсе иде. Их, икегезне Мишә буйлап йөртим әле, көймә яллаган гашыйклар сыман барасыз,—дигән идем, Ләйсәнә ыргылып дигәндәй суга сикерде, чак кына артка мәтәлмәдем. Бу кадәр йөзеп туймаса да туймас икән...

Лагерьга кайткачмы?.. Төшке ашка хәтле, гомердә булмаганча, ашык-пошык линейкага чыгарып бастырдылар. Тетмәмне теттеләр... Пионервожатый бик усал кеше безнең. Линейкага тездерсә, елмаюын күрмәссең. Мин беренчегә килгәндә ул бишенче класска гына йөри иде әле. Киләчәктә шушы кыз хөкеменә калырмын дип кем уйлаган. Әле генә су өстендә нинди әкәмәтләр күргән—шуны яңабаштан сөйләп күрсәтте дә:

—Ләйсәнәне суга батырып үтерә язды, Зөфәрне лагерьдан куарга кирәк,—дип, карар чыгарып та куйды.

Ни әйтсәләр шул әйтелер, әмма лагерьдан кууга барып житәрлек дип башыма да китермәгән идем, көтелмәгән хәбәрдән көпә-көндез төн житкәндәй итте—күз алларым караңгыланды. Шул караңгылыкта Ләйсәнә алга чыкты, минем каршыга килеп басты, юеш чәч толымын кушучына җыйган. Бөтен кеше алдында:

—Гафу ит, Зөфәр,—диде ул. Аннан пионервожатыйга борылып:—Мин үзем гаепле... Зөфәрдән куркып түгел, аңа мактанырга теләп йөздем. Ничек батыра алсын ди ул мине? Балыкның суда батканы бармы?

Пионервожатый көтелмәгән бу яңалыктан бераз исенә килә алмыйча торды, аннан читтәрәк безне күзәткән лагерь начальнигы янына барып нидер киңәштеләр.

—...исәпкә алып, лагерьда калдырырга...—Ниһаять, күз алдымдагы караңгылык таралып кисәк кенә кояш чыкты.—...Лагерьда калдырырга, ләкин слетка баручылар исемлегеннән вакытыннан алда сызып ташларга...

*Ахыры. Башы 1нче санда.*

Тагын көн караңгыланды. Бу көнне мин кояшны бүтән күрмәдем бугай...

Слетка барып Гөлназны күрү бәхетеннән мәхрүм ителгәч, мин аны тагын да ныграк сагына башладым. Лагерьга хатлар килми, газета-журналлар гына житкерелә. Ә өйдә Гөлназ хаты көтеп ята торгандыр...

Кичтән һава кисәк бөркүләнде, озак та үтми, безнең лагерьга дип махсус жыелгандай, болытлар килә башлады. Палаткабыз, аз гына жил иссә дә туп кебек өрелеп авыл ягына тәгәрәп китәргә тора, казыкларын ныгытып, арканнарын тарттырып чыктык. Аннан соң, әле ярый, яңгырга тиклем ашап өлгердек, дип сөенешә-сөенешә, агач ышыгына тезгән өстәл өсләрендәге ипиләрне жыеп алдык та палаткаларга кереп шылдык. Быргычы «Отбой!» дигән хәбәрне яңгыратырга да онытты... Күк күкрәвен көтәбез.

Жәйге яңгыр гел көтелмәгән кунак шикелле. Палатка чаршавын ачып карадым—йолдызлар яктысыннан сипкелләнгән күк йөзе кечерәеп калган. лагерь өстенә төн тартылгандай, болытлар ябырылган саен караңгылык куера. Әле яңгыр башланырга болытларның егәре житми. Офык тирәсендә, туплар гөрселдәп, бомбалар шартлагандай итте, башланды. Безнең лагерь нииндидер билгесез дошманның уты астында калгандай булды. Ут арты ут уйный, эре-эре кургаш ядрәләр сыман яңгыр шыбырдый. Без, малайлар, сугыш турында күпме китап укыдык, күпме кино карадык. Кайбер кызыграк фильмнардан соң шул сәгатькә сугышка китәргә әзер тора идек... Ә менә гап-гади күк күкрәвен ишетеп никтер шым калдык.

Вәт яңгыр ичмасам! Болытлар юмарт, кухня түбәсенең шифер улаклары тулып-тулып ага. Сукмаклар гөрләвеккә әйләнгән. Яңгыр исе сулышка иярә.

—Жап инде палатканы! Жилгә ияреп яшен ташы кермәсен.

—Яшен ташы яңгыр яуганда булмый,—дим мин, калын юрган астыннан ишетелгән әлеге тавышны тынычландырырга теләп.

—Калай әтәчләнмә, үзең дә шүрлисеңдер әле, курыкмагандай кыланасың гына.

—Яшенле яңгыр вакытында куркырга ярамый, дим мин, баш иярга теләмичә.—Курыкканда йөрәк еш тибә, тән ныграк магнитлана, яшенне көчлерәк суыра дигән сүз.

Күбесенең юрган астында ятканын беләм инде, йөзләрен-чырайларын күрәсем килә.

—Юрган белән башыңнан ук каплап ятсаң, сулыш житми,—мин әйтәм,—йөрәк туже сикерә башлый. Ә йөрәк тибеше ешайса ни буласын беләсез...

«Уф-уф!» килеп жиңел сулаучылар күбәйде. Ни уйлаганымны сиздермәскә тырышып, юл капчыгымнан шыпырт кына фотоаппарат чыгарып, яктырткычын көйләдем дә уникe кешелек палатканың түренә барып бастым. Фотога төшерүнең күп эше караңгыда башкарыла, шуна күрә кул ияләшкән инде. Көтәм, ләкин ни көткәнемне үзем дә белмим. Күк күкрәвенә ияреп яктырткычымны уйнатасым, дөресрәге фотога төшерәсем килә.

Күк күкрәде, һәм мин шундук затворга кул тидердем, палатка эче гөлт итте, яшен үзе килеп керде, гүя... Шул мизгелдә гажәеп картина ялтырап алды, яшеннән куркып кайсыдыр күзләрен йомып, колакларын томалап мендәргә ингән, кемдер юл капчыгына тотынган, резина итекләрен салмый гына урынга ятып, каядыр, нигәдер чыгып йөгерергә әзер торучылар да бар, берсе хәтта фотояшеннән коты алынып, кызларча чәрелдәп «әни!» дип кычкырып жибәрде.

Шаяртуның асылына төшенгәч кенә телгә килде малайлар.

—Яшен сукты дип торам.

—Күздән утлар очты.

—Фотограф дигәч тә шулай шамакайланмасаң соң.

—Малайлар, ул бит безне рәсемгә төшерде!

—Мендәргә чумган килеш.

—Мөдәррис чемоданга ябышкан иде.

—Котыгыз алынмасын,—дидем мин кинаяләү белән—бәлки рәсем бөтенләй чыкмас та.

—Чыгамы-чыкмыймы, бер-беребезне күрдек.

—Кеше нигә күк күкрәүдән, яшеннән курка икән?

—Һәркемгә дә үзен сугар төсле.

—Ник?

—Шикле шикләнер, чикмәнен бөркәнер, ди.

—Кем күбрәк курка, шул күбрәк шикле...

—Син ул фотоны эшләмә.

—Ник сорап торасың, әйдә фотоаппаратын ачып тасмасын тартып алабыз...

—Ачып карыйбыз, кешесен күрәбез!..

Яшенле янгырны онытып урамга атылып чыктым, ә малайлар миңа ташландылар. Көчле янгырдан соң аяк астына май түккән кебек, басып торырлык түгел. Шушындый тайгакта унбер малайны ничек күтәреп тормак кирәк?! Әүмәкләшәбез. Безне сүрелдерергә теләгәндәй, янгыр коя гына, йөзләребезне таныргa теләгәндәй, яшен ялт-йолт ут уйната. Мина янгыр тими—фотоаппаратны ике куллап күкрәгемә кыстым да бөгәрләнеп күч астында ятам. Шартлатып торып актыртканчы каерып алдылар, ярар, иң кирәклесе исән әле. Ике яктан кулларымны каерып җиргә утырттылар да фотоаппаратны сугып төшерделәр, кемдер өстенә басып та өлгерде—йөзен танымадым, яшен яшьнәмәгән чак иде. Калганына көч сарыф итәсе дә юк, бетте, чәлпәрәмә килде. Кечкенә палаткадан пионервожатыйның: «Нишлисез анда, салкын тидерәсегез киләме?»—дигән сүзләре ишетелүгә, малайлар юк булды. Пычракка тапталган фотоаппарат янында берүзем басып калдым. Иң якын ике дустымны югалттым мин: Мөдәррисне һәм фотоаппаратны. Янгырны тоймыйм, яшенне сизмим—авыл ягына атлыйм. Юл озын, уйланырга уең житмәс... Нәрсә булды бүген? Фотоаппарат нишләде? Мөдәррис кем? Гөлназ кем? Ләйсәнә?.. Лагерьдан бөтенләйгә кайтып китүемме? Өйдәгеләр ни әйтер... Үз-үзенә биргән сорау ин авыры... Җавап эзләшер өчен дуслар кирәк. Дуслар?! Кемнәр? Гөлназмы? Гөлназ ул—тавышсыз-тынсыз хатлар гына. Дуслыкны уйлап чыгармыйлар, дуслык үзе килә, иң якын кешең булып. Ә миңа кемнәр килде?

Мөдәррис... Без аның белән еш үпкәләшәбез. Татуланышабыз, тагын үпкәләшәбез. Бәлки чын дуслык шундый була торгандыр. Һич көтмәгәндә генә килеп чыга бит сәбәп дигәнең... Шулай, көзнең беренче салкыннары иде. Мишә ярында боз ваткан тавышка йөгереп килсәм—боз өстендә Мөдәррис балык тотып йөри. Ул аларны сөзәк яр белән боз арасына куып кертә дә балта түтәсе белән чүки. Тегеләр мингерәшеп әйләнгәч бозны ватып ала да—балыкларны чиләккә. Ачуың чыкмаслык хәлмени?!

—Браконьер!—дидем мин, йөгереп килгән хутка.

—Синең кулыңнан килми.

—Мал корты.

—Көнләшүеңә чыдый алмыйсың. Ярар, балык ашы пешергәч чакырырмын инде...

Чиләктәге балыклар бик озак күз алдыннан китмәде. Һәм мин башка партага күчеп утырдым. Ике көннән янадан татуландык. Бер урамда туып-үскәч, гел бер партада утыргач, аерым йөрүе дә кыен аның белән... Инде бу яшенле төн... Тагын шундыйрак берәр вакыйгага килеп чыгар да арабыз бөтенләйгә өзелер шикелле.

Ләйсәнә... Ләйсәнә...

Әни миңа еш кына: «Улым, син ясаган фотоларда гел наратлар да

наратлар гына»,—дия торган иде. Нишләргә тиеш соң мин?

Фотога төшерәсең, кешегә рәсемен ясап бирәсең, ә алар рәхмәтенә өстәп акча да суза башлый. Алмасаң, көчләп кесәгә тыгалар, тапканнар Мөхәммәт өммәтен. Мин аларга садака иясемени?! Кеше белән эшең төшмәсен икән, урманда ичмасам, җаным тыныч. Әни юата башлый: «Кеше бер сыный ул, ике сыный, аннан соң кемлегеңне аңлый. Дуслашыр өчен тугабыз ла фани дөньяга»,—ди... Бервакыт, кояш баеганчы йөрим әле, дип фотоаппарат тотып наратлар арасына кереп киттем, әллә ни еракка түгел инде, безгә лагерь колгасына күтәрелгән әләм күренердәй ераклыкка гына таралышырга ярый. Тәвәккәлләп бик тиз атласам да бераздан адымнарым әкренәйде, иң мөһим нәрсәм онытылып калгандай, лагерьга кире кайттым. Ләйсәнәне дәштем... Урманда бик күңелле иде аның белән, сөйләшмичә, юктан-бардан кызык тапкан булып кеткелдәп көлмичә, елмаешып кына атласак та күңелле иде аның белән. Мишә суларын икәүләшеп кичкәннән бирле Ләйсәнәне ешрак очрата башладым әле мин. Кырда чүп үләне утаганда рәтләребез янәшә, ашарга утырсак урындыкларыбыз бергә, йөргән сукмакларыбыз уртак туры килә. Әллә ул мине дусты итмәкче микән? Без аның белән икебез дә класста иң кечкенәләр, линейкада гел янәшә басабыз. Кайсы көннәрдә «Чиртеш» дигән кушаматны бик еш ишетергә туры килә. Никтер әкрен үсәм шул мин. Велосипедны да рама астыннан йөреп кенә өйрәндем. Әти әйтә: «Син миңа охшаган, буйга алдырырсың әле, иптәшләреңне узып китәрсең!»—ди. Әни әйтә: «Арыш кыры биеклеге инде син»,—ди.

Арыш биеклеге генә шул без Ләйсәнә белән. Авылыбыз Арышлыны бик нык яраткангадыр әле... Буй бәләкәй булса да, зур кешедәй сөйләнәсе килә.

—Ләйсәнә, без синең белән утлар-сулар кичкән инде, әйеме?

—Кичтек шул.

—Кинодагы гашыйклар сыман, әйеме?

—Охшаганбызмы?

—Тәк кенә әйтүем, минә синең урында Гөлназ булса, бәлкем...

—Гөлназың хат яза торсын, ә без фотога төшик.

Болыт бүрекле юан нарат янына бастык, фотоаппаратны каршыдагы агачка элеп көйләдем дә тиз генә Ләйсәнә янына килеп утырдым. Тагын биш-алты секунд чамасы вакыт үткәч, автомат рәвештә рәсемгә төшерер. Шушы биш секундны көтеп алҗыгандай, Ләйсәнә искәрмәстән генә иңемә башын кыңгыр салды. Шуны гына көтеп торгандай, объектив тәрәзәсе ачылып ябылды.

—Ләйсәнә, әгәр берәрсе күрсә?

—Урмандамы? Бездән гайре кем йөрсен?

—Рәсемне күрерләр.

—Куркасыңмы, Зөфәр?

—Синең өчен.

—Ә нигә куркырга?

—Рәсем әти-әниеңә эләксә дәме?

—Барыбер.

—Класстагылар күрсә?

—Күрсеннәр.

—Алайса, кабатлыйбыз. Тукта, ялгызыңны гына, бик якыннан, портрет итеп...

Мөмкин кадәр якын килеп нәни тәрәзә аша Ләйсәнәгә карадым. Күз күпне күрсә дә, без үзебез менә күргәннәребезне тоя белмибез икән. Чәчәк яныннан үтсәк—чәчәк кенә дибез. Әгәр тукталып, аның утлы күмердәй янып торган үзәгенә, кояш яктысына куанып берөзлексез тирбәлүче нәфис керфекләренә, көн җылысына үрелгән яфракларына якынрак килсәк... Объектив аша караганда бөтен хирыслыгың, зиһенең һәм игътибарың бер ноктага гына төбәлә. Син шул ноктаны башкаларга караганда ачыграк, якынрак һәм матуррак күрәсең.

Мин хәзер тирә-якка, дус-ишләремә, хәтта бөтен җиһанга объектив аша гына караячакмын... Каршымда Ләйсәнә... Күпертеп таралган чем-кара чәч, киң мангай, туры калын кашлар, яна дәфтәрнең беренче бите кебек шома йөз. Үпкәләгәндә дә ягымлы итеп карый белә торган күзләр...

—Зөфәр, ник озак кыймылдыйсың инде?

—Хәзер, мангай чәченне менә болайрак итеп төзәтим дә.

Мин, батыраеп, аның чәчен төзәтергә дип үрелдем. Үрелдем дә туктап калдым. Әйтерсең лә исле гөл бәйләмен тузгыттым һәм таралган хуш искә буйсынып калдым. Бары тик Ләйсәнәнең елмаюы гына күренә. Объектив ябылды, ә матурлык югалмады...

Җансыз әйберләр дә дустанә була ала. Мин бүген ин якын дустымны—фотоаппаратны югалттым. Әле кайчан гына авылым табигатен, наратларны, Ләйсәнәне рәсемгә төшерә алган дустым берничә кисәк тимергә әйләнеп учымда кайта. Төшерелеп бетмәгән тасмасы чәрдәкләнгән оясыннан атылып чыгып йомгакка әверелергә теләгәндәй бөтәрләнә. Рәсемгә әйләнәсе күпме кадрны яшен яктысы кисә. Бетте, чәлпәрәмә килде, яшен алды.

Тәки кайтып җителгән. Капка эчтән бикле, койма өстеннән сикереп төшәрлек куәт тә юк бугай. Капканы дөбердәтәм. Ишегалдыннан әни тавышы ишетелә.

—Кем йөри шушы төндә?

—Улыгыз әле бу, әни.

—Абау, нишләп?

—Җәяү кайттым.

Капка ачылуга әни мине яшен яктысында гына күздән кичереп чыкты.

—Кеше карарлык чыраең калмаган.

—Юл тайгак ич.

—Бар, мунчага кереп чык, кызуы сүрелмәгәндер әле.

—Әни, Гөлназдан хат юкмы?

—Дивана! Шушындый хәтәрдә хат өчен кайттың мәллә?

—Бер хәбәрегез дә юк ич. Кешенең әти-әнисе, юл унае дигән булып кына лагерьга килеп, малайларының хәлен белеп китә, ә сез...

—Ярар, ярар, тамагың тук, өстең бөтен, күз-колак булырлык кешеләрегез бар. Әтиең белән без дә эш кешесе. Үпкәләгән ише кыланып.—Марш мунчаңа. Сагынуыма чыдый алмыйм дисәң, Гөлназыңның хатларын алып чыгам, мунчада укырсың. Дивана...

—Юынып чыкканчы гына түзәрмен инде...

Миңа дигән урын мич кырыендагы караватка җәелгән иде. «Яңгыр астында кайтып салкын җыйгансыңдыр, йә авырып китәрсең»,—дип, әни мич җылысына арка терәп ятарга кушты, кичтән бәрәңге шәңгәсе пешергәннәр икән... Ләкин мин ашап тормадым инде, вакыт бик соң. Әни ике кулыма ике хат тоттырды да утны сүндерде. Вәт, теләсәң нишлә! Ичмасам яшене дә ерагайды-сирәгәйде, хат укырлык яктылыгы юк.

«Бөтен кешене йоклатам», дип килгән төнне алдалап тик ятам. Хатлар тынгы бирми. Керфекләремне ябып караңгылык ясыйм, җылы йомшак мендәрне тынлыйм. Әллә колак шаулый, әллә чынлап та шулай—мендәр мамыгы эчендә казлар каңгылдашкан сыман тавыш килә. Мин ул казларны кызганып мендәрдән башымны күтәрәм. Әнинең дә, әтинең дә йоклагандагыча сулыш алганнары ишетелми, димәк минем өчен борчылып яталар. Уйлар йокыдан көчлерәк. Шулай да, төнне хөрмәт итеп булса да, йоклыйсы иде. Мендәрнең салкын ягын әйләндереп салдым. Уйлар бер ерагая, тагын якыная... Ниһаять, гел йоклаганга сабышып яткан әтием тавышын ишетәм.

—Тор да укы инде шул хатларыңны. Утны яндыр. Юкса, ни без, ни үзең

йоклый алмыйсын.

Әнидән берәр каршы сүз чыкканчы дип, сикереп торам да ут кабызам, хатка ябырылам.

Минем хатлар кебек үк Гөлназныкылар да бик кыска. Элегрәк мин хаталар күп китмәсен дип аз яза торган идем. Сүзләрне каян алып сайларга белмичә интегеп төне буе хат иҗат итә идем. Язма эшләрдән «4» тә «5» кенә минем үзе... Тик хат язарга өйрәтмиләр шул мәктәптә. Язма эш башка, хат бөтенләй үзгә. Аны көтеп алуы гына рәхәт. Хәзер исә конвертны ачканчы үк Гөлназның ни язганын яттан беләм:

«Исәнмесез... Укыйбыз... Нинди яналыклар бар?..»

«Исәнмесез... Каникулда... Нинди яналыклар бар?..»

Хатларның эчтәлеген тирәнәйтерлек бер очрашу кирәк. Бәлкем, Гөлназ теге слетка барыр баруын, әмма мин инде исемлектән сызылган, лагерьдан куылган—линейкага тезеп, диктор тавышларына охшатып: «...кагыйдәләрен бозган өчен... лагерьдан кайтарып җибәрергә...»—дигән сүзләрен ишеткәнче үз теләгем белән кайтуым лутчы.

Икенче конвертны ачкан булыйк, дисәм, фотоаппарат тәрәзәсе хәтле генә бер фото килеп төште... Тәки рәсемен җибәргән бит Гөлназ... Мин аны ялт кына кулым белән каплап өлгердем, күрмичәрәк торыйм, аз гына, юкса никадәр зарыгып көткән шатлыкның кызыгы бетәр... Юк, артык түзеп торырлык кодрәтем юк, ашыйсы килгән кебек, сусап су эчәсем килгән кебек тизрәк Гөлназның фотосына күз төшерәсем килә... Чәче үтә сары тестәдер, йөгерек вак дулкыннардай бөдрәләре дә сизелеп тора. Йөзендә елмаю, әйтерсен лә бит уртасындагы мәхәббәт чокырын күрсәтер өчен генә юри елмая. Күзләре, җирдәге бар хәрәкәтне дә күреп өлгерергә теләгәндәй, йотлыгып карый. Гөлназның авылларында беренче чибәр булуына шикләнмим. Ана охшаган, һич югы аны хәтерләткән башка берәр кызны очратам дисәң, ким дигәндә бөтен районыбызны йөреп чыгарга кирәктер. Их, лагерьдагы чагым булсамы, палатка эчендәге бөтен малайны уятып мактаныр идем!.. Мин тынып калгач, әти утны сүндерде. Гөлназның фотосы күз алдымда балкып калды...

Әгәр шау-шуга уянып китмәсәм, тоташтан күпме йоклый алыр идем икән мин?.. Кояш көньякка карап торган тәрәзәләребезне әллә кайчан үтеп киткән. Өй эчендә эссе, хәтта бөркү. Әнинең җәй көне тәрәзә ачып куя торган гадәте юк, чебен керүдән курка. Саф һавага сусасаң, урамга чыгып йокларга куша. Ишегалдында әллә ничә тавыш берьюлы сөйләшә, йорт бүрәнәсе аркылы бик ачык ишетелми. Чыксам—әнине уратып алганнар: вожатый апа, Ләйсәнә, Мөдәррис һәм тагын ике-өч кеше. Мине күргәч, бөтенесе дә шым булды. Әни генә борчулы тавышын тыя алмады:

—Улым, син лагерьдан качып киткәнсең икән, иптәшләрен төне буе борчылганнар. Төн уртасында кемдер урман ягына киткәнеңне күргән дә, адашкандыр дип, агач төбе саен эзләп йөргәннәр.

—Туп-туры авылга кайтып хәбәр итсәк, әниеңне борчуга салырбыз дидек.

—Ә син... рәхәтләнеп йокы симертәсең. Без... төне буе йокламадык. Киен әйдә, лагерьга киттек.

—Юк,—дидем мин, ышандырасым килеп,—фотоаппаратны төзәттермичә ике аягымның берсен дә атлыйсым юк!

—Нык ватылганмы?

—Тетелеп беткән...

Шулчак минем кулдан «ялгыш» кына Гөлназ фотосы төшеп китте. Хәер, җиргә төшеп өлгермәгәндер ул, аны шундук Ләйсәнә тотып алды.

Матур нәрсә күзгә тиз күренә шул—рәсем тиз арада кулдан-кулга күчте. Яуды сорау, китте бәхәс...

—Кайдан таптың?
—Кем фотосы бу?
—Нинди фото, открытка кисәге ич!
—Наталья Белохвостикова.
—Син үзең Наталья, Муза Крепкогорскаяны танымыйсың.
Мин аңлатып булмаслык горурлык хисен тоям, бөтенесенең игътибарын җәлеп итте Гөлназ рәсеме. Рәсемгә тел шартлатып әйтелгән сүзләр минем үземә генә әйтелделәр сыман. Елмаюдан тыела алмадым. Өн түгел, әкияттер бу... Очасым килә. Җирдәге һәр кешене сокландырасым килә...
Мөдәррис мине читкәрәк чакырып ымлады да елышып кына сорау алды:
—Кем бу?
—Гөлназ.
—Тегеме?.. Кая, тагын бер карыйм әле.
—Мә, бөгәрләмә түлке.
Мөдәррис бик җентекләп карады.
—Алданма, Зөфәр, рәсем ул күз алдагыч кына. Бик теләсәң... Гөлназ буйга синнән калкурак ул.
—Каян беләсең?
—Күрәсең ич, яңаклары озынча, димәк, бездән биегрәк ул.
—Кыш көне күрешкәндә тигез идек.
—Ә хәзер җәй. Кызлар тиз үсә ул.
—Үсте микәнни?!.
—Аптырамасана. Юк белән хыялланма, Зөфәр, фотода мин дә матур күренәм ул.
—Бабай Мөхәммәт әйтә: «Фотоаппарат художник түгел, юк матурлыкны үзе өстәп куя алмый»,—ди.
Мөдәррис черки куган кебек итеп кул изәде:
—Искә төшермә әле шуның исемен. Бурсык белән төшкән фото турында урман хуҗалыгы инспекциясенә шул Бабай Мөхәммәт язып җибәргән ич, әткәйгә жалобасын укытканнар.
—Ничек инде, Мөхәммәт жалоба язганмы? Ник язган?..
—Синең фотоаппаратка үч итеп!
Безнең сөйләшүне капка төбендәге ат пошкыруы бүлдерде. Әти төшкә ялга кайтып җиткән. Тиз арада аңа хәлне аңлатып бирделәр. Әти, фотоаппарат кисәкләрен кулына тотып, йомшак кына итеп сызгырып күрсәтте дә кире бирде.
—Мә улым, моны хәзер Самарский мастерга илтсәң дә рәтли алырлык түгел. Ну, без бүләк иткәнен саклый алмадың, инде үсеп эшли башлагач, үзең сатып алырсың... Бар, лагереңа сыпырт!
Лагерьда мина кырын карап йөрүчеләр артса да авыз ачып сүз әйтергә кыймадылар. Аңа карап минем хәл җиңеләймәде. Хәер, экранда слетка барырга тиешле алдынгылар арасыннан исемем сызып ташлангач, хәлем бераз җиңеләйде бугай—инде басуда чүп утаганда өзелми калган алабута, солычаларны санап арттан күзәтеп йөрүчеләр юк, йокыдан уянып иртәнге линейкага элгәшмәсәм дә кисәтү ясамыйлар, су коенганда җыйнаулашып текәлмиләр—хет җаным теләгәнчә чумам, йөзәм, кызынам... Әйтәм ич, бөтенләй рәхәткә чыктым. Ә исемлектәгеләрнең законы кырыс. Алар вакыт-вакыт, мина кызыгудан: «Сина рәхәт...»—дип авыр сулап куялар. Мөдәррисне аңлый алам, ул слетта Әнисәсе белән очрашырга хыяллана... Ә соң Ләйсәнәгә бу слет нигә кирәк? Экранында бер генә «минус» та юк, һәммәсеннән дә ныграк тырыша. Чүп утауда икешәр норма үти, төгәллек дигәндә һәр күрсәтмәне үз вакытында башкара—хет сәгатенне дөресләп тор... Аның бу кыланышына үзем дә аптыраган инде.

—Әй син, Ләйсәнә,—дидем мин аның озак-озак итеп кул юганын күргәч—чүп үләннән яшеле бер йокса, кулдан гомергә бетми, нигә шул кадәр тырышасың?

—Слетка барыр өчен!

—Ник?..

—Гөлназыңны күрәсем килә.

—Ник?

—Миннән кай җире артык икән?..

—Анысын белмим инде...

Бүген безне машинага төяп авылга алып кайттылар. Каладан концерт килгән ди, культпоходка киттек, ягъни мәсәлән. Программалары башланганчы бер-әр сәгать алдан кузгалдык. Клуб янына кайтып туктагач, концерттан соң төгәл җыйналу турында тантаналы вәгъдәләр биреште тә... өйләргә таралыштык. Концерт беткәнче авылда йөрдек, туган-тумачаларга кердек, чәйләр эчтек, бәлешләр ашадык, мәктәп тирәсен әйләнеп килдек. Машинабыз янына берәм-берәм җыйналганда концерт бетмәгән иде әле. Эш юктан гына, артистлар автобусы янына да барып килдек. Анда кешеләр шактый, артист абыйлар, артист апалар соңгы җырчының сәхнәдән төшкәнен түземсезлек белән көтеп торалар, капчыклары төйнәлгән, киемнәре бикләнгән, баяннары ябулы. Соңгы җырчы инструменталь оркестрга җырлый, тыңлар өчен залга керәсе дә юк, тавышлары бөтен авылга яңгырап тора. Эшсезлектәндер инде, бер артист безнең белән сүзгә керде.

—Тавышка түзмәдегезме? Чыгып качтыгызмы?

—Бер дә тынлый алмадык шул әле,—дидем мин, Мөдәррис өчен дә көрсенеп.

—Кайда йөрдегез соң шушы төнгә чаклы?

—Лагерьдан авылны сагынып кайттык. Безнең якларга тагын кайчан әйләнерсез икән соң?

—Киләсе бишьеллыкта...

—Аңарчы без дә артист булып бетәрбез әле.

—Алайса, Камышлыга рәхим итегез, егетләр, иртәгә,—артист абый сәгатенә карап алды да төзәтеп әйтте,—бүген без шунда чыгыш ясыйбыз.

—Камышлыга?!

—Әйе, Камышлыга.

—Мине дә алып барыгыз әле.

—Мине дә,—дип кушылды Мөдәррис.

—Чит авылгамы?

—Безнең анда туганнарыбыз бар,—дидем мин бу юлы Мөдәррис исеменнән дә.

—Әйдәгез соң, автобуста урын җитәрлек.

Тиз генә Ләйсәнәне табып: «Безне эзләмәгез, иртәгә лагерьга үзебез килербез»,—дидек тә автобуска кереп утырдык. Камышлыга концерт еш килми. Гөлназ белән Әнисәләр дә культпоход оештырырлар әле.

Камышлыда көнне ничек кирәк алай уздырдык. Ерак апаларга сугылмадык, юкса ахыры ни белән бетәсен алдан ук белеп торам: телефоннан әтигә хәбәр итәр дә аннан соң безне ат белән килеп алырлар...

Көтүләре кайтты, маллары утарга ябылды, чишмә тирәләре тынды, белдерүдә әйтелгән сәгать сигез дә тулды. Ә клублары янында беркем юк. Болар да безнең авылча икән—кояш баемыйча, көндәлек эшләрдән котылмыйча күңел ачу турында уйламыйлар. Аның каравы, чама белән бер вакытка туры китереп, бөтен кеше клуб тирәсенә агыла башлый: бишәрләп тә, унышарлап та, җинел машинага төялеп тә, матайга атланып та.

Ышаныч өчен, кесә дәфтәремне ачып тагын бер кат Гөлназның рәсеменә

карадым. Мине күргәч сөенер әле, ни дисәң дә, көтелмәгән очрашу бит... Мөдәррис тә үзенең Әнисәсен эзли. Җинел хәл түгел: энгер-менгердә, күрше авылда, бер дә белмәгән кешенне тап әле син! Һәр төркемне күздән кичерәм, үзем сиздермәскә тырышам. Болай да бу авылда чит кеше бит мин... Күңел сизенә икән ул, ерактан ук яңа җыр ишетеп: «Алар»!—дигән идем, тәки дөрескә чыкты, сыер савучыларны җәйләүгә ташый торган вахта машинасы килеп туктады. Озын-озын урындыклар тезеп рәт-рәт утырганнар. Баскан җиремдә тик тора алмадым, аяк астына борчак чәчтеләрмени... Йөрәк дигәнем ашык-пошык тибә башлады, әйтеп бетергесез бер көч гел алга этәреп тора, кулларым аптыраганнан күлмәк якамны, пинҗәгемне төзәткәли.

Күзләрем Гөлназга карап хәрәкәтсез калды. Сулыш алырга да оныттым бугай...

—Бар яннарына, күреш,—ди Мөдәррис ашыктырып, минем Гөлназны ул да бик тиз танып алды.

—Ә син?

—Сиңа тылмач кирәкми лә. Әйт кызына, Әнисәне чакырсын, юкса танымавым бар.

Кулымдагы рәсем алдашмаган икән. Ефәктәй чәчләрен тузгытып җилне тотуы, пешкән гөлҗимештәй иреннәрен кыймылдатып сүзләр сайлавы—әкияттәгечә. Ә күзләре—пешкән карагатка төшкән кояш яктысы кебек. Тануыдыр—ул да елмайды.

Машинаның бортын ачтылар. Сикереп төшеп аягын авырттыра күрмәсен тагы, каршы алмакчы идем—өлгермәдем, араларыннан олы гына гәүдәле бер егет сикереп төште дә Гөлназны күтәреп алып чирәмгә бастырды. Чирәмлек машина эзеннән дүрт-биш адымнарда иде. Ул дүрт-биш адымны аларга ияреп мин дә атладым. Бу минем өчен кичергесез авыр минут иде. Җитмәсә, рәшәткә баганасына сөялеп Мөдәррис карап тора.

Гөлназ, янындагы егетнең колагына нидер пышылдап өлгерде, аннан:

—Таныш бул, Зөфәр аның исеме,—дип кулларыбызны кушты.

—Ә-ә, Зөфәр,—дип елмайды тегесе, әйтерсең дә бик кирәкле кешесен очратты.

Тизрәк берәр сорау биреп, үземне бу авыр хәлдән коткарасым килә.

—Әнисәгез кая соң, Мөдәррис тә килгән иде.

—Әнисә дежур торып калды,—диде теге егет, нәфис сүз остасыдай сүзен сүзгә аерып.

Күренеп тора—мине мыскыллавы... Һай, үртәлдем мин бу халәттә. Гөлназ да сөенеп елмаймый, көлә бугай, Мөдәррис тә читкә борылды—ул да көләдер, мөгаен. Алай гына да түгел, клуб янындагы бөтен кеше көлә-көлә мине күзәтәдер шикелле.

Алар клубка таба атладылар. Әгәр Гөлназ мине дә култыклап алса, өметләнер, юаныр урын калыр иде. Юк. Мин алар янәшәсеннән атлавымны иярчек тайга охшаттым. Алай да, багана башындагы лампа төшергән күләгәләребезне чагыштырып өлгердем—буйларыбыз тигез икән...

Аерылып китеп баруымны сизмәделәр дә, «гафу итегез!»—дип тә әйткән идем, югыйсә. Мөдәррис кызыксынса: «Буйга миннән биегрәк ул»,—диярмен, теге егет турында сорашса, туганы дияргә була... Юк! Юк! Иң яхшысы—беркем берни сорамасын. Алдашасым килми.

Мөдәррис белән җитәкләшеп үзебезнең авылга ашыктым. Дустымның сорауларыннан качкандай, йөгерергә керештем. Ул да калышмый. Үзем йөгерәм—үзем Гөлназга язасы соңгы хатка сүзләр сайлыйм:

«Хуш... Гөлназ! Бу хатымны... хуш дип башлыйм!..»

# ХАЛЫК ИЛҺАМЫ

*Татар халкының бөек җырчысы Илһам Шакиров узган гасырның илленче елларында татар һәм төрки халыкларның сәнгать күгендә яктырып балкый башлады.*



*75 яшенә килеп җиткән Илһам аксакалыбыз безнең бөтенебезне дә таң калдырып, бүген дә берниндн фонограммаларга, «фанера»ларга, алдан язылган тасма һәм дискларга кушылмыйча, үзенең табигый тавышы белән бөтен сәхнәләрдә, бөтен залларда тыңлаучының «һушын» ала, сокландыра, моңландыра, елата...*

*Республикабыздагы татар телен һәм мәдәниятен саклау һәм үстерү фонды «Җыен» идарәсе Илһам Шакировның 75 яшь тулган юбилеен халыкара күләмендә үткәрүне күз алдында тотып, аның тормыш һәм иҗат юлы турында татар, рус, инглиз телләрендә затлы, киң колачлы, бөтен дөньяга таралып яшәгән татарларга һәм төрки халыкларга олы бер бүләк булырлык китап-альбом төзеп нәшер итәргә карар кылды һәм шушы тәкъдим белән республика җитәкчелегенә мөрәҗәгать итте. «Җыен» фонды Җир шарының төрле почмакларында яшәүче татар һәм төрки халыкларның күренекле шәхесләренә Илһам Шакиров һәм аның иҗаты хакындагы истәлекләр, фоторәсемнәр, фикерләр сорап хатлар җибәрде...*

*Озакламый без, китапны төзүчеләр, Америкадагы ике атаклы татар профессоры Рифат Таби һәм Юлай Шамил-угылы, атаклы җырчы, Әзәрбайҗан Республикасының Россиядәге гадәттән тыш һәм вәкаләтле илчесе Полад Бюль-Бюль оглы, Кытай татарлары милли хәрәкәте активисты Рабин Сәфәргалиев, Төркиядәге профессор Надир Дәүләт, СССРның һәм Казакъстанның халык артисткасы Бибигөл Тележанова һәм башкалардан Илһам Шакировка багышланган язмалар, фоторәсемнәр алдык. Илһам Шакировның тормышы һәм иҗатына багышланган фоторәсемнәрне мөмкин кадәр тулырак күрсәтү теләге белән китапка 500дән артык фото кертелде. Текстларның өч телдә булуы аркасында китап күләменә сыешу өчен авторлар язмаларын кыскартырга мәҗбүр булдык. Әмма бу язмаларның бик тә кызыклы булуы сәбәпле, «Казан утлары» журналы редакциясе аларны укучыларга тәкъдим итәргә кирәк дип санады. Моның өчен журналга авторлар һәм «Җыен» фонды исеменнән рәхмәт әйтәсе килә. Китапны төзүчеләр төркеме җитәкчесе буларак, мин журналның бу сәхифәсен дәртләнеп һәм илһамланып төзедем.*

*Китап-альбомны Татарстан китап нәшрияты «Идел-пресс» полиграфия комбинатында бастырып чыгара.*

*Илһам Шакиров татар халкының олы илһамы бит ул!..*

**Гәрәй РӘХИМ**

**Полад БЮЛЬ-БЮЛЬ ОГЛЫ,**
*Әзәрбайҗан Республикасының Россия Федерациясендәге*
*Гадәттән тыш һәм Вәкаләтле илчесе,*
*Әзәрбайҗан халык артисты*

# ТАТАР ҖЫРЫНЫҢ ИЛҺАМ ИСЕМЛЕ ИЛҺАМЫ



Халыкара астрономия фәнендә безнең галәмдәге һәр йолдызның гомер озынлыгын, көчен һәм яктылык тарату куәтенең микъдарын билгели торган махсус шкала бар.

Нәкъ шуның шикелле, җирдәге һәр халыкның шәхес югарылыгын, милли йолдыз дәрәҗәсендә булуын билгели торган, үз вакытының милли туграсы дәрәҗәсенә күтәрелгән һәм туган халкының, аның тарихының аерылгысыз өлешенә әверелгән, рухи бөек һәм олы талантка ия булган әлеге астрономик шкала вазифасындагы шәхесләре бар. Күктәге якты, әмма салкын йолдызлардан аермалы буларак, җирдә яшәүче әлеге шәхес-йолдызлар тирә-якка якты нурлар сирпеп кенә тормыйлар, ә җирдәшләрнең күңелләрен җылыталар, ватандашлары өчен рухи маяк булып торалар.

Татарстанның җыр башкару өлкәсендәге, бүгенгечә әйткәндә заманыбызның бөек шәхесе Илһам Шакиров әнә шундый «йолдыз» дәрәҗәсендәге сәнгатькяр. Андыйларны безнең көнчыгыш халыклары аксакал, хәким кеше дип атыйлар.

Бүген, берничә дистә елларга сузылган үткәннәргә борылып карасак, Илһам Шакиров музыка дөньясын сайлап алганмы, әллә музыка дөньясы Илһам Шакировны сайлап алганмы икәнен раслау шактый кыен...

Бер хакыйкать ачык: тормыш аңа туган халкы рухын расларлык гаять олы сынаулар аша үтә торган катлаулы язмыш әзерләгән. Ә җыр аңа үзен-үзе тулысынча белер-белмәстән, балачактан килгән. Илһам дигән илһамлы исем белән ул үзе дә белеп бетермәстән яшьли дәртләнеп, моңланып, саф күңелдән җырлаган да җырлаган. Илһам дигән изге сүз бит татар телендә генә түгел, ә күпчелек төрки халыкларда да, бөек илһамлылыкны аңлата торган илаһи сүз!

Җырчы бөек Илаһыбыз бик сирәкләргә генә бүләк итә торган җылы, аңлаешлы һәм күңел түрләренең иң тирән төпкелләренә барып ирешә торган табигый тавышка ия. Илһам шушы бүләк-тавышны үз иҗатының төп коралы итеп кабул итте.

Берничә буын тыңлаучыларның кумиры, татар музыкасының ару-талуны белмәгән мәгърифәтчесе, татар халык җырларын популярлаштыручы буларак Илһам Шакиров гаять үзенчәлекле җырчы, олы сәхнәләр тамшачысының сөекле башкаручысы булды, һәм ул хәзер дә шушы югары дәрәҗәсен саклап килә. Аның бүген дә сәхнәләрдә төрле техник чаралар кулланмыйча туп-тулы залларда чыгыш ясавы, тыңлаучы белән гаҗәеп җылы мөнәсәбәт булдыруы соклангыч бер күренеш.

Илһам борынгы татар җырларын дөньяга күрсәтү белән генә чикләнмәде, ә аларга өр-яңа сулыш өрде, үзенә генә хас булган мелизмнар, музыкаль үзенчәлекләр өстәде.

Илһам Шакировның тарихи үрнәк булырлык, тулысынча музыкага багышланган тормыш юлы үзе үк иң югары сәнгать дәрәҗәсенә күтәрелгән, үзенең гадилеге һәм камиллеге белән мәңгелеккә ирешкән сүнмәс җыр булып яңгырый. Туктаусыз моң белән өртелгән бу җырда татар халкының төп холыгы, аның тарихи чишмә башына, туган җиренә, рухына, яшәешкә мәхәббәтенә тугърылыгы ачык чагыла.

Татарстанның сәнгати тормышында, артистлар даирәсендә бөтенхалык мәхәббәтен тулаем яулаган, шиксез хөрмәткә һәм данга лаек булган бердәнбер шәхес—ул Илһам Гыйльметдин улы Шакировтыр, мөгаен. Татарстан президенты, мин гаять хөрмәт иткән Минтимер Шәрип улы Шәймиев татар җыры аксакалы хакында шигырьгә тиң соклану сүзләре әйтә икән—бу инде үзе генә дә ни тора!

«Татар җыры—2007» милли музыка фестивалендә «Татар җыры легендасы» номинациясендә бердәнбер җинүче буларак Илһам Шакиров исеме генә аталды.

Юк бу һич кенә дә Татарстан жирендә талантлар кими бара дигән сүз түгел иде. Бүгенге көндә татарлар арасыннан халык жырларын оста башкаручы тулы бер буын үсеп чыкты. Әмма сәнгатьнең иң югары мөнбәрендә Илһам Шакиров булганда әлеге яшьләр һаман әле үз осталыкларын үстерү өстендә эшлиләр.

Татарлар арасындагы дусларымнан ишетеп беләм, Илһам Шакиров үзенең шәхси бәйрәмнәрен шау-шулы итеп үткәрү белән мавыкмый. Хәтта туган көне дә аның өчен зур вакыйга түгел. Аның каравы жырчының бәйрәмнәре, туган көннәре аның исәпсез-сансыз тыңлаучылары өчен олуг бәйрәмнәр. Мондый көннәрдә һәр тыңлаучы чын күңелдән: «Рәхмәт сиңа, Жыр!»—дип кабатлый.

**Юлай ШАМИЛ УГЛЫ,**
*Висконсин университеты (АКШ) профессоры*

## ИЛҺАМ ШАКИРОВ ҺӘМ НЬЮ-ЙОРК ТАТАРЛАРЫ

Илһам Шакиров ижаты минем, Нью-Йоркта туып-үскән татар кешесенең, балачагында әһәмиятле бер күренеш иде. Ә бу хәлнең булуы мөмкин идеме соң? Әйе, мөмкин иде, чөнки салкын сугыш чорларында жир йөзендәге татар диаспоралары өчен бөтен татар мәдәниятының иң күренекле вәкиле Илһам Шакиров булды. Бу Нью-Йорк штаты өчен дә шулай иде. Мин, дөнья буйлап сәяхәтләремдәге күзәтүләрем нигезендә, бу күренеш Төньяк Америка өчен дә, Төркия һәм Европа өчен дә шулай иде дип раслый алам.

Нью-Йорктагы татар жәмәгатьчелеге баштан «Америка Ислам Ассоциациясе» дигән оешма тирәсенә туплана башлады. Ул Россия империясендәге мөселман динендәге төрле милләт вәкилләре качаклары көче белән төзелгән иде.

Алар большевиклар революциясеннән соң күченеп килделәр. Ул еллардагы беренче бурычларның берсе—Клифтонда, Нью Джерсиядә мөселман зираты оештыру иде Бу зиратка йөрүчеләр баштан этник яктан төрле мөселман халыклары вәкилләре булды.

Мин Нью-Йорктагы татар жәмәгатьчелегенең мәдәни тормышында ике төп хәрәкәт чорын хәтерлим. Беренче чорда (ул чакта әле мин бик яшь идем) «Америка Ислам Ассоциациясе»нең үз бинасы юк иде, оешма Нью-Йорктагы биш шәһәр районының берсендәге Куинска якын гына булган Поинт колледжы залын арендага алып торды. Шунда бәйрәмнәр һәм мәдәни чаралар үткәрелә иде.

Ул чорда татар ир-атлары, башка мөселман халыклары вәкилләренә ияреп, Манхэттандагы иң зур кунакханәләрнең бию залларында оештырылган гыйбадәт кылу чараралында катнашалар иде.

Тора-бара бу оешма әгъзаларының саны арта барды—алар, нигездә, Казан татарлары иде. Шул ук вакытта элекеге Россия империясеннән килгән һәм мөселман дине тотучы төрле этник төркемнәр, үз милли мәдәни оешмаларын төзи башладылар. Алар арасында Төркестаннан, Кырымнан, Төньяк Кавказдан килгән төрле милләт вәкилләре бар иде. Шулай да, аларның күбесен немецларга әсир төшкән Кызыл Армия хәрбиләре, 1950 елдан соң Германиядән һәм Төркиядән Кушма штатларга иммиграцияләгән татарлар тәшкил итте. Шулар арасында Башкортстанның Чакмагыш районында туып-үскән әтием Мөхәммәт Шамилоглы да бар иде. Оешма әгъзаларының бер өлеше Россия империясендәге большевиклар революциясеннән Манчжурия һәм Кытайның Харбин һәм Хайлар шәһәрләренә качып киткән, соңрак Америкага күченеп килгән татарлар иде.

Кытай татарлары, Кытайда революция булганнан соң Төркиягә күченеп киллеләр, ә тагын да соңрак күпләр Америкага китте. Әйтик Кытай чиге янәшәсендәге Благовещенски шәһәрендә туган әнием соңрак Харбинда яшәгән.

Мин 1958 елда дөньяга килгәнмен. Нью-Йорктагы яшьлек чорым 1960 еллардан 1983 елга кадәр бик яхшы хәтеремдә. Мин шул елны төрки телләр буенча мөгаллимлек эшенә керешү өчен Мэдисон шәһәрендәге Висконсин Университетының Азия телләре һәм мәдәниятлары бүлегенә күчеп киттем.

Америкага күченүче татарларның ике агымы бергә кушылып Нью-Йоркта татарларның үзенчәлекле бер төркемен хасыйл итте. Төркия аша Кытайдан күченеп килгән татарлар исламны һәм татар мәдәниятының 1920 елларга кадәрге чорын, гарәп хәрефләре нигезендәге татар язуын яхшы беләләр иде. Ә Икенче Бөтендөнья сугышы нәтиҗәсендә Америкага килеп эләккән татар әсирләре 1940 елларга кадәр булган Совет чоры тормышын, латин һәм кирилл хәрефләренә нигезләнгән татар язуын, татар Совет мәдәниятын яхшы белсәләр дә, ислам динен начар беләләр иде.

Кытайдан гаиләләре белән күченеп килгән татарлар үзләре туып-үскән, яшәгән шәһәрләрне җылы хисләр белән искә алалар, ә инде бөтен гаиләләре, туган тумачалары Советлар Союзында киселеп калган әсирләр, салкын сугыш нәтиҗәсендә, туган илдән бернинди хәбәр дә ала алмыйча гаиләләрен, туган-тумачаларын сагыналар, бу чарасызлыкны авыр кичерәләр иде.



*Илһам Шакиров һәрвакыт яшь иҗатчылар белән аралашып яшәде. Рәсемдә (беренче рәттә, сулдан—уңга): Равил Фәйзуллин һәм Рабит Батулла, (икенче рәттә уртада) артистлар Айдар Хафизов һәм Луара Шакирҗан. Егерменче гасырның җитмешенче еллары.*

Яшьлек елларымда татар мәдәнияты белән бәйле хәтерләүләремә нигезләнеп шуны әйтә алам—бу чорда әле татар кешеләре монда үзләрен килмешәкләр итеп хис итәләр иде, салкын сугыш сәбәпле, алар Советлар Союзы белән бөтенләй диярлек аралаша алмадылар. Нью-Йорк татарларының Советлар Союзындагы туган-тумачалары белән ачыктан-ачык аралашырга бернинди дә мөмкинлекләре юк иде.

Бу чорда татар мәдәниятының төп тоткасы Габдулла Тукай булды. Татарларның барысы да аны беләләр һәм һәр елны аның туган көне булган 26 апрельдә төрле мәдәни чаралар үткәрәләр иде. Бу традиция Нью Йоркта бүгенге көнгәчә дәвам итә.

1961 елда Рудольф Нуриев Советлар Союзына кайтудан баш тарткач, ул Көнбатыш илләрендә иң атаклы татар булып китте. Ул безнең өчен татар милләтеннән чыккан бөек биюче иде. Нигездә ул Көнбатыш илләрендә татар мәдәнияты вәкиле түгел, ә шул чордагы салкын сугыш корбаны булды. Шулай да, әле без яшь чакта, әтием безне Нуриев белән очраштыру өчен ул биегән балетка алып барды. Ул чакта Нью-Йорк татарларыннан берничә кеше генә Нуриев белән очраша алдылар.

Соңрак, оешма эшчәнлегенең икенче чорында, «Америка Ислам Ассоциациясе» урам ягында кибете дә булган аерым бина сатып алды һәм ул Нью-Йоркта яшәүче татарларның мәдәни клубына әверелде. Мондагы мәдәни чараларның Казан татарлары тарфыннан һәм нигездә татарлар өчен оештырылуын искә алып, оешма үзенең исемен «Америка Татар Ассоциациясе» дип үзгәртте. Оешманың үз бинасы булгач, анда дини һәм мәдәни чаралар оештыру бермә-бер җиңеләйде. Бу чараларда Америка татарларының балалары да бик теләп катнаша башлады.

Безнең әти туган илен һәм анда калган туган-тумачаларын бик сагына иде. Аны ватаны белән бәйләп торучылар татар җырлары, соңрак «Казан утлары» кебек милли журналлар булды. Ул чакта Советлар Союзының «Мелодия» фирмасында язылган минутка 78, соңрак 33 тапкыр әйләнә торган пластинкалар Америкага да килеп җитә иде.

Мин татар көйләре язылган тәлинкәләрне беренче мәртәбә кайчан сатып алганымны хәтерләмим. Әмма ул җырларны тыңлау минем яшьлек тормышымда әһәмиятле вакыйгалар булып истә калган.

1975 елда мин Колумбия университетына укырга кердем һәм шәһәр үзэгендэге түбән Манхэттендагы рус китап кибетенә йөри башладым. Мин анда төрки халыклар телләре, тарихлары, мәдәниятлары турында китаплар эзли идем. Кибетнең пластинкалар бүлегендә мин гел генә татар музыкасы язылган тәлинкә булмасмы икән дип эзләнә идем.Бермәлне мин Илһам Шакиров җырлары язылган пластинкага юлыктым һәм аны әтиемә алып кайтып бүләк иттем. Илһам җырларын тыңлау әтием өчен дөньядагы иң зур бүләк булды.

Шул чорда Илһам Шакиров Нью-Йорк татарлары арасында иң популяр җырчы булып китте. Безнең оешманың һәр кешесе инде Илһам Шакировның кем икәнен яхшы беләләр иде. Алар бер-берсе белән Илһам Шакиров җырлары язылган пластинкалар алмашалар, дөньяның төрле илләреннән алып кайтканнары белән бүләк итешәләр иде. Аны татар халкының иң күренекле җырчысы дип саныйлар иде.

1975 елда без Нью-Йорктан төньяктарак булган Йонкерска күчкәч тә әтием якшәмбе көннәрендә һәрчак татар җырлары тыңлый һәм илдә калган туганнарын хәтерли иде. Илһам Шакиров җырларын тыңлаганда әтиемнең ике күзе яшь белән тула һәм ул шыпырт кына елый иде.

Еллар үткәч мин Илһам Шакиров җырлары язылган ике музыкаль җыентыкка ия булдым. Бу минем өчен гаять зур шатлык. Аларны тыңлаганда мин Нью-Йоркта үткән бәхетле яшьлегемне хәтерлим. Озак еллар үткәч инде монда Мэдисонда, Висконсинда, әткәм-әнкәм вафат булган Нью-Йорктагы татар җәмгыятеннән ерак яшәсәм дә, Илһам Шакиров җырларын тыңлыйм һәм минем дә күзләремә кайнар яшь тамчылары килә...

**Рабин СӘФӘРГАЛИЕВ,**
*Кытай татарлары милли хәрәкәте вәкиле*

## ИЛАҺИ ӘМЕР БЕЛӘН ДӨНЬЯГА КИЛГӘН ТАЛАНТ

Егерменче гасырның алтмышынчы елларында Казакъстанда һәм Алма-Ата каласында «Татар әдәбияте һәм сәнгате көннәре» үтте. Бу көннәрдә татар артистларының бик күп концертлары булды.

Кытайдан Алма-Атага күченеп килгән татар бу концертларның берсен дә калдырмыйча йөрделәр. Илһам Шакиров җырлавы аларга бомба шартлагандай тәэсир итте—җырчы тавышының гүзәллеге,көче,моны иксез-чиксез иде.Без бүген дә шул тәэссирләр әсирлегендә яшибез әле.

Соңрак Илһам без табынган илаһи зат кына түгел, ә минем һәм минем бик күп танышларымның дусты да булып китте. Без үзара очраша, хатлар языша башладык. Аның Алма-Атага һәр гастроле безнең өчен бәйрәмгә әверелде.

1965 елның сентябрендә Илһам Шакиров мина, Казакъстанның атказанган сәнгать эшлеклесе рәссам Бәхтияр Табига һәм фәннәр кандидаты, профессор Шамил Хәкимовка Казанга чакыру җибәрде. Чакыруга Казанга килеп китү өчен тимер юл билетлары да теркәлгән иде.

Илһам безне Казан тимер юл вокзалыннан туп-туры татар зиратына алып китте. Зират капкасы төбендә 5-6 әби белән бабай утырып торалар иде. Илһам аларның һәрберсенә хәер өләште. Акча биргәндә ул һәр әби һәм бабайга хөрмәт белән җиңелчә башын иеп алды, яшеребрәк торган кәгазь акчаны кулларын сузып торучыларның учына сала барды. Без шунда гына ул акчаларның кызыл унлыклар икәнен күреп калдык. Шунда минем күңелгә Г. Тукайның:

*Ихтыяҗын гарз итеп килсә теләнче капкаңа,*
*Каты сүзләр белән син инсаниятен таптама,-*

дигән шигырь юллары килде! Без бөек татар шагыйре Габдулла Тукайның,

Мәржанинең һәм башка тарихи шәхесләрнең каберләрен зыярәт кылдык.

Шул ук көнне төштән соң Илһам безне Казан фәннәр академиясенә алып килде. Анда ул безне күренекле музыка белгече Мәхмүт Нигъмәтжанов, архитектор һәм тарихчы Фуат Вәлиев белән таныштырды. Без бик кызыксынып һәм эчке бер дулкынлану белән аларның туган халкыбызның музыка мәдәнияте, архитектура истәлекләре турында сөйләгәннәрен тыңладык. Туган халкыбызның дәүләтчелеге бетү аркасында нинди зур югалтулар кичергәнебезне аңлап борчылдык. Илһам М. Нигъмәтжановка без Кытайдан ук алып килгән, бөек шагыйребез Дәрдмәнд сүзләренә жырланучы «Кораб» дигән халык жырын бүләк итте. Сонынннан бу жырны радиодан һәм сәхнәдән ишеткәч безнең шатлыгыбызның иге-чиге булмады!



*Илһам Шакиров дуслары белән Казан Кремле эргәсендә (сулдан—уңга): Фуат Рафиков, Заһир Исрафилов, шагыйрь Разил Вәлиев, Илһам Шакиров, драматург Туфан Миңнуллин, академик Миркасыйм Госманов, шагыйрь Гәрәй Рәхим, музыкант Рафинат Сәлахов. 2004 ел*

Без шунда Фоат Вәлиевның «Татар орнаменты» дигән гаять тирән эчтәлекле фәнни китабының кулъязмасы, республиканың кайбер житәкчеләренең милли ядкарьләребезгә шикләнеп карашлары сәбәпле, дөньяга чыга алмыйча тоткарланып ятуы турында белеп гажәпкә калдык. Мәскәүгә кайткач, без бу китапны алырга теләүчеләр арасында язылу (подписка) оештырдык. Алма-Ата һәм Ташкенттагы дусларыбызга хәбәр итеп, алардан Ф. Вәлиев китабына язылу оештыруларын сорадык.

1972 елда без Илһам Шакиров үтенече буенча үзебезнең танышларыбызга «Казан утлары», «Азат хатын» һәм башка татарча журналларга яздырдык.

Казанга әлеге 7-8 көнлек сәяхәтебездә без Матбугат йортындагы Язучылар берлегендә, музейларда, татарның бөек рәссамы Бакый Урманче остаханәсендә, Аккош күлендә булдык, шәһәрнең истәлекле урыннарын карап йөрдек.

Бу безнең туган халкыбызның башкаласында беренче булуыбыз иде. Безгә бик күп кызыклы мәгълуматлар белән танышу насыйп булды.

Боларның барысы өчен дә без якын дустыбыз Илһам Шакировка рәхмәтле. Мәскәүдә укуымны тәмамлагач, мин яңадан Алма-Атага кайттым, Илһам Шакиров белән хатлар язышуны дәвам иттек. 1969 елда мин Татарстанның Яшел Үзән шәһәрендәге бер завод белән фәнни тикшеренү эшләре алып бару турында өч еллык килешү төзедем. Бу өч елда инде миңа Казанда еш булырга, андагы милли мохит белән якыннан аралашырга туры килде.

Мин инде 1967 ел башында ук Казанда басыла торган бөтен газета-журналларны ала башладым. Аларның барысын да миңа Илһам Шакиров яздырып жибәргән икән. Мин инде алдагы елдан башлап, Казакъстанда Россия матбугатына язылу тукталганчыга кадәр, аларны алдырып тордым.

Узган гасырның сиксәненче елларында Кытай чиге ачылгач безнең анда калган

туганнар һәм дуслар белән аралашу мөмкинлеге туды. Бүгенге көнгәчә Кытайда яшәүче татарлар өчен җыр һәм музыка язмалары, туган телдәге китаплар һәм журналлар иң зур бүләкләр булып санала.

Кытайдан Советлар Союзына күченеп киткән күпчелек татарлар Урта Азиянең эре шәһәрләренә—Алма-Ата, Ташкент, Фрунзе калаларына килеп төпләнде. Без бу шәһәрләрдә яшәүче татарларның тупланыбрак, берләшебрәк көн итүчеләре идек.

Бу чорда безне рухи яктан Илһам Шакиров иҗаты нык берләштерә иде. Без алдан ук Илһам Шакиров һәм аның концерт бригадасының Казакъстанга һәм Урта Азиягә булачак гастроль маршрутларын белеп ала идек тә, аны каршылау, концертларга тамашачы оештыру, артистларыбызны лаеклы рәвештә каршылау һәм озатып җибәрү мәшәкатьләрен хәстәрләп куя идек.

Һәр концерттан соң яшьләр төркем-төркем булып шәһәр урамнарыннан җәяүләп, татарча җырлар җырлап кайталар, шунда ук Илһам концертында ишеткән яңа җырларны өйрәнә дә башлыйлар иде. Монда ул чакта бик сирәк кешедә була торган магнитофоннар ярдәм итә иде.

Илһам Шакировның табигатьне яратуын белгәнгә күрә, без һәр гастроль вакытында артистларыбызны Алма-Ата тирәсендәге тауларга сәяхәткә алып чыга идек.

Кытайда яшәүче татарлар Илһам Шакиров язмаларын беренче тыңлауда ук гашыйк булдылар. Хәзер Кытай татарларының һәр гаиләсендә Илһам Шакиров башкаруындагы бөтен җыр да диярлек бар. Илһам Шакиров шул елларда миңа җибәргән китаплардан Тукайның ике томлыгы, Такташның сайланма әсәрләре Кытайның Голҗа каласындагы югары уку йортында бүгенге көндә дә әдәбият дәреслекләре итеп файдаланыла.

**Бибигөл ТЕЛӘГӘНОВА,**

*СССРның һәм Казакъстанның халык артисткасы*

## ТАГЫН БЕР КАТ ЫШАНДЫМ

Без—Урта Азиядәге төрки халыклар, аерым алганда казакълар һәрвакыт татар халкы, аның сәнгате белән кызыксынып яшибез, татар әдәбиятын, шигъриятен, театрын үз итәбез. Казакъстан җырчысы буларак минем күңелгә татар җыры, татар моңы бик якын. Мин татарларның иң күренекле җырчысы Илһам Шакиров җырлавын аның иҗатының башында ук үз иттем. Татар радиосы, пластинкалар аша һәрвакыт яратып тыңлый идем. Аның халыкчан моңы, көйне үзәккә үтәрлек итеп башкаруы минем күңелне кузгата, үз иҗатыма да дәрт бирә. Әнием татар булгангамы бу моңнар миңа аеруча якын.



*Илһам Шакиров, Бибигөл Теләгәнова, Әлфия Афзалова, Фәридә Кудашева*

Күптән түгел генә әле без Илһам Шакиров белән татарның икенче бер мәшһүр җырчысы Рәшит Ваһапов фестивалендә бер сәхнәдә җырладык. Бу концертларда Илһам Шакировның фонограммасыз-низсез көр тавыш, дәртле һәм гаять аһәнле башкаруын күреп мин аның олы талантына тагын бер кат соклandым.

Илһам Шакиров ул төрки халыкларның уртак җырчысы, уртак баласы.

**Михаил ЛЬВОВ,**
*күренекле рус шагыйре*

# КАРА УРМАН

*Илһам Шакировка*

**Кинәт кенә ерактагы балачакны хәтерләсәм—**
**Мин—сабый... «Кара урман» җыры белән әсәрләнгән...**
**Әй, кемнәр миңа мондый олы мирас калдырды икән?..**
**Даһи җыр миңа күпме җан ярасы салды микән?!.**

**Ул кем икән?.. Мин—малайны көчле итеп кочаклаган?..**
**Йөрәгемә фаҗигале аваз, моңлы көй салган...**
**... Нинди җырлар җырладыгыз, борынгы бабайларым!..**
**Кара урмандай тормышны кичкән җайдаккайларым!..**

**Җырыгызда беркемгә дә җайлашу юк, ярашу юк,**
**«Трәл..ләл...лә...» дип җиңел генә буш аваз тарату юк...**
**...Халкым өчен борынгыдан тормыш итү орыш булган—**
**Шуңа туган-үскән җиргә фаҗигале моң тулган.**

**Тарих фаҗигасе җан ачысыдай җырын тудырган—**
**Бүген дә тәнне чеметә—гасырлар авазыдай.**
**Дөнья, сәясәт мең кат үзгәрсә дә, үзгәрми ул җыр,**
**Яралый күңелне—Җырчы җанын үзгәртми бу чор...**

**Әй, калсын ла иде фаҗигаләр узган гасырларда,**
**Ерак... Бик ерак киттек бит инде без ул чорлардан...**
**Үзем дә бик ерак киттем бугай инде бу җырлардан...**
**...Бер мин генә түгел инде илдә—«җыры җырланган...»**

**Мин ризамын—алай ук фаҗигале булмасын җырлар—**
**Юк, кайтмасын иде ул чорлардагы фаҗигаләр...**
**Ләкин минем халкым күпме бәхетле булса да, гәрчә—**
**Шушы җырны алып барсын... Алып барсын гүргәчә...**

*Русчадан Гәрәй РӘХИМ тәрҗемәсе*

❋

Адлер Тимергалин

# ИКЕ САНДЫК ЙАКУТ

## «ГАБДУЛЛА ТУКАЙ. ШИГЪРИЯТ ТЕЛЕ» ДИГӘН ИКЕ ҖИЛДЛЕ СҮЗЛЕК НӘШЕР ИТЕЛҮ УҢАЕННАН

*Бүгенге цивилизация—сүзлекләр цивилизациясе ул.*

Алан Рэй,
француз лингвисты

2009 елда «Мәгариф» нәшрияты «Габдулла Тукай. Шигърият теле» дип исемләнгән сүзлек бастырып чыгарды. Басма ике китаптан тора, тулаем күләме 95 табаклар чамасы (1030 бит), тиражы 2000 данә.

Сүзлекне төзү эшен Казан дәүләт университетының филология факультеты, теоретик һәм гамәли лингвистика кафедрасы хезмәткәрләре—филология фәннәре докторы Камил Галиуллин һәм Резеда Кәримуллина бүгенге фәнни югарылыкта һәм пөхтә итеп башкарып чыкканнар.

Милли шагыйребезнең теле белән кызыксыну һәм аны өйрәнү бер бүген генә башланган эш түгел. Моннан байтак еллар элек (60нчы елларда) Тел, әдәбият һәм тарих институтында бүлек мөдире булып эшләгән Г. Әмиров, Габдулла Тукайның лексикасын һәм фразеологиясен өйрәнеп, филология фәннәре докторы дәрәҗәсен алу өчен язган диссертациясенә кушымта рәвешендә шагыйрьнең сүзлекчәсен дә әзерләгән иде (бу хакта аның үзенең миңа сөйләгәне булды). Ләкин Әмировка Казанда озак эшләргә туры килмәде, тиздән ул Алма-Ата шәһәренә күчеп китте, диссертациясенең 75 битлек авторефератын да шунда бастырып чыгарды. Каралама сүзлекчәнең язмышы миңа билгесез, һәрхәлдә аның дөнья күрмәгәнлеген генә беләм, чөнки ул рефераттан башка яши ала торган мөстәкыйль хезмәт түгел.

Кулыбыздагы сүзлек исә бөтенләй башка нигезгә—Казан лингвистика мәктәбе принципларына—корылган.

Сүзлекнең төп өлешен конкорданс бүлеге—Тукай шигырьләреннән алынган цитаталар белән китерелгән сүз формалары күрсәткече алып тора. Бу күрсәткеч алфавит тәртибендә төзелгән. Гомумән, конкорданс сүзнең (сүз формасының) теге яки бу әсәрдә, шигырь строфасында һәм шигырь юлында нинди контекстта, нинди бәйләнештә, ничә тапкыр очравын (ешлыгын) күрсәтә. (Сүз җае чыккач, 1869 елда Казан архиепископы Георгий акчасына Коръәннең тулы конкордансы нәшер ителгәнлеген искәртеп үтәсем килә; әгәр бүген мондый белешмәне татар телендә әзерләп бастырып чыгара алса, безнең мөфтият төрки дөнья күләмендә искиткеч зур эш майтарган булыр, Тукай текстларында шактый мул очрый торган дини төшенчәләрне аңлау-аңлату эше дә җиңеләер иде).

«Габдулла Тукай. Шигърият теле» сүзлегенең конкордансында кулланылышы чикләнгән (искергән, диалекталь, алынма һ.б.) сүзләргә, ялгызлык исемнәргә кыскача аңлатма бирелә. Укучы сүзнең мәгънәсен ачыкларга теләсә, аны башка сүзлекләргә юнәлтү алымы кулланылган. Гомумән, 18400 сүз мәкаләсе 2000 ләп төрле аңлатма белән тәэмин ителгән.

Сүзлеккә теркәлгән цитаталарның адресында шигырьнең шушы сүзлектә кабул ителгән номеры, строфаның һәм шулай ук шигырь юлының номеры күрсәтелә. Бит номерлары күрсәтелми, бу исә укучыга Тукай шигырьләренең төрле басмаларына таянырга мөмкинлек бирә.

Сүзлеккә теркәлгән берәмлекне Тукайның төрле басмаларыннан (1985, 1975—76, 1955 һәм 1943 елгы басмалар) эзләп табу өчен икенче китапның ахырында «Шигырьләрнең алфавит күрсәткече» дигән кушымтадан файдаланырга кирәк. Бу кушымтада Тукай шигырьләренең төрле басмалары арасындагы аермалар да күрсәтелә.

Сүзлекнең төзелеше турындагы бүлекчәдә әйтелгәнчә, «Конкорданс кысаларында [берәмлекләргә] тулы аңлатма бирү күздә тотылмый, шулай ук сүзнең Тукай текстындагы мәгънәсен ачу бурычы куелмый». Берәмлекләргә кинәйтелгән аңлатмалар Сүзлекнең Интернеттагы компонентында биреләчәк, ә бу кушымта-компонент тулысынча әзер икән.

«Сүз формаларының кире күрсәткече» аерым әһәмияткә ия. Татар лингвистикасы өчен монысын, гомумән, яңалык дияргә мөмкин. Аерым очракларда ул текстларда очрый торган теге яки бу формаларны төгәлрәк аңларга, нигезләргә һәм төзәтмә кертергә дә ярдәм итә. Ихтимал, ул Тукай рифмаларын өйрәнүчегә дә таяныч булыр.

Тагы бер кушымтада «Г.Тукайның иске татар әдәби телендә язылган шигырьләренең тексты» туплап бирелә. Шигырьләр хәзерге әдәби телгә юлга-юл тәрҗемәләр белән тәэмин ителгән.

Тукайның неологизмнары һәм протологизмнары мәсьәләсе белгечләрнең аерым тикшерүен сорый.

Сүзлектә кулланылган шартлы билгеләргә нечкәләп тукталу кирәкмәстер. Татар укучысы өчен яңа булуларына да карамастан, белешмәдән файдаланучыга ул тамгаларга күнегү кыен түгел дип уйлыйм. Шулай да бу Сүзлек укучыдан, маңгайны җыерып, баш мие җыерчаларын да эшкә кушуны сорый.

Төзүчеләр файдаланган чыганаклар арасында, әлбәттә, татарның ядкәри «Гарәпчә—татарча—русча алынмалар сүзлеге» беренче урында тора. Ана юнәлткәндә төзүчеләр «ГФ» кыскартылмасын куллануны кирәк тапканнар. Бусы да бик дөрес эшләнгән, чөнки әлеге сүзлекнең «дилбегә буе» атамасы аның эчтәлеген дөрес чагылдырмый (сүзлектә фарси алынмалар да житәрлек бит).

Тагын бер мөһим нәрсәне искәртеп китик. Тукайның компьютер фондын эшләгән вакытта Сүзлекнең авторлары шагыйрьнең 1985 елгы академик басмасында киткән аерым хаталарны һәм төгәлсезлекләрне ачыклап, сүз формасын алдагы басмалар буенча тикшергәннәр һәм ул урыннарга төзәтү керткәннәр (мәсәлән, академик басмадагы абый (дөресе—«абзый» булырга тиеш икән), әзһәбенне—мәзһәбенне, каризләре—кариэләре, хыялымнан—хыярымнан һ.б.).

Бу сүзлек белән җентекләп танышканда мин Тукайның инде онытыла төшкән сурәтләрен хәтеремдә яңарттым. Мин Тукайда үзем өчен яңа нәрсәләр ачтым. Яңа метод буларак, конкордансның шундый хикмәтле хасияте бар, ахрысы: элек аерым-аерым йөргән сүзләр һәм сурәтләр укучы аңында бергә оешалар, ана теленнең элек тырышып-тырышып та колачың житмәгән илаһи чиксезлеген берьюлы иңләгән, аңлаган кебек буласың... Нәтиҗәдә Сүзлек гаҗәеп ассоциацияләр уята. Бу мәкаләмне язганда мин шушы «Тукай конкордансы» кузгаткан субъектив тәэссоратларыма да таяндым.

Егерменче гасыр башында ук мәңгелек дөньяга күчкән Тукай бүген безнең замандашыбыз булып яши икән—иң әүвәле мин шуңа ышандым. Адәмнәрнең психологиясе бер гасыр эчендә тамчы да үзгәрмәгән. Ләкин бу канкоюлы болгавыр чор адәми затның биологик күнел төпкелендә йокымсырап яткан динозаврны уяткан—фаҗига шунда. Бүген арабызда менә шул борынгы ерткыч тантана итә. Эреле-ваклы Һитлерлар, Сталиннар, Пол Потлар, Төрекмән башлары—динозаврдан. Ә аларның масштаб ягыннан ваграклары бихисап булганга, кешелеккә китергән

зыяннары, ихтимал, «бөек»ләренекеннән ким түгелдер.

Тукай заманы белән бүгенге көн арасында параллельләр күп, бик күп. Шуна күрә әлеге сүзлектә без тәнгәл төшенчәләрне бик мул очратабыз. Тукайны укыйбыз да, анын нәкъ бүгенге көн кадагына суккан сүзләренә исебез китә.

Параллельләр һәм ассоциация дигәннән.

Һәр ике замандагы кол-куштан психологиясе, әллә каян пәйда булган һәм куып таратылган бичара Думалар, бик күп вәгъдә итүчән ике йөзле демократия, бушбугазлык...

Тукай әйтмешли, әлләкемнәр кереп «тулган» Дума өметләребезне акламады. «Ах, Дума, Дума, Дума... Эшләгән эшен бума?»

Патша заманындагы Думага сайланган татар депутатларын Тукай бер дә өнәмәгән.

Менә, мәсәлән, патша чорында II һәм III чакырылыш Дәүләт Думасы депутаты, мөселман фракциясе әгъзасы Садрый Максуди. 1907 елнын 15 маенда Думада ясаган чыгышында халык мәгарифе мәсьәләләрен күтәреп, 1874 елгы реформа нигезендә Европа һәм Себердәге алты мен мөселман мәктәбенен элеккеге мохтарияте (автономиясе) бетерелеп, аларнын мәгариф министрлыгына буйсындырылуын, яна мәктәпләр ачуга рөхсәтнен фәкать мәҗбүри рәвештә рус теле кертү шарты белән генә бирелүен, ләкин мәктәпләрнең берсе дә дәүләттән субсидия алмавын әйтә. Ул мөселман халыкларынын башлангыч белемне туган телләрендә алырга тиешлеген күрсәтә һәм сүзен: «Без, мөселманнар, анлы рәвештә туган телдә, ягъни һәр мөселман халкынын үз телендә укыту ягында торабыз һәм бу системаны үзенен изге эшенә тугры халык кулында булган барлык чаралар белән яклаячакбыз»,—дип тәмамлый. Максудинын чыгышыннан өземтәне «Собрание речей Гг. Депутатов Государственной Думы I и II созыва» китабыннан алдым *(С.-Петербург, 1908).*

1912 елгы сайлауларда Максуди IV Думага депутат булып сайланмыйча кала һәм заманында бу фактка Г. Тукайнын сатирик каләме дә җәмәгатьчелекнен игътибарын юнәлтә. Монда Шагыйрь бик үк хаклы булмаган, мин хәтта Тукай бу очракта бераз көнләшкән дә кебек дип уйларга җөрьәт итәм. Әгәр көнләшкән булса, юкка көнләшкән: Такташ әйтмешли, «нарком булып» сайлана калса, Шагыйрь Тукай Думанын «алты-биш» утырышыннан сон ук Петербургтан чыгып качар иде...

Анын бүгенге курчак депутатларга мөнәсәбәте тагы да кискенрәк булыр иде.

Ничек кенә мактасан да, демократиянен йомшак, кимчелекле яклары бар.

Нәкый Исәнбәт сүзләренә караганда, 1917нче елларда Уфада җәмәгать җыелышларында мәсьәләне йодрык белән хәл итүдә Фәтхи солдат дигән кеше мәшһүрлек казанган. Шунысы кызык, егерменче гасыр азакларында һәм егерме беренченең башында иҗтимагый тормышта (шул ук җыелышларда), хәтта дин-рухият әһелләре арасында да шушындый «Фәтхи солдатлар», ягъни солдафоннар һәм матрос Железняклар күзәтелә. Зыялыларга болар белән көрәшү җинел түгел. Зыялылар демократиясе «йодрык сугышы»на хәзерлексез—тәрбия башка, культура бүтән...

Бүген дә бездә бөтен юллар бердәнбер мәркәзгә—Мәскәүгә илтәләр. Акча да пәрәвез оясынын мәркәзендә туплана. Бөтен идарә җепләре шушы мәркәздән регионнарга таба сузылган...

Регионнарнын кулы богаулы.

Җирле түрәләрнен баш миен: «Как ты будешь отвечать там, тотса мәскәүләр якан?» дигән коточкыч сорау бораулап торганда, алардан халыкка җинеллек китерердәй чын инициатива көтү авыр, әлбәттә. Хакимият вертикале түбәнге постларга Салтыков-Щедриннын механик «органчик»ларын утырту турында гына кайгырта һәм «әкрен-әкрен китерәдер көйгә бу». «Органчиклар» исә беренче нәүбәттә мәдәният бакчасындагы Апушларны, Габдуллаларны утап чыгалар.

Без инде барлы-юклы мохтарият казанышларыбызны да җуеп барабыз бит. Кабат латиницабызга күчәрбез дип күпме өметләнеп йөрдек, бу өметләрне чираттагы курчак Дума буып ташлады. Менә тагы ЕГЭ—бердәм дәүләт имтиханы дигән афәт чыкты, шунын аркасында татар мәктәпләре фән нигезләрен русча укытуга күчәргә мәҗбүр ителделәр. ЕГЭ (БДИ) милли мәгарифнен тамырына балта чаба...

Тукай әйтә: «Кап-кара кол белми хөррият дигән сүз кадрене»,—ди. Без дә

хөрриятнең кадерен белмәдек, гөнаһкяр Ельциннар, Горбачевлар һәм Гайдар кулыбызга тоттырган хөррият кошының канатын каерып, мәсхәрә иттек, аны янә хакимият вертикаленә алмаштырдык.

Сүзлектә теркәлгән Һималая атамасына карата. Икенче китап, 303 б.: «Һималая тау өстендә алтын бишек, /Кояш йоклый һәр кич саен шунда төшеп» *(Тукай, «Ай һәм кояш» шигыреннән).* Азиядәге бу таулар системасы хәзерге география терминологиясендә, русчага ияреп,—Гималай (таулары) рәвешендә бирелә. Ләкин атаманың килеп чыгышы санскрит телендәге hima—кар һәм alay—урын сүзләре белән бәйле (башка фикер дә бар, ләкин һәр очракта сүзнең беренче хәрефе «h» яки «x» булып кала). Инглиз, немес һәм француз телләрендә Himalaya яки Himalaja, ягъни Тукай заманындагы татарча язылыш беренчел чыганактагыга тәңгәл булган. Дөрес булган! Ә без ... әлифба алмаштыра-алмаштыра, «тәки» юлдан язганбыз.

Бу сүзне шигъри йакут дип атап булмаса да, терминология, этимология һәм орфография фәннәре өчен энҗе белән бер дәрәҗәдәге мисал ул. Һәрхәлдә ул безне телебезнең тарихы һәм киләчәге турында уйланырга мәҗбүр итә. Күрәбез ки, 30нчы еллар ахырында мәҗбүри рәвештә кириллицага күчү безнең орфографиябезгә тискәре тәэсир ясаган, без сүзнең әйтелешендә дә беренчел өлгедән бер дә кирәксезгә ераклашканбыз икән (Стокһольм, Һолландия һәм хәтта Таһран-Тыйһран рәвешендә язылырга тиешле сүзләрдә дә). Бөтен фаҗига шунда—дөреслеккә кайту кайчак мөмкин дә түгел инде. Кәрван китеп барган була...

«Нинди күп бездә ятимнәрне талаучы бәндәләр!» Бу сүзләр дә Тукайныкы.

Баксаң, бүген без, «Бердәм Рәсәй» дия-дия шапырынып, «Ятимнәр империясе»нә әйләнеп барабыз бит!

Ярты планетаны ипекәй белән тәэмин итә алырлык иксез-чиксез Рәсәйдә «ач үлемнән куркусыннан [ярты] ил җылый»... «Бу сәнә ачлык җылавы чын халык бәгърен ашый!»...

Чыннан да, бүген чүплек башларында казынучы бичаралар арасында ипи сыныгы кимереп торучы бомжларны гына түгел, зәңгәр иренле гади (дәрәҗәсез) пенсионерларны да очратасың. Кем белә, бәлки иртәгә без мәчет катындагы теләнчеләр арасында бүгенге берәр миллиардерның соранып торуын да күрербез. Нәкъ Тукай язганча...

Ничәмә-ничә мең гектар уңдырышлы җир сөрелмичә ята, кысыр кала. Басуларны кылган баскан... «Шүрәле асрап ята торган» кара урманнарны да кисеп-егып киләләр... Авыллар аша узганда җимерек ферма кабыргаларын күргәч, күңел сызлана. Сугыш үткән җирләр диярсең... Җир инри... «Изге, шәфкатьле анабыз—мәрхәмәтле җир җылый...»

Йа, нинди гайре табигый хәл соң бу?! Нинди мәнсезлек?! Урыслар мондый күренешне мерзость запустения диләр. Библияви сүз инде. Татар зыялылары әле моның тәңгәл тәрҗемәсен табып өлгермәгән, ләкин Тукай... Тукай булса табар иде.

Сүзлекнең конкордансында теркәлгән «йөз» сүзенә Тукайдан 26 мисал китерелә. Белгәнебезчә, «йөз»—күп мәгънәле сүз. Хәлбуки, Сүзлектә аңа аңлатма-мазар бирелми, укучыны «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»нә яки башка чыганакка юнәлтүче күрсәтмә дә юк.

«Вә әсәф! Ачлык вә коллыктан бүтән һич бездә юк. /Шул гаҗәп: ник бу егерменче гасырда йөз дә юк!»—дип сүз уйната Тукай яшь аралаш.

Шагыйрь күңеле егерменче гасырның битсез (йөзсез, чырайсыз) һәм кимчелекле булачагын сизә... Егерменче гасыр... Рәсәй-Русия, СССР һәм янә Россия Федерациясе «башаягы белән оттырган» битсез гасырыбыз... Ә бит егерме беренче гасырның да йөзе алдагысыннан матуррак булырга охшамаган... Алар икесе дә икейөзле...

«Читен тормыш!—капиталга табынмасаң...» Әйе, бүген капиталга табынучылар заманы килде. Кичәге фирка-совет житәкчеләре һәм аларның чагалары халык җилкәсен кимерә дә, хаксыз туплаган акчаларын чит ил банкыларына күчерә, анда аксарай шикелле виллалар салдыра... Гади халыкка ни кала? Ул инде, гадәтенчә, вак-төяк урлашу белән мәшгуль. Рәсәйдә алдау һәм ялган патшалык итә.

«Мөселман каз[ы]лыгы чыккан базарга...»

Хәзер дә чыкты бит андый казылыклар, пилмәннәр. Бәяләре генә мөселманча

түгел—дөньякүләм финанс империясе әһелләре кушканча.

Мин Тукайны бүгенге Казан урамнарында йөргән, радио тыңлаган, яшьти Шүрәлесе белән бергәләп телевизор карап утырган кыяфәттә күз алдыма китерә алам-алуын. Тик менә, әйтик, берәр фирка яки, әйтик, ПЭН-клуб әгъзалары җыелышында утырган Тукай һич кенә дә күз алдыма килми. Аның Шүрәлесе рәсми җыелыш-утырышларны бер дә өнәмәгәндер...

Телевизор экранында чытлыкланып, тырыша-тырыша авызын бөрештереп һәм шакмакландырып сөйләүче маймунә (чибәр) дикторлардан Шүрәле белән ярыша-ярыша көләр иде Тукай! Алар бит икәвесе дә—табигать баласы, чынлыкны сөяләр, битлек кигән ясалмалыкка һәм фальшка дошманнар.

Тормыштагы ялыктыргыч һәм күңелсез хәлләрне—тормыш прозасын Тукай, шигърияткә каршы куеп, «нәсер» дип атый (бу сүз «Шигърият сүзлеге»нен конкорданс бүлегендә юл хәрефләре белән җыелып, аның янына унга таба юнәлгән ак ук куелган һәм 3.1 дигән шартлы адрес күрсәтелгән, ягъни бу сүзне кушымтадан—«Шигырь исемнәрендә һәм баш өлешләрендә теркәлгән сүзләр күрсәткече»ннән эзләп табарга кирәк. Бусы беркадәр уңайсызлык та тудыра сыман. Ә конкрет бу очракта «нәсер» сүзенең тормыш прозасы мәгънәсендә килүе бүгенге укучы өчен ачылып бетмичә кала. Монда Тукайның руска һәм гарәбкә ияргәнлеге аермачык).

Тукайны шагыйрьгә һәм прозаикка аерып карау аның табигатенә каршы килсә кирәк. Кулыбыздагы бу Сүзлек исә Тукайның шигърият телен теркәүне максат итеп куйган. Сүзлекнең «Кереш»ендәге сүзбашына караганда, «Казан дәүләт университетының филология факультеты, теоретик һәм гамәли лингвистика кафедрасы Тукай фонды нигезендә рифмалар, искергән сүзләр, проза, хатлар сүзлекләре кебек төрле төрдәге белешмәлекләр» төзү белән дә шөгыльләнә. Шуңа күрәдер, мәсәлән, «куштан» сүзе Сүзлеккә «Казан вә Казан арты» шигыренә нисбәтән генә теркәлә, аның Тукай цитата рәвешендә китергән халык җырларындагы мәгънәсе ачылмый кала («Сөйгән генә ярың булса куштан, /Чыгарасың килми куеныңнан»—монда фарсы чыгышлы куштан сүзе «тәмле, татлы телле» мәгънәсенә ия).

Бәрәңге... Соңгы гасырларда Рәсәй тарихын алга тәгәрәтүче гаять әһәмиятле нәрсәкәй...

«Яуме мәхшәрсез онытмаслар бәрәңгемне минем...» (конкорданста—363-3:2). Әгәр мич башында түшәмгә төкереп, «чуртан кушуын» көтеп яткан һәм һәр яңаны «кара майт» белән каршылаучы халыкны Рәсәй патшасы мәҗбүриләп америкаң бәрәңгесе үстерергә өйрәтмәгән булса, җир йөзендә бүген Россия федерациясе дигән алагаем зур мәмләкәт яшәр идеме соң? дисең.

Бәрәңге кебегрәк йомарлак нәрсәгә чыра аяклар калап ясалган тәгәрмәчле уенчык ат (?) янында палас җәйгән сәкедә катыклап бәрәңге ашап утыручы сабый Габдулла күз алдыма килә. Бер кулында—тәмле ипекәй. Хаҗи-Морат Казаковның картинасы шундый булып исемдә калган. Бәләкәй Габдулла, нигәдер, фоторәсемдәге кебек туп-туры сиңа караган төсле. Йа, сабыйлар күзендә бу кадәр моң буламени? Бу кадәр ... уй? Яшь килә... күздән яшь килә... Аннары мин хыялымда бу картинада сабый янына бүгенге Тукай томнарын һәм менә шушы Тукай сүзлеген тезеп куям. Үзем елмаям, ә күздән яшь ага... Әтисе ГУЛАГ ятьмәсенә эләккәч, дөньяның «розасын» гына түгел, Тукай әйткән «угроза»ларын һәм «розга»ларын татыган, ары сугылып, бире сугылып гомере буе хаклык эзләгән рәссам Хаҗи-Моратны да кызганам мин. Сүз уңаеннан әйтеп китим, Казандагы Бауман урамында нәкъ «Матбугат йорты»на каршы урнашкан тәбәнәк йортта Хаҗи-Морат Казаков гомер кичергән ике тәрәзәле бүлмәдә ул үзе «Тукай «Кәфер почмагы»нда» дип атаган рамсыз (димәк, тәмамланмаган) картинаны күргәнем бар. Бу картинаның язмышы миңа билгесез. Ихтимал, картина Кырлайның Габдулла Тукай исемендәге музей фондларындадыр.

Тукай...

Галәттә, Тукайның үз сүзләренә ияреп, аны рус шагыйрьләре Пушкин һәм Лермонтов белән янәшә куюга тап буласың. Ләкин психология күзлегеннән карагандa, Тукай мәшһүр рус шагыйре Василий Жуковскийга якынрак. Жуковскийның әнкәсе—1770 елда Бендеры (фарсы һәм төрек телләрендәге мәгънәсе—«гавань», култык) шәһәрен алганда русларга әсир төшкән төрек кызы Сәлиха. Ә биологик әтисе—әсир

кызны үзенең кәнизәге һәм беркетелмеш колы иткән өлкән яшьтәге рус алпавыты Бунин. Василий туганнан соң, баланы әнкәсеннән аералар һәм ул рус җирлегендә, аристократик шартларда тәрбия ала... Жуковский белән Тукайның күнел нечкәлеге һәм романтикасы шушы ятимлектән, нәкъ кеше булып житешкән мизгелдә әйләнә-тирәндәге җансыз бушлыкны тоюдан, фани дөньянын тотрыксызлыгын аңлаудан, иң кирәк чагында ана мәхәббәтенең шифалы җылысын алып бетермәүдән дә килә торгандыр. Аларның тагын бер уртак ягы бар—шагыйрьләр икесе дә «яшерен сөю» афәтен кичергәннәр... Әйе, аларның күңелләре китек булган, мәҗрух. Бу гигант шәхесләрне челпәрәмә килеп ватылган һәм вакыт-патша иркендәге табигать исемле оста табиб-реставратор тарафыннан җилемләп, кабат тормышка кайтарылган искиткеч гүзәл фарфор ваза белән чагыштырырга бик мөмкин.

Кулыбыздагы сүзлекнең конкордансыннан Жуковский фамилиясен эзләп тапсагыз, Тукайның: «Мокътәбислектә Жуковский зур остазым минем» дигән сүзләренә тап булырсыз... «Безгә ят, чит телдәге изге фикерне тәрҗемә /Биш вакытта биш намаз күк керде инде фарзыма»,—дип яза ул «Буш вакыт» дигән шигырендә.

«Безнең Тукайны тәрҗемә итә белмиләр шул»,—дигән зарны ишетергә туры килә. Ихтимал, дөрестер дә. Әгәр тарих куласасы кирегә әйләнеп, Тукай шигырьләрен аның рухи карендәше Жуковский тәрҗемә итеп бирсә, шәркый йакут һәм җәүһәрләр нурыннан рус укучысының күзләре камашыр иде.

Бер факт. 2006 елда «Нева» нәшрияты тарафыннан нәшер ителгән өч томлы иң бай «Афоризмнар» китабында, әйтик, элекке премьер В. Черномырдинның анекдотка лаек сүзләре күзгә чалынды, ә Габдулла Тукайдан алынган бер генә цитата да таба алмыйсың. Бу абруйлы, саллы басманың төзүче авторлары А.Ю. Кожевников белән Т. Б. Линдберглар Тукайны белмиләр, Россиядәге төрки әдәбият эченә алар, гомумән, кереп тормаганнар. Их, дисең, төпле акыллы бер татар егете табылып, Тукайның һич югы бер-ике дистә канатлы йакутларын һәм энҗеләрен бер җепкә тезсә иде дә, Жуковскийча шигъри (!) тәрҗемәдә ошбу авторларга бүләк итеп җибәрсә иде...

Тукай сүзләрне кушып-ялгап яңа берәмлекләр ясарга маһир (мәс., әһлинсафлә—әһле инсаф лә—инсафлы кешеләр ич, балүрдәк—бала үрдәк, беләлмисең, тизүк, яумасайде, яп-яхшук, шулайтеп, эсситеп—эссе итеп, өстеналып—өстенә алып һ. б.).

Кайчагында Шагыйрь, мавыгып китә дә, яна сүзләр оештырып, уйнап ял итеп ала, безне дә елмайтырга ярата. Менә аның кайбер «гарәпчә яна масдарлары»: тәвәррес—руслашмак, тәвәррек—төрекләшмәк, тәяппен—японлашмак, тәнәммес—немсәләшмәк...

Монда уены-чыны бергә.

Бу «ләшмәк-лашмак»ларның берсе дә безгә кирәкми бит, милләттәшләр! Бигрәк тә руслашу белән төрекләшү дигәне колакны сагайта, ә соңгылары безгә куркыныч түгел ... Төрекләшү-төрекләштерү мәсьәләсендә Тукайның төпле фикере билгеле: «Андый мөхәррирләребез татарларны төрекләштерергә аз тырышмадылар. Ләкин булдыра алмаслыкларына тәмам күзләре житкәч кенә туктадылар.»

Руслашуга килгәндә, без катгый: «Нет!» дигән сүзне генә белергә тиешбез.

Дөресен әйткәндә, бүгенгесе көндә безгә,—башка халыклар белән бергә, русларны да кертеп,—кабат маймыллашу һәм роботлашу куркынычы яный. Кайсысы хәтәррәктер? Әллә соң алар бер үк нәрсә булып чыгармы? Һәрхәлдә—тормышның ачысын-төчесен татып үсә-камилләшә торган кеше сыйфатларын җую булыр... Ә ахырын кем белә? Массакүләм компьютерлаштыру соңгы исәптә яман нәтиҗәгә китерер төсле... Без, чынбарлыктан качып, ясалма дөньяда төш кебек татлы хыяллар кочагында яши башларбыз микәнни?..

Ачы чынбарлык татлыны татып карарга чакыра.

Менә бүгенге Казанда кая барсаң, шунда «тәтәйләр рәте»н күрәсең... Диварлар гарби европалы «sex» сүзе һәм «төнге күбәләкләрнең» телефон номерлары белән тулган... Ул язуларны кырып та карыйлар, буяп та карыйлар... Файдасызга! Кыз-кыркыннар пәрдәсезлеккә мәктәптә үк өйрәнеп, актин-ак «өлгергәнлек аттестаты» алып чыгалар бит... Ә Тукай заманындагы «проститутка Наташа, Мәрьям, Рабига, Гайшә»ләргә сары кәгазьгә басылган мөһерле паспорт («сары билет») бирелә торган булган... Без дә бүген фәхешханәләрне рәсмиләштерү алдында торабыз шикелле.

Мобильниклы фахишәләрнең һәм аларның сутенерларының да паспортын «сарыга» алмаштру файдалы булыр иде.

Егерменче гасырның беренче чирегендә яшәгән һәм хакимияткә килгән шашкын рус/еврей революционеркаларының женси мөнәсәбәтләрне «бер тустаган су эчүгә тиңләү теориясе» бүгенге яшүсмерләрнең төнге субкультурасында гарип һәм вәхши төстә чыңга ашканын күрәбез. «Афоризмнар» китабына теркәлгән «Эротика—сәнгать ул, ә порнография—тормышның үзе» дигән сүзләргә тикле барып житкәнбез... Илаһидан иблисигә кадәр бары тик бер генә адым икән ...

Без бүгенге яшьләрнең психологиясен аңлый алмыйбыз.

Аталар белән балалар арасындагы аңлашылмаучылык кадимнән үк, Адәм һәм, әйтик, Нух пәйгамбәр заманыннан ук килә ич дип үз-үзебезне алдамыйк. Мондый фикер, икесенең дә хортумнары булганга, чебенне фил белән тиңләүдән башка нәрсә түгел. Кичә мәхәббәтле Адәм заты ишәюга юл тоткан булса, бүген дәһри илебез, балалар аз туу һәм зәгыйфь туу сәбәпле, дәһшәтле демографик упкын якасына килеп житкән инде.

Әйдәгез, артка, артка—мәңге яшь һәм саф табигатькә табан!

Менә монда инде без Габдулла Тукайның: «Артка бакма, даһием, идеал һаман да алда ул» дигән сүзләре белән килешә алмыйбыз төсле. Хәер, моны әйткәндә мин офык артындагы ялган мираж-сагымнарны гына күздә тотам.

Актара торгач, Сүзлектә Тукайның: «Эчә халык суык дип тә, бәйрәм дип тә, /Эчә халык хәләл дип тә, хәрәм дип тә» дигән юлларына тап булдым. «Их Тукай, Тукайгынам» дими ни диим? Тукайның вафатыннан соң 20—25 еллар үткәч, олы сугыш чыгар алдыннан, безнең авылга күрше Карамалы базарында «ике борынга» бер «чөлли» (чәкүшкә) кәгеп, жәяү генә жырлый-жырлый алпан-тилпән кайтып килгән агайлар турында бөтен авыл атна буе сөйләгәне истә әле... Бүген исә алкогольләшү ягыннан Татарстаныбыз Идел буенда, көмешке коярга бездән күпкә маһир чуашларны да артта калдырып, беренче урында тора имеш. «Год трезвости в Казанской губернии» (Казань, Типография Губернского Правления, 1916) китабына ышансак, Тукай заманында мөселман (жан башына) эчкән исерткеч күләмен тустаганлап үлчәп булган әле, егерме беренче гасырга чыккач, моны көянтә-чиләкләп үлчәргә туры килә. Өстәвенә әфьюннең «героин» дигән тагы да усалрак төре пәйда булды. Барын да белүче статистика героин сатылу буенча да Рәсәйнең беренче урында торганын күрсәтә.

Айну кирәк. Юкса—инкыйраз.

Без бүген «житлеккән һәм чыныккан милләт» дәрәжәсендә калу өчен имтихан тотабыз. Моның өчен безгә аек, саф акыл кирәк.

Менә «Тукай конкордансы»ыннан тагын бер сүз: «Жиһанда болгарың вар улдыгына канигъ улсыннар; /Безем парлак бәхеткә гыйбтачы һәм тамигъ улсынлар.» (241б.)

Моның бүгенге татар теленә тәржемәсе: «Дөньяда болгарлар әле дә бар икәненә ышансыннар; /Якты бәхетебезгә көнләшеп һәм үзләре дә [шуна?] омтылсыннар [?]». Безне бу тәржемә канәгатьләндерми. Иң әүвәле шул: монда, күбәүләр уйлаганча, Шәһри Болгар турында сүз бара дип белөм, болгар кауме турында түгел. Аннары бу шигырь юлларының Гали Чокрыйга катнашы бар түгелме? («Гарәпчә—татарча—русча алынмалар сүзлеге»ндә шулай күрсәтелә). Тукай Гали Чокрыйның фикерен цитата рәвешендә генә файдаланган булырга мөмкин. Мондый алым Шәрык шагыйрьләренә хас, ул сарика (плагиат, ягъни әдәби караклык) булып исәпләнми.

Сүзлекне төзүчеләр кайбер сүзләргә кайсы чыганакта аңлатма бирелүен дә күрсәткәлиләр, ә күпчелек сүзләрнең мәгънәсенә Тукайдагы мисаллардан ук төшенәсең. Шулай да шәрык алынмаларының байтагы аңлатуга мохтаж, чөнки Тукай ижаты житәрлек тикшерелмәгән, аның тел байлыгы аз өйрәнелгән, шактый сүзләр, әйтик, ГФ сүзлегенә дә кермәгән. Өстәвенә, кайбер гарәпчә яки фарсыча окказиональ (очраклы) сүзләрне алынма дип атау да читен... Дөрес, «Шигърият теле»нә кушымта рәвешендәге «Тукайның иске татар әдәби телендә язылган шигырьләренең тексты» бүлеге «хәзерге әдәби телгә юлга-юл тәржемәләре белән» тәэмин ителгән, бу исә чит-ят сүзләрнең мәгънәсен белеле бер дәрәжәдә ача дип әйтер идем. Шунысы гына кызганыч, кайчак бу тәржемәләрне шагыйрь каләме түгел, кичәге «пуркилар» каләме генә эшләгән кебек тәэсир кала...

Сүзлектә пырак сүзенә «жәннәттәге фантастик ат» дигән кыска гына аңлатма бирү

кирәк табылган. Төзүчеләр укучыны ГФ һәм МС чыганакларына юнәлтәләр, ләкин МС («Миллият сүзлеге») бу сүзнең мәгънәсен башкачарак аңлата, аны җәннәткә генә кайтарып калдырмый. Җөрьәт итеп, шуны да әйтеп китим: «Миллият сүзлеге»нең хәзергә кульязма хәлендә генә яткан тулы версиясендә Борак/бурак/пырак сүзенең аеруча тулы аңлатмасы бар.

Ятим тормышында, ифрат җайсыз көнкүрешендә Шагыйрь Тукай әдәпсез сүзләр ычкындыргалаганмы-юкмы икәнен мин тәгаен белмим. Ә Тукайның шигырьләрендә мин сүгенүгә тартым «И пычагым кергере!», «Кит! пычак керсен җиһанның барча сандугачына!» һәм «Җен оргыры!» дигән усал сүзләрне генә хәтерлим. Беренчесе төнлә кеше бимазалап, тәрәз кагып йөрүче су анасына карата әйтелә. Борынгы сүз булса кирәк. «Ни пычагыма...» кебек гыйбарәләргә караганда, монда «пычак» эвфемизмга да охшыйохшавын. Әзләнеп маташмагыз, Нәкый Исәнбәт бу хакта төпле сүз әйтмәгән.

Кыскасы, Тукай үз иҗатында, Шүрәлесен авызлыклап, «шакшы сүз»ләргә табу салган, авыз пычратмаган. Бу яктан ул яшь Пушкинны түгел, инде житлеккән һәм карарлашкан нәфис Пушкинны хәтерләтә. Битараф язмыш ниләр генә кыландырмасын, Шагыйрь Тукай әнкәсе теленә кер кундырмый, «ана» сүзе аның өчен мәңгегә изге, илаһи төшенчә булып кала. Беләсезме, Такташыбыз да, «кызып китеп», Чемберленның «анасын сатып» маташмаган булса әйбәтрәк буласы иде дә бит...

Тел нәфислеге мәсьәләсендә «Габдулла Тукай. Шигърият теле» белешмәсенең авторлары да минем бу фикерем белән килешерләр дип өметләнәм.

Спортта алтын медаль яулап алу өчен чит илләрдән саф алтыннан да кыйммәт бәягә төшереп төрле төстәге легионерлар чакырып китерергә мөмкин икәнен беләбез. Ләкин әдәбиятта легионер Тукайлар булмый, аларны туган туфракта, үзебезнең шифалы чишмә суларын сибеп, үзебезнең бишек җырларын—«әллүкибәллүки»ләрне көйләп үстерергә кирәк. Чын шагыйрьлек «чишмәләр дә акмый тынлый» торган җырларны җырлап үссән генә чәчәк ата. Тагын... тагын Шагыйрь аяз күктә җемелдәшкән серле йолдызларны, әллә инде тулып ашкан күкрәгеннән ана сөте чәчрәгәнгә аксыл-аксыл Киек Каз Юлын күреп үсәргә тиеш—югары, гали хакыйкатьләрне тою өчен патшави Кояш белән Айны гына белү житми, алар тирәсендәге бихисап «халык»ны да күрә белергә, бер мизгелгә йолдыз булып кабынган тузан бөртегенә кадәр яратырга кирәк дөньяны...

Аннары. Ятимнәрнең һәркаюсы үзенең «исендә калганнар»ын озын-озак иттереп яза ала, әмма һәр Апуштан Тукай чыгалмый. Табигать бушлыкны сөйми, диләр. Ә җәмгыять исә тыгынлыкны өнәми.

Тукай геронтократия дигән нәрсәгә каршы.

Геронтократияне борынгы заманнарда хөкем сөргән карый-картлар—аксакаллар хакимлеге диләр-диюен, ләкин шулай да бу—фараздан башка нәрсә түгел. Табигать картайган организмнарны үз вакытында алмаштыра, бөтен тәрәккыять-алгарыш шуңа корылган. Шулай кирәк.

«Бозмасын мәҗлес хозурын акчасы беткән кеше, Измәсен яшьләрне дә күптән яше үткән кеше»,—ди Тукай-философ.

Тотрыклы цивилизация өлкәннәрне ихтирам итүгә нигезләнгән була. Ләкин без шуны да яхшы беләбез: Кояш хәтле Кояш картлар артыннан чыга дип уйлау астрономия фактларына туры килми. Кәбестә төсле бер катлы булмыйк: Тукай әйтмешли, «Курыкма, бабагыз мич башыннан белмичә егылып төшмәгәндер!»,—дип, үз-үзеңне юату шикелле көлке-көленеч куштан психологиясеннән арынмасак, без бер үк геронтократия тырмасына кайта-кайта басып маңгаебызны күгәртеп бетерербез.

«Даһи»ларның кулын пус әйләргә (үбәргә) әзер торучылар бүген тагы «саф-саф гаскәр кеби»... Әйтерсең лә, тарихта егерменче съезд булмаган, Никита Хрущев, имеш, шыр тиле, дивана, сантый булган...

Юк, илебез халкының каймагын—ин-иң ирдар, затлы кешеләрне—сугышсыз утта харап иткән явыз шәхеснең культына карата «Пычак кергере!» дигән сүз генә урынлы.

Ничәмә миллиард яшьлек Кояшны яшь титаннар күтәреп йөртсен. Кичәге көн—безнеке, туар көннәр—яшьләрнеке. Алар өлешенә кереп гөнаһлы булмыйк.

«Урыс байса, сала аулында дәү чиркәү»,—ди Тукай, аннары мәкаль булып шомарып беткән бу сүзне үзенчәләп: «Урыс байса, сала чиркәү, вәләкин әүвәле мәктәп»,—дип

өсти. Әйе, бүгенге «яна татарларыбыз» байтак кына авылларда күркәм мәчетләр салып бирделәр. Рәхмәт аларга. Хәзергесе вакытта мескен хәлгә төшкән татар мәктәпләрен торгызу, егылган татар матбугатын аякка бастыру бурычлары нәүбәттә тора. Юк, нәүбәттә түгел! Чиратсыз эшләнергә тиешле эшләр бу. Безнең бүгенге милли идеябез шул булырга тиеш—ярым үле татар китабына җан өрергә кирәк.

Китапсыз калсак, «Без бетәрбез, эз дә калмас—Җиһан моны сизәрмени?» (Гомәр Хәйямнан бусы.)

Бай абзыйлар арасында моны аңлаучы зур шәхесләр бармы? Җитәрлекме? Артка китешне туктатыр өчен милләтебезнең гакылы һәм ихтыяры җитәрме? Инкыйраздан коткарып калырлык интеллектуаль көчләребез сүнеп-сүрелеп бетмәгәнме? Турысын әйткәндә, бу мәсьәләдә оптимист булу кыен... Агач кыңгыраулар гына күп, ярык барабаннар...

Югыйсә китапларыбыз сабыйлар өчен кәттә рәсемнәр белән бизәлгән такмаза дәфтәренә—примитив уенчыкка әйләнеп бара. Чөнки башка китаплар начар сатыла, яки һич сатылмый ята. Мохитебездә рус теле өстенлек иткән шартларда безнең нәфис дигән әдәбиятыбыз да, фәнни дигәне дә русныкы белән ярыша алмый, аяусыз конкуренциядә оттыра. Еш кына чирмеш җене телендә язылган тарихи хезмәтләр исә җилкуар студентларның аннан-моннан йолкып укмаштырган курс эше дәрәҗәсеннән яки тирәнлегеннән узмаган була.

Китап үлә, Китап укый торган кеше/Человек читающий/Homo litteratus/Homo legens биологик яктан бетеп бара дигән караш бар. Әйдәгез, оптимист булыйк. Юк!—диик,—Юк! Homo litteratus сакланып калачак, фәкать ул укый торган текстның формасы гына башка булыр (мәс., компьютер-китап, сурәтле һәм тавышлы интернет һ.б.). Насыйб булса, Тукайны без интернетта укырбыз һәм тыңларбыз әле.

Укучым! Татар телендә үзлегеннән бик мәгънәле палиндром пәйда була, менә киредән укып карагыз әле:

Тукай—Йакут.

Түбәндәге икеюллык та бәхәссез хакыйкать:

*Табыладыр Тукай йакут берлән,*
*Югалмыйдыр Тукай вакыт берлән.*

Тукай—символ, байрак. Тукай—безнең милли йолдызыбыз. Беләсезме, без күктә күзәткән йолдызлар арасында бүгенгесе көнгә инде сүнгәннәре дә күп бит. Без кайчак аларның моннан миллион, миллиард еллар элекке халәтен—кайнар яшьлекләрен генә күрәбез...

Узган гасыр башларында мәңгелеккә китеп барган Тукай йолдызының да нуры татар галәмен озак яктыртыр әле.

Кулыбыздагы шушы һәйбәт Сүзлек—моның дәлиле.

Мин бу Сүзлекнең идеалда гадәти китапка кушымта рәвешендә аның электрон-версиясе белән бергә сатылуын теләр идем (китапта диск өчен махсус кесә җайлап куеп булыр иде). Хәер, киләчәктә Тукай теле сүзлегенең генә түгел, башка төр сүзлекләрнең дә шулай нәшер ителүе кулай булачак. Өстәвенә, электрон версиядә сүзләрнең әйтелешен, яңгырашын да чагылдырып була (югыйсә кайбер тележурналистлар һәм диктор кызлар да, әйтик, «һ» авазын «х» авазына әйләндереп маташалар, «гъ»ны да әйтә белмиләр...).

Тукайның вафатына 100 ел тулачак 2013 нчедә наширләр Шагыйрьнең кулга сакланып кына тотышлы сувенир булырлык зиннәтле бер томлыгын зур тираж белән татар һәм рус телләрендә бастырып чыгарсалар иде.

Соңгы сүзем «Габдулла Тукай. Шигърият теле» сүзлегенең авторларына һәм нәширләргә:

—Рәхмәт сезгә, юлдашлар! Акылны да, хисләрне дә баета торган китап өчен рәхмәт!

# ТЕТРӘНҮЛӘР ШИГЪРИЯТЕ

## РИМ ИДИЯТУЛЛИНГА 70 ЯШЬ

*Бәхетсез шагыйрь булды ул,—*
*Кайгы күрмичә үлде...*

Р. Идиятуллин

«Һәр Шагыйрьнең, әгәр ул чын Шагыйрь икән, үз Моабиты булырга тиеш»,—дигән иде бер сөйләшкәндә күренекле әдәбият галиме Камил ага Дәүләтшин. Чынлап та, әгәр дә мәшһүр Җәлилебез «пистолеты хыянәт итеп», дошман әсирлегендә коточкыч тән һәм җан җәзалары аша үтмәсә, Ватан һәм Хыянәт дилеммасы каршында калып, беренчесен сайламаса, данлы үлемне мескеннәрчә яшәүдән югарырак куймаса, аның аккош җыры булган «Моабит дәфтәрләре» циклы тумас иде дә, ул Шагыйрь һәм Шәхес буларак үлемсезлеккә ирешә алмас иде. Җәлил тимердән нык кешеләрне дә сындырырлык рухи сынаулар аша үтеп, үзенең җәлиллеген, шагыйрьлеген раслады һәм мәңгегә халык күңелен яулады.

Уфада яшәп иҗат итүче татар әдибе Рим Идиятуллинны да мин Җәлил рухлы шагыйрь дип атар идем. Юк, бу очракта мин аларның иҗатларындагы тәңгәллекләрне күз уңында тотмыйм (алары да җитәрлек булса да!), Рим абыйның шигъри талантының тормыш сынаулары, кайгы-фаҗигаләр аша үткән саен тулырак ачылуы турында әйтүем. Гомумән, аның иҗатын тетрәнүләр шигърияте дип шикләнмичә әйтергә мөмкин. Үзегез уйлап карагыз: бишектә чагында ук әтисенең сугышта һәлак булуы—ятимлек, аңлашылмас сәбәпләр аркасында иҗатының вакытында киң таныла алмавы, газиз улы Илдарның яшьлеккә аяк басканда суга батып үлүе (ата кеше өчен моннан да зуррак фаҗига була ала микән?!), картайган көнендә операция өстәле... Болар бар да бер йөрәккә сыйган, тирән яралар калдырган, ташып чыгып, шигырь юлларына күчкән...

Күрәсең, шунадыр да, Рим Идиятуллин иҗаты сагыш-моң белән тулы. Шигырьләренең поэтикасында фольклор традицияләренең зур урын тотуы да нәкъ шуның белән аңлатыладыр, минемчә. Чөнки халык авыз иҗаты әсәрләре—бәетләр, мөнәҗәтләр, лирик җырлар—кешенең күңеле кайгылардан, сагыштан тулып ташканда асылын аңлатып та бетерә алмаслык Моң булып туа. Шул Моң күңелдән—күңелгә, йөрәктән—йөрәккә күчеп, үсә, тирәнәя, һәркем аңа үз тормыш тәҗрибәсеннән чыгып яңа төсмерләр өсти. Рим ага Идиятуллин шигърияте дә шушы үзенчәлеккә ия. Һәркемнең күңелендә ул үзенчә яңгырый, һәркем аны үзенчә аңлый. Менә калса, бары тик туң йөрәкле, «Рамай», «Ак калфак», «Әдрән диңгез» кебек халкыбызның шаһәсәрләрен аңламаган кешеләр генә аның шигъриятенә битараф калырга мөмкин.

Күптән түгел Татарстан китап нәшрияты шагыйрьнең «Хәерле кич» дип аталган күләмле шигъри җыентыгын бастырып чыгарды. Бу—Рим Идиятуллинның өченче китабы, моңа кадәр 1983 елда Уфада башкорт телендә—«Хәерле иртә», 1996 елда

татар телендә—«Хәерле көн» исемле китаплары дөнья күргән иде. Яңа җыентык якташыбызның иҗатын гомумиләштерүче, күпмедер дәрәҗәдә ана йомгак ясарга, лирик геройның үсеш-үзгәрешен, эволюциясен күзалларга мөмкинлек бирүче китап булып тора.

Әлеге җыентыкны фольклорчы күзлегеннән чыгып укыганда, Рим Идиятуллин шигъриятендә халык авыз иҗаты традицияләренең көчәмлелеген күрсәтеп торучы ике төп үзенчәлекне тоемларга мөмкин:

1. Иҗатында фольклор жанрлары—бәет, мөнәҗәт, лирик җыр, мәкаль-әйтем, әкият традицияләренең зур урын тотуы;

2. Фольклордан һәм мифологиядән кергән төрле образларның Рим Идиятуллин шигъриятендә яңа эчтәлек алуы.

Әлеге бүленеш күтәрелгән мәсьәләне шактый тулы һәм эзлекле анализлау мөмкинлеген бирә.

Рим Идиятуллинның күп кенә шигырьләре җыр кебек яңгырый. Бу сыйфат аның халык авыз иҗатына, милли моңнарга гаять игътибарлы булуыннан киләдер, мөгаен. Юк, минем аны көне-төне фольклор җыентыклары укып, җыр поэтикасын өйрәнеп утырадыр, дип әйтәсем килми. Моң аның күңеленә әнкәсенең бишек җырлары, ана сөте белән кергән.

*Кайда да бер кояш,—дидем,—*
*Киттем ялгыз башларым;*
*Калдырдым шул туган якның*
*Айларын, кояшларын.*

*Һич сагынмас кебек идем,*
*Бик сагындым, дусларым!*

*Талпынышыннан таныймын*
*Туган якның кошларын;*
*Яз җиткәнен көтмәс идем,*
*Кайтыр идем кышларын.*

*Һич сагынмас кебек идем,*
*Бик сагындым, дусларым!*

*Хәлләремне сорамагыз,*
*Була төрле чакларым;*
*Коштай очып барып җитсен*
*Сезгә сәлам хатларым.*

*Һич сагынмас кебек идем,*
*Бик сагындым, дусларым!*

Бер карасаң, шигырьдә әллә нинди катлаулы образлар, тирән фикер, кабатланмас сурәтләү чаралары да юк кебек. Шуңа кайберәүләр: «Тапкан шигырь»,—дип каһкаһәләп көлеп тә куяр. Ләкин бу әсәрнең кыйммәте дә гадилегендә. Анда бар да халыкчан—сагыну хисләре һәркемгә таныш; һәр сүз, һәр юл йөрәктән чыккан. Йөрәктән чыккан юллар башка йөрәкләрдә дә яңгыраш таба, үзенә аваздаш хисләр тудыра. Шигырь күңелдә үк көйгә салына. Чөнки ул эчтәлеге белән дә, формасы белән дә—җыр. Һәр строфа азагындагы ике юлның кабатлануы ук халык җыры поэтикасына туры килә. Ләкин иң мөһиме: ул рухы белән халык җыры.

Шагыйрь үз әсәренә салынган фикерен бар тулылыгы, бар көче белән җиткерү өчен халык җырларын бик оста файдалана. Мәсәлән:

*Китә казлар, китә казлар,*
*Китә казлар Донбасска;*

*Мин дә уйлап торам әле*
*Шул казлардан калмаска,—*

дигән халык җыры юллары һәркемгә таныш. Революциягә кадәр (хәер, аннан соң да!), бәхет эзләп, читкә—шахталарга (бүгенге көндә—Себергә!) чыгып китүчеләрнең күңел халәтен чагылдыра ул. Рим аганың «Толлар урамы» циклындагы Гөлҗамал әбинең авызыннан бу җыр бүген язылган кебек, заман чынбарлыгына аяусыз хөкем булып яңгырый:

*«Китә-әү...» Тукта, көйләр көйләгәнче*
*Ипи-тозын чемчим иң башта;*
*Казлар, бәлкем, очып кайткандыр да,*
*Кызым калды ерак Донбасста...*

Кыз һәм каз параллеле... Заманында ир-атлар авылларын ташлап, бәхет кошы артыннан чит якларга чыгып китсә һәм күпмедер вакыт үткәч, аны кулларына төшереп (ә ешрак, булганын да югалтып, бөлеп—авырып!) туган якларына, сөйгән ярлары, газиз ата-аналары янына кайтып төпләнсә, гаилә корып, балалар үстереп, нәсел-ыруны дәвам итсә, бүгенге көндә хәл күпкә фаҗигалерәк. Риза Фәхретдинов тарафыннан «милләт анасы» буларак бәяләнгән хатын-кызларыбыз бүген «Донбасска китүче каз» хәлендә: алар күңел җылыларын да, сөю-назларын да күбрәк чит милләт вәкилләренә бүләк итәләр, аларга балалар үстерәләр. Татар йөзле күпме урыс, әрмән, грузин йөри шәһәр урамнарында?! Бу кызлар инде мәңгегә «Донбасска очкан»нар, алар беркайчан да (хәтта оныклары, оныкларының оныклары белән дә) үз тамырларына, үз теленә, үз халкына әйләнеп кайтмаячак... Казлар киткән җирләреннән әйләнеп кайтса да... Кызлары белән бергә милләт тә Мәңгелек чоңгылында югала... Шушы фаҗигане күңелләрне тетрәндерерлек итеп нибары дүрт юлга сыйдырган шагыйрь!

Рим Идиятуллинның «Сукбайлар җыры» (1998) исемле шигыре дә XIX-XX гасыр башларында киң таралган зимагур җырларының поэтикасы белән авазадаш. Бу шигырь шулай ук бүгенге көн чынбарлыгына, туң күңелләргә аяусыз хөкем чыгара. Чөнки рәсми чыганакларда зимагурлык—хәерчелектән качып читкә китү—узган гасырның 30нчы елларына кадәр дәвам иткән «иске җәмгыять калдыгы» буларак бәяләнсә дә, хәзерге заман зимагурлары—бомжлар, сукбайлар—янәбызда: һәр шәһәрдә, һәр йортта, һәр ишек алдында. Шагыйрь аларны Ш. Камал кебек «канатсыз акчарлаклар»га тиңли. Безнең йорт ишекләребез дә, күңел ишекләребез дә алар өчен ябык, йөрәкләребезгә зур йозак салынган, миһербанлык хисе—үзе зимагур хәлендә. Ул бары тик акча—алтынга корылган бүгенге җәмгыятьтән оялып, каядыр чыгып качкан. Шуңа да лирик герой:

*Их, дөньяны булсын иде акшарлап;*
*Канатсызлар өчен дә оч, акчарлак!*

—ди.

Рим Идиятуллин иҗатына көчле йогынты ясаган фольклор жанрларының янә берсе дип бәет һәм мөнәҗәтләрне атарга мөмкин. Күренекле татар фольклорчысы Фатих Урманче язуынча, мөнәҗәтләрнең «асыл мәгънәсе кешенең йөрәк түреннән, иң нечкә кичерешләреннән, кайгы-хәсрәтеннән туа. Әнә шундый мизгелләрдә, кайдан да булса ярдәм алу мөмкинлеге тәмам юкка чыккач, соңгы чиктә адәм баласы җиһандагы иң изге затка—Аллаһы Тәгаләгә мөрәҗәгать итә».

Шагыйрь—дөньядагы иң зур кайгы, бала кайгысын кичергән шәхес. Унсигез яшьлек улы Агыйдел суларында һәлак булгач, аңа акылын җуймаска, кайгы-хәсрәт утында кара янып үлмәскә ярдәм итүче—нәкъ шул Шигърият булгандыр, мөгаен. Чөнки Рим аганың кайгы-зары йөрәгеннән ташып чыгып, шигырьләренә түгелмәсә, шагыйрь йөрәге генә түгел, бөтен дөнья шартлар иде. Мондый фаҗига ни йөрәккә,

ни акылга сыеша алмый! Шуңа да шагыйрь бәргәләнеп, нәкъ мөнәҗәтләрдәгечә Күкләргә мөрәҗәгать итә:

*Уйламадым түгелер дип*
*Учымдагы бодаем;*
*Алыр булгач, нигә генә*
*Бирдең икән, Ходаем?!*

Матурлыгы халык җырларында данланган, үзенең дистәләгән шигырендә яратып тасвирланган Агыйделкәе дә шагыйрь өчен бер гөнаһсыз адәм балаларының җанын алучы Газраил төсенә керә:

*...Ак Иделгә карасам да,*
*Йөзкәйләрем карала;*
*Ходай, башка бәндәләрне*
*Бу кайгыдан арала!*

Фатих Урманче билгеләвенчә, «мөнәҗәт бу дөнья белән теге дөнья арасында торучы кеше тарафыннан иҗат ителгән әсәр булып янгырый, һәрбер мөнәҗәткә, күләме зур булмаса да, кешенең бөтен гомере, кайгы-хәсрәтле, фаҗигале тормышы, шундый тормышта яшәп үлем бусагасына килеп житүе—барысы-барысы сыеп бетә. Бәлки шуңа күрәдер, аларда сорау, үтенеч, ялвару, ялыну, Аллаһы Тәгаләгә өметләнү төп урынны алып тора. Мөнәҗәтләрнең зур күпчелеге изге дога кебек кабул ителә». Әлеге юллар Рим Идиятуллинның югарыда каралган шигырьләренә дә туры килми дип, кем әйтер?!

Рим Идиятуллин иҗатында без милли мифологиябездәге Тәнречелеккә нигезләнгән борынгы төрки һәм Ислам идеологиясе белән сугарылган гарәп-мөселман катламнарына караган образларның берегеп, синтезлашып килүен күрәбез. Шагыйрь, кайбер зыялыларыбыз кебек, дини чикләнгәнлек күрсәтми. Аның өчен Тәнречелек тә, Ислам да халык тарихының бер этабы, фәлсәфәсенең, милли менталитетының—бер сүз белән әйткәндә, асылыбызның аерылгысыз өлеше. Шуңа да аның шигъриятендә Хозыр Ильяс, Адәм, Һәва, Фәрештә, Нух пәйгамбәр, гыйфрит, шайтан, кебек Коръәни персонажларның һәм Тәнре, Күк, Ут, тулпар, тугыз башлы дию, аждаһа, албасты, шүрәле, кебек тамырлары белән Тәнречелеккә килеп тоташучы затларның бердәй тигез урын алуын күрергә мөмкин. Ләкин шагыйрь аларның һәммәсенә бүгенге чынбарлыктан чыгып, яна идея-эстетик мәгънә сала. Мәсәлән, аның 2003 елда язылган «Бергәләшеп китәләр дә...» исемле әсәрен тулы хокук белән «мифологик шигырь» үрнәге дип атарга мөмкин:

*Уралтаудан Кафтауларга*
*Күз күгәрер аралар;*
*Бергә-бергә китәләр дә*
*Берәм-сәрәм кайталар,—*
*Әгәр исән калсалар...*

*Көньяклардан көн дә хәтәр*
*Хәбәр китерә җилләр:*
*Анда адәмнәр ашаучы*
*Аждаһалар бар, диләр.—*
*Кафтауда булмас нилэр!*

*Әйтәләр: кыя кашында*
*Ут бөркер чәчкә үсә;*
*Ят куллар кагылды исә,*
*Яшәү гомерен кисә,—*
*Сабагын кыеп өзсә...*

..........................................

*Бергәләп киткән егетләр*
*Берәмләп кайта тора;*
*...Уты сүнгән өйдә кайгы*
*Керфек какмый утыра;*
*Ана укый бәддога...*

Күренүенчә, меңнәрчә яшь гомерләрне кискән урыс-чечен сугышы фаҗигасен гәүдәләндерер өчен, шагыйрь борынгы мифологик образларны бик оста файдалана, ләкин аларның мәгънәви эчтәлеге кинәя, алар символ дәрәҗәсенә күтәрелә. Кафтау—Кавказ гына түгел, ә яшьләрне үлем көткән яу урыны, Аждаһа—үлем, утлы чәчәк—азатлык символларына әверелә. Йөрәк парәсен җирләгән Ананың, аны үз мәнфәгатьләрен яклау өчен сугыш утына тыгып йоткан Аждаһаларга—хакимнәргә бәддога укуы шигырьнең укучы күңеленә тәэсир көчен тагын да арттыра. Сәясәт, идеология, нинди генә яхшы булмасын, ул кеше гомеренә тормый әсәрнең төп идея мәгънәсе шул.

Рим Идиятуллин шигъриятендә иң еш очраган мифологик образлар дип, һич икеләнүсез Кояш һәм Ай, Күк һәм Җир параллельләрен китерергә мөмкин. Аларга шагыйрь һәр шигырендә диярлек мөрәҗәгать итә. Борынгы төркиләр Кояш белән Айны—агалы-энеле бертуганнар, ә Күк белән Җирне ирле-хатынлы итеп күзаллаганнар. Ә шагыйрь өчен аларның берлеге һәм бөтенлеге Дөнья гармониясен, күңел тынычлыгын аңлата.

*Ай-Кояшы сүнгәч, өши-өши*
*Дөньялыкта кеше ник яши?!—*

дигән сорау куя ул үзенең «Тояк тавышы» исемле шигъри триптихында. Ә улының истәлегенә багышланган «Күңел күнегер булса...» шигырендә:

*Бу дөньяда яшәсәм дә,*
*Ай-Кояшны танымам;*
*Галәмгә сыймас җылымны*
*Суырдың шул җанымнан,*

—ди.

Күренүенчә, шагыйрь улы белән бергә күңелендәге Ай һәм Кояш берлеген, ягъни дөнья гармониясен дә җуйган. Нибары өч сүздән торган бер юл шигырь белән Рим ага фаҗигане сүз белән аңлатып бирә алмаслык тирәнлеген ача да сала. «Ай-Кояшны танымау»—яшәешнең мәгънәсен, асылын җую белән бер.

Икенче бер шигырендә ул:

*Зар-кайгымны тыңлап тормыйча да*
*Ят иткәндә якын туганым,*
*Ялгызларны ялгыз аңлар диеп,*
*Көткән идем Айның тулганын*
*Дүрт күз белән,—*

дип яза.

Шагыйрьнең тулган Айны көтүе бер дә юктан түгел. Ул әйләнә-тирәне чолгап алган Төннән—гамьсезлектән, караңгылыктан, гомумән, ялгызлыктан—котылу өчен берләнбер яктылык, нур чыганагы Айга мөрәҗәгать итә. Ә ышануы буенча, тулы Ай—Ай тәңресенең иң мәрхәмәтле чагы. Димәк, шагыйрь Айга үз кайгы-зарларын сөйләп, аның теләктәшлегенә өмет итә. Бу исә, бер яктан, халкыбызның борынгы мифологик карашларын чагылдырса, икенче яктан Рим Идиятуллинның күңел халәтен дә ачып сала.

*Кояшларың сүнсә, хәсрәтләрең*
*Сүрәнәйми икән кичен дә:*
*Мин яшәдем яуда янган әткәм,*
*Суда баткан улым өчен дә,—*
*Шул бер гомер эчендә...*

Бу юлларны бары тик рухы имәннәрдәй нык кеше генә яза аладыр. Кояшның сүнгән, ә хәсрәтләрең жаныңны күмергә калдырган чакта да яшәргә көч табу, сынмау-сыгылмау—үзе үк батырлык.

* * *

«Шәп шагыйрь шул!»—дип язган иде Роберт Миннуллин каләмдәше Рим Идиятуллин турында. Мин, үз чиратымда, «шәпләр арасында шәп» дип өстәр идем. Чөнки көчле шагыйрьләр бар (күп түгел!), ә Рим Идиятуллин берәү генә. Үзе әйтмешли, «туң гасырның соңгы җырчысы...» Поэтик таланты буенча Мөдәррис Әгъләм, Зөлфәтләргә тиң, алар рәтендә йөрергә тиеш шәхес...

Рим Идиятуллин шигъриятендә күзгә бәрелеп торган сыйфат—ихласлык. Аның бар әсәре йөрәктән чыккан, бер генә юлы да ясалма түгел! Нәкъ бәет, мөнәҗәт, халык җырлары кебек үк... Гонорар, китап чыгару, мактаулы исем алу өчен язмый ул. Һәм бу сыйфаты белән күпләрдән аерылып тора. Хәтта хаталанса да, ул ихлас хаталана, үз-үзенә хыянәт юлына басмый. Шуңа да укучы аның хисләрен үзенеке дип кабул итә, Рим Идиятуллин шигырьләрен укыганда аның язмышы белән яши башлыйсың. Чөнки ихласлык—чын Шигъриятнең асылыдыр...

**Илдус ФАЗЛЕТДИНОВ,**
*филология фәннәре кандидаты,*
*Уфа.*

## Арзангарак язылырга була

Хөрмәтле укучылар!

Почта бүлекләрендә 1 февральдән льготалы подписка ачылды. Ул 31 мартка кадәр дәвам итәчәк. Шушы вакыт аралыгында сез 2010 елның 1 яртыеллыгына булган бәяләр белән 2 яртыеллыкка языла аласыз.

«Казан утлары»н арзангарак алдырырга теләсәгез, ашыгыгыз!

## ТУГРЫЛЫК

Рәшит Бәшәр—татар балалар әдәбиятында югары урын биләргә хаклы әдипләрнең берсе. Мал иясенә охшый диләр бит, аның иҗаты да үзенең холкы шикелле—иплəп кенә агучы саф чишмәне хәтерләтә. Юлдагы бар нәрсәне вата-җимерә аккан ташкын сулар кебек түгел, тирә-юньне шифалы суы белән сугарып, бертуктамый челтер җыр көйләгән чишмәдәй, тыныч кына, тыйнак кына яза да яза ул. Табадан гына төшеп торган китапларының чираттагысы—«Йолдызлы тай»—узган ел Татарстан китап нәшриятында дөнья күрде. Үзе һәм бала шәхесе арасында бернинди киртә тоймаган шагыйрь бу юлы да иҗатына тугры: шигырьләрендә—мәңгелек балачак иле, аның ваемсыз, самими чагылышы.




Шәехзадә Бабичның «һәр шигырь юлында йолдыз янмаса, шигырьне язып торырга кирәкми» дигән сүзләре бар. Р. Бәшәрнең китап исеме үк вәгъдә иткәнчә, шигырьләрдән йолдызлар яктылыгы һәм серлелеге көтелә, алардан баланың үз күңеледәй сафлык һәм беркатлылык бөркелә.

Бер караганда, балалар шигъриятендә инде яна сүзгә, яңа темага урын да юк: әниләр турында да, уенчыклар, кошлар, җәнлекләр, агачлар, инеш-күлләр... хакында да языласы язылган кебек. Әмма аларга һәр шагыйрьнең үз бәяләмәсе бар. Дөньяны үзенчә күрә белгәннәр генә укучыга яңа сүз җиткерергә сәләтле.

«Йолдызлы тай» китабын шәхсән мин үзем табигать әлифбасы дияр идем. Тик шагыйрьнең табигатьтәге искиткеч гармонияне, матурлыкны сурәтләвен мәңгелек темаларның берсенә чираттагы мөрәҗәгать итү дип кенә бәяләргә ярамый. Беренче карашка гап-гади тоелган шигырьләр нигезендә дә автор шәхесенең уйланулары, киләчәк буын өчен борчылулары ята.

Ни аяныч булса да, хакыйкатьнең күзенә туры карарга мәҗбүрбез: бүген җәмгыятьтә өр-яңа буын—рухи яктан гарип буын—формалашып килә. Өендә, бакчада, мәктәптә ана телендә аралашмаган, аралашырга теләмәгән, аралашудан мәхрүм ителгән татар баласының киләчәген күзаллау да куркыныч. Теленнән, моңыннан, милләтенең рухи тамырларыннан коточкыч тизлек белән ераклашып баручы бүгенге буын вәкилләренең күзендә—бушлык, мәнсезлек, кансызлык. Ата-ана назыннан битәр, күбрәк урам һәм компьютер, телевизор тәрбиясе алган сабыйларның йөзендә самимилек күрермен димә. Бишектән төшүгә үк аларны сугыш һәм көчләү

идеясе шыплап тулган мультфильмнар «тәрбияли» башлый. Иң куркынычы—һәрдаим вакыт юклыкны сәбәп иткән олылар белән бергә, балалар да табигатьтән аерылып бара. Ә бит кояш нурын йотып уйнаган балыкларны, чишмәләргә чума-чума биешкән чиләкләрне, кош көтүен күккә чөйгән каеннарны күрергә сәләтле баланың күнелендә шәфкатьсезлеккә урын калмас иде.

Шигырьнең тәрбияви көче—гапгади сүз белән тылсымлы рәсем ясый белүдә, шул рәсем аша сабый күнелендә матурлыкка, табигать могҗизасына соклану уятуда. Р.Бәшәр үзенең рәсемшигырьләрендә төрле «төстәге» сүзләр ярдәмендә шулкадәр камил картина тудырырга сәләтле:

*Күбәләк тә кызарды,*
*Кызарды, алсуланды—*
*Күбәләк канатына*
*Җиләк суы сыланды.*
(«Җиләк малай»)

Бу урында мәшһүр Тукаебызның сүзләрен искә төшерү артык булмас: «Балаларымызның күзе гүзәл нәрсәләр күрергә вә борыннары да хуш вә татлы исләр иснәргә ияләшсен. Кечкенәдән үк гүзәл нәрсәләр укыган балаларның күнелләре дә назик вә латыйф булып, анчак гүзәл вә мөкатдәс нәрсәләрне генә сөючән буладыр».

Балаларыбыз каты бәгырьле дип зарланабыз, ата-анасын картлар йортына илтеп ташлаган дип шаккатабыз, тудырган нарасыен чүплек савытында калдырган дип аһ итәбез икән, монын өчен җәмгыятьне һәм андагы кануннарны гына гаепләү берниндн кысага сыймас. Иманым камил: әти-әни, әбибабай кочагында «Сак-Сок» бәетен, Тукай әкиятләрен, Бари Рәхмәт, Шәүкәт Галиев, Роберт Миннуллин, Рәшит Бәшәр шигырьләрен тыңлап үскән бала таш бәгырьле була алмый.

*Өй түрендә бакчада*
*Күз йөри кыштыр-кыштыр.*
*Алма да юк, җиләк тә—*
*Күзнең кесәсе буштыр.*
(«Кыш сулышы»)

Р. Бәшәрнең пейзаж картиналары—аның табигать турындагы шигырьләрен нәкъ менә шулай атыйсы килә—һәрвакыт якты төсләр белән өртелгән. Бала күнеле аклыкка, җылыга мохтаҗ—автор моны беркайчан да онытмый. Шуна да шигырьләреннән кояш нуры бөркелә («кояш куна гөлләргә, кояш куна әнигә»), саф сулы чишмәләр ага («бертуктамый таш агарта челтер-челтер чишмәләр»), иркә дә, чая да җилләр исә («ап-ак юрган эченә бөтерелеп тулды ул»). Дәрдемәнднең «Чыкты кояш», «Яз иртәсе», «Кыш иртәсе», Тукайның «Бала белән күбәләк» кебек шигырьләре, «Шүрәле» поэмасы ни өчен балалар әдәбиятының кыйммәтле хәзинәсе санала?—Бу шигырьләрнең һәммәсендә табигать поэзиясе аша кешелеклелек идеясен җиткерү күздә тотыла. Р. Бәшәрнең «Таң вакыты», «Җылы куян», «Табышмак», «Кондызлы күл» кебек шигырьләре дә менә шундый хис-тойгылар белән сугарылган—аларны укыган бала, үзе дә сизмәстән, шомырт куагындагы кошчык турында уйлана, чикерткә кунган чәчәккә аяк басарга кыймый, тунарга өлгергән нәни куян баласын кызгана...

Татарча сөйләшкән, әлегә ана телендә китап укый белгән балаларның тамыры, кайда яшәвенә карамастан, авылга барып тоташа. Шуна да ташкалада үскән шәһәр баласының да әлегә шактые әтәчләрнең «кикрикүк!» дип кычкырганын, җиләкләрнең болыннан йөгергәнен, кәҗә сакалын ашарга ярaганны, мичтә ипи пешкәнне, колын маңгаена йолдыз кунганны, сәнәктырма төяп печәнгә баруларны ишетеп-күреп белә. Китап битләрендәге малайлар дөньясы белән укучының үз дөньясы әллә ни аерылмый; яктылык сирпеп торган шигырьләр баланы өй җылысына, әби-бабайның чирәмле ишегалдына дәшә:

*Агып китте болытлар,*
*Һава аязып калды.*
*Чыгып киттем...*
*Әбием*
*Өйдә май язып калды.*
(«Мунчалы иртә»)

Бала өчен язылган шигырь ясалмалыкны, төчелекне күтәрә алмый.

Аларда гадилек аша ирешелгән галилек булырга тиеш. Бу җәһәттән Р. Бәшәр шигырьләре кечкенә герой исеменнән, аның фикерләвеннән чыгып сөйләве белән җәлеп итә: автор һич кенә дә үз фикерен көчләп такмый, дидактик формага, төче романтик күпертүләргә мөрәҗәгать итми, бала психологиясеннән читкә тайпылмый. Мәсәлән, «Эш», «Ай Рамил, Рамил», «Әйдә, энем, урманга», «Бәрәнле яшен» шигырьләрен укыган һәр бала аларда үз холкын, үз йөзен күреп, рәхәтләнеп елмаер иде.

*Ашап туйгач, әйбәтләп*
*«Аллаһеәкбәр!» әйтмәсәм,*
*«Рәхмәт, әни!» димәсәм,*
*«Рәхмәт, әти!» димәсәм,—*
*Өйдәгеләр шулай ди:*
*—Бик әдәпсез малай,—ди,*
*—Яшәп булмый болай!—ди.*
(«Ай Рамил, Рамил»)

Акыл сатуга, үгет-нәсихәткә караганда, менә шундый ихлас шигырьләрнең тәрбияви роле күпкә югарырак. Беренче карашка гади генә тоелган сүзләрдән тезелгән шигъри муенса эчке затлылыгы белән кыйммәт. Рәшит Бәшәрнең җиңел, лирик пландагы шигырьләре нигезендә сабый бала күңеленә дә, олыларга да уйланырлык азык бирергә сәләтле фәлсәфә ята. «Бәбкәле болын» шигырен мисал итеп алыйк. Бала янында пипелдәшкән сары томшыклы бәбкә күзләрендә—сагыш. Салкын яңгыр яуганда җылы канат астына сыенырлык әнкә каз юк. Әрекмән астына ышыкланырга мәҗбүр бу бәбкәләр—инкубатор бибиләре.

*Пипелдидер...*
*Бу аларның*
*Күз яшьсез үксүләре.*
*Бәбкәгә дә рәхәт түгел*
*Әнисез үсүләре.*

«Яз. Тупыллар» шигыренә дә күз төшерик. Шәһәрдә үскән тупылларның язмышы һәрберебезнең күз алдында. Яз җитүгә, әй тотыналар аларны кыркырга. Ә бит алар да табигатьнең җанлы бер бизәге. Талларның гына түгел, аларның да сайрар сандугачы бар.

*Тупылларга төш керә:*
*Җилле аяз төннәрдә*
*Яланбашлы тупыллар*
*Ябалдашлы төш күрә.*

Мондый шигырьләр балага аны урап алган тирәлекнең аллы-гөлле төсләрдән генә тормаганлыгын искәртә. Дөньяда югалтулар да, фаҗигаләр дә җитәрлек. Бу фикерне бала күңелен яраламаслык, әмма уйланырлык итеп җиткерү шагыйрьдән психолог булуны таләп итә.

Балалар шигырендә баланың үз дөньясы чагылырга тиеш. Авторның уйлануы олыларча «акыллы» булса, шигырь үзенең нәни укучысын бик тиз җуя. Чөнки бала күңеле күбрәк шуклыкка омтыла, ул тегеннән дә, моннан да һәрдаим мажара эзли. Рус әдәбиятыннан К. Чуковский, С. Маршак шигырьләрен генә искә төшерик: аларның тәэсир көченең бер сере—нәкъ менә мажараларга бай булуда. Балага шул гына кирәк тә, чөнки аның теләкләре дә, хыяллары да үзе кебек үк тиктормас, хәрәкәтчән; аны сер тулы дөнья кызыксындыра, тузга язмаган хәлләр ымсындыра. Р. Бәшәрнең «Буталмыш», «Әкиятле төннән соң» кебек шигырьләре менә шундый сәер хәлләргә бай булуы белән ота. Аның бал ашап йөргән яшел төлкесе, сәпитләргә атланган күселәре, кып-кызыл кычытканнары, инеш төбенә баткан ак ае укучыны җәһәт кенә тылсымлы илгә бөтереп алып кереп китә, шул арада балага «алай түгел, болай булырга тиеш» дип уйланырга мөмкинлек бирә.

*Ә күлдә... Кызыл күлдә...*
*Бүре ята дулкында,*
*Тәмсез шоколад чәйнәп.*
*Ә мәчеләр көймәдә*
*Утыра әнә чәйләп.*
(«Буталмыш»)

Автор мондый шигырьләрдә укучыны мавыктыруны гына күздә тотмый, вакыты-вакыты белән мөгаллимнәрчә сабак та биреп ала. Кечкенә генә күләмле шигырьләрдә кызыклы сюжетка корылган вакыйга чагылдыру—шагыйрьнең зур уңышы. Хәер, ул бу уңышка сюжет кора белү осталыгы аша гына ирешми. Р. Бәшәрнең фоникада—әсәр телен авазлар ягыннан оештыруда—судагы балык

кебек йөзүе анын шигырьләрен тагын да югарырак күтәрә. Балалар өчен язылган шигырьнен ни дәрәҗәдә камиллеге анын укучы тарафыннан ничек ятлануына бәйле: отышлы сайланган сурәтләү чаралары белән бергә, тасвирланган күренешләргә тәнгәл фонетик янгыраш шигырьнен көчен бермә-бер арттыра. Андый шигырь бер-ике укуда хәтердә кала, җиңел ятлана.

*Тамчы сибәр болытлар,*
*Җир тамчы эчеп туяр.*
*Җып-җылы түтәлләрдә*
*Елмаеп яткан кыяр*
*Чиләккә ничек сыяр?*
(«Кыяр»)

Р. Бәшәр аллитерация—тартык авазларны янәшә китерү юлы белән сурәтлелек тудыру алымын кулланып, шигырьләренә үзенчәлекле төсмер бирә. Анын «Гөлбакча»сында бал кортлары бертуктамый «з»-зенли, «Мышмыш»ында бала-чага мәш-«ш» килә, «Кырмыскалар»ы куе куаклыктан калкулыкка күченә...

Унышлы кулланылган омофоннар, омографлар да шигырьгә сәйлән белән чиккән бизәк өсти, каламбур рифма барлыкка китерә:

*Кояш кыздыра битен,*
*Болай тору бик читен.*
*Үрелеп көч-хәл белән*
*Тотуга кояш читен.*
*Пешерде сул бармагын.*
(«Буталмыш»).

«Бакчабыз тулы кыяр, кемнәр өзәргә кыяр?», «Карале, кара, кара; Кәҗә сакалы кара», «Өй түрендә шомыртымнын кунган да иң очына; Өзелеп лә сайрый бер кош, әй очына-очына»... Мондый мисалларны шактый китерергә булыр иде. Шигырьләрнен эпитетларга, метафораларга бай булуы; авторнын кошболыт, табашка, көлбестә, сукыяр, алмакояш, Нурчәчәк кебек үз табышлары, күзгә күренмәс төсләрне дә шигъри телдә чагылдыруы—болар барысы да шагыйрьнен нәзакәтле рәссам икәнен раслый.

«Йолдызлы тай» (мөхәррире—Ленар Шәех, рәссамы Рөстәм Хәбибуллин)—бала күнелендә йолдыз кабызырга, мәхәббәт һәм мәрхәмәт уятырга сәләтле якты китап. Әйткәнемчә, анда—балаларнын үз дөньясы; шагыйрьнен мәңгелек балачак илен сагынуы, ана тугрылыгы, шуннан китәсе килмәве. Хәер, «покостагы печән кәнфит кәгазе күк кыштыр-кыштыр килеп тора» дип яза белгән авторны ул илдән киткән дип әйтеп буламы?..

**Айгөл ӘХМӘТГАЛИЕВА,**
*Чаллы.*

Әзһәр
Шакиров

# ТАРИХ СӘХНӘСЕНДӘ—БЕЗ ЭЗЛЕБЕЗ...

АРТИСТ МОНОЛОГЫ

*Моңаймагыз, дуслар, китеп барсам*
*Кинәт кенә сезнең арадан:*
*Әверелеп матур легендага,*
*Мин кайтырмын әле яңадан.*

Фәнис Яруллин

Мин бит үз гомеремдә беренче мәртәбә Мәскәүдә Щепкин исемендәге театр училищесында укый башлагач кына чын театрны, тере артистны күрдем. Авылда, мәктәптә укыган чакта артист булу турында уйлау түгел, хыяллана да алмадым. Ничек инде авыл кешесеннән артист чыксын–укытучы, врач, һич югы авыл хуҗалыгында инженер дисәң, бер хәл. Гомумән, артистлыкка укыткан институт турында ишеткәнем дә булмады. Театр училищесында укыганда минем бер генә теләгем бар иде, ничек кенә булса да дөрес уйнарга өйрәнү. Урыслар аны «школа переживания» дип атыйлар. Гади генә итеп әйткәндә, син уйный торган рольнең бөтен эчке кичерешләрен йөрәгең, күңелең аша уздыру. Ягъни, аның язмышы белән сәхнәдә яшәү. Икенчесе–«школа представления», монысы каһарманың булып кылану, ягъни син уйный торган рольнең эчке кичерешләрен йөрәгең аша уздырмыйча да тамашачыны ышандыра аласың икән, шул җитә; бик гади генә итеп әйткәндә, аермасы менә шул. Менә шушы ике төрле уенны аңлар өчен мин укытучыларымның тәнкәсенә тиеп бетә торган идем. Төннәр буе күңелем, җаным белән Станиславскийны укыйм, өйрәнәм. Минем укытучыларым М. Гладков, В. Смирнов–Малый театр мәктәбен бетергән кешеләр. Аларның укыту алымнары К. Станиславский язганча түгел, бәлки үзләре театр сәнгатен ничек аңласалар, шулай укытырга тырышалар иде. Шуңа күрә мин, Станиславский менә шулай язган, менә болай язган, дип укытучыларым белән бәхәскә керә идем. Әлбәттә, мин әле Станиславский системасын һәр актер үзенең табигатенә яраклаштырырга тиешлеген бөтен тирәнлеге белән аңлап бетермәгәнмен. Әйткәнемчә, мин ул «школа переживания» дигән уенны каныма, җаныма сеңдерергә тырыштым. Шул гына минем эчке дөньямны ачарга ярдәм итәр дип уйладым. Хәзер инде аңладым, күп очракта «школа переживания» белән «школа представления» артист уенында шул хәтле нык бәйләнгән, аларны аерым-аерым бик сирәк очратырга була. Хәер, тамашачылар өчен син нинди «школа»да уйныйсың, барыбер. Беренче курста чагында үзеңне гений итеп саныйсың. Беркем дә дөрес уйнамый төсле тоела. Менә син уйнасаң, бөтенләй башка төрле уйнар идең, алай әле бер артистның да уйнаганы юк, дип, үз-үзеңне ышандырырга тырышасың, ә инде

сонгы курста азрак үзеннен кем икәненне анлый башлыйсын. Икенче курста чагымда Е. Вахтангов турындагы китапларны укый башладым. Алар нишләптер минем күнелемә, жаныма көчле тәэсир итмәде, бәлки, мин аларны анлар дәрәжәгә үсеп житмәгән булганмындыр. Хәер, минем укытучыларымнын «Вахтангов» училищесына бик исләре китми иде. Менә «Малый» театр мәктәбенен нәрсә икәнен В. Пашенная, И. Ильинский уеннарын карап күрдем. Кайчагында үземә дә ара-тирә сүзсез рольләрдә катнашырга насыйп булды. Шунда сәхнә артыннан урыс артистларынын уеннарына карап сокланам, өйрәнергә тырыша идем. Ул елларда, безнен бәхетебезгә, Мәскәүгә дөньянын ин көчле театрлары Англия, Франция, Германия, Италия, Греция, Испаниядән килде. Мин, хәтта 20 сум түләп (безнеӊ бер айлык стипендия), П. Скофильдны «Гамлет» ролендә карадым. Гамбург театрынын ин көчле спектакльләренен берсе Гетенын «Фауст»ында, Гитлернын ин яраткан артисты З. Гюнтерны, «Мефистофель» ролендә күрергә насыйп булды (ул турыда бер язармын әле). Шул вакытта Хораваны–Эдип патша, Тхапсаев–Отелло, Хәлил Әбжәлилов–Король Лир ролендә, саный китсән алар шактый күп жыйналалар. Әлбәттә, мондый биеклектә уйнаган артистларны карагач, күнелендә әз генә булса да артист булу теләге булган яшь егет, үзе дә сизмәстән чын, сәләтле артист булырга хыяллана. Минем дә бөтен теләгем талантлы артист булу иде. Аннан сон «Малый» театрнын үзендә дә беренче урында режиссер түгел, артист торды. Безгә, театр ул драматург, артист, тамашачы, дип өйрәттеләр. Укыганда күнелебезгә: режиссер булырга кирәк, хәзер артист сәнгатендә режиссерсыз берни эшләп булмый, дигән фикерне сендермәделәр. Мин үзем режиссернын артист өчен никадәр кирәк икәнен бик сонынннан гына анладым. Чөнки мин күргән бөек артистларга режиссерлар кирәкми, алар үзләре театр, дип уйладым. Мина, гомумән, спектакльдә артист уенын карау гына кызык иде, матур декорация, музыка, сәхнә эффектлары тамашачыны жәлеп итмиләр. Бары тик артист уены гына тамашачыны өч сәгать буе тотып тора. Талантлы артистнын сәхнәгә чыкканын гел көтеп торасын, аңа гына карарга кызык, чөнки ул һәрвакыт үзгәрештә. Гомумән, режиссернын кем икәнен анламагач, анын хезмәтен артист хезмәте белән тин күрми идем. Артист һәр көнне тамашачы белән очраша, шуннан үзенә ләззәт ала, бигрәк тә яшь артист өчен моннан да зур бәхет юк. Хәер, мин укыган заманда барлык режиссерлар башта артист булып эшлиләр, бу профессиядә зур уңышларга ирешмәгәч, күбесе режиссер булып китәргә мәжбүр булалар. Шуна күрә артист белән режиссер дәрәжәсе бертигез түгел, халык күбрәк артистны белә, хөрмәт итә, бигрәк тә безнен театрда. Шулай, укуны бетереп театрга кайткач, һәрбер яшь артист ничек кенә булса да үзенен сәләтен күрсәтергә тырыша.



*А. Вампиловның «Булмас димә— дөнья бу» спектаклендә Колошин ролендә.*

Мин Мәскәүдән кайтканда академия театры бик югары биеклеккә күтәрелгән, житлеккән, талантлы артистлар коллективы иде. Хәер, мин алар турында күп яздым инде, кабатлап тормыйм. Шуны гына әйтәсем килә: уку бер нәрсә, театрда артист булып эшләү бөтенләй икенче нәрсә. Беренче мәртәбә сине укытучын түгел, менләгән тамашачы карый. Сүз дә юк, Татар академия театрында ин беренче сыйфат–чын татарча сөйләшергә кирәк. Татар телен камил белмәгән яшь артистны академия театры сәхнәсеннән кабул итү бик авыр. Мин моны ни өчен әйтәм: безнен укытучыларыбыз татарча белмәгәч, без сәхнәдә татарча сөйләшүгә бик зур игътибар бирмәгәнбез. Укыганда безнен өчен ин кирәкле әйбер сәхнәдә дөрес яшәү иде. Ә менә татар теленен серләренә, бигрәк тә сәхнә теленә кирәк кадәр

игътибар бирелмәгән. Бу күбрәк миңа кагыла: безнең якта бик тиз сөйләшәләр, кешенең теле телгә йокмый, аңласаң аңлап каласың, аңламасаң юк. Аннан соң мин бит әле тумыштан сакау, «р» хәрефен әйтә алмый идем. Шуңа күрә аңлашылсын өчен җөмләне бүлеп сөйләдем, җөмләне бүлеп сөйләмә, дип, миңа гел «замечание» ясыйлар иде. Сәхнәдә сөйләшә белмәгәч, режиссердан сүктермәс өчен, мин тизрәк кешенең характерын, җанын, темпераментын ачарга омтыла идем. Юк, син башта гади генә татарча сөйләшергә өйрән икән, бу–драма артистының иң кирәкле сыйфатларының берсе. Эшли башлаганда ук үзенә күтәрә алмаслык зур максатлар куйма, бер артистка да ошамаска тырышып табигать биргән сәләтеңне югалтма. Мөмкин кадәр үзеңә хас табигыйлекне табарга тырыш. Укыганда ук үз фикерем белән эшләргә өйрәнгәнгә, кайвакыт режиссер белән килешә алмыйча төннәр буе уйланып, газапланып чыгам.

Мин уйнаган рольләрнең күбесе ак яки кара буяу белән язылган, аларны уйнар өчен зәңгәр, яшел, кызыл краскалар кирәкми бит, моны, әлбәттә, образлы итеп әйтәм. Шуңа күрә уйнаган рольләрем гади, җинел, бик якын булып тамашачы күңеленә кереп калмаганнардыр. Нишлисең, табигатем шундый, бик гади генә язылган сәхнәгә дә үземә кирәк булган мәгънәне салырга тырышам. Хәзер инде әйтә алам, һәрбер артист үзенә генә хас алымнары белән сәхнәгә кереп китә. Театрда өч-дүрт ел эшләгәч кенә, үзенә аек акыл белән карый башлыйсың. Әкрен-әкрен генә артист хезмәтенең серләренә төшенәсең, чөнки бу бит һөнәр–моңа өйрәнергә кирәк. Сәхнәгә чыгып уйнамыйча берничек тә үсеп булмый.

Бер вакыйганы искә төшерәсем килә. Мәскәүдә укыганда Ленин комсомолы исемендәге театрда Инокентий Смоктуновскийны карарга туры килде. Әле яңа гына Мәскәүдә эшли башлаган чагы. Беренче мәртәбә сәхнәдә берниндй гримсыз, бик табигый, нәкъ тормыштагы кебек әкрен генә сөйләшә, хәтта кайбер сүзләрен аңламадым да. Бергә уйнаган иптәшләреннән шулхәтле аерылып тора, кызганып куйдым. Нишләп бу артист болай уйный икән? Сәхнәдән андый уенны каравы бик авыр иде. Гади генә итеп әйтсәк, мин андый уенны кабул итә алмадым. Менә берзаман ишетәм: Смоктуновский: сәхнәгә «современные манеры игры» алып килде диләр, бөтен яшь рус артистлары Смоктуновский булып уйнарга тырышалар. Әгәр дә Смоктуновский бөек рус артисты икәнен исбатламаган булса, аны «проф.не пригодный» дип театрдан куарлар иде. Сәнгатьтә бөтен эш талантка килеп терәлә шул! Безнең эштә яшь артист белән бик сак эш итәргә кирәк, бәлкем ул бөтенләй икенче яктан ачылырга да мөмкин. Минем язмышымны театрда Ширияздан абый Сарымсаков хәл итте. Ул мине күктән җиргә төшерде. Берсеннән-берсе катлаулы, зур рольләр бирде. Т. Гыйззәтнең «Чаткылар»ында–Рамай, Индонезия язучысы А. Муисның «Фаҗигале юлда» әсәрендә Хәнәфи, М. Кәримнең «Ай тотылган төндә» трагедиясендә Дәрвиш. Әле мин мондый рольләрне уйнарга артист буларак бигүк әзер дә булмаганмындыр.

Әйткәнемчә, мин сәхнәдә сөйләшә белми идем. Аңа артист, мескенкәем, еллар буе өйрәнгәнен хәзер генә аңладым. Син уйный торган һәрбер герой үзенчә сөйләшә, артист шуның мелодиясен сизәргә тиеш. Рольләр алар музыка законнарына тәңгәл киләләр, һәр рольнең үзенә генә хас эчке музыкасы яңгырый, син аны күңелең, җаның белән тоясың. Кайвакытта рольнең бер җөмләсен искә төшерү белән күңелдә аның мелодиясе яңгырый башлый. Мин моның белән шуны әйтмәкче булам: рольнең характерын, эчке дөньясын ачарга сәхнәдә сөйләшә белү шулкадәр ярдәм итә ки, мин моны хәтта сүз белән аңлата да алмыйм. Артист рольнең характерын, темпераментын шулкадәр дөрес ача, ә шулай да нәрсәдер барыбер җитми, ул да булса–һәр рольгә генә хас табигый сөйләшә белү. Урыслар аны «словами не умеет действовать» диләр. Үз яшендәге рольләрне уйнаганда аңа бик зур игътибар бирмисең, ул турыда уйламыйсың.

Ә менә үз яшенә туры килмәгән карт кешене уйнаганда бу ап-ачык сизелә. Яшь чагында кемнең инде картларны уйныйсы килсен, җитмәсә, театр тулы өлкән яшьтәге артистлар.

Язган идем инде, театрда бик яшьли өлкән яшьтәге картларны уйнарга туры килде дип. Шәүкәт абый Биктимеров, Ринат Таҗетдинов, Равил Шәрәфиевләр минем балаларымны уйнап йөрделәр. Миңа аларның әтиләре, бабалары булып сәхнәдә ышандыру чиксез авыр иде. Ярый әле, бәхетемә күрә авылда туып-

үскәнмен, шуна күрә өлкән яшьтәге кешеләрнен сөйләшүен, хәрәкәтен, үзара мөгаләмәсен каныма сендергән булганмын. Беренче рольләремдә этиемне уйный идем, кайвакытта Гатуф абыйны, бик кирәк чакта Садыйк бабайны. Аларны күз алдыма китерүем була, үзеннән-үзе ничектер уйнарга жинел була иде. Урысча әйтсәк, бу минем «эмоциональ хәтерем» була. Шуна күрә мин кешенен характерын тиз тотып алам, һәрхәлдә, тамашачы минем карт кеше икәнемә ышана иде. Шуна күрә мине бик карт артист дип күз алдына китерәләр; хәзер дә, әле син исәнмени, дип сорыйлар.

Әйткәнемчә, мина картларны, яки начар кешеләрне уйнарга туры килгәч, нишләптер үзем дә сизмәстән, шул кешеләрне тамашачылар тарафыннан жәлләтергә тырыша идем. Шуна күрә тамашачы, бу жылак артист тагы сәхнәгә чыккан икән, дип каршы ала иде. Сәхнәдә рольнен характерын таба белгән артист (монда сүз тышкы кыяфәте турында гына бармый, эчке характеры турында бара) бик бәхетле була.

*Уят, дер селкет син, сискәндер!*
*Халкым жаны, бәлки, исәндер.*
Фәнис Яруллин

Шулай да бер фикергә тукталасым килә. Безнен заманда, XX гасырда, артистнын талантын партия, дәүләт житәкчеләрен уйный белүгә карап бәялиләр иде. Шуна күрә талантлы артист ничек кенә булса да Ленинны, Сталинны яки райком секретарен, һич югы карт большевикны уйнарга тырышты. Исемнәр, премияләр, зур хезмәт хакы шундый рольләрне уйнаган артистларга тизрәк һәм жинелрәк бирелә иде. Әлбәттә, коммунистик идея ул–кешелекнен мәнгелек хыялы. Бөтен телэгебез, омтылышыбыз–кешеләрне бәхетле итү! Бигрәк тә эшче-крестьянны! Шушы идея һәрбер спектакльдә ярылып ятарга тиеш. Юк, адәм балалары бу дөньяда тигез булалмый, Ходай Тәгалә адәм баласын тигез яратмаган, адәм баласы бу дөньяга килгән икән, телиме-теләмиме, ул якты дөньядан китәргә дә тиеш. Юк, мондый тормышта яшәп булмый! Бу дөньяда барыбер адәм баласынын бәхете юк, дип сәхнәдән әйтә алмагач, син тамашачыны үзеннен уенын белән тетрәндерә, уйландыра алмыйсын! Без бит киноларда, театрда үзебезнен чын тормышыбызны түгел, күбрәк хыялланган, уйлап чыгарган тормышыбызны күрсәтә идек.

Менә сугыш беткәнгә 60 елдан артык гомер узды, без әле бер мәртәбә дә халкыбызга бу сугышта күпме кеше һәлак булганын, чын дөреслекне, ни өчен андый зур фажигаләргә килүебезнен асылын, мәгънәсен ачып күрсәтмәдек. Мона бер вакытта да урыс дәүләте бармаячак. Чөнки үз халкын һәлакәткә алып баруын бөтен тирәнлеге белән ачып күрсәтсәк, бөтен дөнья алдында хур булыр идек. Без әле һаман фажигабезне бөтен тирәнлеге белән анлата алмыйбыз, ялганга корылган хакыйкать исә миллэтне эчтән тарката. Житәкчеләр үз халкына ышанмый, халык житәкчеләренә ышанмый. Шуна күрә ин дөрес юл–урыс хөкүмәте, анын житәкчеләре халыкка китергән фажигаләре, газаплары өчен халкыбыз алдында гафу үтенергә тиешләр. Әйе, безнен фильмнарыбызда, спектакльләребездә халкыбызнын фажигале язмышын, тормышыбызда булган чын дөреслекне тамашачыбыз сәхнәдән күрмәде. Ә бит театр–тормышнын көзгесе булырга тиеш! В. Маяковский аны «зурайта торган көзге» дип атый.

Безнен театрда да тормышнын бөтен катлаулыгын ачып биргән әсәрләрне сирәк күрдем, бармак белән генә санарлык. Андый әсәрләр юк икән, ничек инде талантлы артистлар үссен. Уртакул әсәр буенча куелган спектакльдә сәләтле артист зур унышка ирешергә дә мөмкин. Әмма, катлаулы, бөтен дөньяга танылган классик әсәрне сәхнәгә куйгач кына, талантлы артистнын кем икәнен анлыйсын! Безнен эштә зур максатларга ирешү өчен катлаулы язмышларны уйнарга кирәк.

*Юк, узмадык без гомер юлларын*
*Ак атларга менеп атланып!*
Зөлфәт.

Артист ул шулай туган: спектакльдә язганны гына уйнамый, үзе әйтергә

теләгән фикерне ничек кенә булса да барыбер житкерергә тырыша. Урыслар моны «подтекст» диләр, бигрәк тә сәхнәдә «пауза» вакытында артистның уены чын тирәнлеге белән күренә. Гомер узгач шуны әйтәсем килә: талантлы артист «пауза» тота белә, тамашачының нәрсә әйтергә теләгәнен, нәрсә уйлаганын сүзсез дә аңлый. «Пауза»ны уйный белү артист өчен зур бәхет, ул сирәк артистларга бирелә. Бик күп артистларга сөйләгәндә генә карарга кызык, ә инде репликалары булмаса, алар шиңгән гөлне хәтерләтәләр. Кайвакытта яшь артист уйный торган рольгә шул хәтле туры килә, тамашачы аны бөтен барлыгы белән кабул итә.

Минем үземә коеп куйган уңай геройлар уйнарга туры килмәде. Үз яшемдәге рольләрне уйнаганда да, миңа бик бәхетсез кешеләрнең язмышларын уйнарга туры килде. Монда эзләнеп торырга кирәкми, мин үзем шундый кеше дип, үз-үземне ышандырырга тырыша идем. Шушы ышанычым, бәлки, бик нык ярдәм иткәндер дә. Инде язган идем, шактый күп рольләрне икенче составта уйнадым, дип, нишләптер миңа рольләрне үземә генә бик сирәк бирделәр, бирсәләр дә гел минем арттан икенче артистны билгелиләр иде. Шуны әйтәсем килә, бу минем характерымнан киләдер, үземне сәләтле дип уйлап, шуны режиссерларга күрсәтергә тырышканмындыр. Яшь артистка әйтәсем килә: талантың барын сиздермә, мин кем дип күкрәк киереп йөрмә, театрда тормышың җиңелрәк булыр. Икенче составта уйнау артист өчен иң авыр, иң күңелсез эшләрнең берседер. Шуңа күрә театрда эшлисе килми, чөнки синең күңелеңдә режиссерга карата бик зур рәнҗү ята. Безнең эштә бер-береңә хөрмәт булмаса, уңышка ирешү турында уйлама да. Беренче состав белән куелган спектакльне син дә уйнап чыгарга тиешсең. Ничек инде мин Шәүкәт абый Биктимеров яки Илшат агай Йомагуловка атап куелган спектакльне уйнарга тиеш? Спектакль бит аларның уенына, ягъни табигый талантына корылган. Минем табигый сәләтем бөтенләй икенче, монда сүз әле кем талантлырак булуы турында бармый, хәер, була шундый рольләр, аларны шушы артист кына уйнарга мөмкин. Әгәр дә сез минем хәлдә калсагыз, Ходай сезгә сабырлык кына бирсен. Ничек кенә булса да шул спектакльнең җанын, рухын тоярга тырышыгыз, һәр көнне эшкә әзер булып килегез. Хәзер, 70 яшькә җиткәч, ул турыда әйтүе җиңел, билгеле. Урыслар безнең профессияне «женская профессия»–диләр, ягъни хатын-кызлар кебек, бөтен кешегә һәрвакыт ошарга, ярарга тырышырга, буйсынырга тиешсең. Ир кеше өчен менә шунысы иң авыры, чөнки үзеңнең табигатеңне үзгәртергә тиеш буласың. Ярый әле минем бер бәхетем бар, ул да булса–рольләрне кат-кат эшләргә яратам (кайчагында репетиция, тамашачы каршына чыгып уйнауга караганда, күпкә кадерлерәк), ягъни режиссердан нәрсә эшләргә икән дип көтеп тормыйм, үземчә эшләргә тырышам. Шуңа күрә икенче составта уйнаганда да миңа җиңелрәк булгандыр. Е. Вахтангов юкка гына язмагандыр бит: «актер–үз роленең режиссеры». Үземнән алдан уйнаган артистның уенын кабатламыйм, рольне үзем аңлаганча эшлим, үземчә уйнарга тырышам. Шуңа күрә минем җаным тыныч!

Артист өчен иң зур бәхетсезлек–аның тышкы кыяфәте белән эчке дөньясының туры килмәве. Тормышта искиткеч матур кеше, ә сәхнәдә үзенә җәлеп итә алмый, эчке дөньясы сай булуы өстенә, табигать биргән темпераменты да җитми, артист өчен моннан да зур бәхетсезлек юк! Хатын-кызларга килгәндә, үзе шундый ямьсез, сәхнәгә чыккач гаҗәп матурланып китә. Их, әгәр тышкы кыяфәте дә булса, ул нишләмәс иде микән, дип, аның өчен бөтен күңелең белән борчылып утырасың.

Театрда эшләү өчен миңа ярдәм иткән тагын бер сыйфатым бар, ул да булса тамашачылар мине яратсыннар иде дип уйнарга тырышмадым. Тамашачы мине яратамы-яратмыймы, бу минем өчен артык зур бәхет түгел иде. Ничек кенә булса да, үземчә дөрес уйнарга тырыштым, рольнең мәгънәсен бөтен тирәнлеге белән җиткерергә тели идем. Мине аңларга, кабул итәргә тамашачы аз гына булса да укыган, театр сәнгате белән беразкызыксынган кеше булырга тиеш. Хәер, мин уйнаган рольләрне тамашачы ничек яратсын инде. Алар артык катлаулы, начар кешеләр иделәр, тамашачы булсам, мин аларны үзем дә яратмас идем. Ә менә нишләптер бөтен күңелем, җаным шундый рольләрне уйнарга ашкынып, атлыгып торды. Соңыннан гына бер әйбергә игътибар иттем: яшь артистка уңай геройларны уйнау зур бәхетләр китерә, чөнки тамашачы андый артистларны ярата, бигрәк тә безнең тамашачы. Артист уңай рольләр уйнаса, ул үзе шундый кеше дип, тамашачы аны зурлап хөрмәт итеп кабул итә. Әгәр артист берәр исерекне, яки кешеләрнең

тормышын җимерүче явыз рольне уйнаса, ул үзе дә шундый, шуңа күрә ана андый рольләр бирәләр, дип чын күңелдән ышана. Ин кызыгы шул, син роленне никадәр яхшы уйнасан, тамашачы күңелендә шулкадәр начар кеше булып каласын. Тормышта да бит әшәке кешене уйнаган артист белән бик үк сөйләшәсе дә килми. Бу ни дигән сүз, тамашачы артистны уйнаган роле белән тәңгәл күрә. Ягъни, театрда күпвакыт киресенчә: тормышта артист кеше буларак бик әйбәт, ә менә тискәре рольләрне уйный, кайвакыт унай геройны уйнаганы кеше буларак бер тиен дә тормый! Ә бит театрда гомерләре буе гел начар кешеләрне уйнаган артистлар да бар. Кайвакыт артист сәхнәгә чыгу белән көлә башлыйлар, әле ул кемне, нинди кешене уйный, ул турыда уйламыйлар, хәзер көлдерә башлар дип анардан көлке, кызык көтеп торалар. Тамашачы бу артистка тамга салган: ул аннан бары тик кызык, көлке генә көтә. Гел унай рольләрне генә уйнап килгән артистны да әшәке кеше ролендә уйнавын тамашачы кабул итми. Артист үзе дә шуны сизеп тора, анын бөтен күңеле, җаны өзгәләнә. Бу артистлар өчен бик зур күңелсезлекләр китереп чыгарырга мөмкин. Тамашачыга ошар өчен артист кирәксә-кирәкмәсә дә көлдерергә тырыша, гел унай геройларны уйнаган артист, ничек кенә булса да тискәре рольләрдән котылырга тырыша, мина моны безнен сәхнәбездә шактый күрергә туры килде. Ә бит чын сәләтле артистны тамашачы бөтенләй икенче төрле кабул итә. Ул бу рольне ничек итеп уйнар икән дип көтеп ала, кара әле, бу рольне болай да уйнап була икән бит дип, артист өчен чын күңелдән шатланып, сөенеп, горурланып утыра.

Мин үзем тамашачыны көлдереп кенә тәм таба торган артист түгел, залда киеренке тынлык урнашса, вакыты-вакыты белән тамашачы йөрәгемнен ничек типкәнен тойса, мина шул житкән, артыгы кирәкми.

Артистнын сәләте–тамашачынын җанына, күңеленә тәэсир итү көче. Әлбәттә, тамашачы катлаулы әсәрләрне авыр кабул итә, бигрәк тә андый әсәрләрне карарга өйрәнмәгән булса. Без Эдуардо де Филиппонын «Бәйрәм кичендә» әсәре буенча куелган спектакль белән авылларда йөрдек. Бу әсәрдә вакыйгалар Италиядә бара. Беренче пәрдәсен шул хәтле көлеп, алкышлап, кул чабып карыйлар, артистлар барыбыз да: «Ну, малай, спектакль шул хәтле яхшы бара, тамашачы болай кабул итәр дип беребез дә көтмәгән идек!» Спектакльнен икенче пәрдәсен уйный башлагач, тамашачы безнен уенны кабул итми, анламый башлады. Ничек инде, әле генә шундый әйбәт кеше иде, хәзер анардан да әшәке кеше юк. Монысы шундый начар кеше иде, ә хәзер аннан да гадел, әйбәт кеше юк. Тамашачы андый уенны, андый кешеләрне кабул итми, чөнки ул өйрәнгән: начар кеше–әшәке кеше инде ул, яхшы кеше–яхшы кеше инде ул. Ә бит тормышта кеше гел яхшы гына да, начар гына да булмый, шуңа күрә аны кеше диләр. Без сәхнәдән гомер буе, бу ак, бу кара дип уйнап килдек. Чын тормышны бөтен катлаулыгы белән уйнарга өйрәнмәдек. Шуңа күрә тамашачы безнен бу спектаклебезне кабул итәргә әзер түгел иде. Безне: «Зинһар, мондый спектакльләр алып килмәгез»,–дип, чын күңелдән рәнжеп, сүгеп калалар иде, бигрәк тә тәрҗемә әсәре булганы өчен.

Әйе, ул вакытта әле чит ил сериалларын телевизордан күрсәтмиләр, халык чит ил әсәрләрен карарга күнекмәгән иде. Әгәр дә ул урыс тормышыннан булса, җиңелрәк кабул итәрләр иде.

Хәзер инде гомер узгач, шуны әйтәсем килә, тамашачы да артистлар белән бергә үсә, әкрен-әкрен генә катлаулы әсәрләрне карарга өйрәнә. Моның өчен талантлы режиссер, талантлы артистлар кирәк, шунсыз гади тамашачыны классик әсәрләрне карарга җәлеп итә алмыйсын. Тукта әле, без дә Шекспирны яки Чеховны куеп карыйк әле дип, хәзер бер кешене дә шаккатырып булмый. Сүз дә юк, театр булгач, анын режиссеры да, артисты да дөнья классикасын куярга, уйнарга тырыша. Әйткәнемчә, талантлы режиссер яки талантлы актер бар икән, нигә куеп карамаска. Бездә дә «Антоний һәм Клеопатра»ны куеп карадылар, нишлисен бит, көчле яңгырамады шул. Бу спектакль, режиссернын андый әсәрләр куярга тумаганлыгын, артистларнын андый режиссер белән Шекспирны уйнарга әзер түгел икәнлеген күрсәтте. Классик әсәрләрне куясын икән, син бит анын бөек үрнәкләре белән ярышырга тиеш буласын. Бу әсәрләр йөз еллар буе куелып, уйналып үзләренен бөеклеген исбат иткәннәр. Шуңа күрә аларны татар сәхнәсенә куярга алыну, режиссердан искиткеч батырлык, үз-үзенә ышану сорый.

Празат абый Исәнбәт В. Шекспирнын «Чамасына күрә чарасы» комедиясен

сәхнәгә куеп театр өчен зур эш башлаган иде, әмма шул эшен дәвам итмәде, бик кызганыч. Менә 50 елдан артык инде Татар академия театрында В. Шекспирның «Гамлет», «Макбет», «Король Лир», «Отелло» кебек бөек трагедияләрен куеп карамадылар. Әллә режиссерларыбызның көче житмәде, әллә үзләренә артык таләпчән булдылармы? Чыннан да, классик әсәрләрдә артистның табигать биргән бөтен мөмкинлекләре ачылырга мөмкин. Минем үземә андый бәхет эләкмәде. Сәхнәдә катлаулы язмышларны уйнарга өйрәнергә кирәк, ул бик жинел әйбер түгел. Ә инде шул катлаулы язмышлар аркылы милләтеннең фажигасен, жанынны борчыган уйларны, сорауларны тамашачыга житкерү, уйный торган ролең белән тамашачыны, залны тетрәндерә алу–зур бәхет!

*Кайгырма баш, түгелмә яшь,*
*Без күрәсен, кем күрсен!*
Халык сүзләре

Мин инде язган идем, театрда артистның язмышын режиссер хәл итә дип. Бигрәк тә татар театры артисты язмышын, чөнки бездә дистәләгән академия театры юк, ул берәү генә. Шуңа күрә син, телисенме-теләмисенме, театрда нинди режиссер бар, шуңа буйсынырга мәжбүр буласың. Ә бит урыс артисты ул үзенең режиссерын эзли. Шул режиссер белән үзенең язмышын бәйли, шуның белән бергә гомер буе бергә эшләргә тырыша. Кая инде ул безгә, татар артистына андый бәхет. Булса да шул бик сирәк артистларга гына эләкте, бармак белән генә санарлык. Ни өчен соң артистка үзе теләгән, үзе табынган режиссер белән эшләве иң зур бәхет? Синең жаның, күңелең, дөньяны аңлавың, театр сәнгатенә карашың режиссер белән тәңгәл килергә тиеш. Бигрәк тә бүгенге татар тормышының фажигасе, татар милләтенең бәхетсезлеге, киләчәктә ни өчен татар милләте болай яшәсә юкка чыгачак икәнен татар режиссеры күңеле, жаны белән сизәргә тиеш. Моны Станиславский «сверх-сверх задача» дип атый. Татар академия театрының миссиясе шул, ничек булса да үз милләтеңне саклап калу юлларын күрсәтергә тырышу! Әлбәттә, театр сәнгате биеклегендә, әгәр дә ул чын сәнгатьчә эшләнмәгән булса, иң бөек фикерләрне дә юкка чыгарырга мөмкин.

Театрда иң катлаулы эшләрнең берсе–ул режиссер белән артистның фикер каршылыгы. Чыннан да, режиссер безнең милләтебезгә, бүгенге тормышыбызга, дәүләтебезгә нинди күзлектән карый? Ул шушы милләтне саклап калу, үз дәүләтеңне торгызу, татар дигән халыкның бер милләттән дә ким түгел икәнлеген сәхнәдән күрсәтергә әзерме? Шушы тормышка яраклашып, милләтнең юкка чыгуына риза булып, бернәрсә дә бездән генә тормый, булганына канәгать булып, ничек яшәдек, шулай тыныч кына яшик, татар милләте барыбер бетәчәк, аның киләчәге юк, дип кул кушырып утырыйкмы?

Халкыбызның ирекке, азатлыкка булган омтылышын, үзебезчә яшәргә хакы барлыгын, милли аңын уятыйк, бөтен дөньяга сибелгән татарларны берләштерик дигән бөек фикерне театр сәнгате дәрәжәсенә күтәрик! Шул вакытта гына безнең өстән бурыч төшә! Сәнгать дәрәжәсенә күтәрелгән фикер ул бөтенләй икенче яңгыраш ала. Минем шушы фикерләремнән иптәшләрем дә, режиссерлар да гел көләләр иде. «Син нишләп анда, Ирек мәйданында революция ясап, әйдәгез, татарлар, урамнарга чыгыйк, үзебезнең барлыгыбызны бөтен дөньяга күрсәтик, дип кычкырып йөрисең!» Янәсе, иптәшләрем мине шулай мыскыл итәләр иде, әлбәттә, үзләренчә яратып.

Мин исә театр сәхнәсеннән әйтелмәгән фикерләремне меңләгән халык алдына чыгып әйтергә мәжбүр була идем. Бездә бит кеше үзен шушы илнең гражданины итеп тоймый, ник бөтен дөньясы асты-өскә килми, минем югалтыр нәрсәм юк дип, булганына канәгать булып, тыныч кына яши бирә. Без бит әле чын мәгънәсендә ирекле илдә ирекле гражданнар булып яши алмадык. Шундый бөек революциядән соң, 100 ел узгач үткәннәргә кире кайту, империя төзергә хыяллану, бу урыс халкына хас сыйфаттыр, күрәсең! Ничә 100 еллар дөньядагы иң әшәке урыс империясенең таркалуын бөтен дөнья халыклары сөенеп, шатланып, куанып каршы алды. Ниһаять, Европа иркен сулап куйды. Советлар Союзы дигән дәүләтнең таркалуыннан Россия мәңге онытылмаслык сабак алырга теш иде. Ленин юкка гына: «Россия есть тюрьма народов»,–дип әйтмәгән.

Халыкларга үзенчә яшәргә ирек бирмәсә, бу дәүләт тә киләчәктә барыбер таркалачак. Аккан суга ике кереп булмый. XXI гасырда патша Россиясен кире торгызырга тырышу иң зур хаталарыбызның берсе булачак, тагын әйтәчәкләр, нишләп без шундый зур хаталар җибәрдек, дип. Дөньяның алга киткән илләре, Европа безгә ничек яшәргә юл күрсәтеп тора. Шулардай үрнәк алмыйча янадан-яна «велосапидлар» уйлап чыгарабыз. Иң аянычлысы, шул үткәннәрдән дөрес сабак алмау, гаделсезлеккә, алдауга, караклыкка корылган илнең язмышы фаҗигале бетә.

*Җирдә тигезлек булмас,*
*Кемдер көткәнгә генә.*
*Барыбыз да бер булырбыз—*
*Дөнья беткәндә генә.*

Илдус Гыйләҗев

Үз фикере белән уйнарга өйрәнгән артистны сәхнәдән караву кызыграк, ул кабатланмаска тырыша. Фикер дигәннән, сәхнәдә уйлый белә торган артистларны сирәк күрдем. Бу чын мастерларга гына бирелә. Хәзерге артистның үенын, әйтергә теләгән фикере, сәхнәдә уйлый белүе, үзенә генә хас органикасы билгели. Шуңа күрә талантлы артист кайчагында уйный торган роленә караганда үзе кызыгырак. Чехов, Достоевский, Шекспирны уйнаганда гына бу рольне артист уйный алмый, дип борчыласың. Чөнки аларны уйнар өчен, үзенә дә бөек булып туарга кирәк. Шундый рольләрдә күренә инде ул артистның Ходай Тәгалә биргән сәләте. Күпвакыт мине иптәшләрем, режиссерга ярарга тырышып, режиссер синнән күбрәк белә дип, бик каты сүгәләр иде. Яшь артистка әйтәсем килә, әйтергә теләгән фикереңне уйнап күрсәт, шунсыз режиссерларны җиңеп булмый. Хәер, бер генә артистның да режиссер алдында үз иптәшен бик үк талантлы итеп күрсәтәсе килми. Күп очракта без бергә эшләгән иптәшләребезнең сәләтенә дөрес бәя биреп бетермибез. Минем өчен иң зур бәхет: иптәшемнең талантлы булуын сизү, шуңа чын күңелдән шатлана белү. Югыйсә, ничек инде татар артисты, урыс артисты белән тиң булсын дип, безнең каныбызга сеңдергәннәр. Хәзер без дөньяның шактый илләрендә булгач, төрки халыкларының бик күп театрларын күргәч, үзебезнең театрга дөрес бәя бирә башладык. Күп вакыт спектакльнең уңышы артист үене белән билгеләнә, әгәр артист дөрес тональностьтан башласа, тамаша бөтенләй көтмәгән яктан ачылып китә. Музыкантлар әйтәләр бит, анда «абсолютный слух» диләр. Драма артистында бар ул «мотлак ишетү» сәләте, артистның «фальшивить» иткәнен спектакль саен сизеп торасың. Барыбер табигать үзенекен эшли, сиңа җаныңны ачарга ярдәм итә. Җан дигәннән, сәхнә адәм баласының бөтен җанын, күңелен белеп ала, сәхнәне берничек тә алдап булмый. Хәтта артист тормышта намуслы булса, ул да үзен сиздерә. Сәхнә үзе дә артистны тәрбияли, үстерә, сәхнәгә изге урын дип караган артист—ул бөтенләй икенче кешегә әверелә. Әгәр Аллаһы Тәгалә бар һәм бер дип ышанучы дин әһелләре дә артистлар кебек үз эшләренә чын күңелдән бирелеп хезмәт итсәләр, халкыбыз өчен нинди зур бәхет булыр иде.

Чын артист гомер буе «власть, хакимият» белән көрәшеп яши, бигрәк тә хәзерге хакимиятне яраткан артистка минем ышанычым юк, чөнки чын артист ул гаделлек өчен көрәшә торган шәхес! Кайбер артистларда халкыбызның җаны чагылып китә, болай бары тик татар артисты гына уйларга мөмкин дип, сөенеп куясың. Бер әйбергә игътибар итәсем килә, нинди генә рольне эшләсә дә, артистка үз роленең хуҗасы булырга туры килә. Сез әйтерсез: артист Шекспирдан, Чеховтан да талантлырак булырга тиешмени? Әгәр дә ул бүгенге тамашачыны тетрәндерә алмаса, моннан 400 еллар элек язган Шекспирдан үзен өстен итеп санамаса, аның бүгенге тамашачыга әйтер сүзе юк! Әлбәттә, моның өчен бөек акыл кирәк, мин театр сәнгате, образлы акыл турында әйтәм.

*Иртән яуган яңгыр,*
*Соңга калган карда*
*Безнең язмыш белән охшаш нидер бар.*

Клара Булатова

Мина гомер буе нәрсәдер житмәде, эшләгән эшләремнән гел канәгать булмадым. Менә иртәгә тагын да әйбәтрәк уйнармын дип, үз-үземне төннәр буе җәфалый идем. Йөрәк бүгенге белән яши, акыл киләчәк белән, шуңа күрә адәм баласында акыл белән йөрәк көрәшә. Сез әйтерсез, һәрбер кеше үзен яхшырак, акыллырак күрсәтергә тырыша. Бу очракта миндә андый теләк юк, мин кем, нинди кеше икәнемне иптәшләрем күреп торды. Үзенне мактап язып кына, мин менә мондый, мин тегенди дип кенә, кешеләрне ышандырып булмый. Миннән артист чыктымы, юкмы дип, кайчагында хәзер дә уйланып куям. Хәтта, артистның рәсемен күргәч тә аның турында нindидер фикерләр калырга тиеш, әгәр дә ул чын артист булса, юк икән, бик кызганыч. Гомер узгач кына без аңлыйбыз, бу артистның кем булганын, чөнки чагыштырып карагач кына күрәсең, нинди талантлы артист булган ул! Татарда гына түгел, урыс дөньясында да Смоктуновский, Лебедев, Ульянов, Леонов кебек артистлар юк хәзер. К. Станиславский дөрес язган, чын талантлар 50 елга бер туа, бу табигатьнең законы. Табигать законы дигәннән, мине артист булып уйнарга өйрәткән мәктәп, артист образны тудырырга тиеш, дип өйрәтә. Ягъни ана баласын ничек тудырса, артист үзенең ролен шулай тудырырга тиеш. Кайвакытта бит бала үле дә туарга мөмкин, менә шул инде артистның бәхетсезлеге. Бөтен дөнья шушы мәктәпнең серләренә төшенергә тели, тырыша, тырмаша. Хәзерге заманда иң көчле мәктәпләрнең берсе–урысларның театр сәнгате мәктәбе дип саныйм мин.

Техника белән сәнгатьнең үсеше бик нык аерылып тора. Техника һәрвакыт үсештә, хәзер космоста рәхәтләнеп очып йөриләр, тагын йөз елдан Марска туганнарына «кунакка» йөрерләр, Айдагы җирләрне сатып, баеп бетәрләр. Театр сәнгате законнарының үсеше бөтенләй башка юлдан бара. Менә без «Джоконда»ны карыйбыз. Аны эшләгән Леонарда да Винчи моннан 450 еллар чамасы элек вафат булган, ләкин рәсемгә үзенең җанын биреп калдырган. Шуңа күрә ул бүген дә, киләчәктә дә адәм балаларына шулай көчле тәэсир итәчәк. Яки француз скульпторы Роденның «Поцелуй» скульптурасы, Бакый ага Урманченың «Сагыш»ы–ул бит мәңге калачак. Мин инде татарның бөек шагыйрьләре Кол Гали, Габдулла Тукай, Һади Такташ турында әйтеп тә тормыйм. Әдәбиятта алар ирешкән биеклеккә ирешеп буламы? Мин шуны гына әйтергә телим: әдәбиятны, сәнгатьне даһилар гына үстерә, бу–табигать законнарына бәйләнгән. Театр сәнгате 40-50 елдан соң шулай булачак дип, беркем дә әйтә алмый. Медицина, космос, биологиянең 40-50 елдан ничек булачагын хәзер үк әйтеп бирергә тырышалар һәм күп очракта ул дөреслеккә туры килә. Әле кайчан гына йөрәккә операция ясый башлаганнар иде, хәзер инде миллионнарга ясыйлар, ул гадәти эшкә әйләнеп бара. Чыннан да, әдәбиятта, сәнгатьтә шундый биеклектәге үрнәкләр бар, аларны берничек тә кабатлап булмый, ул техника түгел. Шуңа күрә минем күз алдымда элекке артистларның уены бүген дә бөек үрнәк булып торадыр. К. Станиславскийның «верю-не верю» термины белән уйнарга өйрәнгәнгә күрә, кайвакытта мин артистларның уеннарына ышанмыйм, монда сүз теләсә нинди жанрга да карый, трагедияме, комедияме, драмамы, барыбер. Мин кеше буларак артистның хезмәтен хөрмәт итмәсәм, таланты алдында чын күңелдән баш имәсәм, болай язмас идем. Хәзер бит театрга, режиссерларга шул хәтле авыр, алар бөтен дөньядагы сериаллар белән ярышырга тиешләр. Алай гына да түгел, тамашачы тели икән: урыс, инглиз, испан, италия театрын карый ала, чөнки «Культура» каналы дөньядагы иң көчле, иң кызык яңалык алып килгән спектакльләрне күрсәтә. Безнең заманда боларның берсе дә юк иде бит. Татарлар өчен бары тик татар театры гына бар иде, хәзер инде менә шулар белән ярышып кара. Сез әйтерсез, синең дөреслекне әйтергә хакың бармы соң дип, сүз дә юк, моның өчен мөмкин кадәр гадел кеше булырга кирәк. Барыбер бит, сизелеп тора, сине тәнкыйтьләгән кеше чын күңеленнән әйтәме, әллә иптәшенең иң авырткан җиренә тибеп, шуннан ләззәт, рәхәт аламы...

Мин инде язган идем, иптәшләремнең талантлы булуы миңа үсәргә бик ярдәм итте дип. Без бит әйтәбез, бу артист йөрәге белән уйный, дип. Аның белән бергә уйнаган иптәше дә, телиме, теләмиме, партнер буларак барыбер ана ияргә мәҗбүр була. Талантлы кеше янында үзең дә сизмәстән талантлы булырга тырышасың. Без сәхнәдә бер-беребездән шулкадәр бәйлебез, моны сүз белән генә аңлатуы авыр. Мине рольләрне уйнаганда соңгы мәртәбә уйнаган кебек уйнарга тырыша, дип язып чыктылар, бәлки чыннан да соңгы мәртәбәдер, аны бары тик бер Алла

гына белә. Шулай да теләгән теләккә ирешеп булмый, син якынаясын, ә ул һаман ерагая бара.

Урыслар әйтә: «Талант не пропьешь,»—ул йә бар, йә юк, диләр. Мин театрда эшләгәндә талантлы кеше эчмичә түзә алмый, талант үзе кешене эчәргә мәҗбүр итә, дип анлаталар иде. Кем талантлы, шул эчә! Әлбәттә, бу сүз урыс артистының девизы! Без дә урыслардан уздыру өчен, үзебезнен талантны күрсәтү өчен, алардан ким эчмәдек. Хәзер гомер узгач, яшьләргә шуны әйтәсем килә, ул чирне җинә белү татар артисты өчен ин бәхетләрнен берседер. Без урыслар кебек мең еллар буе аракы эчеп өйрәнмәгәнбез, бездә аракыга каршы торырлык геннар юк. Зинһар, ул эшәке чирдән мөмкин кадәр сак булыгыз! Хәер, хәзер инде Аллага шөкер, Академия театры ул чирдән котылды кебек...

Татар артистының язмышы эшли башлаганда ук билгеле була, мин инде кинотелевидение турында әйтеп тә тормыйм. Сез әйтерсез, син нишләп татар артистын урыс артисты белән тинлисен дип. Сүз талантлы артистлар турында бара. Минем белән бергә эшләгән татар артистларының шундыйлары бар иде, алар берниндидә урыс артистыннан ким түгел иделәр. Мин моны дөньядагы иң талантлы артистларны күреп, өйрәнеп үскәнгә әйтәм. Хәер, моны анлар өчен урысча уйнаучы берничә татар артистын искә төшерү дә җитә. Мин аларны татар дип шуна әйтәм, алар үзләрен татарлар дип йөртәләр. Эра Иркә Зиганшина, Сергей–Сәет Шәкуров, Чулпан Хамматова, Марат Бәширов, Роза Хәйруллина–саный китсән, алар һәр урыс театрында бар. Бу ни дигән сүз, татар артисты урысча яхшы белсә, теләсә нинди урыс театрында, теләсә нинди кинода төшә ала, урыс артистыннан бер дә ким түгел! Хәзер инде мин куркам, татарнын ин талантлы балалары, татар театрын ташлап, урыс театрында эшли башларлар дип.

Исемә төште: безнең «Баскетболист» спектаклен карарга «УНИКС»та уйнаучы баскетболчылар килгәч, шулай үзара сөйләшкәндә сүз артыннан сүз чыгып, алардан: сез бер уенга күпме акча аласыз, дип сорыйлар. Алар әйтә: 15-20 мен доллар, диләр. Ә сез? Безме, без 3500 сум. Бер спектакльгәме? Юк, бер айга. Сезненчә 125 долларга якын. Шулай дигәч, беркем дә ышанмый, ничек инде академия театры артисты шушындый хезмәт хакына эшләсен? Мин бу турыда күп сөйләдем, күп яздым инде. Без бит хәтта, Оренбург, Самара, Омск, Новосибирск театры артистларыннан да ким алабыз. Ни өчен мин бу турыда ачынып язам? Дөнья үзгәрде, талантлы татар артисты үзенең язмышына риза булып яшисе килмәс. Хәзерге заманда бөтен нәрсә акчага корылган, милләт, Ватан юкка чыкты. Әгәр акча түләмиләр икән, берсенен дә кирәге юк. Акча кайда, илем шунда! Нишләп әле мин юк-бар акчага академия театрында эшләп йөрим. Кайчагында, мыскыл итеп, миннән сорыйлар: «Если ты такой великий, почему ты нищий?» Кызганыч, мин яһүд түгел, аларнын гына таланты бик кыйммәт тора, дип әйтәм. Әйе, зур-зур шәһәрләр, матур-матур йортлар, метролар, кин-төзек юллар да салырлар, ләкин, ул юлларда йөрүче, матур-матур йортларда яшәүче, үз телендә сөйләшүче, үз җырларын җырлаучы, үз динен тотучы татар дигән милләт кенә булмас. Мең еллар килгән тарихын, әдәбиятын, мәдәниятен, гореф-гадәтләрен, үз дәүләтен төзим дигән дәртен, бөеклеккә омтылышын югалткан, урыслашкан милләт кенә булыр.

*Күңелләремнең бетте кәгъбәсе.*
*Җирдә яшәүнең бетте мәгънәсе.*

Кабатлама, күп яздың диярсез. Нишлим, йөрәгем, җаным әрнегәнгә язам. Мин бит артист, дөньяны образлы итеп күрәм. Юк, татарны әле тиз генә бетерә алмассыз, «господа»! Әгәр ул үзен-үзе бетермәсә...

Әйе, үткән гасырның 80 нче елларында урыс халкының ин укымышлы, иң акыллы, бүтән халыкларга мөмкин кадәр гадел, демократик дәүләт төзергә хыялланган интеллигенциясе милли азатлык идеясен безнең күнелләребездә уятты. Ул вакытта без шактый зур уңышларга да ирешкән идек. Татарстандагы референдум, Россия белән килешеп яшәүче Татарстан дәүләте, телләр турындагы законнар, чит ил дәүләтләре белән турыдан-туры бәйләнешләр, саный китсән–алар әле шактый. Шушы күпме көч түгеп эшләгән гаять зур эшләр, милли аныбызны үстерергә, милләтебезне, телебезне саклап калырга, киләчәк буынны чын татар баласы итеп тәрбияләргә без

теләгәнчә ярдәм итмәделәр. Бөтен көчне, акылны, халкыбыз күнеленә без аерым дәүләт булсак, һичшиксез, яхшырак яшәр идек, үзебезне милләт буларак саклап калырга мөмкинлекләребез күбрәк булыр иде, дип аңлата алмадык. Шушы фикер белән халкыбызның милли җанлы балаларын берләштерергә мөмкин булыр иде. Вакытында безгә бирелгән мөмкинлекләрдән тулысынча файдалана алмадык: милли аңыбыз түбән булуы, җитәкчеләребезнең милли хәрәкәтләрдән дөрес файдалана белмәве, Татарстан дәүләтенең дөньякүләм оешмаларга тәкъдим ителмәве, татар дигән милләтнең бөеклегенә ышанып җитмәү, байлыкка омтылу, безне урап алган «враждебный мир» халкыбызның милләт буларак киләчәген авыр хәлгә куйды. Сез әллә һаман да ышанасызмы, урыс хөкүмәте безгә милләт буларак яшәргә, үсәргә мөмкинлекләр тудырыр дип? Юк, ул бөтен милләтләрне бер телле иттереп, бу илдә бары тик урыс телле халыкларның гына яшәргә, үсәргә хакы бар, дип кисәтеп тора. Йә без милләтебезне, халкыбызны саклап калабыз, йә ул безнең белән бергә юкка чыгачак.

*Татар менә шундый зат ул:*
*Шатландымы, аша күкләргә.*
*Бик аз гына бәхет татыса да,*
*Рәхмәт белдерә ул күпләргә.*

Ш. Әхмәдулла

Моннан 100 еллар элек Гаяз Исхакый татарлар урыс телен, әдәбиятын, сәнгатен белмәсәләр, университетларда укымасалар, урыслардан артка калып милләт буларак юкка чыгачаклар, дип язган иде. Әлбәттә, 1902 елда бу фикерләр чын мәгънәсендә зирәк, бөек булганнар, чөнки ул заманда дөньяның ничек үзгәрүен, үсүен бары тик урыс телен яхшы белгән кеше генә аңлый алган. Хәзер дә без дөньяның бөек ачышларын, аның бүгенге тормышын урыс теле аша беләбез. Гаяз Исхакыйның бу бөек фикере безнең каныбызга сеңгән. Ә бүген иң зур фаҗигабез–хәзер безгә газиз ана телебез кирәкми, хәтта без татар исеменнән хурланабыз. Гаяз Исхакый бит моны 1902 елда күз алдына да китермәгән, халык үз теленнән, диннән, дәүләтчелегеннән ваз кичәр дип. Дөньяны күпме яхшырак белсәң, үз милләтеңә, халкыңа шул кадәр хөрмәт уяныр, дип уйлаган. Бүген беркем урыс телен белмәгез дип әйтми, ләкин үз ана телен белмәгән кеше кем була?

Минем миллионлаган халыкның үз ана теленнән ваз кичкәнен күргәнем дә, ишеткәнем дә юк иде. Хайван да үз телен онытмый–без шул хайваннардан да түбәнмени? Телләр бетәчәк, бары тик биш-алты тел генә калачак дип, безне юатырга тырышалар. Алайса урыслар тизрәк кытай теленә күчсеннәр, чөнки дөньядагы халыкның дүрттән бер өлеше кытай телендә сөйләшә. Әлбәттә, үзен бөек милләт дип санаган, аның киләчәгенә ышанган халык, үзенең газиз ана телен мәңге югалтмаячак. Хәзерге вакытта милли аңыбызны уятырлык, үз артыннан ияртерлек шәхесләр тәрбияләү безнең иң изге бурычыбыздыр. Корал белән урысларны җиңә алмыйсың, әмма милләтнең көченә, аның киләчәгенә ышанган кеше ул инде бөтенләй икенче татар була. Әйе, минем фикерләремне кабул итмәскә дә мөмкин, әмма мин аларны чын күңелемнән яздым. Аннан соң бу фикерләрне миңа караганда акыллырак, төплерәк, кискенрәк итеп язган милләттәшләрем дә бар. Әмма артистлар түгел. Шуңа күрә гади тамашачыга, мине белгән, аңлаган, хөрмәт иткән милләттәшләремә бераз тәэсир итәрмен дип уйлыйм. Бөтен әйберне юкка чыгарырга мөмкин, ә менә бөек идеяне юкка чыгару мөмкин түгел.

Сез әйтерсез, үзеннән тормышың турында, рольләреңне ничек эшләвең турында, театрдагы кызык хәлләр турында нигә язмадың дип? Үзем белән булган кызык хәлләр турында, рольләрне ничек эшләвем турында мин инде күп яздым, аларны кабатлап тормыйм. Мин бары тик К. Станиславский ачкан театр сәнгате турындагы законнарның дөреслеген үз эшем белән расларга гына теләдем. К. Станиславский артист хезмәте турында шундый югары биеклектә язган, күпме генә тырышсаң да үз максатыңа ирешеп булмый. Урыслар: «артистом ты можешь и не быть, но гражданином быть обязан» диләр. Бу миңа бик туры килә. Артистлар алар шундый халык. Аларга һәрвакыт эш бирергә кирәк, ансыз алар яши алмый.

Минем иң зур үкенечем шул: милләтне саклап калу өчен аның дәүләтен торгызу өчен жанын фида кылырга әзер булган шәхесне уйнарга насыйп булмады. Милли аңның үсүе турында уйландырырлык, тамашачыны тетрәндерерлек әсәрләр иң кирәк чакта сәхнәгә менмәде. Ислам диненнән биеклеген ачкан әсәрне сәхнәгә куймадык. Гаяз Исхакый кебек бөек шәхеснең язмышын театрда, кинода күрергә насыйп булмады. Милләте хакына үзен корбан итәргә әзер булган, әдәбиятыбызны бер баскычка күтәргән, халкыбызны «йокысыннан» уяткан, фикеренең тирәнлеге белән замандашларыннан бик күпкә аерылып торган милли героебыз үзенә тиешле бәяне алмады! Казан ханлыгының жимерелүе, Сөембикәнең фажигале язмышы, татарлар турында бүгенге күзлектән карап, чын дөреслекне, бабаларыбызның бөек фажигале язмышын ничек кенә булса да татар театры сәхнәсенә менгезергә иде. Әдипләребезне, язучыларыбызны күпме хәзинә көтә. Милләтнең бөеклеген талантлар билгели. Чыңгыз Айтматов, Рәсүл Гамзатов, Мостай Кәрим, Касыйм Кулиев, Давыд Күгелтдинов кебек талантлар урысның кайсы язучысыннан, шагыйреннән ким? Ә бит боларның милләте татар халкы кебек сан ягыннан зур милләт түгел. Татар театры да Россиядә иң көчле театрлардан саналды, мин моны урыс театр тәнкыйтьчеләре әйткәнгә генә әйтмим, заманында урыс театрларын мин күп карадым. Халкыбызның таланты сәнгатьтә, бигрәк тә театрда мина калса көчлерәк ачыла сыман, бәлки үзем шул эш белән шөгыльләнгәнгә шулай тоеладыр. Юк, әлбәттә, театрны шулкадәр нык яраткан тамашачыны мин беркайда да күрмәдем. Ул яктан Аллаһы Тәгаләгә мең рәхмәт, без бәхетле артистлар булдык. Рәсәйнең кайсы шәһәрендә булсак та халкыбыз, тамашачыбыз безгә күрсәткән хөрмәтне минем мәңге онытасым юк. Башка милләт артистлары бездән гел көнләшәләр иде, сезнең бөек тамашачыгыз бар дип. Хәтта урыс артистлары, урыс авылына кермичә спектакльләрен татар авылында уйнарга тырышалар иде, чөнки татар авылында заллары тулы була. Бүген дә Качалов театрында тамаша залының яртысыннан күбесе безнең милләттәшләребез утыра. Менә хәзер милләт үз телен югалткач, татар театры белән нәрсәләр булыр–мин әйтә алмыйм. Халкыбызның милләт буларак яшәргә омтылышы, милли жаны, бөтен рухы, шул театрда гына сакланып калгандыр, ахрысы. Чыннан да, татар үзен милләт буларак театрда гына кеше итеп хис итә. Мондый милли фажигане мин жаным, йөрәгем, күңелем белән аңлыйм. Бөтен милләттәшләрем шушы фажиганең тирәнлеген аңламыйлар, безнең киләчәгебезне, бәхетсезлегебезне күз алдына китермиләр төсле тоела, әллә аңлап та шул кадәр сабыр, артык акыллы кешеләрме? Гел акыл кушканча гына яшәсәң, үз-үзеңне югалтасың, кайвакыт акылны читкә куеп, йөрәк, жан кушканча яшәргә кирәк. Тукай сүзләре хәтергә килә:

*Юк, коягиым, мин беләм: син батмагансың мәңгегә,*
*Син вөҗдан белән торырсың, ятмагансың мәңгегә.*

---

## РЕДАКЦИЯДӘН.

***Быелның февралендә артист (һәм публицист) Әзһәр Шәфыйкъ улы Шакировка 70 яшь тула. Олуг юбилее уңаеннан аны күпсанлы укучыларыбыз исеменнән котлыйбыз һәм алдагы тормышында да иҗади уңышлар, саулык–саламәтлек теләп калабыз.***

# К

**КАРГАЛЫЙ** Әбелманих (тәхәллүс, чын исеме Габдессәлам Әбелманих Әбелфәиз угылы) (1782, Оренбург губ., Каргалы бистәсе—1833 тән сон), шагыйрь, дин һәм җәмәгать эшлеклесе. Шагыйрь Габдессәлам бине Урай оныгы. Бохара мәдрәсәсендә белем ала. 1816-17 дә Бохара әмире сараенда дипломат хезмәтендә. 1816 нын июнендә дипломатик миссия әгъзасы буларак (илчелек имамы һәм илчелек җитәкчесе Мөхәммәд—Йосыф-бәк кинәшчесе сыйфатында) Төркиягә бара, шәхси рәвештә Мисыр һәм Гарәбстанда булып кайта. Мисырда танылган җәмәгать эшлеклесе Мөхәммәд Гали паша б-н очраша. Хаҗ кыла, Гарәбстанның изге урыннарын барып күрә. 1817 дә Истанбулга кайта. Шул ук елда, хезмәтеннән китеп, Каргалы бистәсенә кайта һәм Оренбург Дини Мөселман кануннары Җыенына каршы булган абызлар хәрәкәтенә кушыла. Абызлар карашын уртаклашып, К. рухани дәрәҗәсе алыр өчен имтиханнар бирүдән баш тарта, игенчелек б-н шөгыльләнә башлый. 1833 тә хаҗ кылу сылтавы б-н иленнән китә.

К.—суфичылык әдәбияты вәкиле. Ул мөнәҗәт, сәяхәтнамә, мәхәббәт, фәлсәфә лирикасы жанрларында яза. Аскет дәрвишләр, суфи—шәехләрләр тормышына багышланган күп санлы шигырьләр авторы. Шигъри иҗат б-н мәдрәсәдә укыган чордан бирле шөгыльләнә. Безнең көннәргә килеп җиткән К.ның мирасы 2200 юл чамасы тәшкил итә. Язылган вакыты күрсәтелгән беренче «Шәфәгать, йа рәсулуллаһ!» исемле шигыре 1816 да хаҗ кылганда туа, «Тәшәккер» исемле шигыре 1817 дә Бохара әмире Мөхәммәд-Йосыф-бәк үтенече б-н языла.

Чама б-н, 19 йөзнең 1 нче чирегендә «Тәрҗемәи хаҗи Әбелмәних әл-Бистәви әс-Сәгыйди» (1845 тә басыла) исемле шигъри җыентыгы языла. Аңа 10 оригиналь характердагы, сюжетлары борынгы Көнчыгыш авторлары ат-Табаринын (839—923) «Тәфсир әл-кәбир»еннән, әл-Газалинын (1058/59—1111) «Мишкәт әл-әнвәр»еннән һ.б. алынган, хикәясе керә. Аннан тыш китапка К.нын Якын Көнчыгышка кылган сәяхәте турында автобиографик хикәя, дини-этик эчтәлекле өч ода һәм элегияләр кергән. К. танылган суфичилык вәкилләре—Басрыдан мистик Хәсән Басрыйны (642-723), суфи-шагыйрь Рәбига Годувины (713-801), суфи кадыйрия борадәрлек оештыручысы Абдул-Кадыйр Гиләниләргә (1166 да вафат) дан җырлый һәм аларны идеаллаштыра. К. суфи тарикаты нигезендә абызларны берләштерү турында хыяллана, югары әхлаклы суфилар тормышыннан мисаллар китерә, хикәяләрен үзенен фәлсәфә-этик характердагы фикерләре б-н куәтли, җәмгыятьнең әхлаксызлыгын тәнкыйтьли.

Тормыштан күнел кайту мотивлары, дөньядан ваз кичү идеяләре К. шигъриятендә шактый урын алып тора. Байлар һәм түрәләрнең комсызлыгы аркасында гаделлек мөмкин булмаган әйбер булып кала. Анынча оптимистик мотивлар бары тик Аллаһ, анын кодрәте һәм изгелеге б-н генә бәйле булырга мөмкин.

К.ның иҗаты тулаем алганда социаль төсмергә ия түгел, ана көндәлек көнкүреш характеры хас. Ләкин аерым шигырьләрендә (мәс., «Кибәй (Гобәйдулла) байга») шагыйрь үз ватанында анын тәҗрибәсе һәм таланты кирәк булмаган өчен күнел төшенкелегенә бирелә. Охшаш мотивлар «Хаҗи Мөхәммәд байга» шигырендә дә очрый: шагыйрь Мөхәммәд байны наданлыкта, тәкәбберлектә, җәмгыять ихтыяҗларыннан читләшүдә гаепли; мыскыллы көлү б-н ул, акыл хезмәте кешеләрен санга сукмаган, иске фикерле кеше образын тасвирлый. Юллама формасында язылган шигырьләре, шагыйрьгә ачыктан-ачык фикерләрен белдерергә, заманының чынбарлыгын чагылдырырга мөмкинлек бирә. К. хәйләгә бирешмәскә, байлыкка кызыкмаска өнди. Борынгы суфи шагыйрьләр шикелле ул саранлык, комсызлык, көнчелекне тәнкыйтьли (мәс., «Җиһанның җаһы...» шигырендә).

К.—Мөхәммәт пәйгамбәргә багышланган күп санлы мөнәҗәтләр, мәдхияләр (шулар арасында «Мөнәҗәте әл-Хәҗи Әбелмәних», 1898) авторы. Анын зирәк

*Дәвамы. 2005 елның 4нче саныннан басылып килә.*

күзәтүчәнлеге бигрәк табигать һәм мәхәббәткә багышланган шигырьләрендә үзенчәлекле сиздерә. К.—новатор-шагыйрь: татар әдәбиятында беренче тапкыр лирик әсәрнең темасы булып аерым бер кешенең эчке кичерешләре тора. Ул дөнья күпкырлылыгының, кеше хисләренең һәм аларның үзара мөнәсәбәтләренең тирәнлегенә төшенә. Аның поэзиясе музыкаль аһәңгә һәм эмоциягә бай. Әсәрләренең телендә гарәп-фарсы сүзләре өстенлек итә, ана образлылык, сурәтлелек һәм осталык хас.

К.ның кайбер шигырьләре М.Ивановның «Татар хрестоматиясе»ндә («Татарская хрестоматия», 1842) урын алган, тагын берсе С.Күкләшевнең «Диване хикәяте татар» (1859) җыентыгына кергән, 10 шигыре «Өммикамал китабы»нда (1884) кушымта рәвешендә бирелгән. Шигырьләренең бер өлеше Р.Фәхретдиннең «Сәгыйд» (1897) китабында урын алган, кабат аның «Асар» (1903) китабының 4 нче кисәгендә басылган. К.ның аерым әсәрләре «XIX йөз татар әдәбияты ядкярләре» (1982) хезмәтенә кертелгән. Аеруча тулы шигырьләр җыентыгы М.В.Гайнетдинев тарафыннан 2002 дә бастырылды. К. кулъязма мирасының күп өлеше Казан, С.-Петербург, Ташкент архивларында саклана.

Әсәр.: Мөнәҗәтләр. Хикәятләр. К., 2002.

Әд.: Гайнуллин М.Х. Татарская литература XIX в. К., 1975; Садретдинов Ш., Гайнетдинов М. Ә.Каргалый: студентлар өчен ярдәмлек. К., 1978; Татар әдәбияты тарихы. К., 1985. 2 том; Татар поэзиясе антологиясе. К., 1992. 1 кит.

*М.В.Гайнетдинев.*

**КАРИ** (Кариев) Әнәс Кари улы (1920, Бөгелмә кантоны Уразай ав.—4.4.1954, Теләче р-ны Саурыш ав.), шагыйрь. 1937 елдан Үргәнеч шәһәрендә (Үзбәкстан) яши. Шунда Укытучылар ин-тын тәмамлый (1939) һәм 1941 елга кадәр ин-тка әзерләү курсларында укыта. 1941-42 дә Азнакай р-ны мәктәпләрендә укыта. Бөек Ватан сугышында катнаша: Орёл шәһ. янындагы сугышларның берсендә каты яралана. 1945 елдан соң башта Арча педагогия уч-щесында, Теләче р-ны Янсуар урта мәктәбендә укытучы булып эшли. «Балаларга бүләк» (1947), «Гөлбакча» (1948; 2 нче басмасы 1996), «Күңелле ел» (1951), «Дуслык» (1953), «Сыналган мәхәббәт» (1956), «Тамчы тамганда» (1957; 2 нче басмасы 1990) исемле шигырь җыентыклары авторы. Кайбер әсәрләре «Татар балалар поэзиясе антологиясе»нә (1980) кертелгән.

Әд.: Нур Г. Үсү юлында // Совет әдәбияты. 1950. №2.

**КАРЛОВА** Тамара Сергеевна (25.3.1932, Казан—20.9.1989, шунда ук), әдәбият галиме, филол. фән. д-ры (1981), проф. (1984). 1954тә Казан ун-тын тәмамлый, 1958дән шунда эшли. Хезмәтләре Л.Н.Толстой, Ф.М.Достоевский, К.И.Чуковский иҗатларына, журналистика мәсьәләләренә бәйле.

Хезм.: Достоевский и русский суд. К., 1975; Лев Толстой в движении истории. К., 1978; Слышу зовущий звук. К., 1992.

**КАРТАШОВА** Ирина Вячеславовна (19.4.1931, Казан), әдәбият галиме, филол. фән. д-ры (1984), проф. (1986). 1953 тә Казан ун-тын тәмамлый. 1957 дән Казан ун-тында, 1972 дән Тверь ун-тында (1987-91 кафедра мөдире). Хезмәтләре Н.В.Гоголь иҗатына, романтизм теориясенә, рус һәм чит ил романтизм юнәлешендәге әдәбиятларның үзара бәйланышына карый.

Хезм.: Гоголь и романтизм. Калинин, 1975; Введение в теорию романтизма. Тверь, 1991 (автордаш).

**КАСЫЙДӘ** (гарәп.-максат, ният, теләк), Якын һәм Урта Көнчыгыш, Урта һәм Көньяк-көнчыгыш Азия, Көнчыгыш Европа халыклары әдәбиятында таралган лирик поэзия жанры. Эчтәлеге буенча К.—кемгә дә булса (гадәттә түрәләргә, зур дәрәҗәдәге персоналарга, меценатларга) яки нәрсәгә дә булса (әһәмиятле вакыйгага, истәлекле датага) мәдхия җырлау, артык мактау (күкләргә күтәрү). К. ш.у. элегик, дини-фәлсәфи, сатирик характерда да була. Классик К. тотрыклы структурага ия һәм 3 өлешкә бүленә: лирик кereштә (насыйб) мохит, пейзаж тасвирлана, төп эчтәлекне үзләштерү өчен фон, рух тудырыла; төп өлеш; макталган затка авторның теләген эченә алган азаккы өлеше (мәдхия). Күләме ягыннан 12 дән алып 200 бәйткә кадәр булырга мөмкин. К.гә гаруз б-н язылу, рәдиф (шигъри юл ахырында бер яки берничә сүздән торган кабатлау) һәм тәхәллүс (авторның поэтик псевдонимы) булуы хас. К.нең классик үрнәкләре Мәгарри, Рудаки, Нәвои иҗатларында теркәлгән. Төрки-татар поэзиясендә К. жанрын Харәзми, Өмми Камал, Ә.Каргалый, Г.Чокрый, Г.Кандалый, Г.Тукай һ.б. иҗади үстерәләр. Аерым очракларда К. атамасы ода, зур күләмле шигъри әсәргә карата кулланыла.

Әд.: Әдәбият белеме сүзлеге. К., 1990; Миңнегулов Х.Ю. Гасырлар өнен тыңлап. К., 2003.

*Х.Й.Миңнегулов.*

**КАСЫЙМОВ** Наил Васыйл улы (20.8.1955, Арча р-ны Ашытбаш ав.),

шагыйрь. Казан төзүче-инженерлар ин-тын тәмамлый (1977). 1992 елга кадәр Казанның төзелеш оешмаларында өлкән инженер булып эшли. 1992-97 дә «Татарстан» ДТРКсендә мөхәррир, сонрак өлкән мөхәррир булып эшли. 1997-99 да Казан шәһәр советы мәдәният идарәсе башлыгы урынбасары, 1999 дан юл төзелеше идарәсе башлыгы урынбасары. «Су буенда учак яна» (1992), «Күнелем каршында тезләнде» (1996), «Күнелем кояшы» (2004) шигырь җыентыклары; «Ак яулыклы әнием» (Л.Батыр-Болгари көе), «Туй күлмәге» (Р.Әхиярова көе), «Су буенда учак яна» (З.Хәйретдинов көе) кебек популяр җыр текстлары авторы.

**КАСЫЙМОВ** (чын фам. Исрафилов) Хатип Касыйм улы (15.11.1932, Шереметьево (хәзерге Түбән Кама) р-ны, Болгар ав.), шагыйрь. Чистай авыл хуҗалыгын механикалаштыру техникумын тәмамлагач (1969) Түбән Кама р-ны «Память Ильича» совхозында механик, куркынычсызлык техникасы инженеры, партия оешмасы секретаре булып эшли. 1983-90 елларда «Нижнекамскнефтехим» берләшмәсенең №6 йорт идарәсе инженеры. 1990-95 тә «Туган як» (Түбән Кама шәһ.) газетасында бүлек мөдире. Шигырьләре «Беренче карлыгачлар» (1988) күмәк җыентыгында урын алган. «Ак чишмә» (1991), «Кичке моң» (2001), «Мин җирдә калам» (2004) исемле шигырь җыентыклары авторы.

**КАСЫЙМОВ** Эдуард Салихҗан улы (8.11.1930, Киров өлкәсе Слободской р-ны Нократ ав.—21.3.1986, Яр Чаллы шәһ.), язучы, филол. фән. канд. (1966). Казан ун-тын тәмамлагач та (1953) Aзнакай эшчеләр поселогында, соныннан—Киров өлкәсе Вятка Аланы р-ны Түбән Шөн авылында укытучы булып эшли. 1957 елдан СССР Фәннәр академиясенең Казан ф-лы Тел, әдәбият һәм тарих ин-тында. 1965-67 дә Алабуга педагогия ин-тында татар фольклорын һәм әдәбиятын укыта. 1980-81 дә ТАССР Язучылар берлегенең Яр Чаллы бүлеге җаваплы секретаре. Беренче хикәя һәм очерклары 1950 еллар башында күренә башлый. Аның төп әсәре—«Гомер ике килми» (1964) дигән, илдә барган катлаулы тарихи вакыйгаларны бер гаилә үрнәгендә алып тасвирланган автобиографик романы. Бондюг химия з-ды эшчеләре коллективының хезмәт көнкүрешеннән алынып язылган «Томан аша» (1968) һәм «Һаваларда тургай» (1971) романнары дилогия тәшкил итәләр. «Чулман—река внуков» (М., 1976) гомумисеме астында басылып чыккан бу роман 1978 елда, эшчеләр темасына язылган проза әсәрләренә оештырылган Бөтенроссия конкурсында СССРның ВЦСПС һәм Язучылар берлеге премиясенә лаек булды. «Шинмәсен гөлләрен» (1986), «На Каме-реке» (М., 1979) исемле очерк җыентыкларында КамАЗ төзелеше белән бәйле авылда социаль-икътисади үзгәрешләр турында сүз бара. «Почёт Билгесе» ордены белән бүләкләнгән.

Әд.: Сафин Ф. Еллар яктысы // Казан утлары. 1980. №11.

**КАҺАРМАН КИТАБЫ**, төрки-татар әдәбияты ядкаре, дастан. Кайбер мәгълүматларга караганда "Каһарман-намә" (11-12 йөз) фарсы эпосына карый. Төп герой—кыю, кодрәтле баһадир Каһарман. Аның туачагын һәм үзләрен үтерәчәген явыз диюләр 70 ел алдан беләләр. Шуна күрә алар яна туган Каһарманны урлап, үз илләренә алып китәләр. 7 елдан соң Каһарман очраклы рәвештә туганнарын очрата, алардан дөресен белеп, диюләрдән үч алырга була. Күп төрле сынаулар аша узып, ул аларны җинә, исламга кертә, илләрендә мәчет-мәдрәсәләр төзетә; аннан соң үз иленә кайтып китә. Татарлар арасында ядкарьнең сөйләм һәм язма версияләре 14 йөздән тарала башлый. Беренче тапкыр ул Казанда 1879 елда басыла, соңыннан да басылып килә. 1900 елда И.Лаптев тарафыннан, нигездә казак версиясенә таянып, әсәр рус теленә тәрҗемә ителә. Дастанның тулы тексты бүгенге татар язуында 1998 елда М.И.Әхмәтҗанов тарафыннан бастырыла. Дастанның күчерелмәләре Казанда һәм Ереванда саклана; иң борынгысы 18 йөзгә карый (ТР ның Милли музеенда саклана).

Чыганаклар: Лаптев И. Материалы по казак-киргизскому языку // Тр. По востоковедению, издаваемые Лазаревским институтом восточных языков. М., 1900. Вып. 2; Кыйссаи Каһарман. К., 1879; Каһарман Катил дастаны. К., 1998.

Әд.: Катанов Н. Кыссэ-и Кагырман (повествование о Кагырмане) // Деятель. 1901. № 1.

*М.И.Әхмәтҗанов.*

*Дәвамы киләсе саннарда.*

Альфред
Халиков

# БОЛГАР-ТАТАР ЧЫГЫШЛЫ 500 РУС ФАМИЛИЯСЕ

**ПЕШКОВЛАР.** Шәҗәрәләрендә төрки мохит белән бәйләнештә торган (к. Сабуровлар) Семен Пешек-Сабуровтан *(БК II, 413).* Пешек-Сабуровнын улы Муса Семеновнын XV—XVI йөзләрдә Костромада эре биләмәләре булган, ул воевода һәм Вологда кенәзе *(Веселовский 1969, 172).*

**ПОЖАРСКИЙ** Дм. Кенәз Дмитрий Михайлович Пожарскийнын ( 1548-1642) әнисе Бекләмишева (к.) була, ягъни өлешчә төрки канлы *(РБС XVII, 220-221).*

**РАДИЩЕВЛАР.** Кече Ярославецта 1604 һәм 1627 елларда дворян дәрәҗәсендәге Кунай Радищев исемле чукындырылган татар телгә алына *(Веселовский 1974, 265).* Исеме төрки көн «көн,кояш,шатлык» сүзеннән *(Баскаков 1979, 258).*

**РОМАНОВЛАР.** Үзләренең чыгышлары Ширәмәт кушаматлы Андрей Кобыладан булган Шереметевлар (к.), Колычевлар кебек төрки нәселләр белән туганлыкта *(Баскаков 1979, 82).*

**РОСТОПЧИННАР.** «Граф Федор Васильевич Ростопчин борынгы затлы нәселдән килә. Разряд архивы белешмәсендә күрсәтелгәнчә, аның башлангычы Бөек кенәз Василий Ивановичка чыккан Растопча кушаматлы Кырым татары Борис Федоровичтан. Аның варислары—Ростопчиннарның күбесе Россия тәхетенә хезмәт иткән»,—дип язылган *(ОГДРда IV, 12).* Фамилиянең этимологиясен Н.А.Баскаковтан *(1979, 13)* карагыз.

**САБУРОВЛАР.** ОГДР (1,43) буенча, «Сабуровларнын фамилиясе 1330 елда Урдадан Бөек кенәз Иоанн Даниловичка чыккан кенәз Четадан. Ул чукынганда Захарий исемен алган. Аның туруны Федор Иванов улы Сабур, шуннан—Россия тәхетенә хезмәт иткән Сабуровлар». Фамилия сабур «сабыр» гарәп-төрки сүзеннән ясалган *(Баскаков 1979, 57).* Урдадан чыкканлыкларын БК (II, 373) һәм А.А.Зимин *(1980, 273)* тарафыннан раслана. Ләкин С. Б. Веселовский *(1969, 166-194)* бу фикер белән килешми, ул бу нәселнең XV йөзнең беренче яртысында яшәгән Федор Иванович Сабурдан килүен әйтә *(Веселовский 1969, 171).* Ләкин икенче бер хезмәтендә ул *(к. Веселовский 1974, 276)* Федор Иванович Сабуровны—Сабуровларның нәсел башын—XIV йөзнең икенче яртысында яшәгән дип күрсәтә дә, аны 1304 елда Костромада үтерелгән бояр Александр Захарьевич Зерно нәселеннән булган кеше дип атый. Ихтимал, Захария-Четаның Алтын Урдадан китүен иртәрәк булган дип уйларга кирәктер. Сабуровлар Вельяминовлар, Годуновлар, Пильемовлар

*Дәвамы. Башы үткән елгы 5, 6, 8, 9, 11, 12 саннарда.*

(к.) белән тугандаш. Сонгарак Сабуровлар—Иван IV нең танылган һәм актив воеводалары, сенаторлар, дәүләт һәм җәмәгать эшлеклеләре.

**СЕЛИВАНОВЛАР.** «Бәрхет китабы»нда (11,375) Селивановлар Алтын Урдадан чыккан Селиваннан килә, диелә. А.А.Зимин (1980, 269) бу фикерне берникадәр тулыландыра—1401 елда Урдадан Федор Ольгович Рязанскийга чыккан Качибей улы (чукынгач Василий) Селиваннан. XV йөз ахырында—XVII йөздә Селивановлар Рязань төбәгендә җирләре булган дворяннар буларак билгеле *(Веселовский 1974, 284).*

**СТРОГАНОВЛАР.** Дмитрий Иванович Донской идарә иткән елларда христианлыкны кабул итеп, Спиридон исемен алган татардан *(ОГДР I, 33).* 1568 елда Казанда Оникий Строгонов хуҗалыгы теркәлгән *(ПКК, 24).* Соныннан—промышленниклар, дипломатлар, дәүләт эшлеклеләре.

**СУВОРОВЛАР.** Суворовлар нәселен олылау максатында, аларның затлы нәселләре—1622 елда Россиягә килгән швед Суvордан булулары турында легенда уйлап чыгарыла *(ОГДР II, 14).* Ләкин чынлыкта Суворовлар, йомышлылар буларак, XV йөздә үк телгә алыналар; 1482 елда Горяин Суворов йомышлы кеше, XVI-XVII йөзләрдә Бежеск һәм Кашинда утарлары булган дворяннар *(Веселовский 1974, 303-304).* ИРРДта (I, 247) Суворовларның Ишук Бухарин (к.), Кобяковлар белән туганлыгы әйтелә. А.А.Зимин (1980, 270) Суворовларны Рязань дворяннары һәм Измайловлар, Сунбуловлар, Коробьиннар белән тугандаш дип уйлый. Алдарак әйтелгәнчә, бу фамилияләрнең нигезендә төрки атамалар ята. Шуннан чыгып, Суворов фамилиясен дә шундый ук нигезле булырга тиеш дип әйтә алабыз, бу сувор «җайдак» атамасының төрки икәнлеге белән дә раслана *(Баскаков 1979, 84-85).*

**СЫТИННАР.** Руська күченгән Сыт исемле татардан *(БК II, 383).* 1489 елда Ростов владыкасының дьягы Федор Сыт, ә 1510 елда Дмитровтагы җирләре белән кенәз Юрий Ивановичның дьягы Федор Евстафьевич Сытин телгә алынган *(Веселовский 1974, 310).*

**ТАТИЩЕВЛАР.** Рәсми рәвештә нәселнең башы Бөек кенәз Иван III гә хезмәт иткән Соломер кенәз (Солых әмир) Иван Дмитриевич Шахның туганының улы Василий Татищевтан (каракларны тота белгәне өчен бирелгән кушамат—«татей») башлана *(ИРРД I, 54; Баскаков 1979, 87-89). С. Б. Веселовский (1960, 361)* Татищевларның төркиләрдән булуына шик белдерсә дә, башка тикшеренүчеләр моның белән ризалашмыйлар. Мәсәлән, А. А. Зимин *(1980, 267)* князь Солых Әмир Шайның чынлап та булганлыгын таный, ләкин бу кенәз Руська XIII йөзнең уртасында чыккан дип уйлый. Үзенең карашын дәлилләү өчен А. А. Зимин 1257 елда Иван Шаинга бирелгән грамотаны китерә, шулай ук кенәзнең Апраксиннар, Измайловлар, Хитровлар (к.) нәселләре белән бәйләнешләрен күрсәтә. XV йөз урталары тирәсендә Татище—Татищевлар исеме Русьта да киң кулланыла башлый, шул исәптән төрки исемнәр белән дә, мәсәлән, Асанчук, Кекса, Мунт, Пурыш *(Веселовский 1974, 313).* Татищевларның беренче буыны ,ихтимал, болгар-буртаслар арасыннан чыккандыр.

**ТЕНИШЕВЛАР.** ОГДР (XIII, 20) буенча, Тенишевлар нәселенең бер өлеше рус хезмәтенә 1528 елда татар-мишәрләрдән, Тениш Кугушевка (к.) Мещерада җир һәм крестьяннар бирелгәч чыккан. Шушы нәселдән—танылган кенәз Тенишевлар. Н.А.Баскаков *(1979, 247-248)* фикеренчә, фамилия төрки *тыныч—тыныш* сүзеннән ясалган.

*Дәвамы киләсе саннарда.*

Фирдәвес
Гарипова

# АВЫЛЛАРЫБЫЗ ТАРИХЫ

## Иске Кармәт

Исемнәрендә «Кармәт» сүзе булган авыллар Аксубай районында урнашкан: Иске Татар Кармәте, Яңа Кармәт авыллары—жирле үзидарә советы үзәкләре. Аксубай белән аралары 8 һәм 6 чакрым.

Археологлар тарафыннан Яңа Кармәт авылы янында имәнкискә кабиләкавемнәре чорына мөнәсәбәтле авыл хәрабәләре кабер ташлары булган зират билгеләнгән. Авыл урынында элек кара урман үскән. Аю аланы, Аю аланы елгасы, Аю аланы чишмәсе кебек топонимнар бу урманнарда ерткыч жанварлар да яшәгәнлеген дәлилли. Авылны нигезләүчеләр урман кисеп йорт урыннары, чәчүлек жирләре ясаганнар. Аксакаллар сөйләвенә караганда, Иске Татар Кармәте авылына иң беренче Кариәхмәт исемле мөселман килеп утырган. Башта авыл бернича йорттан гына тора. Тора-бара ул зурая. Авылдагы нәселләр арасында Сембер якларыннан килүчеләр дә бар.

Казан ханлыгы яулап алынганнан соң, авылга чуашлар һәм руслар килеп утыра. Христианлаштыру сәясәте башлангач, авыл халкының бер өлеше керәшен татарларына әверелә. Чукындыру көч, ирексезләү юлы белән алып барыла. Чукындырылган халык поп килгәндә тәреләрен чыгарып куя, ул киткәч яшерә. Кайберәүләр чукындыру максаты белән килгән попны кыйнап та ташлаган. Авыл халкының мөселман өлеше—Олы ара, алар яшәгән урам Татар очы дип йөртелә. Керәшен татарлары—Кече ара, алар торган урамны Керәшен очы диләр. Зиратлары аерым була. Революциягә кадәр Олы аралар керәшен татарларына кыз бирмиләр, аралашмыйлар. Соңыннан керәшен татарлары исламга кире чыга. Олы һәм Кече аралар революциядән соң гына гына дуслашалар.

1900 елның 27 ноябрендә Иске Кармәт авылында урта хәлле крестьян гаиләсендә татар поэзиясенең классик шагыйре Хәсән Фәхри улы Туфан сигезенче бала булып дөньяга килә. Ул 1981 елның 10 июнендә Казанда вафат була. Авылда хәзер аңа багышлап музей ачканнар.

Авыл тирәсендәге куаклар арасына бер ачыклыкка чуашлар килеп утырган. Мәетләрен алар (һәм руслар да) Рус Кармәтенә илтеп күмә торган булганнар. Елга буендагы каенлык чуашларның кирәмәтләре булган. Алар шунда чыгып, нәзер әйтеп сарык һәм бәрән суя торган булганнар. Авылда Чуаш ягы дип атала торган топоним (урам исеме) бар. Революциядән соң татар, рус, чуаш халыкларыннан оешкан өч колхоз барлыкка килә.

Рус Кармәтен халык Иске авыл дип йөртә. Анда элек татарлар яшәгән. Бу авыл халкы арасында кайчандыр хәзерге Буа районыннан күчеп килгән Кушай бабай да булган. Казан ханлыгы алынганнан соң, авылга ике рус бояры килеп утыргач, андагы татарлар Яңа Кармәткә күченәләр, Кушай нәселе хәзер Яңа Кармәттә яши, авылның яртысын шушы нәсел тәшкил итә. Бу авылга Иске Кармәттән күченүчеләр дә булган. Яңа Кармәт авылы кешеләре аксыл йөзле, аксыл кашлы һәм керфекле, күзләре зәңгәрсу; К, Р, Х авазларын нечкә итеп әйтәләр.

*Дәвамы киләсе саннарда.*

*Дәвамы. Башы 2006 елның 6нчы санында.*

# УЛ ГЕЛ БЕРЕНЧЕ РӘТТӘ БУЛДЫ...

Без Марат абый белән Татарстан Югары Советында беренче рәттә утырган идек...

Бүген ул беренче рәттән өч кеше дөньяда юк инде—башта, йөрәге яныд, Марат абый ауды, аннан милләтче депутатлар Мөдәррис Шәйхиев һәм Дамир Сиражиевның йөрәге туктап калды.

Марат абый Мөлеков белән без милләт мәйданында 10 ел янәшә торып көрәшкәнбез икән. Аның белән беренче очрашуым 1988 елның июнь аенда Татар иҗтимагый үзәген оештыру җыелышында булган иде. Һәм шул көннән башлап 1997 елның май аена кадәр, Марат абыйның йөрәге туктаганчы, без бер рәткә, милләт өчен көрәшнең иң алгы рәтенә басып хәрәкәт иттек. Дөрес, безнең араларның бераз ерагаеп торган вакытлары да булды, без кайбер очракларда бер-беребезнең эшләгән адымнарын кабул да итеп бетерми идек. Әмма, ни генә булса да, зур максатта—дәүләт бәйсезлеге өчен көрәш мәсьәләсендә, милләтебезнең телен, тарихын, мәгърифәтен һәм мәдәниятен саклау юлында без бер фикердә идек.



Минә Марат абый белән бергә бик күп җыелышларда, корылтайларда, митингларда, халыкара форумнарда катнашырга туры килде. Татарлар яшәгән төбәкләргә, хәтта чит илләргә дә без еш кына бергә бара идек. Татарстан Югары Советында биш ел буе бергә, бер комиссиядә эшләүне инде әйтеп тә торасы юк. Шушы елларда алып барган күзәтүләремне Марат абыйның холык-фигылен ачарлык кайбер истәлекле вакыйгалар аша укучыларым белән дә уртаклашырга булдым.

Марат абыйның төп сыйфатларыннан берсе—ул бик кешелекле, киң күнелле һәм зыялы кеше иде. Ул үз янындагыларны беркайчан да авыр хәлдә калдырмый иде, киресенчә, вакыты белән үзен-үзе кыен хәлгә куеп булса да, башкаларга ярдәмгә ашыга иде. Хәтеремдә, 1989 елны беренче тапкыр «Хәтер көне» уздырырга уйладык. Әмма Татар иҗтимагый үзәге җитәкчелеген Казан шәһәр Советына чакырып, «Хәтер көне»н уздыруны катгый рәвештә тыйганнар. Онытмагыз, бу бит әле коммунистлар заманы, бөтен нәрсә тыелган заман, ә монда ниндидер милләтчеләр гомер булмаган «Хәтер көне» уздырырга йөриләр! Бу вакытта мин Бакуда идем һәм үзем белән бергә «Хәтер көне»н уздырырга берничә әзәрбайҗан мулласын да алып кайткан идем. Инде нишләргә? Чакырулар таратылган, хәбәр киткән һәм халык иртәнге якта ук Кремль каршына, Муса Җәлил һәйкәле янына җыела башлады. Ә Иҗтимагый үзәк җитәкчеләре юк.

Килгән халыкны сафларга тезеп куйдык та, тәкъбир әйтеп, татар тарихында беренче тапкыр Казан Кремленә үтеп кердек. Милиция бездән дә күбрәк, безгә борылырга да ирек бирмиләр. Сөембикә манарасы янында әзәрбайҗан муллалары «Ясин» чыктылар, мин «Казан бәете»н укыдым. Гөлзадә Сафиуллина мөнәҗәт

әйтте. Шунда ниндидер провокация килеп чыгып, милиционерлар безне кыйный башламасыннармы?! Инде нишләргә, ике як та кызды, кинәшергә милли хәрәкәт житәкчеләре дә юк... Шул вакытта, жир астыннан үсеп чыккандай, ярсыган төркем уртасында Марат абый пәйда булды. Ул тегеләрнең үзләрен провокациядә гаепләп, безне яклый башлады. Аларга татар халкының фажигале тарихын аңлатты, милләтнең әби-бабаларны дога белән, жылы сүз әйтеп искә алырга хакы барлыгын әйтте, «Моның өчен безгә беркемнең дә рөхсәте кирәк түгел!»—диде. Милиционерлар чигенергә мәжбүр булдылар, без исә «Хәтер көне»н дәвам иттек...

Зур жыелышмы, кечкенәме, зур эшме, кечкенә генә бер акцияме—әгәр милләт язмышына кагыла икән, Марат абый аларның берсен дә калдырмый иде. Кайвакытта хәтта саклык чараларын да онытып жибәрә иде. 1991 елның маенда, без мәйданда сәяси ачлык игълан итеп ятканда, бер төркем милләтчеләр Әлмәткә, «Дуслык» нефть үткәргечен символик рәвештә ябарга митингка киттеләр. Алар арасында Марат абый да бар иде. Кайтканда, әлеге урыс шоферлары провокация оештырып, милләтчеләрне бик каты кыйныйлар. Вафирә ханымның кулын сындыралар, Айдар Хәлимнең маңгаен яралар, Рабит Батулланы кыйнап ташлыйлар... Күкрәгендә депутат значогы булуга да карамастан, чал чәчле Марат абыйны да кыйныйлар. Әмма Марат абый барыбер алар белән кешечә сөйләшүләр алып бара, урысларны тынычландыру өчен бөтен көчен куя, нәтижәдә, бу бәрелеш зур канлы вакыйгага әйләнми.

Гомумән, нинди генә көтелмәгән хәлдә калсак та, Марат абыйның иң беренче эше—ике якны да тынычландыру, көйләү, мәсьәләне тыныч юл белән хәл итәргә тырышу була торган иде. Әмма бу Марат абый үз позициясеннән чигенгән, үз фикереннән кире кайткан дигән сүз түгел иде, ул, Себер татарларына хас бер үжәтлек, сабырлык белән, барыбер әкрен генә үзенекен эшли, үзенчә эшли иде...

Беренче тапкыр чит илгә дә мин Марат абый белән бергә чыктым. 1990 елның мае иде, бу СССР заманы һәм чит илләргә чыгу да шактый зур каршылыкларга очрый иде. Безнең белән дә шулайрак булды. Безне әле ел башында ук төрек милләтчеләре ГФРга, бик зур төрек-ислам корылтаена чакырганнар иде. Марат абый белән икебез дә депутатлар булуга карамастан, ярты ел буе документларыбызны тоткарладылар, нәтижәдә, мартта буласы корылтайны төрекләр безнең өчен май аена күчерделәр. Бары тик Марат абыйның тырышлыгы аркасында, аның элемтәләре аша гына без Германиягә китә алдык. Безнең Германиядә үткән бу көннәребез гаять эшлекле, мәгънәле, файдалы булды. Европа илләреннән милләтчеләр, Ислам хәрәкәте лидерлары, ижади интеллигенция жыелган иде. Без бер генә көнебезне, бер генә сәгатебезне дә бушка уздырмадык. Без биредә, беренче тапкыр, легендар шәхесебез Гали Акыш белән очраштык. Мюнхен шәһәрендә «Азатлык» радиостанциясендә булып, чыгышлар ясадык, сугыштан соң биредә калган Идел-Урал татарлары белән очрашып сөйләштек, алардан күп материаллар алдык. Безгә Марат абый белән зур корылтайларда чыгыш ясарга, татар милләте, Татарстан турында беренче тапкыр халыкара трибунадан үз сүзебезне әйтергә насыйп булды. Күп илләрнең матбугат чаралары, радио, телевидение безнең эшебезне яктыртып барды. Без ул чакта ук, бөтен дөнья алдында, Татарстанның ирекккә, бәйсезлеккә лаек икәнлеген һәм шуның өчен көрәшүен әйттек.

Марат абыйның көнеле бик тиз тула иде. Германиянең Аусбург шәһәрендә без Кырым татарларының «Хәтер көне»ндә катнаштык, өйләрендә кунак булдык, үзара бик якынайдык. Марат абый алар белән аерылышканда бик елады, һәрберсен аерым-аерым кочып елады... Казанда да ул Кырым татарларын гел үз тирәсенә тартты, аларга гел ярдәм итәргә тырышты. Марат абый Мөлеков житәкләгән Татар ижтимагый үзәгендә беренче булып Кырым татарлары секциясе эшли башлады, без Кырым татарлары белән бәйле барлык вакыйгаларны митинг һәм пикетлар белән билгеләп үтә идек.

Марат абый беркайчан да «Мин кем!» дип йөрмәде. Әйткәнемчә, ана эшнең зурысы да, кечесе дә, кешенең дәрәжәлесе дә, гап-гадие дә бертигез иде. Казан дәүләт университеты доценты, ТИҮ житәкчесе, Татарстан халык депутаты булуына карамастан, аның өе еш кына кунакханәне хәтерләтә иде. Милли мәсьәлә буенча Себердән киләләрме, Кавказданмы, авыл татарлары килеп керәме—аның өе барысы

өчен дә ачык иде. Марат абыйның күп вакыты читтән килгән татарлар белән сөйләшеп, аларның йомышларын йомышлап, шул татарларга ярдәм итеп үтә иде. Ул беркайчан да кешедән арымады, туймады, алар өчен яшәде, алар белән бергә яшәде. Ул коттеджларда да тормады, гап-гади өч бүлмәле шәһәр фатирында яшәп ятты, аның кечкенә генә бер машинасы бар иде, анда да күбрәк малайлары йөри иде. Әмма Марат абыйның бик күп кешеләрне көнләштерерлек, сокландырырлык бер байлыгы бар иде, ул—хатыны Рәшидә апа. Чын татар зыялысы, күп еллар чит илләрдә укыткан, Марат абый белән бергә югары белемле ике ул үстергән, искиткеч акыллы оныклар тәрбияләгән Рәшидә апа безнең күпләребез өчен матурлык, сабырлык һәм зирәклек үрнәге булып тора. Аллаһы Тәгалә ир-атны бәхетле итәргә теләсә, ана менә шушындый хатын бирәдер, мөгаен...

Мин әле 1990 елның 30 августында, төнге сәгать унберенчедә Декларация кабул иткәч, урамдагы халыкның Марат абыйны Югары Совет бинасыннан митинг була торган урынга кадәр кулларына күтәреп алып баруларын хәтерлим. Татар улларыннан тагы кем күргәне бар бу кадәр кадер-хөрмәтне? Милләтнең болай олылавын ханнар да, байлар да күрмәде, мондый зурлауны бары тик бәйсезлек өчен көрәшкән милли азатлык хәрәкәте житәкчесе Марат абый Мөлеков кына күрде...

Әмма һәр талантлы татар баласы кебек, кадер белән бергә кадерсезлекләр дә күрде Марат абый. Ул житәкчеләр белән дә килешеп, уртак тел табып эшләргә тырышты, әмма, шуна карамастан, зур сәясәттә алар аны бер читкә этеп калдырдылар. Бу хәл 1995 елда, Марат абый икенче тапкыр Татарстан Дәүләт Советына депутатлыкка чыккач булды. Казан хәтле Казан бәйсезлек өчен көрәшкән кешене, Мөлеков кебек милләтчене депутат итеп сайлыймы соң инде?! Башкалар авыл районнарыннан тыныч кына депутат булып үткәндә, Марат абыйны Казанда карап торып дөрләтеп яндырдылар. Шуннан соң аның бик нык күнеле төште һәм шул төшүдән ул инде сәясәтче буларак башка күтәрелеп китә алмады. Өстәвенә, Марат абыйга төрле яктан басым ясап, тарткалап-йолыккалап тордылар. Без Марат абыйны житәкчелеккә артык ышануда, аларга таянуда гаепләсәк, Марат абый тирәсендәгеләр аны безгә якынайтмас өчен барысын да эшләделәр.

Соңгы елларда Милли Мәжлес һәм «Иттифак» партиясе уздырган корылтайларда катнашмады ул. Әмма үләр алдыннан Марат абый барыбер безнең янга килде. Бу хәл 1997 елның май аенда—Милли Мәжлес сессиясендә булды. Без бераз эшләгәч, Марат абый килеп кереп, арткы рәтләрнең берсенә барып утырды. Милли Мәжлес рәисе Айдар Хәлим бу турыда халыкка житкерде. Зал аягүрә басып, Марат абыйга кул чаба башлады. Без Марат абыйны президиумга чакырдык. Әмма ул түргә үтмәде, арткы рәттә утырып калды... Бәлки, ул үзе бөртекләп туплаган шушы милләтчеләр белән түрдән торып түгел, бер читтән генә бәхилләшергә уйлагандыр. Тын гына үзенең фатихасын биргәндер...

**Фәүзия БӘЙРӘМОВА**

# ГОМЕР ЗАЯГА УЗМАГАН

Кулымда «Казан утлары» журналының былтыргы беренче саны. Анда Фәрит Хатиповның «Өр-яңа эчтәлек» дип аталган мәкаләсе басылган. Автор бу мәкаләсендә Г. Ибраһимовның «Тирән тамырлар» романын бөтенләй башка яссылыкта бәян итә, әсәрдән өр-яңа эчтәлек китереп чыгара...



«Казан утлары»ның тугызынчы санында исә Ф. Хатиповның үтә дә әһәмиятле һәм кирәкле тагын бер мәкаләсе басылган. Ул «Укучы ышанырмы?» дип атала. Мәкаләдә тәнкыйть күзлегеннән чыгып кайбер яңа әсәрләргә анализ ясала. Тәнкыйть утына байтак кына язучылар, әсәрләр эләгә. Автор мисаллар китерә-китерә аерым әсәрләрнең укучыны ышандыру көче аз булуын исбатлый. Ф. Хатипов үзенең бу мәкаләсендә халкыбызның «кеше ышанмастайны чын булса да сөйләмә» дигән сүзенә таяна.

Әйе, әдәби тәнкыйтьнең төп максаты—әсәрләргә карата җәмәгатьчелек фикерен формалаштыру, әдәби хәрәкәткә һәм әсәрләргә вакытында дөрес бәя биреп бару, язучылык талантын югары максатларга юнәлтү.

Филология фәннәре докторы Фәрит ага Хатипов әнә шул изге тәгълиматка тугрылык саклап, әдәбият дөньясында ярты гасырдан артык хезмәт итеп килә. Аның әдәбиятка аяк басуы да очраклы булмый. Яшьтән үк әдәбиятка гашыйк, «Пионер каләме» журналы белән «Яшь ленинчы» газеталарының бер битен калдырмый укып барган, китапханәләрдән алган китапларын «сериялап» иптәшләренә сөйли торган малай мәктәпне тәмамлагач, кая барсын инде? 1947 елда ул Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга керә. Анда Латыйф Җәләй, Мөхәммәт Гайнуллин, Гази Кашшаф, Гали Халит кебек галим-остазларның дәресләрен тыңлый. Чын әдәбиятка нигез дә университетта укыганда салына. Үзен матбугатка якынайтучы олы остазы дип ул Гази Кашшафны саный. Шушы тәҗрибәле һәм күркәм холыклы педагог йогынтысында 1951 елда Фәрит Хатиповның беренче тәнкыйть мәкаләсе өченче курста укыганда ук «Совет әдәбияты» журналында басыла. Соңрак ул «Яшь сталинчы» газетасы редакциясендә эшләп ала.

Ә бишенче курсны тәмамлагач аңа аспирантурада калырга тәкъдим итәләр. Ризалаша, әлбәттә. Фәнни җитәкчесе—университетка яңа гына кафедра мөдире булып килгән Хатыйп Госман. Эшнең темасы—«Мирсәй Әмир иҗатында уңай герой проблемасы». Әлеге хезмәтендә яшь галим әдипнең «Агыйдел» повестен һәрьяклап анализлый. 1955 елда исә ул кандидатлык диссертациясе яклый һәм шуның нигезендә «Мирсәй Әмир» дип исемләнгән монография чыгара. Бу хезмәтендә Ф. Хатипов М. Әмир әсәрләрен анализлый, аларга бәя бирә, объектив булырга омтыла.

Ә кандидатлык диссертациясен яклагач Фәрит Миргалимович Себергә китеп бара. Хәер, бер аңа гына түгел, университет галимнәренең күпләренә Себер якларында

чирканчык алырга туры килгән икән: Гомәр Саттаров, Азат Әхмәдуллин да шунда эшләп кайта. Биредә Тубыл институтында укыту, шәхси китапларыннан бүлек өчен китапханә булдыру, Тубылда «Ленин юлы» дигән татарча газета оештырып чыгару, авылларда чыгышлар ясау, үзешчән сәнгать эшен җанландырып җибәрү... Ниләр генә эшләргә туры килми 25 яшьлек егеткә! Казандагы газета-журналлар белән дә элемтәсен өзми—яңа әдәби әсәрләргә рецензияләр бастыра.

1959-1972 елларда Ф. Хатипов Уфада яши һәм Башкорт дәүләт университеты филология факультетының доценты итеп сайлана. Ф. Хатипов ул чорда татар һәм башкорт язучыларының иҗатларын өйрәнү белән шөгыльләнә. Совет әдәбияты һәм әдәбият теориясе курсларын алып бара. Татар әдәбияты гына түгел, башкорт әдәбияты вәкилләре—С. Кудаш һәм Б.Бикбай турында күләмле мәкаләләре белән «Башкорт совет әдәбияты» ике томлыгында катнаша.

Галимнең фәнни хезмәтләренә дә, тәнкыйть мәкаләләренә дә әдәби әсәрнең асылын күрү, аның фәлсәфәләренә төшенү, әсәргә чын сәнгатьчә бәя бирү кебек сыйфатлар хас. Мисал китереп үтик. Аяз Гыйләҗевның «Өч аршын җир» повесте дөньяга килгән алтмышынчы еллар башы. Тәнкыйтьчеләр «Өч аршын җир»дән тырышып-тырышып кимчелек эзлиләр. Ф. Хатиповның «Өч аршын җир»гә бәя биреп язылган мәкаләсе исә аерым игътибарга лаек. Бу мәкаләне укыгач,тәнкыйтьченең акылына, төпле анализына, сабырлыгына, мөһим сүзне укучыга житкерә белүенә һәм, барыннан да бигрәк, кыюлыгына сокланасың. Мәкаләдә авторның чын сәнгать әсәрен тоюы ярылып ята, ул аның эстетик кыйммәтен дөрес аңлата.

Аяз Гыйләҗевның «Өч аршын җир»повесте әдәбият дөньясына әнә шулай: шау-шу куптарып, шактый каршылыклы фикерләр белән, күбрәк тискәре яктан бәяләнеп килеп керә. Аны «рухи яктан гарип кеше» сурәтләгәне, кабул ителгән иҗат методына туры килмәгәне өчен тәнкыйтьлиләр. Ф.Хатипов шушы бәяләрнең барысына да игътибар биреп, әдәбият теориясенә нигезләнеп, аларның дөрес түгеллеген кат-кат исбатлый. Язучы Фаил Шәфигуллин тәнкыйтьче турында болай дип яза: «Халыклар дуслыгы» журналы үз канаты астына алмаса, А. Гыйләҗевның укучылар яратып каршылаган «Өч аршын җир» повесте, белмим, нинди язмышка дучар ителгән булыр иде. Рәхмәт инде Фәрит Хатиповка—әлеге гүзәл әсәр турында матур гына тәнкыйть мәкаләсе белән чыкты». *(Казан утлары.—1967.—№ 4)*

Галимнең шул елларда басылган тәнкыйть мәкаләләреннән Салих Батталның «Сигезенчесе кем?» повестена карата язылганын искә алмау хата булыр иде («Казан утлары» 1975, № 8). «Документлар шәкелендә—үкенечле язмышлар» мәкаләсе Фәрит Хатиповның «Мөлкәтебезне барлаганда» исемле зур хезмәтендә урын алган. Шунысы игътибарга лаек: С. Баттал үзе дә әлеге мәкаләгә битараф калмый, галимнең туган көненә туры китереп, хәтта ки шигырь бүләк итә.

*Уннарча ел ялаларга тап булган идем гәрчә,*
*табылды бит иҗатымны яклаучылар ирләрчә.*
*Әнә, паника куптарып ялачылар сафында*
*Фәрит Хатипов туа бит һәр Яңа ел башында!*

Бу юлларны укыгач, Фәрваз Миңнуллинның тәнкыйтьчеләргә булган таләбен искә төшерәсе килә. Ф. Миңнуллин фикеренчә, тәнкыйтьче бик күп сыйфатларга ия булырга тиеш. Әмма ике сыйфат аеруча мөһим. Аларның берсе—әдәби зәвык, икенчесе—принципиальлек. Әлеге сыйфатларның икесе дә Фәрит Хатипов эшчәнлегенә хас.

Ф. Хатипов 1960-1970 нче еллар аралыгында Ә. Еникинең «Йөрәк сере» повестен, И. Газиның «Онытылмас еллар», Г. Әпсәләмовның «Сүнмәс утлар» һәм Ф. Хөснинең «Җәяүле кеше сукмагы» романнарын һ. б. өйрәнә, бу әсәрләргә бәясен, үз мөнәсәбәтен укучыларга житкерә. Галимнең һәрбер тәнкыйть мәкаләсе билгеле бер системага салынган, һәр җөмләсе төгәл, җыйнак, аз сүздән күп фикер аңлашыла, болар аның үз-үзенә нык ышанган шәхес булуын исбатлый. Галим үз мәкаләләрендә башка тәнкыйтьчеләр фикеренә дә битараф калмавын искәртә, еш кына алар белән бәхәсләшә, каршылыкка керә. Ләкин бер нәрсә ачык: каршылык

нинди генә кискен булмасын, автор нигезле мисаллар китереп, үз фикерен исбатлап бирә ала.

Язучы Г. Әпсәләмов та үзенен «Сугышчан тәнкыйть өчен» дигән мәкаләсендә Ф. Хатиповның әдәби тәнкыйть эшчәнлеге турында болай ди: «Әдәбиятның бүгенге көненә багышланган тәнкыйть мәкаләләреннән кайбер авторларның шактый кыю һәм мәсьәләне белеп язган хезмәтләре күзгә ташлана. Алар, әдәби әсәрләр турында, гомумән сөйләүдән качып, конкрет күренешләргә игътибар итәләр. Я.Халитов «Язгы җилләр» романының тел-стиль үзенчәлекләре турында, Ф.Хатипов «Онытылмас еллар» романының художество эшләнеше турында яза». *(Совет әдәбияты.—1954.—№ 6.)*

1972 елдан бирле Фәрит Хатипов Казан дәүләт педагогика университетында әдәбият укыта. Ике дистә ел чамасы ул татар әдәбияты кафедрасын җитәкли, кафедрага өметле, хәзерлекле, дәрәҗәле белгечләр җыя, студентлар укыту, тәрбияләү, аларны фән юлына тарту эшләрен җайга сала, ике елның берендә фәнни җыентыклар чыгып торуын тәэмин итә ул. Иң әһәмиятлесе: нәкъ шул чорда бигүк зур булмаган шушы кафедра үз традицияләренә таянып эшләүче нык, тату, бердәм фәнни-педагогик һәм иҗат коллективына әверелә. Фоат Галимуллин, Мәдинә Җәләлиева, Эльмира Галиева кебек җитди, талантлы педагоглар янәшәсендә хезмәтләре белән мәгълүм яна шәхесләр, чын милләтпәрвәрләр күтәрелеп, үсеп чыга.

Фәрит Хатипов 1973 елда басылган «Эпик жанрлар» дигән теоретик хезмәтендә татар әдәбиятының классикасына әйләнгән язучыларның иҗатларын өйрәнә. Әмирхан Еники, Аяз Гыйләҗев, Баязит Бикбай, Гариф Ахунов, Фатих Хөсни кебек талантлар бар. Галим язучы иҗатының фәлсәфи җегәрен, укучыга чын ләззәт бирә алырдай интеллектуаль кыйммәтләрен оста тотып ала, шуңа да аның әсәрләргә биргән бәясе асылда объектив була. Совет хакимияте тарафыннан бик яратылмаган язучылар иҗатына аның принципиаль унай карашы әнә шуннан килә. Тәнкыйтьче бу сыйфатын 90 нчы елларда да югалтмый. Заман үзгәреп, рухи кыйммәтләргә карашлар алышына башлагач, әдәбиятта ориентирларның алышына баруын тоеп алган бериш каләмдәшләре совет чоры әдәбиятын тоташ утка тоту позициясенә басканда да, галим үз мәслəгеннән читкә тайпылмый. Һәр заманда да үзгәрешсез калачак намус ориентирына таянып, чын сәнгать әсәрләренең беркайчан да югалмаячак казанышларын яклап чыга. Сабырлык, кайнар хисләр урынына акыллы дәлилләр куллану—Ф. Хатипов тәнкыйть эшчәнлегенең төп хасиятләре.

Галимнең икенче зур хезмәте рус телендә басыла. Ул «Духовный мир героя: Психологизм современной татарской прозы» (1981) дип атала. Бу монография татар әдәбиятында психологизм мәсьәләләрен тикшерүгә багышлана.

Хезмәттә егерменче гасырның икенче яртысында иҗат иткән язучылар белән берррәттән татар әдәбиятының тарихы да тикшерелә. Кол Гали, Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимов, Ш. Камал, Г. Әпсәләмов, М. Гафури, Ә. Еники, Г. Бәширов, И. Гази, Ф. Хөсни, М. Әмир, А. Шамов, К. Нәҗми, Г. Ахунов әсәрләренә психологизм ноктасыннан карап эстетик анализ ясала, психологизмның стиле, поэтикасы тикшерелә. Галим төрле чорларда иҗат иткән татар әдипләренең әсәрләрен дөнья әдәбияты классикасы югарылыгына күтәрә.

Татар әдәбияты тарихын теоретик яктан өйрәнү бүгенге әдәбият белемендә иң актуаль мәсьәләләрнең берсен тәшкил итә. Моңарчы әдәбиятның милли үзенчәлекләре, аның үсеш закончалыклары җитәрлек дәрәҗәдә исәпкә алынмаганга, милли әдәбият теориясе авыр үзләштерелә торган өлкә булып кала бирде. Әмма, безнең карашыбызча, милли әдәбият хәзинәләренә таянып төзелгән теория рус, Аурупа фикер казанышлары белән иплe үрелгәндә генә әйбәт нәтиҗә бирә ала.

Профессор Ф. Хатиповның югары уку йортлары һәм көллият студентлары өчен 2000 елда һәм кабаттан 2002 елда чыгарылган «Әдәбият теориясе» исемле китабы нәкъ әлеге максатны күздә тота да инде.

Фәрит ага 80 яшен тутырган көннәрдә дә эшен дәвам итә, укучылар һәм студентлар өчен кулланмалар, китаплар яза, педагогика университетында укыта. Студентлар аудиториясенә кереп, яшь буынга белем бирү аның үзенә дә яшәргә көч өсти, аның иҗади гомерен озынайта кебек. Студентлар үзләре дә Фәрит Хатипов дәресләрен бик яраталар, чөнки ул әдәби күренешләрнең иң катлаулыларын да

җинел генә төшендерә белә. Аңлаешлы мисалларны тормышның үзеннән китерә. Инде лекциясе бетәр алдыннан мавыгыбрак китеп, әле генә табылган җанлы, кызыклы мисалларына сабыйларча куанып, кинәт кенә көлеп тә җибәрсә, Фәрит Хатипов аудиториядәге яшьләр өчен бөтенләй үз кеше була да куя!

«Шулай да анардан бераз шүрлиләр дә. Бигрәк тә имтиханнар якынлашкан көннәрдә. Фәрит абыең белән әңгәмә корыр өчен, һай күп белергә кирәк шул! Бигрәк тә әнә шул теория дигәне җәфалый. Ярый әле Хатиповның үз китаплары ярдәмгә килә: «Эпик жанрлар», «Геройның рухи дөньясы» дигән томнар, студентларга кулланма әсбап төсендә язылган «Әдәбият теориясе» исемле дәреслеге мондый вакытта кулдан-кулга күчеп йөри»,—дип яза үзенең бер мәкаләсендә профессор Рифат Хәсән улы Сверигин. *(«Мәгърифәт», 2000 ел, 12 фев. саны)*

Фәрит Хатиповның татар телендә белем бирүгә караган кайбер фикерләре дә кызыклы. Үзенең «Шәһри Казан»да басылган (1994 ел, 28 июль саны) бер мәкаләсендә ул болай ди: «Татарстан—татар иле дигән сүз. Әгәр дә мәгариф эшен дәүләт үз кулына алган икән, ул милли мәгарифне тергезү, нормаль эшләтү бурычын да үз өстенә йөкләгән дигән сүз. Безнең кодрәтле бай телебез иң катлаулы күренешләрне дә җинел аңлаешлы итеп, иң нечкә төсмерләре белән төшендереп бирергә сәләтле. Бу яктан ул дөньядагы бер телдән дә калышмый. Татар мәктәбендә яшьләр рус телен белми чыгарлар, дип хафаланырга да нигез юк. Анда бу телгә сәгатьләр үз телебезгә караганда да күбрәк бирелә. Үз телебездә җанга якын, матур, җегәрле шивәдә белем алу исә балага дәрес материалын аңлауны, белгәнен сөйләп бирүне бик нык җиңелләштерә, чөнки ул ясалма кыенлыкларга очрамый, төшенчәләр бала зиһененә турыдан-туры юл белән, һава сулагандай, мәшәкатьсез барып җитә, хәтерендә уелып кала. Шунлыктан җир йөзендәге үз-үзен хөрмәт иткән мөстәкыйль, азат, горур халыклар укыту-тәрбия эшен ана телендә алып баралар».

Югары уку йорты укытучысы, профессор Фәрит Хатипов менә шушы үтә дә кирәкле, әһәмиятле эшнең үзәгендә кайный. Аның авторлыгында традицион программалардагы таләпләргә һәм үткән тәҗрибәләргә нигезләнгән, тарихи-эстетик принципка таянган яңа программа һәм дәреслек төзелде. Җыеп кына әйткәндә, күпсанлы монографияләр, дәреслекләр авторы булган профессор Ф. Хатиповның уку-укыту өлкәсендәге эшчәнлеге аерым бер зур тармакны тәшкил итә. Бөтен гомерен татар әдәбиятын үстерүгә багышлаган олы галимнең яшь буынга белем бирү максатыннан язылган хезмәтләре шул бөек эшнең бер өлеше булып тора.

Бу көннәрдә олы галимебез сиксән яшен тутыра. Үз халкына көн-төн хезмәт иткән кеше бүген нәрсәләр турында уйлана? Әлеге сорауны мин галимнең үзенә бирдем. Фәрит абый, гадәттәгечә, кеткелдәп көлеп куйды да, җитди сөйләшүгә күчте. «Чорыбыз бик катлаулы һәм каршылыклы. Бу бигрәк тә сан ягыннан кечерәк милләтләргә кагыла. Әмма алып барыла торган сәясәт бер дә безнең файдага түгел. Милләтебезнең киләчәге нинди булыр? Без үз-үзебезне саклап кала алырбызмы? Мине менә шул мәсьәлә борчый. Икенче күңелне тырнап тора торган мәсьәлә, әдәбиятка, аның сәнгатьлелек дәрәҗәсенә кагыла. Язучылар күп, Әмирхан Еники, Нурихан Фәттахлар... юк! Өченчесе инде—язылган әйберләрем. Мин аларны бастыра алырмынмы, бусы да бик катлаулы мәсьәлә бит».

Күрәсең, гомере буе үз милләтенең язмышы, киләчәге өчен борчылып гомер кичергән, аның рухи үсешенә армый-талмый хезмәт иткән ил агасы сиксән яшен тутырган көннәрдә дә тыныч кына утыра алмыйдыр шул.

**Әлфинур НӘҖИПОВА-ЗИННӘТУЛЛИНА,**
*филология фәннәре кандидаты.*

## Мәхмүт Газизовка 70 яшь



Шагыйрь Мәхмүт Минәхмәт улы Газизов 1940 елның 8 февралендә Татарстанның Лениногорск районы Туктар Урдаласы авылында колхозчы гаиләсендә туа. 1958 елда Иске Шөгер урта мәктәбен тәмамлагач, Казан дәүләт педагогия институтының тарих-филология факультетында югары белем ала. 1963-69 елларда Лениногорск районы мәктәпләрендә тарих, җәмгыять белеме фәннәре укыта, мәктәптә укыту бүлеге мөдире, директор булып эшли.

М. Газизовның әдәби иҗат эше урта мәктәптә укыганда башлана. Аның беренче шигыре («Такташ безнең белән») тугызынчы сыйныфта укыганда район газетасында басылып чыга. Шуннан бирле газета-журнал битләрендә, күмәк җыентыкларда, әдәби альманахларда исеме даими күренә килә. 1969 елда яшь шагыйрьнең «Миләш сиртмә» исемле шигырьләр җыентыгы дөнья күрә. Әлеге китап матбугатта унай бәя ала.

КамАЗ төзелеше башлангач, М. Газизов Чаллыга күчеп килә һәм шунда яшәп иҗат итә. Биредә ул тулай торакта тәрбияче, төзелештә геодезист, мастер һәм башка хезмәт вазифаларын башкара. Табигый, шәһәрдәге зур үзгәреш, янарыш, аның кешеләре шагыйрьнең иҗатында үзәк урынны ала. М. Газизов көндәлек матбугатта әледән-әле үзенең шигырьләрен, хикәя, очерк, репортажларын бастыра. Эш-хезмәт, төзелеш темасы аның «Тәгәри китте йомгагым» (1976), «Мәйдан» (1990) исемле җыентыкларының төп эчтәлеген тәшкил итә.

Мәхмүт Газизов балалар шигъриятендә дә актив эшләүче шагыйрьләрдән. Төп белгечлеге буенча укытучы-тәрбияче буларак, мәктәп дөньясы аның өчен якын, үз. Шуна күрә ул балалар телен аңлап, алар тормышын чагылдырган шигырьләрен аеруча яратып яза. Шагыйрьнең балаларга багышланган шигырьләре «Бер, ике, өч...» (1972), «Гаҗәеп көн» (1995), «Ике куян койрыгы» (2001) дип аталган җыентыкларында, «Аргамак» журналының «Журнал эчендә китап» сериясендә басылган «Серле ижек» (1996) һәм «Көмеш кыңгырау» газетасы китапханәсе сериясендә дөнья күргән «Кыска буйлы әкиятләр» (1998) исемле кушымта-китапларында урын ала.

Шагыйрьнең аерым әсәрләре «Новый мир», «Волга» журналларында һәм коллектив җыентыкларда русчага тәрҗемәдә дә басылып чыга.

М. Газизов—1978 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы.

Мәхмүт Газизов бүгенге көндә Яр Чаллы шәһәрендә яши. Аның шигырьләре, юмористик һәм сатирик язмалары республика матбугатында даими басылып килә.

## Хәсән Хәйринең тууына 100 ел

Әдәбият галиме һәм тәнкыйтьче Хәсән Хәйри 1910 елның 5 февралендә Россиянең элеккеге Урал губернасы Лбищенск дигән өяз үзәгендә туа. Сигез-тугыз яшьләрендә әти-әнисез калып, Жаек (Казакъстан) шәһәрендәге балалар йортында тәрбияләнә, шунда башлангыч белем ала. Җәйге каникул вакытларында Җаекта казакъча чыга торган «Кызыл ту» («Кызыл байрак») газетасында эшләп, журналистика өлкәсендә беренче хезмәт күнегүе үтә. 1931 елдан Хәсән—Новосибирск шәһәрендә чыга торган «Азад Себер» газетасының җаваплы сәркәтибе. Себердә Кузнецк металлургия комбинаты төзелә башлагач, ул әлеге гигант төзелешнең елъязмасын алып бару өчен оештырылган махсус редакция коллегиясендә эшли. Шул елларда көндәлек матбугатта дистәләрчә очеркларын, хикәя һәм шигырьләрен бастыра. Соныннан бу әсәрләр ике китапка тупланып, Казан һәм Новосибирск нәшриятларында басылып чыгалар.

1934 елда Х. Хәйри Казанга килә һәм, икееллык Укытучылар институтын тәмамлап, башта «Уку ударнигы» исемле газета идарәсендә—әдәби хезмәткәр, аннары «Совет мәктәбе» (хәзерге «Мәгариф») журналында җаваплы секретарь булып эшли. Бер үк вакытта Казан дәүләт педагогия институтының читтән торып уку бүлегендә белем алуын да дәвам иттерә. 1939 елда институтның рус теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамлаганнан соң, 1942 елга кадәр Татарстан китап нәшриятының матур әдәбият секторына җитәкчелек итә. Шушы елларда әдәбият белеме һәм әдәби тәнкыйть өлкәсендәге иҗат эшчәнлеген башлап җибәрә: татар әдәбияты буенча урта мәктәпнең тугызынчы сыйныфлары өчен дәреслек китабы, хрестоматияләр төзешә; татар классик язучыларының басма җыентыкларына сүз башлары һәм шул чор әдәби хәрәкәтенең аерым мәсьәләләренә багышланган тәнкыйть мәкаләләре яза; 1941 елда «Эзләнүләр» исеме астында тәнкыйть мәкаләләре тупланган беренче җыентыгын бастыра.

1942—1943 елларда Х.Хәйри Татарстан Тел, әдәбият һәм тарих фәнни-тикшеренү институтының әдәбият секторы мөдире, ә 1944 елның гыйнварыннан 1947 елның августына кадәр партиянең Татарстан өлкә комитетында пропаганда буенча инструктор булып эшли. 1949-1950 елларда ул—«Совет мәктәбе» журналының җаваплы мөхәррире хезмәтендә. 1950-1953 елларда Мәскәүдә Иҗтимагый фәннәр академиясе аспирантурасында укып, «Сугыштан соңгы татар әдәбиятында социалистик реализмны үстерү өчен көрәш» дигән темага кандидатлык диссертациясен яклагач, Х. Хәйрине СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Тел, әдәбият һәм тарих институтына директор итеп билгелиләр. Бу хезмәтен ул 1959 елның җәенә кадәр алып бара, аннары, пенсиягә чыкканчы, шул ук институтның әдәбият секторында мөдир һәм өлкән гыйльми хезмәткәр булып эшли. Бу чорда Х. Хәйринең әдәбият белеме һәм әдәби тәнкыйть өлкәсендә йөздән артык мәкаләсе, дистәгә якын китабы, Һ. Такташның иҗат һәм тормыш юлын яктырткан күләмле монографиясе дөнья күрә.

Әдәбият өлкәсендәге хезмәтләре өчен Х. Хәйри 1957 елда «Почет Билгесе» ордены белән бүләкләнә, 1970 елда исә аңа «Татарстанның атказанган фән эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирелә.

Х. Хәйри 1936 елдан Язучылар берлеге әгъзасы иде.

Галим 1994 елда Казанда вафат булды.

## Тәүфикъ Камалиевның тууына 70 ел

Тәүфикъ Камалиев (Камалетдинов) 1940 елның 3 февралендә Буа районы Ташкичү авылында дөньяга килә. Алтынчы сыйныфка кадәр туган авылында һәм Апас районының Кызыл Тау мәктәбендә укый, жиденче сыйныфны исә Казанда тәмамлый. Әтисе сугышта үлеп, тормышның бөтен авырлыгы үз жилкәсендә булган Тәүфикъ, югары белем алудан алдарак һөнәр үзләштерүне кулайрак күреп техник училищеда укый, 1958-61 елларда заводта эшли, бер үк вакытта кичке урта мәктәпне дә тәмамлый. Шигъри күнелле егет 1961 елда Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга керә. Аны тәмамлауга «Ялкын» журналына эшкә урнаша. Бу елларда аның «Ромашкалар эзлим» (1967), «Сабыр канатлары сынмый» (1968), «Озата бармагыз» (1969), «Сезгә генә сөйлим» (1970), «Хәләл көчем белән» (1972), «Яшьлеккә кайту» (1978) исемле шигырь жыентыклары дөнья күрә.

Т. Камалиев беренче шигырьләреннән үк үзен укучыларга әйтер сүзе булган гади хезмәт кешеләрен зурлый белгән, милләт язмышын кайгырткан шагыйрь итеп таныта, 1971 елда СССР Язучылар берлегенә кабул ителә. Тәүфикъ Камалиев—татар матбугатының төрле өлкәләрендә эшләп үзеннән сон якты эз калдырган шәхес. Телевидение һәм радиотапшырулар комитетында өлкән мөхәррир (1973-75), «Социалистик Татарстан» (хәзерге «Ватаным Татарстан») (1976-78) газетасында бүлек мөдире, күптиражлы газетада мөхәррир вазифаларын башкара. Көн саен диярлек газетага партия таләпләренә жавап бирерлек язмалар әзерләү, район-авылларга командировкаларга йөрүләр ижат кешесеннән күп көч, энергия, вакыт таләп итә.

«Ак өметләр» (1986) дигән шигырь жыентыгы аның өлгергән талантлы шагыйрь булып житешүен раслый:

*Сабый жанлы сизгер ирләр булып*
*Без карыйбыз хәзер узганга...*

«Шигырьләрем кирәгеннән артык озын булсалар да, үткән юллар бик кыска әле... Билгеле, язылачак шигырьләрнең кыскарак, мәгънәлерәк, ә үтәсе юлларның чиксез озын булуын телим»,—дип яза ул үзенең бер язмасында.

Кызганыч, аяусыз үлем аны бу якты дөньядан иртәрәк алып китә, гомер юлы кыскарак булып чыга, 1980 елның февралендә 40 яшендә вафат була.

Туфан
Миңнуллин

## МИНҺАЖ МАҖАРАЛАРЫ

Иртән йокы туеп та торырга иренеп, «Сәхнә» журналын укып ята идем, Вәлиәхмәт абый шалтыратты.

—Төн уртасында Минһаж абзыйларга кем килде икән?—ди.—Йоклый алмый ята идем, безнең яннан бер машина выжылдап үтеп китеп, Минһаж абзыйлар капкасы төбендә туктады. Белеш әле, кем икән.—ди.

Вәлиәхмәт абый сүзе безнең өчен Мәскәү законыннан да өстен. Чөнки ул укымышлы кеше. Хәтта «Элита» дигән журналны да укып бара. Торып киендем дә киттем Минһаж абзыйларга. Өйдә Җомабикә җиңги генә иде.

—Алып киттеләр абзагызны,—ди.

—Кемнәр?

—Кем белә инде...

Куркуга төштем. Төн уртасында кара машинага утыртып киткән елларны ишетеп-укып белгәнгә йөрәк сөрлегеп куйды.

—Алып киткән машина нинди төстә иде?—дип сорадым.

—Ак иде бугай.

Йөрәк җиңел сулый башлады.

—Машинаның номерын күреп кала алмадыңмы?—дим.

—Нишләп күрмәскә, барысын да күреп өлгердем. Р 444 КК дип язылган иде. Алып киткән кешесен дә хәтерләп калдым. Бик тәртипле күренә. Минем белән матур итеп исәнләште. Абзагызга да тавышын күтәрмәде. Чоланга чыгып мылдыр-мылдыр сөйләштеләр дә киттеләр. Берәр айдан кайтырмын, диде абзагыз.

Машинаның номеры буенча аның кем машинасы икәнлеген эзләргә керештек.

—Район гыйбадулласында минем белгән кешем бар, белешермен,—диде Садретдин.

Гыйбадулла дигәне ГИБДД икән, шунда идән юучы булып эшләгән хатын кайчандыр Садретдинның йөргән кызы булган икән, шул ханым озакка сузмыйча гына машинаның хуҗасын табып бирде. Р 444 КК машинасы Татарстан Язучылары берлегенеке икән. Җомабикә җиңгинең тәртипле кеше дигәне шул берлекнең рәисе икән. Загста язылган исеме Илфак Ибраһимов икән, үзе кушканы Мөхәммәт Мирза ди.

Тотындык ваш ватарга: нигә кирәк булган аңа безнең Минһаж абзабыз?

Алай-болай иткәнче Минһаж абзый үзе дә кайтып төште. Билгеле инде, без жыйнаулашып анын янына чаптык. Минһаж абзый гадәттәгечә барысын да түкми-чәчми сөйләп бирде.

### Әгъза һәм рәис булдым

—Жомабикә жингәгезнен аркасына сыртымны терәп Маручка турында уйлап ята идем, килеп туктады бер машина. Ишекне итәгатьле итеп кенә шакыдылар. Ачтым. Итәгатьле генә атлап бер тәртипле кеше керде.

—Минһаж Габсаматович, мөмкинме сезне бер генә минутка чоланга чакырырга,—ди.

Чыктык. Таныштык. Татар язучыларынын башлыгы икән.

—Гажәпләнмәгез, Минһаж Габсаматович,—ди.—Сез мине белеп бетермәсәгез дә мин Сезне яхшы беләм. Дөресрәге, Сез язганнар белән таныш,—ди.—Сезнен Ләнит Илич Брежневка язып биргән романыгызнын кульязмасы безнен берлекнен шүрлегендә саклана,—ди,—укып чыктым—кин колачлы роман. Ә инде Колшәриф мәчете төзелеше турындагы поэмагыз безнен бик күпләребез өчен үрнәк. Сонгы вакытларда ижат иткән дүртъюллыкларыгыз шидивыр,—ди.—Заманында Сезне Язучылар берлегенә әгъза итеп алмыйча ялгышканнар. Мин ул ялгышны төзәтергә килдем,—ди. —Рәхим итеп алыгыз, менә Сезгә язучы билеты,—ди.

Билетны кул биреп тапшырды бу. Бик тәртипле итеп кул чапты.

—Инде мондый нәрсә, Минһаж Габсаматович,—ди рәис.—Мин бер айга ижат командировкасына китәм, минем урында калып тормассыз микән,— ди. Шикләнмәгез, Сезнен кулдан килә торган эш. Чөнки Сез заманында Лилин белән бергә эшләгән, Сталин белән бәхәсләшкән, Хруччов белән хат алышкан, Ләнит Иличкә роман язып биргән, Гарбачув белән чәй эчкән кеше,—ди.—Рукавадящи урында эшләү тәжрибәгез зур ди. Ә безнен язучылар арасында андыйлар юк икән, ди.

—Ничек инде ул «юк икән?» Нигә юк дип кенә әйтмисен, әллә үз язучыларыбызны белмисенме?—дим.

—Белеп бетермәгән икәнмен шул, «Элита» дигән журналны укып белдем, рәтле-жүнле язучы юк икән бездә. Бөтен ышаныч синдә, Минһаж Габсаматович, коткар,—ди.

Кеше үтенеп сорагач, ничек инде сүзен аяк астына саласын, киттем машинасына утырып Казанга.

Эшне тиз тотты бу. Икенче көнне үк утырыш жыйды. Идарә утырышы дигән утырыш икән. Башта ике идарә утырышы арасында эшләгән эшләр турында сөйләделәр. Мин аларны бигүк тынламадым да. Чөнки мин кушып эшләткән эшләр түгел, нигә мина аларнын кирәге бар. Шунысы гына истә калган—Чаллы язучыларынын башлыгы Вахит Имамов атлы иптәшнен басып сөйләве әллә ничегрәк булды. Ул унга-сулга бөгелгәләп «Ярый инде, күнелегез булсын, мин дә бер-ике сүз әйтәм» дигән шикелле иренеп кенә сөйләде. Эшләнгән эше турында түгел, эшли алмаган эше турында иде бугай сүзе. Эшләнгән эшләр саналып беткәч, идарә әгъзасы Роберт Миннуллин «Минем эшем бар» дип чыгып китте. Бүтәннәргә күтәрелеп карарга теләмичә өстәлгә генә карап утыручы Камил Кәримов мәгънәле итеп тамак кырып алды да ишетелер-ишетелмәслек итеп сарказм белән «Нинди эше булырга может анын» дип куйды. Ләби Лерон дигәне серле итеп елмайды.

Гөргөри кушаматлы Гәрәй Рәхим дигән язучы мина шикле караш ташлап:

—Бу иптәш кем һәм ул монда нишләп утыра?—дип сорады.

—Сез Федотовкада подпольеда ята идегез, шул вакытта берлеккә алдык,—дип рәис минем турыда сөйләде.—Туфан Миннуллинның якташы,—дип тә өстәде. Туфан Миннуллин дигәч, Нәбирә Гыйматдинова Туфан Миннуллинга яратып карап алды. Барысы да җаваптан канәгать булып калдылар.

Утырыш дәвам итте.

—Көн тәртибендә оештыру мәсьәләләре—диде рәис.—Мин бер айга иҗат командировкасына китәм. Минем урынга калып торучы кирәк. Мин безнең әгъзабыз Минһаҗ Габсамат углы Габсматовичны тәкъдим итәм.

Чичнә белән Ингушитиедәге сыман шомлы тынлык урнашты. Бу тынлык шартлау белән бетәсен сизеп Ыркаел Зәйдулла:

—Мин Минһаҗ абзыйны күптән беләм, лаеклы кандидат—дигәч кенә идарә әгъзаларының йөзе яктырып киткәндәй булды. Шулай да:

—Нигә ул? Союзга кереп өлгермәгән килеш... Бездә бүтән язучылар юкмыни?—дигән тавышлар ишетелгән иде, рәис иптәш:

—Юк,—дип кистереп куйды.—Ышанмасагыз, «Элита»журналын укыгыз. Анда безнең булачак классигыбыз «Бездә адәм укырлык рәтле нәрсә язучы юк» дип урыс телендә чартлатып әйткән. Укырлык нәрсә булмагач, аларны язучылар да шәләй-бәләй генә була түгелме? Булачак классикка ышаныйк, җәмәгать,—дигәч, барысы шым булдылар. Мине бертавыштан диярлек язучылар берлегенең вакытлыча рәисе итеп сайладылар.

## Димакрәтия уены уйнамыйбыз

Эшне мин дә утырыш җыюдан башладым. Мине санга сукмыйчарак шаулашкан идарә чилиннарына:

—Тынычлык!—дип кычкырдым. Шым булдылар.

—Менә нәрсә, иптәш чилиннар! Мин сезгә Елсин түгел, демократия уены уйнамаячакмын. Мин тәртип ярата. Аң булыгыз, мин Союзда Ринат Мөхәммәдиев режимы урнаштырачакмын.

Бүтәннәр давыл киләсен сизгән каргалар шикелле тынып калдылар. Шәле тәрбиясе канына сеңгән куркусыз Камил Кәримов кына:

—Ринат Мөхәммәдиев режимын урнаштырсаң, без Сезне Рәмис Аймәттән кыйнатабыз,—дип бер күзен кысып кына елмайгандай итте дә «юк, юк, мин бер сүз дә әйтмәдем» дигәндәй як-ягына каранып алды.

Мин вакланып тормадым, утырышның көн тәртибен игълан иттем.

—Ике утырыш арасында эшләнгән эшләрне санап вакыт уздырмыйбыз, Равил Фәйзуллин каядыр ашыга, ул киткәнче төп мәсьәләләрн тикшереп калыйк,—дидем.—Кыстати, Роберт Миннуллинның да утырышны ташлап китә торган гадәте бар диделәр. Туфан Миннуллинны аңа сакчы итеп куям,—дидем.—Уяу бул, якташ, адашың кача башласа, тавыш куптар, дидем.

—Димәк, көн тәртибе болай,—дип дәвам иттем утырышны,—беренче көн тәртибе тере язучыларны күму мәсьәләсе. Икенчесе үлми калган язучыларның юбилиләрен билгеләп үтү, өченчесе татар әдәбиятының аксакалын сайлау. Көн тәртибенең нигә алай икәнен аңлатам. Җәйнең матур бер аенда «Элита» журналында бик тә тирән эчтәлекле мәкалә басылып чыкты. Аңа безнең эшебезгә тирән анализ ясалган. Анализның ризюмисе шул: бездә адәм укырлык рәтле нәрсә язылмаган. Идарә язучылардан даһи әсәрләр яздырасы урынга юбилиләр һәм үлгән язучыларны күму белән генә шөгыльләнә. Безнең әдәбиятыбызда каршына тезләнеп баш орырлык аксакалларыбыз юк. Мин бик зур игътибар белән мәкаләне укып чыктым һәм автор белән 120 протсинт килешәм. Үзегез беләсез, адәм укырлык

нәрсәләр тиз генә язылмый, ул. Бу сезгә такмак язу түгел, шуңа күрә бу мәсьәләгә тукталып тормаска кирәк санадым. Шуны гына әйтеп куям—әгәр дә даһи әсәрләр язарга теләмәсәгез, заставим. Әрмиядәгечә—не умеете—научим, ни хатите—заставим. Панятно? Мин бу сүзләрне нарушный урыс телендә чилин правления Микулай Алишев аңласын дип әйтәм.

Шунда минем уң ягымда утыручы урынбасар Вакыйф Нуриев:—Алишев түгел, Алешков, Микулай да түгел, Николай,—дип миңа пышылдый. Мин үземне төзәткәннәрен яратмыйм.

—Өйрәтмә,—дидем дә сүземне дәвам иттем.—Беренче көн тәртибен тикшерергә керешәбез. Димәк, тере язучыларны күмү.

Шунда телләр турындагы законны яттан белүче, шунын аркасында башы судтан чыкмаучы Разил Вәлиев:

—Тере язучыларны күмү түгелдер, үлгәннәрне күмүдер,—диде.

Бу юлы ялгышымны төзәтергә мәҗбүр булдым. Шулай да сер бирмәс өчен:

—Бездә тере язучыларны да күмәләр, язганына акча түләмәсәң, күмелә дә кала инде,—дигән булдым.—Димәк, яңа үлгән язучыларны күмү. Бүгеннән башлап күмүне туктатабыз, иптәшләр. Шунарга күрә, үлмәскә тырышыгыз. Кем дә кем үлә, Мәскәүдән килеп урыс язучылары күмсеннәр. Бездә берәр урыс язучысы үлсә, бер урыс та килми бит, татарлар җыелып күмәбез, дидем. «Элита» авторы, минемчә, шуны күз алдында тоткан.

Үлем турында сөйләшү күңелсез нәрсә, шуңа күрә:

—Тә-әк,—дидем,—Икенче көн тәртибенә күчәбез. Үткән 2008-2009 елда кемнәрнең юбилие булды әле?

Вакыйф Нуриев санап чыкты. Мин юбилярларның һәрберсенә тукталып үз фикеремне әйтә бардым.

—Әһе, Рабит Батуллага 70 тулган. Кем үткәрде аның юбилиен?

—Үзе,—диде Ыркаел Зәйдулла.—ике малае белән.

—Димәк, бу юбилидә язучылар берлегенен гаебе юк. Ары киттек, тагын кем?

—Мансур Вәли-Баржылыга 60 тулган икән.

—Нигә,—мин әйтәм,—аңа юбили үткәрдегез? Кыстати, нишләп ул Баржылы дип фамилиясенә коерык таккан?

—Чөнки ул Баржы авылыннан,—диләр.

—Булса ни,—дим,—Мин Кайперде авылыннан, ләкин Кайперделе дип язмыйм. Баржылы икән, Баржыда үткәрсеннәр.

—Без аңа юбилей үткәрмәдек.—диде Вакыйф Нуриев.—«Казан утлары»нда гына җыелышып нәрсәдер ниттеләр.

—Дөрес эшләгәнсең, Баржылы булып бар җылыны үзенә алып ятмасын, дидем дә сүз уйнатуыма куанып Гәрәй Рәхимдәй рәхәтләнеп көлдем.

—Миргазиян Юныска 80 тулды дигән булып кем юбили үткәрде?—дип сорадым.—Тулса ни. Мәкалә авторы белән кинәшергә кирәк иде. Юбилиләр үткәрү белән генә маташмасын язучылар берлеге дияр иде. Ә бу кем әле безнең? Шәүкәт Галиев. Кем рөхсәт бирде? Монысы Зиннур Мансуров, Рафис Корбан, Газинур Морат... Бер кәтү язучыга юбили ярамый болай. Бусы тагын кем? Әмирхан Еники. Нигә аңа юбили? Үлгән түгелме сон ул? Фатих Кәрим дип язылган монда. Күп бу иптәшләр. Мәкалә авторы дөрес яза.

Юбилиләре үткәрелгән әллә ничаклы язучыларны санап чыккач, Роберт Миңнуллинга килеп җиттек. Мин сүз әйтергә өлгермәдем, юбили авторы бәхәскә урын калдырмаслык итеп:

—Монда язучылар берлегенен катнашы юк. Минем юбилеине Республика җәмәгатьчелеге һәм татар халкы үзе үткәрде,—диде.

Халык дигән сүз әйтелгәч, тирәнгә кереп китәргә ярамый. Чөнки Рәсәйдә бөтен нәрсә дә халык исеменнән эшләнә. Халык әйтте: «безгә татар теле кирәкми» дип, шунда ук Дәүләт думасы «Милли телләрне укытмаска» дип закон да чыгарды. Әйтер татар «безне бетерегез» дип—бетерерләр. Халык бит шундый төркем—ни әйткәнен һәм ни уйлаганын үзе белми—өстәгеләр генә белә.

Тәк, кайда туктаган идем әле? Ә-ә, юбили. Әйе, бетердек без аларны ул утырышта. Үткәрмәскә—һәм вәссәләм.

Тик рәис урынбасары Вакыйф Нуриев кына:

—Ә Тукай белән нишлибез?—дип пышылдады.—2011 елда ана 125 ел тула бит. Без моннан ничә ай элек юбилей үткәрергә дип сөйләшкән идек. Ничек үткәрергә дип Культура министрлыгына язып та биргән идек. Зилә ханым иртәгә карарбыз дип тә әйткән иде.

Сез беләсез, мине өйрәтеп торуларын мин яратмыйм.

—Иртәгә дигәч иртәгә инде. Иртә җитмәгән бит әле. 2011 ел җитсен, 25 апрель көнне иртәгә дип әйтерләр дә 26 сында үткәрерләр,—дидем дә өченче көн тәртибенә күчәргә тәкъдим ясадым.

## Аксакал сайлау

—«Элита»дагы мәкалә авторы бездә аксакаллар юк дигән. Бу килешә торган нәрсә түгел. Аксакалсыз әдәбият була алмый. Без бүгенге утырышта аксакал сайларга тиеш,—дидем.

Тарих язучылар төпченүчән булалар бит—тарих фәннәре докторы Искәндәр Гыйлаҗев:

—Сез, Минһаж Габсаматович, мәкалә авторы да мәкалә авторы дисез, ә мәкалә авторының исем-фамилиясен әйтмисез,—ди.

Андый гына төрттерүләргә исем китми минем:

—Нимес телендәге әллә нинди китаплар укыганчы «Элита» журналын укыгыз,—дидем.

Гомере буе «Ызба» белән «поезда»ны рифмалаштырып шигырь язарга кызыгып йөргән Гәрәй Рәхим:

«Элита» белән «Мелита» рифмалаша икән,—дип көлеп куйды.

—Читкә китмәгез,—дип тәртип урнаштырдым да,—Аксакал мәсьәләсендә нинди тәкъдимнәр бар?—дидем.

Дәшмиләр. Карыйм—барысы да битләрендәге сакал үсәргә тиешле җирләрен сыпырып-сыпырып карыйлар. Хәтта Илсөяр Иксанова да килешле генә иреннәре өстендәге бала йоннарын чеметеп-чеметеп карый. Бары тик Газинур Морат кына: «Ә минем сакалым бар» дигәндәй Сәрдек мужиклары елмаюы белән канәгать елмаеп утыра. Мин һаман күзәтәм. Шул вакыт, ышанасызмы-юкмы, Роберт Миңнуллинның иягендә сакал үсә башлады. Мыегыннан үзгә буларак, сакалы сирәгрәк, татар белән башкорт сакалының кушылмасы сыманрак. Уйга калдым. Юкка гына түгелдер бу дип уйлыйм. Кайдадыр галәмдәге бер серле көч: «Ялгышма, Минһаж, аксакалны дөрес сайла» дип әйтә сыман.

Минем уйларымны бүлеп, сагышлы тынлыкны бозып, Зиннур Хөснияр:

—Аксакал берәү генә булырга тиешме, берничәме?—дип сорады.

—Аксакаллар күп булмый, татар язучылары өчен әлегә берәү җиткән,—дип кырт кистем.

—Алайса, тагын бер сорау,—диде Зиннур Хөснияр,—аксакал бөтен язучылар арасыннан сайланырга тиешме, әллә идарә членнары арасыннан гынамы?

Бөтенесе берьюлы:

—Идарә членнары арасыннан, диделәр. Һәм тагын тынлык урнашты.

—Кандидатуралар күрсәтегез,—дигәнемне дә игътибарсыз калдырдылар. Ниһаять, Камил Кәримов:

—Мөмкинме?—диде.

—Әйдә, әйдә, рәхим ит,—дим.

—Мин Нәбирә Гыйматдинованы тәкъдим итәм.

Утырыш шартлап ярылыр да аннан кешни-кешни көлгән тавышлар сибелер дип уйлаган идем, алай булмады, шым гына утырдылар. Нәбирә үзе генә:

—Син Шәле пәрие, тик кенә утыр, ярыймы,—дип чәпчеде дә,—Мин Камил Кәримовның үзен тәкъдим итәм,—диде.

Камил ни өчендер бу юморны әллә анламады, әллә бәяләп бетермәде:

—Ә нигә...—дип кенә куйды да тыйнак кына итеп башын иде.

Мин инде күнелемнән генә ике Миннуллинның берсе булырга тиеш,—дип уйлап куйган идем. Янәшәмдә генә утырган Туфан Миңнуллинга карадым.

—Якташ, син аксакал булырга теләмисенме?—дип сорадым.

—Мин күптән аксакал инде, кырынып йөргәнгә генә сакалымның агы күренми,—диде якташ.

Нәбирә Гыйматдинова тагын сикереп торды.

—Чыннан да, җәмәгать, Туфан абыйны аксакал итик,—ди.

Роберт Миңнуллин мыек астыннан гына елмаер-елмаймас:

—Туфан Абдулловичны карт булса да кызлар ярата инде,—дип куйды,—Дәүләт Советы кызлары да яраталар аны. Мине яшь булсам да никтер яратмыйлар.

—Яратабыз шул,—дип монолог сөйләргә җыенган иде Нәбирә Гыйматдинова,

—Идарә утырышы мәхәббәт анлата торган урын түгел,—дип туктаттым.

Туфан Миңнуллин «яратабыз шул» дигәнгә куанып, мөкиббән китеп, аксакаллык турында да онытып тәмле-татлы уйларына чумган килеш оеп утыра бирде. Утырыш беткәч, кабинетка чакырып алдым үзен, кыздырдым.

—Син нәрсә,—мин әйтәм,—дуракны вәләеш? Мин сине блат белән якташ дип аксакал итмәкче булдым, син мине җыен шантырапа каршында авторитны киметәсен.

Бәхәсләшеп маташа.

—Аксакал нинди булырга тиеш?—ди,—Акыллы сүз генә сөйләп йөрергә тиешме?—ди.

—Тиеш,—мин әйтәм.

—Акыллы сүз генә сөйләп йөргәнне кызлар яратмый. Кызлар җүләрсымакларны ярата,—ди.

—Кызлар да кызлар дисен, үзенә ничә яшь дип беләсен?—дим.

—Булса сон. Минем яраткан кызларым да 18дә түгел—50 белән 60 арасында,—ди ахмак. Куып чыгардым кабинеттан.

Равил Фәйзуллиннары бар бит әле язучыларның. Ана карадым. Кульяулыгы белән җир шарының яртысы чаклы мангаен сөртеп утыра. Эссе дә түгел инде, нигә тирли икән дип уйлыйм эчемнән генә. Болай анлашыла да инде үзе—ике «мин» көрәшә аның күнелендә. Такташ әйтмешли:

Хәзер инде миндә ике мин
Берсе анын аксакаллык яклы,
Икенчесе каршы—сукин сын.

Аның газаплануын күреп сорадым үзеннән:

—Равил Габдрахманович, Сезнең аксакаллыкка фикерегез ничегрәк?—дидем.

—Эше күп булыр микән аның,—дип тамак кырып алды да, үзегезгә карагыз инде дип иңнәрен сикертеп куйды. Равил янәшәсендәге Вахит Имамов:

—Чаллыны һаман да яшь шәһәр дип йөртәләр. Ул да картая инде, диде.—Юк, мине сайлагыз дип әйтүем түгел, Чаллыны гына онытмагыз диюем.

—Әлмәт Чаллыдан өлкәнрәк,—дип һәркемгә билгеле тарихи фактны Әлмәт язучылары башлыгы Данил Салихов кабатлады, тик аны ишетмәделәр. Татар кнәжнәсе Лилия Газизова:

—А русскоязычный писатель может быть аксакалом?—дип сорагач куркып киттем. Куркырсың да: «может» дисәң, милләтче татарлар башыңны бетерәчәкләр, «нет», дисәң, милләтче русскоязычныйлар Минһаҗ Габсаматов урысларны кыса дип тавыш чыгарачаклар. Урысларны кыса дигән сүз бүген теге вакытта «долой Советский Союз» дию белән бер.

Ярый әле Камил Кәримов бар—ул коткарды

—Аксакалом не может, акшакалом может,—дип халыкны көлдергәч мәсьәлә шунда ук хәл ителде, дип уйлаган идем Гәрәй Рәхим:

—Между прочим, керәшеннәрнең дә сакалы агара,—дип әйтеп салды. Анысына минем җавап әзер иде:

—Григорий Василич, әле яна гына «Халык язучысы»н алдыгыз, аллы-артлы ике ызвание алу килешмәс,—дигәч:

—Юк, болай гына әйтүем,—диде Гөргөри.

Турыдан туры әйтеп тә, кактырып-суктырып та бөтен идарә әгъзаларын тикшереп чыктык.

—Нишлибез, иптәшләр, табылмады бит әле сайларлык аксакал,—дидем.

—Бөтенесен дә тикшермәдек. Тикшерелмәгән кеше дә калды,—диде Роберт Миңнуллин.

—Кем ул?—дидем.

—Мин тыйнак кеше буларак үземне әйтмим. «Элита» журналындагы мәкалә авторын күздә тотам. Ул да Идарә әгъзасы.

Бик вакытлы әйтелгән сүз булды бу. Килделе-китделе язучы халкы белән чиләнеп утыру туйдыра башлаган иде. Роберт Миннуллинның тәкъдимен тавышка куйдым.

Сүзнең ни турында барганын аңламый да калган идарәчеләр кулларын күтәрделәр.

—Бертавыштан аксакал сайланды,—дидем дә утырышны ябык дип белдердем.

Соңыннан Ыркаел дус Зәйдулла:

—Кемне сайладык соң без? Нигә безгә анлатмыйлар? Бу нинди безобразие?—дип дулап йөрде йөрүен, ләкин эш узган иде инде.

## Кол Галигә—«табу»!

Бер мәл район гәзитләре редакцияләрен урта белемле «самородоклар» басып китте. Арада талантлылары да күренгәләде, әмма андыйларының беркадәресе мәдәни яктан нык аксады, шешә белән дуслашты.

Чүпрәледә шуның киресенә тап булдым. Олы гәүдәле, куе бөдрә чәчле, калынрак иренле, мут күзле, сөйләшергә бик тә җаптәш, кешеләрне йөзе белән сөендерүче бу егет янарак кына Казанда югары уку йортын тәмамлап кайткан. Шундук үзен җаваплы сәркатип итеп куйганнар—гөрләтеп эшләп ята. Гәзитнен йөзен нык үзгәрткән. Нурмөхәммәт Хисамов дигән инсан белән әнә шул чакта таныштым. Аннары ул, Чүпрәле күлмәгенә сыешмыйча, гаиләсе белән Казанга күчеп килде. Ләкин дуслыгыбыз өзелмәде. Типографиядә минем хатын белән бергәләп, тәзүчеләрнең күптиражлы гәзитен чыгардылар...

Кинәт—аспирантура, фәнни гамәл. Тиз арада фән кандидаты булды, докторлык диссертациясен яклады. Күп кенә фәнни мәкаләләр, монографияләр язды, китаплар бастырды. Профессор дәрәҗәсенә иреште. Аннары Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры итеп сайланды. Язма әдәбиятыбызның башында торган Кол Гали иҗатын өйрәнү буенча, галим Җәвад Алмаздан соң, күренекле урынга чыкты.

—Кайда күреп бәйләним икән дип йөри идем, очравың шәп булды әле,—дим, моны китап нәшрияты баскычында туктатып.

—Ник бәйләнәсең, дуслар ич без,—ди профессор.

Сорау ала башладым моңардан. Сөйләшүнең стенографиясен китерәм менә:

—Нурмөхәммәт, син Чүпрәледән, мин Балык бистәсеннән—дөресме?

—Шулай дип беләм.

—Казан ханлыгына чаклы яшәгән Кашан ханлыгы кайда алайса?

—Сездә инде, сездә.

—Димәк, Чүпрәледә түгел.

—Төрттерәсең килдеме?

—Юк, иптәш профессор, шуны ачыкларга телим: Кол Гали безнең Кашан шагыйреме, әллә түгелме?

—Урта Иделнеке. Китабым чыга, шуннан укы!

—Чүпрәле мишәрләре әйтмешли, стоп брат! «Йосыф вә Зөләйха» поэмасының берничә дистә нөсхәсен тапкан Җәвад Алмаз Кол Галине болгар-татар шагыйре,—дип яза.

—Ә мин Урта Иделнеке дим, поэмада кыпчак-угыз теле элементлары тулып ята.

—Сарай-Бәркә дисеңме?

—Бәлки...

—Кол Галине безгә бирмисеңме?

—Әлегә—табу!

Уйландым: алайса шагыйрьнең үз «мөһер»ен «Кол Гали бине Мирхаҗи әл Кашани» дип сугуын ничек аңларга соң?!

Кол Галиче галим булгач, монысына да җавап тотарга тиештер бит инде...

## Йөземле пылау

«Татарстан яшьләре» гәзитендә эшләгәндә минем янга виртуоз гармунчы Фәйзи ага Биккинин еш килеп йөрде. Болай гына, кызлар күзләр өчен.

—Энем, теге бүлмәгә керик әле тагын. Көлүләре ошый шуларның. Үзең сөйләштер, мин яннарында утырып торсам, шул житә,—ди беркатлы Фәйзи ага.

Мәктәпләр бүлегенә кереп, Галия Рәимова белән алдан сөйләшеп, килешеп чыгам. Ул белмәмешкә салыша инде. Юк-барны, гәпләшеп, көлешеп алабыз. Фәйзи ага, Галия утырган өстәл почмагын сыпыргалап, аңа мәдхия яудыра: «Пылау өстендәге йөзем инде, валлаһи!»

Бер ай дигәндә тагын килде абзыкай. Пылау белән сыйламакчы.

—Галия бездән китте бит, хәзер Мәскәүдә партия мәктәбендә укый,—дим Фәйзи агага.

—Алай икән, кызлар күрсәтмисеңмени инде?!

—Бүлектә Роза Рәхмәтуллина дигән ханым эшли. Керик шуның янына.

Нишлисең, ул көнне ирексездән йөземле пылау белән сыйланырга туры килде безгә.

## Түбәтәй кыйссасы

Башта түбәтәйне түрәләргә баш бирмәс шагыйрь Салих Баттал киеп йөрде. Аннары Язучылар берлеге идарәсе сәркатибе, партизан Зәки Нури элеп алды. Чират миңа житте. Шулай булмыйча! Журналистлар берлеге идарәсенең җаваплы сәркатибе иттеләр бит абзагызны. Икенче көнне үк өскә—-ул чакта модага кереп барган эре-эре итеп пичәтләнгән шакмаклы күлмәк, башка дүрт кырлы үзбәк түбәтәе киеп жибәрдем. Соңгысын Мамадыш районының Иске Комазан авылы кибетеннән эзләп таптым. Бөтен хикмәт тә әнә шул түбәтәйдә иде. Язучыларның Тукай исемендәге клубында ниндидер зур бер җыелыш бара. Партия өлкә комитетыннан пропаганда һәм агитация бүлеге мөдире Николай Андрианов үзе катнаша. Президиумда Зәки Нури белән рәттән утыралар. Мин залда, арттарак, тегеләргә тиңләшергә бик иртә әле. Шулай да Зәки абый белән без җыелыштагылардан шактый аерылып торабыз. Караштыргалап утыргач, Андрианов күршесеннән:—Зәки, теге нинди малай ул түбәтәйле?—дип сорый икән.

—Нинди малай? Минем кебек зур кеше ул,—дия икән ике метрлы Зәки Нури.

Беразга тынлык урнаша. Эче поша гына бит мөдирнең. Угалана торгач, тагын өн сала:

—Шаяртма әле, Зәки, кем ул теге?

—Зур, дим бит. Бүген Хамматов (гәзит мөхәррире, журналистлар берлеге рәисе) аны синең янга алып барачак, раслатырга,—ди шагыйрь.

—Да-а-а,—дип, бик озаклап суза Андрианов.

Шулай да килешеп, аңлашып эшләдек үзе белән.

Рәхмәт Зәки абыйга. Ярты метрга үстереп күрсәтә белде үземне. Урыны ожмахта булсын!

## Кемгә—белен, кемгә скрипкә

Нәкый Исәнбәтнең 60 яшьлек юбилей мәҗлесе Татар ашлары йортының банкет залында үткәрелде. Минем урын атаклы композитор, оста скрипкәче Заһит Хәбибуллин белән рәттән туры килде. Әлбәттә инде, Заһит ага үзенең

виртуоз уйнавы белән мәжлеснең йөзек кашына әйләнде. Өлкән әдип Нәкый ага да бик канәгать калды.

Таралышканда мин Заһит абыйның сумкасына бер «төрек малае»н салдым (сәркәтиб буларак, хакым бар, чыгымнарның бер өлешен Журналистлар берлеге үз өстенә алган иде). Чыктык. Композиторны Божрага чаклы озатып куярга булдым. «Белен» кафесына житкәч, Заһит абый:

—Карчык белен ярата, алыйк әле,—ди.

Анысына да ирештек. Юлда скрипкәсен тотып кайтырга сорадым. Булышмакчы идем.

—Уйнамаячак ул синең кулда, Госман дус! Мә, тот сумканы. Сина—белен, мина—скрипка!—дип, инструментын кулыннан ычкындырмады.

Хәзер гажәпләнәм: кайдан белде икән ул минем «колакка аю басканны?!»

### Икенче сортлысы кирәкми

Нәүбәттәге ижат командировкасы тәгаенләнгәч, язучы Габдрахман ага Минскийга шылтыраттым.

—Кәефләрегез ничек, иптәш Синский (ул шаяртуымны аңлый), минем белән Кама Тамагына чыгасызмы? «Беренче»ләре әшнәм үзе чакырып тора.

—Кубага (Ф. Кастроның дөньяны дер селкеткән чагы) дәшсән дә барам. Синең белән не пропайдешь, Госман дус,—дип, учакка май сибеп жибәрде әдип.

Райкомның беренче секретаре Мөхәммәт Борһанов—Саба егете, мин әлеге районда эшләгәндә партия мәктәбен тәмамлап кайткан иде, шул чакта таныштык. Аннары ул Чүпраледә икенче секретарь булды. Хәзер менә Кама Тамагы хужасы. Безне күккә чөеп каршылады. Идел буенда балык шулпасы әзерләргә иң ышанычлы инструкторы Шәех Беляевны билгеләгән.

—Без бераз коллегалар,—дидем язучыга.

—Балык шулпасының шулпасы,—дип үртәде Минский.

—Анысы өчен борчылмагыз, ухасы да булыр,—дип вәгъдә итте табынчыбыз.

Казан асып, учак тергездек. Беляев сынамак өчен Иделгә кереп чыкты.

—Суы бик жылы, коенырга мөмкин.

—Анысы ярый,—дип эләктереп алды Габдрахман ага.—Ни, мин трусиксыз гына. Актанышта, Агыйдел буенда безне хатын-кыз сыйлаган иде.

Беляев язучыны икенче төрле аңлады, ахрысы.

—Бездә комсомолкалар гына шул. Менә Госман ишеләр.

—Ярый алайса, аңа булсын, безгә икенче сортлылары кирәкми,—дип әйтеп куйды.

Борынгы Хажи Тарханда туып-үскән егет ялангач килеш Иделгә кереп чумды...

**Госман ГОМӘР**

# «МАТБУГАТ.РУ»ДАН БЕЗНЕ УКЫГЫЗ

*Ниһаять, бөтен татар матбугатын бер йодрыкка туплап торучы «Матбугат.ру» интернет-порталы барлыкка килде. Биредә татар телендә чыгучы һәр газета-журналның үз урыны, үз почмагы бар. Хәзер «Казан утлары»нда дөнья күргән кайбер язмаларны дөньяның барлык кыйтгаларында укырга мөмкин. Интернет челтәренең мөмкинлеге зур, ул океаннар аша да үтә, таулар да аңа комачау түгел.*

*«Матбугат.ру»га ай саен журналыбызның яңа санындагы өч-дүрт язма элenə. Аларга карата укучылар фикерләрен дә язып калдыралар. Киләчәктә журналны яхшырту, аны сез күрергә теләгәнчә чыгару өчен ул фикер-теләкләрне ишетү безгә дә кызык.*

*«Казан утлары»нда басылган мәкалә-язмаларны соңгы айларда интернет аша 15 меңләп кеше укыган, шуның 300ләбе үз фикерен язып калдырган. Бүген исә игътибарыгызга кайбер кызыклы җөмлә-фикерләрне тәкъдим итәбез.*

### *Мәкруһлар. Тәфкил Вафин. №1–4. 2009.*

Мәкруһлар—көчләп чукындырылган һәм бөтен рәсми кәгазьләрдә урыс исемнәре астында йөргән саф мөселман татарларыбыз. Мәкруһларның төп билгесе шунда ки, аларга татарча исем-фамилия алу катгый тыелган, шуна күрә алар фамилияне ата исеменнән түгел, ә ана исеменнән алырга мәҗбүр булганнар. Мәкруһлар күмәкләшеп урыс түрәләренә акчалата ришвәт, ә пуп-атакайларга аракы-көмешкә хакына мөселманча яшәүләрен «сатып» алганнар. Бу очракта әллә корылык елы булуга, әллә салымнарның үсүе аркасында, ришвәткә акчалары җитмәгән, булса кирәк. Түрәләренең припискаларындагы яна мәсихче татарларның искечә, мөселманча яши бирүләре ачылды. Урыссиядә һәрвакыттагыча, кем гаепле?

Ришвәт белән тыгынып бетә алмаслык бирән түрәләрме? Юк—гади халык! Мәкруһлардан чыккан иң билгеле татарларыбыз: Габдрәхим Утыз-Имәни әл-Болгари, Гаяз Исхакый, Абдулла Алиш, Хәсән Туфан һ.б.

### *«Казан утлары»нда—«Ак җилкән». №1–4. 2009.*

«Үткәндә матур мәхәббәте булмаган кеше—кызганыч. Ләкин шундый мәхәббәте булып та саклый алмаган кешеләргә караганда аңа биниһая җиңел.

Чөнки ул мәхәббәтнең татлыдан татлы кичерешләрен белми, чөнки ул мәхәббәтнең тетрәткеч бәхетеннән гафил.» Ш.Хөсәенов.

Шәриф абыйның «Мәхәббәт сагышы»—искиткеч әсәр! Ярата белгән кеше язган шул!!!

### *Гөлчәчәк Галиева. Газзәбану. Роман. №7,8. 2009.*

Романда күпхатынлылык, көндәш белән яшәү проблемасы күтәрелә. Ир-атлар бу мәсьәләгә бик үк җитди карамыйлар. Мондый тормышта иң авыры хатын-кыз башына төшә, аларнын ничек газапланып, күнелләре белән ялгыз калып, әрнеп яшәүләре гаиләгә дә, җәмгыятькә дә зыянлы булуын ирләр уйлап ук житкерми шул.

Романда төрле вакыйгалар матур итеп бирелә. Гореф-гадәтләр буенча үткәрелгән элеккеге чын Сабан туе сурәтләнә. Үзен дә шунда йөргән кебек хис итәсең. Кечкенә булса да тапкыр сүзле, сакау Хафизны тупырдатып яратасы килә, телләрне йотарлык итеп пешерелгән бәлеш-коймакларны ашап карыйсы, геройлар белән бергәләп кушылып җырлыйсы килә.

Бер үк төрле әйберләрне укып, шундый ук сериаллар карап туйганбыз, менә мондый Газзәбануларга сусаганбыз ахры. Рәхмәт, Гөлчәчәк апа, матур романыгыз өчен!

***ТР Язучылар берлеге рәисе***
***И. Ибраһимов белән әңгәмә. №10. 2009.***

Озын булды бу, ләкин укып чыга алдым. Мондый көчле әңгәмәләр интернетта бик сирәк. Без инде «шаблонный» сорауларга күнеккән. Монда исә бөтенләй башка. Әңгәмәдәшләрнең акыллы, бөек кешеләр икәнен аңладым.

***

«Язучылар берлеге белән хәтта Иманметдинов кебек язучы булмаганнар да рәислек итеп алган...» Зыян юк, тарих кабатлана. Бүген дә Язучылар берлеге белән язучы булмаганнар да рәислек итә.

***Нурулла Гариф. Гыйбрәтле хикәятләр. №12.2009.***

Нурулла әфәнде! Мин көткән заманнар килә бит, укырлык әйбер язу өчен физик булырга кирәк икән. Рәхәтләнеп укыдым. Тик сезне генә ничәгә бүләргә соң!? Бер яктан караганда, балаларга сездән яхшылап физика укыттырыр идем, кодрәтемнән килсә, тиешле зарплаталарын биреп. Икенче яктан, тормыш фәлсәфәсен дә бик матур, мавыктыргыч итеп язасыз. Сез чынлап та татарның бүгенге көн герое.

***

Шәп язмалар. Теле матур, рәхәт укыла. Ун еллар элек «Казан утлары»нда аның «Мин сезнең арада яшәдем» дигән язмалары чыккан иде. Кат-кат укыган идем.

***Р. Фәйзуллин. Яшь шагыйрә***
***Ләйсән Фәтхетдинова иҗаты турында. №12. 2009.***

Равил Фәйзуллин якташ, туган җанлыклы. Булдыра алган кешене күрә, күтәрә, кирәк вакытында ярдәм дә итә белә. Миңа да аның ярдәме зур булды, һәрберегезгә дә шундый якташны Ходай насыйп кылсын!

***

«Казан утлары»нда күп яшьләр басылды. Равил абый якташлары гына түгел. Лилия Гыйбадуллина, Ленар Шәех, Рифат Сәлах... Элегрәк Илгөлем, Гөлнур Корбанова, Гөлнара Җәлилова, апасы белән... Ләйсән Мөстәкыймова... Бик күпләр басылды. Ләйсән булдыра, күз генә тимәсен! Кешедә йолдыз чире булса, ул күзләренә үк чыга. Ә Ләйсән—ихлас.



Балачак белән яшьлек арасындагы
гүзәл дөньяда яшәүчеләр, бу—безнең сәхифә!

*Ак җилкән*

Илдус
Хуҗин

# ЯҢА РОБИНЗОННАР

ХИКӘЯТ

Ул киңлекләрдә караңгы бик кинәт төшә, шуңа күрә алар утрауны әйләнеп чыгу белән үк якорь төшереп, төн үткәрергә булдылар. Диңгез тыныч булса да, көймәне шактый тирбәтә, гүя диңгез егетләрне йоклатырга тели. Ләкин дүрт дусның күзләренә йокы керми. Бу кадәр киеренке хәлләр, көтелмәгән вакыйгалар арытса да, якын киләчәкнең тагын да мәшәкатьлерәк булуын сизү аларны ярсыта, йөрәкләрен кыса, дулкынландыра иде.

## Ерткыч оясы

Яктыра башлау белән экипаж утрауны әйләнеп чыгып, тарлавык янына килеп җитте. Көймәнең туктавы булды, аннан таныш катер чыгып, Минданао атавы ягына ыргылды.

Кыю диңгезчеләргә шунда ук аның артыннан куарга туры килде. Хәсән бераз баргач иптәшләренә:

—Боларны тотмыйча без берни дә кыра алмыйбыз,—диде.

—Син хаклы,—дип күнде Фәрит. Утрау тирәсендә күпме әйләнергә була? Ләкин алар кораллы. Автоматлары да бар шикелле. Ничек «алырга» тәкъдим итәсең?

Озак кына гәпләшкәч, көймәнең кайбер өстенлекләреннән файдаланырга булдылар. Хәер, бу очракта бүтән мөмкинлек юк та иде.

«Виктория» иң зур тизлегендә катер артыннан ыргылды. Су өстендә пуляларга бирешми торган калын органик пыяла капкач кына күренеп бара. Хәтта перископ та эчкә алынган.

Катерны куып җитәргә ярты кабельтов калгач кына андагы ике таныш кеше куучыларны күреп алдылар. Бинокль аша аларның чиктән тыш курыкканлыгы күренде. Коточкыч тизлектә якынаючы көймәнең пыяла калфагы астында утыручылар аларга ниндидер икенче дөньядан килгән затлар булып тоелдылар ахрысы. Башта алар калтыранган кулларындагы пистолетларыннан да ата алмый азапландылар. «Автоматларын утрауда калдырып йөриләр күрәсең»—дип куйды Расих.

Пуляларның күбесе читкә очалар, өч-дүрте генә капкачка тиеп рикошет ясап үтте. Бу хәл качып баручыларны тагын да куркыта төште. Менә аларның берсе рульне капыл уңга борды. Кире иптәшләре янына китәргә телиләр иде ахрысы, ә моңа һич тә юл куярга ярамый. Хәсән дә уңга борылды һәм көймәнең борынын катерның

*Дәвамы. Башы 1 нче санда.*

юлына аркылы җибәрде. Ике судно бер-берсенә бик тиз якынлаштылар. Соңгы мизгелдә катер сулга борылырга тырышып караса да, соң иде инде: «Виктория» очып килгән уңайга,борыны белән катерның кабыргасына төрттерде. Мондый көчле бәрдерүдән көйманең корпусы гөрселдәп куйды. Егетләрнең башлары кайсыныкы пультка,кайсыныкы утыргыч аркасына бәрелде. Ләкин алар моңа әзер иделәр. Көймә янтайган катерны акрын гына этеп бара,ә катерда бер кеше дә күренми иде.

— Фәрит! Тизрәк!—дип, Хәсән өскә атылып чыкты. Аның артыннан Фәрит белән Идрис тә катерга ашыктылар.

Катерда, руль астында төшеп киткән пистолетын эзләп маташучы пиратны шундук кулын каерып кулга алдылар һәм икенчесен эзли башладылар, ләкин катерда башка кеше юк иде. Шунда гына ун-унбиш метр ераклыкта кайсы якка йөзәргә дә белми аптыраган икенче пират күренде. Анысының коралы юк иде шикелле. Күрәсең, көймә катерга бәрдергән чакта ул егылып төшкән һәм коралын да шунда югалткан.

Хәсән белән Фәрит аңына килгән флибустьерның чигәсенә үзеннән алган алтатарны терәп сорау алалар иде.

— Сиңа бер минут!—диде Хәсән пиратка инглиз телендә һәм аңа Алсуның фоторәсемен күрсәтте.—Кая илттегез бу кызны?

—Нинди кыз? Мин аны белмим!—дип башын чайкады бандит.

—Бер ел элек сез аны Сингапур портыннан көчләп алып киттегез. Кайда ул?!

—Минем Сингапурда бөтенләй булганым юк!—дип, гаебен инкарь итәргә тырышты җинаятьче.

— Алай булса,сине акулаларга биреп калдырып,иптәшеңне чыгарабыз,—диде Фәрит дингез ягына ымлап.—Ул дөресен сөйләп бирер.

—Ул кыз,—диде европалыга охшаган диңгез юлбасары,—әле без булган утрауда.

Фәритнең һәм аның иптәшләренең үзләрен ничек хис итүләрен аңларга була, бу бит Алсу турындагы беренче чын хәбәр иде.

—Ни өчен ул анда? Барын да сөйләп бир! Тиз генә!

— Утрауда,—дип сөйләп китте пират, судагы иптәшенә күз сала-сала,— Ченның базасы урнашкан. Сез аның турында бәлки ишеткәнсездер, нәселдән килгән кыю сугышчы.

—Ягъни пират,—диде Фәрит.

—Юк! Безнең максат—капкорсакларның кесәләрен юкарту,—дип пафоска бирелергә уйлаган иде диңгез юлбасары,ләкин егетләрнең күз карашы астында бу уеннан кире кайтты.—Кызларны һәм егетләрне эшләтер өчен алалар. Күбрәк чит илнекеләрне эләктерәләр,чөнки аларны сирәк эзләп маташалар. Алар кача да алмыйлар. Кайвакытта алар өчен йолым алына. Кызларның ямьсезләрен алмыйлар: үзегез аңлыйсыздыр, алар анда төрлечә файдаланыла.

Иң төп эш—су төбеннән энҗе һәм мәрҗән җыю, аларны эшкәртү...

—Дәвам ит!—дип тешен кысты көчкә генә түзеп утырган Фәрит.

— ...Безнең махсус көймәләр бар, катамараннар. Шулардан водолазлар (без тоткыннарны шулай дип атыйбыз) тирәнгә чумалар һәм 4-5 минут эчендә берниндн аквалангсыз-нисез меңәр долларлык нәрсәләр алып чыгалар. Башта аларны су төбендә озак йөрергә өйрәтәләр.

Утрауда утызлап кораллы сугышчы бар. Аларның кайсылары сакчылар, башкалары водолазлар белән эшли...

— Ә кайсылары кораблар талыймы?—дип мыгырдады Хәсән.—Аңлашыла. Нинди кораллар бар сездә?

—... Төрле системадагы автомат һәм пистолетлар. Ракеталар да бар: базукалар һәм «Стингерлар». Сугышчылар буйдаклар,дип әйтергә була. Гаиләләре төрлесенең төрле җирдә. Ә монда алар узләренә вакытлыча хатын-кыз табалар...

—...Үлүчеләр дә еш була,чөнки авыруларны дәваламыйлар, шундук юк итәләр...

—...Бу кызның хәзерге вакытта андамы-юкмы иканен белмим, чөнки без утрауда аз булабыз. Күбрәген курьер һәм разведка хезмәтләрендә йөрибез.

—...Сакчылар алты-җиде кеше була. Шуларның икесе яр буенда,ә калганнары базада төрле постларда.

Егетләрне кызыксындырган мәгълүматлар алынгач, Расих Фәриткә:

—Боларны юк итәргә кирәк. Юкса, алар безгә комачаулаячаклар,—диде.

— Оныттыңмыни? Без кан коюга каршы,—диде Фәрит.—Без бандитлар түгел. Ә җинаятьләре өчен тиешле урында хөкем ителерләр.

—Алайса, нишләтәбез соң?

—Хәзергә берәр кеше яшәми торган утрауга илтеп куйыйк, соңыннан полиция килеп алыр.

Ул арада судагы пират ярдәм сорый башлады.

—Йөзсен-йөзсен!—дип көлде Фәрит.—Башкаларны күп йөздергәннәр болар.

Бераз киңәшкәч, ике юлбасарны моннан утыз миль ераклыгында булган кешесез утрауга илтеп куярга, аннан соң катерда Хәсән Сингапурга полиция алып килергә китә, ә калганнар утраудагыларны күзәтә, дип килештеләр.

Юлбасарларның кулларын бәйләп катерга утырттылар да әлеге әйткән вулканик утрауга таба юл алдылар. Ике сәгатьләп баргач, утрау да күренде. Бу кечкенә җир кисәгендә җан иясе түгел, үсемлек тә юк иде.

Утрауга җитмәс туктап, егетләр пиратлардан яңадан сорау ала башладылар.

— Тиздән монда полиция булачак. Бандагызны алгач, монда килерләр. Әгәр аларны тотарга ярдәм итсәгез, һичшиксез сезнең хәлегез җиңеләячәк. Әйтегез, аларны ничек юк итү уңайлырак?—дип сорады Хәсән катгый тавыш белән.

Бу сорауга җавап булмады. Европалы бандит иптәше ягына ымлап куйды: ул белә янәсе. Шуннан соң аңа суга сикерергә куштылар һәм бандит озак көттермәде: ярга кадәр артык ерак түгел иде.

Инде тегесен боргычлый башладылар:

—Ишеттеңме сорауны? Җавап бир, сезнең банданы ничек кулга төшерү җайлырак?

Бандит аңламаганга салышып башын чайкады. Хәсән аңа сорауны кытайча бирде, пират исә дәшмәде.

— Егетләр, бу юлбасарның безнең белән сөйләшәсе килми, алып киттек диңгез уртасына, анда акулалар белән уртак тел табар,—диде Хәсән көлемсерәп.

Куллары ныгытып катерга беркетелгән пират шундук аңлый да, җавап та бирә башлады:

— Утрауга һөҗүм була калса, иң элек анда эшләгән кешеләр юк ителергә тиеш, чөнки Чен шаһитлар калдырмаска күнеккән. Моның өчен алар яшәгән зур мәгарә шартлатыла, һәм анда булган бөтен кеше җир астында терелә́й күмелеп кала. Бик көчле шартлаткыч зарядның детонаторы белән идарә итү пультын Чен үзендә йөртә.

Сугышчылар, җиңелә башласалар, үзләре генә белгән юл белән яр буена киләләр. Бик яшерен җирдә тизйөрешле зур катер әзер тора. Урынын мин белмим: бу—сер.

Утрау тирәсендә даими рәвештә махсус катер йөреп тора. Бу—тышкы сакчылар. Алар чит судноларны ерактан ук күреп алалар һәм батыралар.

—Әйт әле!—дип Хәсән бандитның күзенә карады.—Чен турында ни-нәрсә беләсең? Кем ул? Аны ничек танырга була?

— Сезгә Ченны алу юк!-диде юлбасар.—Ул—Юлбарыс кебек җанвар. Кеше үтерү аның өчен төкерү генә. Аны сары, җиңсез кыска курткадан танырга була. Чәче кара озын.

— Тагын нәрсә әйтә аласың?—дип сорады Хәсән.—Никадәр күбрәк сөйләсәң, шулкадәр тизрәк төрмәдән чыгарсың.

Пират башын чайкады.

—Алай булгач, сикер!—дип боерды Фәрит, тегенең кулын ычкындырып. Бандит озак көттермәде, башы белән суга чумды һәм ярга таба йөзеп китте.

— Эш бетте монда,—диде Хәсән,—хәзер бензинны карыйбыз да, сөйләшенгәнчә, Сингапурга чабабыз. Бер тәүлектән полиция белән килеп тә җитәрмен. Нәрсә бу!—дип, Хәсән сызгырып куйды.

—Ни булды?

— Бензин юк бит бакта. Менә нәрсә икән: бакка пуля тигән һәм ягулык агып беткән. Инде нишлибез? Сингапурга ничек барабыз?

— Мин уйлап торам,—дип куйды Фәрит,—анда барып эш чыгар микән?

Бу бит Индонезия җирләре. Ә анда барсак, рөхсәтсез чикне үтеп кергәнлектә гаепләрләр.

—Син хаклы—диде Хәсән.—Алай булгач, үзебезгә генә ышанырга кала.

—Шулай туры килә. Кем каршы? Юкмы?

—Димәк,—дип йомгак ясады Хәсән,—Алсуны үзебез коткарыйк та, Сингапур полициясенә пиратлар турында хәбәр итик. Алар бер төрле дә чара күрмәсә, Халыкара полициягә җиткерербез.

Моның белән барысы да килештеләр.

—Ә бу катерны нишләтәбез?

—Батырырга да, вәссәлам!

***

«Виктория» яңадан Алсу тоткынлыкта яткан утрауга якынлашты. Атауны ерактан гына урап чыктылар да, анда үтеп керү ысулын эзли башладылар. Текә ярның һәр җирен тикшерделәр. Ниһаять, бер җирдә көймәне яшереп тотарлык уңайлырак урын таптылар, аннан соң текә кыяга якын килделәр. Бандитлар дөрес сөйләгән булып чыкты: кыя шундый биек һәм текә, хәтта альпинистлар да авырлык белән менә торган. Егетләрнең борыны салына башлады. Шулчакны Идриснең шатлыклы тавышы ишетелде:

—Гарпун!..

—Нинди гарпун? Кайда? Саташасыңмы әллә?

—Гарпун белән өскә ыргак ыргытабыз, ә аңа бау беркетәбез...

—Ә ыргагың кайда?

—Шул ук гарпуннан эшлибез.

Шунда ук эшкә тотындылар: гарпунны бөгеп, ыргак ясадылар һәм аңа нык бау бәйләделәр, бер очын көймәгә беркеттеләр. Фәрит гарпунны өскә каратып атып җибәрде. Ыргак әйләнә-әйләнә кыя өстенә очты. Ләкин баудан тартып карагач, кире килеп төште. Шулай итеп биш-алты кабат аткач кына ыргак яр башында эләгеп калды.

—Идрис! Өскә мен!—дип боерды Фәрит.—Синең беләкләрең ныграк. Тегесе, биленә бау бәйләп, биш-алты минуттан яр башына менеп җитте.

—Нәрсә бар анда?

—Таш-кыялардан башка берни дә юк.

—Алай булгач, кире төш. Тик башта бауның очын ныгытып бәйләп куй.

Тагын уйлашып алдылар. Юлга чыгар алдыннан бәхәс тә булып алды: көймәдә кеше калдырыргамы, әллә барысына да китәргәме? Айнык акыл җиңеп чыкты: көймәне һәртөрле очраклылыктан сакларга кирәк иде. Расихны калдырырга булдылар.

Өч эзтабар утрауның уртасына таба кузгалдылар. Аларның өчесенә бер пистолет, радиотелефон аппараты, ике пычак, озын гына бау, бинокль иде. Азык та алдылар.

Адым саен тирә-юньне тикшереп, сакланып кына бардылар. Юлга чыгуларына өч сәгатьләп вакыт үтте, ләкин әйләнә-тирәдә бер үзгәреш тә сизелмәде. Ниһаять, кич булып караңгы төшкәч, Идрис:

—Диңгез!—дип алга күрсәтте.—Кайдан килеп чыккан ул монда?

— Кайдан булсын,—дип аңлатты Фәрит,—без утрауның икенче, капма-каршы ягына килеп чыкканбыз.

—Соң, алай булгач, бандитларның базасы кайда калды?

— Бер яктарак торып калган.—диде Хәсән.—Яхшылабрак эзләргә кирәк булган. Инде кире кузгалып торудан мәгънә юк: караңгыда барыбер күрмәбез. Монда гына төн үткәрик.

«Аучылар» уңайлырак урын табып, ял итәргә урнаштылар. Әлбәттә, уләнсез-нисез ташлы җирдә ятуны ял итү дип әйтүе кыен иде, ләкин егетләр бу турыда уйлап та карамадылар.

Шул вакытта диңгез ягыннан мотор тавышы ишетелде. Фәрит бинокльен шул якка төбәде.

—Караңгы!—диде ул.—Әнә! Катер күренә. Тагын берәү. Икесенда егермеләп

кеше булыр. Уңнан сулга бара. Димәк,базага таба килә. Болар кемнәр булыр икән?

—Дозордагылар булмас,—дип фараз итте Хәсән,—чөнки артык күпләр. Мөгаен, энҗе җыючыларны алып кайталардыр.

Иртәнгә таба,тау-ташлар сорылана башлагач,егетләр тагын юлга кузгалдылар. Бу юлы тарлавыкка якынрак килергә булдылар. Озак кына баргач, уң яктан ниндидер тавышлар ишетелде. Эзтабарлар сакланып кына шул якка атладылар һәм ... исләре китеп, тукталып калдылар: аста җинаятьчеләр яшеренгән җир җәелеп ята иде.

Бу урын теге катерлар керә торган тарлавыкның киңәебрәк киткән җире иде булса кирәк. Чыннан да арырак өч таныш катер тора.

Фәрит бинокль аша җентекләп эшкә китүче тоткыннар арасыннан Алсуны эзләде,ләкин аңа охшаган хатын-кыз күренмәде.

Пиратларны эзәрлекләүчеләр,яр читенә ятып,сакланып кына күзәтергә тотындылар. Эшкә китүчеләрнең катер тавышы ерагайгач, лагерьда тынлык урнашты. Бераздан аста бер кеше күренде. Ул каршыдагы кыя төбенә якын ук килде дә юкка чыкты.

—Анда тау куышы бар бугай,—дип пышылдады Фәрит Хәсәнгә.

—Әйе!

Ята торгач,тагын ике мәгарә барлыгын белделәр. Табигый тау куышларымы алар,әллә кеше кулы белән эшләнгәнме,анысы билгесез иде.

Күзәтә торгач, үзләре өчен файдалы бик күп нәрсәләр мәгълүм булды: мәгарәнең берсендә җинаятьчеләр үзләре яши,икенчесендә коллар ябып тотыла. Шунда ук яшерен җирдә сакчы тора. Өченче мәгарә—су юлы иде ахрысы: чөнки анда бер кеше утырган моторлы көймә кереп киткәне күренде.

Кичкә кадәр күзәткәч, яшерен урыннарда торган тагын ике сакчы барлыгы беленде. Алар өчесе бөтен тирә-якны күзәтәләр,ләкин үзләре күренмиләр иде.

—Уйлап эшләнгән!—дип пиратларны мактап куйды Идрис.—Кайда качып ятуларын алдан белмәсәң,тиз генә табарлык та түгел. Вертолеттан да күрмисең.

Ул арада караңгы төшә башлады. Өч дус бер яккарак киттеләр дә, пышылдашып кына киңәшә башладылар. Ничек итеп Алсуны коткарырга?

Озак кына бәхәсләшкәч,шундый фикергә килделәр: бандага каршы ниндидер хәйләле, пиратлар һич тә көтмәгән йөреш эшләргә кирәк. «Башларны эшләтик, дуслар!»—диде Фәрит.

— Безгә Ченны кулга төшерергә кирәк,—диде Хәсән.—Ул чакта бөтен проблемалар җиңелрәк хәл ителәчәк.

— Ченны эләктергән хәлдә дә аңа ультиматум куяр өчен,көчле дәлил кирәк булачак. Ул,кулларын дистәләрчә кеше канына буяган җанвар, алай җиңел генә бирешмәс. Безнең исә аңа катгый таләпләр куярлык козырьларыбыз юк,—диде Фәрит.

Шулвакытны радиотелефон тавышын биреп куйды. Расих «Виктория» торган җирдән ерак та түгел тарлавык барлыгын һәм аның мәгарәгә кереп киткән урынында зур гына катер торганлыгын хәбәр итә иде.

—Мин ул якка музыка тавышы ишетеп барган идем,—диде ул.—Анда катерның сакчысы икән.

— Ярый,бик шәп!—диде Хәсән.—Шул тирәдәрәк бул,тик саклан,күрмәсеннәр. Үзгәрешләр булса, безгә белдер.—Аннан соң иптәшләренә борылды:—Менә ул,безгә кирәкле козырь.

—Йә-йә! Нинди план туды башыңда?

—Безгә аларның су юлларын ябарга кирәк. Бандаңы утрауда бикләргә.

—Ничек итеп?—дип аптырадылар егетләр.

—Элементар рәвештә. Минем шартлаткыч пакетлар, динамит бар. Бик куәтлесе.


—Кайда ул?

—Көймәдә. Болай итәбез...

Кәефләре күтәрелгән эзтабарлар Расихка хәбәр иттеләр дә көймә янына ашыктылар. Ул аларны элекке урында көтә иде.

*Ахыры киләсе санда.*

## Чайнворд




1. Судта яклаучы юрист;
2. Өч электродлы ярымүткәргеч;
3. Искергән әйберләрне янарту;
4. Кара диңгез буендагы курорт шәһәр;
5. Битнең алдан караган сурәте;
6. Бикләнә торган юл сумкасы;
7. Конкурста катнашучыларга бәя куючылар төркеме;
8. Кытайларның язма графикасы;
9. Тискәре күренешләрдән көлеп язылган кыска күләмле әдәби әсәр;
10. «Яшел эшләпә» комедиясе авторы;
11. Кипкән виноград;
12. Хәрбиләр киеме;
13. Күп зарядлы кечкенә ату коралы;
14. Пуляның каты әйбергә бәрелгәннән соңгы очышы;
15. «Кандыр буе» мелодрамасы авторы;
16. Биеклекне билгеләү өчен кирәкле геодезик прибор;
17. Сүз төркеме;
18. Өй җиһазы;
19. Геометрик фигура;
20. Кәрәз чималы;
21. Африканың кыргый аты;
22. Океанда йөзеп йөрүче боз тавы;
23. М. Фәйзи язган драма әсәре;
24. Радиоактив элемент;
25. Краснодар краендагы герой-шәһәр;
26. «Туган җирем—Татарстан» җырына көй язган композитор;
27. Җиләк-җимеш кайнатмасы;
28. Континент;
29. Татарстандагы район;
30. Ашарга яраклы аксыл сары гөмбә;
31. Тыныш билгесе;
32. Алма сорты.

*Төзүчесе*—**Зөфәр ХИСАМОВ.**
*Буа, Түбән Наратбаш.*

*Җаваплары 182 биттә.*

## Интер–кайтаваз («www. matbugat. ru»дан). Әйтергә микән? (2010 ел, № 1)

*Ак җилкәннәр белән кичеп үтәм*
*Хыялымның күксел диңгезен.*
*Син яшәгән ярлар ерак микән,*
*Шуны гына уйлыйм мин үзем...*

Бу минем яратып жырлый торган жырым. Ак жилкән! Ак жилкән! Хыялымда мин ак җилкәнгә утырып аның янына китәм. Мина шундый рәхәт. Мин дә бит яратам, Ләйсән. Аны гел уйлыйсы гына килеп тора. Ләкин бер ләкин бар. Аның буе миннән беразга кечкенәрәк. Ул үзе моңа алай игътибар итми. Бу бит бәләкәй мәсьәлә, ди. Шулаен шулай да. Дус кызым котырткан була, шуңа гына бераз уйлыйм. Бер көнне буйларны үлчәп торган була. Мин синнән бераз кечерәк, ди. Мин дә сер бирмәдем. Озын буй модада, дидем. Ләйсән, мин дә синең кебек Жилкәнкәйгә хат язам әле. Аның турында матур сүзләрем күп минем. «Ак жилкән» аша дуслар да табасым килә. «Ак җилкәң»дә очрашырбыз, яме, Ләйсән. Пока.

**Сылу**

Сылу, сиңа ничә яшь соң? Син кайсы яктан? Нинди «Ак жилкән» соң ул? Кабат монда керсәң, яз әле. Безнең нэт (Интернет—АЖ) юк шул. Мин күршеләрдән генә керәм монда.

**Алмазия**

Алмазия, син инде дөньядан артта калма. «Казан утлары» журналында безнең өчен яңа сәхифә эшли башлады. Шунда язам дим хат. Теләсәң, син дә яза аласың. Арча кызы Ләйсәннән калышып тормыйк әле. Ул мине монда күрмәде, күрсә язар иде. Интернетка керү мөмкинлеге бөтен кешедә дә юк шул пока.

**Сылу**

Бик матур язылган... Яшьлегем исемә төште, нәкъ шулай, кирәкмәсә дә, йөгерә-йөгерә су ташулар, күрмәмешкә салышып узулар...

**Зиләйлүк**

Матур хатирәләрем яңарды, яшүсмер чагым исемә төште. Без дә аның белән болында йөрибез... Бозауга су эчертергә төшкән идек. Сулы чиләкне икебез ике ягыннан тоттык. Бер уйласаң, әллә нәрсә дә түгел. Ләкин бик рәхәт иде миңа шул чакта. Бозауга суны эчерткәннән соң без әле өйгә кайтмадык. Болында чәчәкләр җыйдык. Ул миңа болын чәчәкләрен җыеп гөлләмә бүләк итте...

Безнең авыл уртасында зур гына түм-түгәрәк бер күл бар. Җәйнең матур эссе көннәрендә шул күлдә коенулар, ярына чыгып хәл алулар, җиң очынмы, кай җир уңайлырак, чиялэп бәйләп, «каз ите ашатулар»... Күлдә балык күп иде. Аңа ияреп балык тота башладым. Ул миңа кармак ясап бирде... Әле ул мине тагын матайда йөрергә өйрәтте. Ай-яй йөрәкләр дөп-дөп тибә, газга басып бер җибәрәсең дә, очасың гына алга полный ход. Очып килеп төшкән чаклар да булды. Барыбер рәхәт иде. Чөнки мин аның янында, мин аның белән янәшә. Без аның белән кинода да янәшә утырабыз. Утлар сүнгәч, ул минем акрын гына кулыма кагыла...

Әй, балачак, тиле яшьлек! Сездә минем иң матур, кадерле хатирәләрем!!!

**Моңсылу апагыз**

*Гади генә авыл кызы идем,*
*Урман янындагы авылдан.*
*Күңелдәге яшерен хисләремә*
*Әрәмәләр җиле кагылган.*
*Яфрак шавын тыңлап үскән кызый,*
*Көйләр откан кошлар теленнән,*
*Бака такмакларын тыңлый-тыңлый*
*Балык тоткан урман күленнән.*
*Гади генә авыл кызы идем,*
*Бәке ватып керләр чайкаган,*
*Аю-бүре яткан чокырларны*
*Такта чаңгы киеп айкаган.*
*Егетләргә кул да бирмәгән кыз,*
*Мәхәббәттән үлеп оялган,*
*Тормышымда маяк булып торыр*
*Якты максатларны куялган...*
*Гади генә хатын бүген үзем,*
*Чыныгылган җилгә, давылга.*
*Күңелдәге якты уйлар өчен*
*Рәхмәтлемен мәңге авылга.*

**Үтте дә китте яшьлегем**

Монда күнелле икән. Матурлык, ихласлык. Рәхәтлек кичердем сездә. Рәхмәт!!!

**Укучы**

---

## Әйтмәскә!

*Исәнме, Ләйсән!*

*Әти белән әни ала торган журналны караганда (№ 1) синең хатны күрдем.*

*Юк, мин чишмә буенда арканланган бозавы «ул сине ярата!» дип мөгрәгән М. түгел. Мин гүпчем дә Казан җегете. Минем әти белән әни дә Казанга Арча районыннан килгән, ике әбием белән ике бабам шунда яшиләр, так что без синең белән может авылдашлардыр да. Кайсы авыл икәнен язмыйм, үзең әйтмешли, белми тор әле! Утынны мин дә шәп ярам, җәен 5 м³ ярып киттем!*

*Мин татарча шәп язмыйм. Әбием (олырагы) «Почтальон төзәтеп укыр» дип әйтергә ярата, так что журнал редакторы минем хатны сиңа төзәтеп укытыр, может.*

*Мин синең соравыңа (яратуыңны теге «мускуллы» «малай»га әйтергәме, әйтмәскәме?) «әйтмәскә!!!» дип җавап бирәм. Мәхәббәт ул тилертә торган чир генә! Кешенең күпме гомере әрәмгә китә. Авылдагы кешеләрне тикшереп чык, аларның барысы да диярлек «беренче мәхәббәт» «заразасы» киткән и «икенче мәхәббәт» әле килмәгән чакта өйләнешкәндер. «Мәхәббәт» үтә, и үзе белән күпме иң кирәкле вакытны алып китә. Болай башыңны җуеп йөресәң, «өчле»ләр генә түгел, может «икеле»ләр дә ала башларсың әле, Ләйсән, мәктәпне бетергәч, укырга да керә алмассың, теге үсеп җиткән бозауларны савып йөрерсең фермада!*

*Минем фикер белән килешмәсәң, алай түгел дип доказать ит. Пусть моны укыган бүтән «җегетләр» һәм кызыйлар да доказать итсеннәр, булдыра алсалар!.. Алар әле, может, үзе ярата, шуңа яза дип уйлыйлардыр. Юк, Ләйсән, мин сиңа дус булыйк дип кенә язам. Дуслык тилертми, и ул заразный да түгел.*

*Минем бозавым юк, компым (компьютерым-АЖ) гына бар. Ул М.ның бозавы кебек дурак түгел, «мөгрәсә», гел дөп-дөрес и төп-төгәл! Синең дә компың булса, хатны НЭТтан (Интернеттан—АЖ) гына язарбыз. Син минем бердәнберем булырсың, чөнки мин башкалар белән язышмыйм, чөнки вакыт җәл, син әле белмәгән эшләрем күп. Между прочим, әтием СССРда ЭВМны (компларның бабасы!) кертүдә иң каты тырышкан Рәмиевне татар кешесе диде!*

*«Ак җилкән»не чыгаручыларга сүзем: мин яраткан (көнләшмә, Ләйсән!) физика һәм астрономия турында языгыз, мәхәббәт заразасы турында түгел! «Җилкән»егез ак түгел, вак була, алайса!*

**Шамил Г.**

*... мәктәп, 10 б класс.*

*«Казан җегете» Шамилнең теләгенә (беренче өлешенә!) колак салып, АҖда фән бүлеге ачарга булдык. Аны күренекле галим Ким Шакиров алып барачак. Бу юлы бер «алма» гына бирәбез әле.*

## Ньютон башына алма төшкәнме?

Ньютон бөтендөнья тартылу законын башына алма килеп төшкәч уйлап тапкан дигән фикер киң таралган. Юк шул, төшмәгән. Һәрхәлдә, беркайда да теркәлмәгән бу. Ә менә мондый хәлнең мәзәк итеп сөйләнгәне—мәгълүм. Һәм бу мәзәкне Вольтер уйлап чыгарган диләр...

Хәер, алма төшкән булса да, бу әле ярты ачыш та, чирек ачыш та түгел. Кемнәрнең генә башына төшмәгәндер ул алма дигәннәре. Аны Җир өслегенә тартып китергән көчнең зурлыгы никадәр, бу көч нинди ераклыкка тиклем тәэсир итә?—шуның кебек сорауларга җавап табар өчен барыбер дә байтак вакыт һәм бик тә кәттә баш кирәк булыр иде.

### Куен дәфтәренә

*Ихтирамсыз мәхәббәт еракка бармый һәм биеккә күтәрелми, ул—бер канатлы фәрештә.*

**Александр Дюма (өлкәне)**

*Мәхәббәт—кешегә хас зәгыйфьлекләрнең иң кызыклысы һәм иң гафу ителә торганы.*

**Чарлз Диккенс**

*Мәхәббәт һәр кешенең үз күңеле, рухи байлыгы дәрәҗәсендә була. Күңеле сайның мәхәббәте дә сай, хыяллары фәкыйрьнең гыйшкы да фәкыйрь.*

**Шәүкәт Галиев**

***179 биттәге чайнворд җаваплары:***

1. Адвокат; 2. Транзистор; 3. Реставрация; 4. Алта; 5. Анфас; 6. Саквояж; 7. Жюри; 8. Иероглиф; 9. Фельетон; 10. Насрый; 11. Йөзем; 12. Мундир; 13. Револьвер; 14. Рикошет; 15. Тинчурин; 16. Нивелир; 17. Рәвеш; 18. Шифоньер; 19. Ромб; 20. Балавыз; 21. Зебра; 22. Айсберг; 23. «Галиябану»; 24. Уран; 25. Новороссийск; 26. Ключарев; 27. Варенье; 28. Европа; 29. Актаныш; 30. Шампиньон; 31. Нокта; 32. Антоновка.


*АҖга дигән хатны «тартма почта»га гына түгел, электрон почтага да салып була. Адресы:* **kazanutlari@telebit.ru.** *«АҖ»га дип өстәргә онытмагыз!*



Ватан сугышы ветераннарыннан бер төркем. Сулдан уңга—Әдип Маликов, Әмирхан Еники, Нәби Дәүли, Әхмәт Исхак, Гомәр Бәширов. 1985 ел.



Язучы Рөстәм Кутуйга Державин премиясе тапшыру тантанасы. Июль, 2009 ел. Лаеш. Әдипнең соңгы рәсемнәренең берсе. 2010 елның 7 январенда вафат булды.



Узкән гасырның соңгы дистә елларында бик популяр саналган композитор Рим Хәсәнов. 1975 ел.



*Ислам дине кабул ителүнең 1100 еллыгы уңаеннан оештырылган тантаналы җыелыштан бер күренеш. Сулдан уңга: галим Әнвәр Хәйри, мөфти Тәлгат Таҗетдин, мөфти Равил Гайнетдин, язучы Туфан Миңнулин. Март 1990 ел.*



*«Казан утлары»нда каләмдәшләр җыйналган. Сулдан уңга—Мәдинә Маликова, Кояш Тимбикова, Рәшит Гәрәй, Фәрваз Миңнуллин, Рафаэль Мостафин, Илдар Юзеев, Барлас Камал, Абдулла Сәләхетдинов, Әхәт Гаффар. 1976 ел.*

## Айгөл Әхмәтгалиева



Айгөл Габдулла кызы Әхмәтгалиева 1973 елның 27 ноябрендә Актаныш районы Качкын авылында укытучылар гаиләсендә туган.

1990 елда урта мәктәп тәмамлагач, Казан дәүләт университетының татар теле, әдәбияты, тарихы һәм көнчыгыш телләре факультетына укырга керә.

Хезмәт юлын студент елларында Казанның 10нчы гимназиясендә укытучы, «Мәгърифәт» газетасында корректор булып башлап җибәрә. 1994 елда гаиләсе белән Чаллы шәһәренә күчеңә, «Нур» газетасында корреспондент, Чаллы дәүләт педагогия институтында укытучы булып эшли.

2001 елда яңа ачылган «Мәйдан» журналына эшкә күчә.

Айгөлнең тәүге шигырьләре һәм язмалары мәктәп елларында районның «Игенче даны», республиканың «Яшь ленинчы» газеталарында, «Ялкын» журналында дөнья күрә. Соңгы елларда хикәяләре, публицистик язмалары һәм юморескалары белән «Казан утлары», «Идел», «Сөембикә», «Мәйдан», «Тулпар», «Чаян» журналларында, «Мәдәни җомга», «Ватаным Татарстан», «Татарстан яшьләре» газеталарында актив катнаша.

2008 елда «Мәгариф» нәшриятында аның балалар өчен «Болытта җиләк үсә» дигән китабы басылып чыкты. 2008 елдан Татарстан Журналистлар берлеге әгъзасы. Бүгенге «Мәйдан» әдәби-нәфис, иҗтимагый журналының әдәбият бүлеген җитәкли.

2009 елның 21 декабрендә Зиннур Мансуров, Рәшит Бәшәр, Ләбиб Лерон тәкъдимнамәләре нигезендә, Кабул итү комиссиясе һәм Идарә Айгөл Әхмәтгалиеваны Татарстан Язучылар берлегенә әгъза итеп алу турында карар чыгарды.

**Хөрмәтле «Казан утлары» редакциясе!**

Галимә, язучы Ф. Бәйрәмованың 2009 елның 12нче санында басылган «Чәрдән ханлыгы» исемле тарихи хезмәтен бик кызыксынып укыдык. Мин аны, үзем өчен, татар тарихына бик тә мөһим вә бик тә кирәкле өстәмә материал дип кабул иттем. Афәрин, Фәүзия ханым, олуг рәхмәтебезне кабул ит! Сүз унаеннан бер теләгемне дә әйтим әле: «Чәрдән ханлыгы» яшьләребез өчен «Идел» журналында рус телендә дә басылса иллә дә шәп булыр иде.

Мин бу хезмәтнең кайбер урыннарын кайта-кайта укыдым да, атналар буе уйлар өермәсендә калдым. Татар тарихына кагылышлы, үзебездә сакланган күп кенә чыганакларга мөрәҗәгать иттем. Гаилә дустыбыз мәрхүм галим Габделбәр Фәйзрахмановның бүләге—Себер татарлары тарихын да *(«Древние тюрки Сибири и Центральной Азии»)* яңадан карап чыктым. Фәүзия ханым бу хезмәтен, күңелләргә җиңелрәк кереп урнашсын өчен, бүлекләргә бүлеп бирә: «Адашкан Атом», «Тарихтагы Чәрдән», «Тормыштагы Чәрдән», «Чәрдән өчен сугышлар һәм чукындыру тарихы», «Мәңгелек Атом» һ. б. (Урыс философы Иван Ильин татарны «Блуждающий атом» дип атаган икән. Авторча әйтсәк, «Мәңгелек атом ул татар»).

«Бу язмам Котып карларында, Себер сазлыкларында, Урал ташлары арасында—тарих төпкелләрендә адашып калган татарлар турында, Атлантида кебек җир астына киткән татар тарихы турында...»—дип яза Фәүзия ханым. Шушы сәяхәтендә генә дә никадәр юл узган бит ул. Чаллыдан Пермьгә автобус белән—ун сәгать, Пермьнән Чәрдәнгә янә алты сәгать барасы. Кала һәм салаларның үз эчләрендә, музей-архивларда, төрле корылмаларда никадәр материал туплап йөрүләрен дә исәпләсәң, исең-акылың китәрлек бит...

Ошбу юллар тарихи хезмәтнең соңгы өлешеннән алынды.

«Менә мин килгән юлым буйлап, тагы мең чакрымнар ара үтеп, мең еллык тарихны кичеп, өйгә табан кайтып барам... Татар тарихының башланган урыныннан—бүгенгесенә кайтып барам... Тирә якта—татар тарихы кебек ерып чыкмаслык кара урманнар, милләт фаҗигасе кебек төпсез сазлыклар... Бу минем Ана Ватаным, ата-бабаларым кулларына кылыч алып саклаган мөкатдәс урыннар—Татар иле... Моны бар дөнья белгән, бар дөнья таныган, бар дөнья татар белән хисаплашкан... Бары тик XVIII гасырда гына, Петр патшаның теләге һәм Ломоносов кебек галимнәрнең тырышлыгы белән, татар тарихы талана башлаган, чөнки русларның үзләренә бөек тарих кирәк булган...»

Ф. Бәйрәмова «Кырык сырт», «Караболак» исемле әсәрләре белән дә милләтебезнең коточкыч фаҗигаләр эчендәге яшәешен үзенә генә хас кыюлык белән күрсәтә алган шәхес. Ул тарихчы язучы буларак заман тудырган һәр төрле гаделсезлекне һәм шуңа риза булып, буйсынып яшәүне тәнкыйтьли. Аның бу гамәлләре—үз иркеннән үзенә каршы ягылган учакка барып керергә әзерлеге һәм әхлакый батырлык белән коралланып иҗат итүе ул. «...Сүз ирегенең вактөяк кагыйдәләрен үзләштердек шикелле, һич югында горурланырлык үткен каләмдәшләребез исән әле. Фәүзия Бәйрәмова бар, Айдарыбыз бар... Изге Хозер Ильяс төкергән телләренә бал да май аларның»,—дип тикмәгә генә язмагандыр шул күренекле язучыбыз һәм акыл иясе Адлер Тимергалин.

**Әхмәт ГАЛИЕВ,**
*СССР хөкүмәте премиясе һәм Ш. Маннур премиясе лауреаты, техник фәннәр докторы.*

## ЖУРНАЛИСТЛАРГА ҖЫЛЫ КОТЛАУЛАР

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгында Россия матбугаты көненә багышланган тантаналы чара булды. Журналистларны парламент башлыгы Фәрит Мөхәммәтшин тәбрикләде.

Ул журналистларны республика җитәкчелеге исеменнән котлап: «Россия матбугаты көнендә очрашуларыбыз традициягә әйләнде, һәм бу күпне сөйли. Хакимият белән журналистлар арасындагы принципиаль, шул ук вакытта эшлекле мөнәсәбәтләрнең урнашуы зур игътибарга лаек, һәм без моны һәрдаим аңлап, белеп торабыз»,—дип ассызыклады.

Фәрит Мөхәммәтшин, кризис сәбәпле, узган елда шактый авырга туры килүен, әмма уртак тырышлыклар белән ана бәйле кыенлыкларның Татарстанда уңышлы хәл ителүен искәртте. «Халыкка аңлату һәм тиешле мәгълүмат бирү юлы белән кризис йогынтысын киметүдәге ролегез бик зур дип уйлыйм»,—диде.

Дәүләт Советы Рәисе фикеренчә, «дүртенче хакимият» төшенчәсе массакүләм мәгълүмат чараларын гына түгел, бәлки тулаем иҗтимагый фикерне дә үз эченә ала. «Демократик, хокукый гражданлык җәмгыяте төзергә телибез икән, журналистиканың бу эштәге роленең гаять зур булуын истә тотарга кирәк»,—дип басым ясап әйтте ул.

Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, Татарстан Журналистлар берлеге рәисе Римма Ратникова, республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы башлыгы Марат Моратов та журналистларга җылы котлау сүзләрен җиткерде.

## БӘЙРӘМГӘ ӘЗЕРЛЕК

ТАССР төзелүнең 90 еллык юбилеен бәйрәм иткән көннәрдә республика үсешенә зур өлеш керткән затларның исемнәре мәңгеләштереләчәк. Бу хакта бәйрәмне оештыру комитеты утырышында килештеләр. Җыелышны республика Парламенты Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин алып барды.

Юбилей чараларына әзерләнүдә министрлык һәм ведомстволар актив катнаша. «ТАССР төзелүгә 90 ел» дип аталучы истәлек медале якын арада әзер булачак. 2010 елның маенда Татарстанның шәһәр һәм районнарында махсус сквер һәм парклар булдырылачак. Төп чара—Дәүләт Советының тантаналы утырышы—Салих Сәйдәшев исемендәге Дәүләт Зур концерт залында 27 майда узачак.

## ТРАДИЦИЯЛӘР ДӘВАМ ИТӘ

ТР Президенты Минтимер Шәймиев Казан Кремлендә ТР Композиторлар берлеге рәисе Рәшит Кәлимуллин белән очрашты. Анда шулай ук ТР Премьер-министры урынбасары—мәдәният министры Зилә Вәлиева, ТР Президентының эчке сәясәт мәсьәләләре буенча идарә башлыгы Александр Терентьев, ТР Композиторлар берлеге идарәсе әгъзалары—берлек рәисе урынбасарлары Резеда Ахиярова, Виталий Харисов һәм Леонид Любовский да катнашты. М. Шәймиев, берлекнең юбилей унаеннан яхшы хисап ясавын ассызыклап, аның традицияләрне дәвам итүенә югары бәя бирде. «Иң шатландырганы шул—Композиторлар берлеге төзелгәннән бирле нигез салынган традицияләр бүген дә дәвам итә. Горурланырлык композиторларыбыз, алар иҗат иткән әсәрләребез бар. Алар республика мәдәниятенә генә түгел, башка мәдәниятләргә дә йогынты ясый»,—дип белдерде ул.

## ЛАУРЕАТЛАР АРАСЫНДА ШАГЫЙРЬ ДӘ БАР

Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев фән һәм техника өлкәсендә 2009 ел өчен республика Дәүләт бүләкләрен бирү турындагы Указга кул куйды. Быел бу абруйлы бүләккә конкурска тәкъдим ителгән унҗиде эшнең тугызы лаек дип табылды. Алар арасында Казан архитектура-төзелеш университеты, Казан дәүләт университеты галимнәре һәм белгечләренең уртак эше—«Татарстан Республикасы мәгариф

системасында дәүләт теле буларак татар телен гамәлгә ашыруны фәнни, укыту-методик һәм мәгълүмати-программ тәэмин итү» дип исемләнгән хезмәт тә бар. Аның авторлары: Н. Туктамышев, Р. Сәлимов, Р. Шакиржанов, А. Камалов, Ж. Сөләйманов, Р. Бохараев, Ф. Сәлимов, Р. Гыйльмуллин. Атап әйткәндә, без әлеге исемлектә техник фәннәр докторы, ТФА академигы, Фәннәр академиясенең «Гамәли семиотика» фәнни-тикшеренү институты директоры, КДУ профессоры Җәүдәт Сөләймановны да күрәбез. Өстәвенә, ул әле Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, танылган шагыйрь дә.

## ТАТАР КИНОСЫНА—75!

«Мир» кинотеатрында «Татаркино» кинематографистлары үзләренең 75 еллык юбилейларын бәйрәм итте. Бәйрәм тантанасына Татарстан Премьер-министры урынбасары—мәдәният министры Зилә Вәлиева да килгән иде. «Татаркино»да авыр заманнарда да кино сәнгатен аңлый белә торган, үз һөнәрләренә тугрылыклы калган шәхесләр эшләде. 75 ел эшләү дәверендә бик күп документаль, нәфис фильмнар төшерелде. Әгәр 2009 елда «Алтын мөнбәр» фестивалендә без ике нәфис фильм күрсәтә алганбыз икән, бу барлык кинематографистларның да иҗат җимеше дип бәяләргә кирәк»,—диде ул. Министр шулай ук Татарстан Президенты Минтимер Шәймиевнең Рәхмәт хатын да укыды. Кинематографистлар берлеге әгъзасы, кинорежиссер Батыр Баишевны—Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе һәм Мәдәният министрлыгының әйдәп баручы киноәшчесе Владимир Николаевны Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре дигән мактаулы исемнәре белән дә тәбрикләде.

## АРХИВ ЭЛЕКТРОНЛАША

«Электрон Хөкүмәт» проекты кысаларында ТР Министрлар Кабинеты каршындагы Төп архив идарәсенең эшен тамырдан үзгәртмәкчеләр. Бүген архивта эшләүчеләр үзләре янына теге яки бу мәгълүмат сорап килүчеләрнең күп, ә хезмәткәрләрнең аз булуына зарлана. ТР премьер-министры Рөстәм Миннеханов әлеге унайдан болай диде: «Хезмәткәрләрнең санын арттырып кына борчыган мәсьәләләрне хәл итә алмаячакбыз, архивларның эшләү рәвешенә үзгәрешләр кертергә кирәк. Архивларга мәгълүмат сорап килүчеләрнең гозере 20 көн дәвамында түгел, тизрәк үтәлергә тиеш». Аның фикеренчә, моңа кадәр кәгазь битләрендә сакланган архив материалларын кыска гына вакыт аралыгында электрон вариантка күчереп бетерү мөмкин түгел. Шуңа күрә, бүгенге көндә иң еш кулланыла торган мәгълүматларның исемлеген төзеп, беренче чиратта электрон вариантка күчереләчәк юнәлешләрне билгеләргә кирәк. Мисал өчен, кешеләрнең эш урыннары һәм хезмәт хаклары турындагы мәгълүматлар. Быелның гыйнвар аеннан башланган пенсияләрне валоризацияләү, ягъни совет чорындагы хезмәт стажын яңадан санап билгеләнгән күләмгә пенсияне арттыру нисбәтендә архивларга мөрәҗәгать итүчеләрнең саны артачак. Бүгенге көндә кәгазь өемнәрен актарып утыру отышлы түгел, шуңа күрә иң беренче чиратта шушы өлкәгә караган архив материаллары электрон вариантка күчереләчәк.

## КАЗАН МУЗЫКА КӨЛЛИЯТЕНӘ 105 ЕЛ

Казан музыка көллияте—республикабызга күп кенә танылган шәхесләрне биргән уку йорты. Төрле чорда төрле исемнәр йөртсә дә (музыка техникумы, музыка көнчыгыш техникумы, Татар сәнгать техникумы, музыка училищесы), аның максаты үзгәрми. Республикабызга талантлы кадрлар әзерләү элек-электән коллективның төп бурычы булган. Көллият диварларында әле дә күренекле шәхесләр рухы саклана. Заманында анда белем алган Салих Сәйдәшев, София Гобәйдуллина, Нәҗип Җиһанов, Заһид Хәбибуллин, Ренат Еникеев кебек композиторлар; Гөлсем Сөләйманова, Илһам Шакиров, Венера Ганиева кебек сәхнә осталары—бүген дә коллективның горурлыгы.

Хәзерге вакытта көллият Ильяс Әүхәдиев исемен йөртә. Ул җитәкләгән чорда училищеда хор-дирижерлык, композитор теориясе бүлекләре ачыла. Фасил Әхмәтов, Әнвәр Бакиров, Исмай Шәмсетдинов кебек композиторлар шунда укыганда ук көйләр яза башлыйлар.

Көллиятне озак еллар Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Резидә Сабитовская җитәкләде. Аның тырышлыгы белән биредә татар бүлеге ачылды. Бүген көллият укучылары зур сәхнәләрдә чыгыш ясыйлар, конкурсларда катнашып җиңүләр яулыйлар. Хәзерге вакытта көллияттәге тугыз бүлектә 313 укучы белем ала. Аны тәмамлаган укучылар Татарстан дәүләт җыр һәм бию ансамблендә, симфоник оркестрда, музыка мәктәпләрендә үзләренең хезмәт юлларын дәвам итәләр. Күбесе югары белем алу максатыннан, мәдәният һәм сәнгать университетына, консерваториягә юл тота. «Шунысы кызганыч, читтән килеп укучы кайбер талантлы яшьләр, фатирда яшәргә мөмкинлекләре булмау сәбәпле, кире китәргә дә мәҗбүр була. Шуңа күрә алар өчен Жуковский урамындагы 6 нчы йорт бинасын алу турында сөйләшүләр алып барабыз»,—ди көллият директоры Айрат Җаббаров. Көллияттә киләсе елдан арфа дигән уен коралында уйнаучыларны әзерли башларга ниятлиләр. Әлеге уку

йортын тәмамлаучылар барысы да диярлек сәнгатьтән читкә тайпылмыйча, үз белгечлекләре буенча халыкка хезмәт итә.

### ИГЪТИБАР: КОНКУРС!

Татар журналистикасы фәненә нигез салган, КДУның журналистика, социология һәм психология факультетында озак еллар декан вазифасын башкарган Флорид Әгъзамов исемендәге стипендия программасына язмалар кабул ителә башлады. «Татмедиа» агентлыгы уздыра торган әлеге бәйгедә «Журналистика», «Татар филологиясе», «Җәмәгатьчелек белән эшләү» белгечлеге буенча көндезге бүлектә III-V курста укучы теләгән һәркем катнаша ала. Конкурска 2009-2010 ел аралыгында басылган язмаларны, видеотасмаларны, шулай ук басмага тәкъдим ителгән, эфирга әзерләнгән, ләкин әле басылырга, күрсәтелергә өлгермәгән материалларны да тапшырырга мөмкин. Уку барышында җәмәгатьчелек белән эшләү өлкәсендә әзерләнгән проектлар тәкъдим ителә. Узган еллардан аермалы буларак, быел «ТАССРга—90 ел», «Җиңүнең 65 еллыгы» дип исемләнгән махсус номинацияләр дә булачак. Конкурска гаризалар һәм материалларны юллау 2010 елның 1 апреленә кадәр дәвам итәчәк. Аларны түбәндәге адреска юллагыз: Казан шәһәре, Академия урамы, 2, 412нче бүлмә. Элемтә өчен телефон: 570-31-06.

Җиңүчеләрне котлау 2010 елның маенда булыр дип көтелә. Тулырак мәгълүмат—www. tatmedia. ru, www. tatmedia com сайтларында.

### ЭЛЕКТРОН КИТАПХАНӘ АЧЫЛДЫ

Татарстанда уникаль—«Таткнигафонд» электрон китапханә системасы эшли башлады. Хәзер анда меннән артык китап исәпләнә (нигездә, татар телендә), ә алдагы айларда аларга тагын 500 басма өстәлергә тиеш.

«Книгафонд» проектының житәкчесе «КоммерсантЪ» нәшрият йорты шеф-редакторы Андрей Васильев. Нәкъ менә ул Татарстан житәкчеләренә татар телендәге электрон китапханә булдырырга тәкъдим иткән, бу идеяне хуплаганнар. Проектны Президент Минтимер Шәймиев үз химаясе астына алган, ә дәүләт заказчысы ролендә —«Татмедиа» Республика матбугат һәм гаммәви коммуникацияләр агентлыгы.

Ике ай эчендә электрон китапханәгә 1072 китап туплый алганнар, шул ук вакытта авторлык хокуклары сакланган. Хәзер «Таткнигафонд» сайтында классик, бүгенге көн, балалар, дини әсәрләрне табарга була. «Таткнигафонд» Россиядә иң беренче легаль төбәк электрон китапханә дип санала.

Татарстан хакимияте бөтен яктан да легаль электрон китапханә туута ярдәм иткән уникаль үрнәк булып тора.

«Таткнигафонд» сайтында авторлык хокуклары чыннан да житди саклана. Мисал өчен, укучы китапны тулысынча күчерә алмый. Ана текстның 10 проценты гына бирелә.

ТР Премьер-министры урынбасары—мәдәният министры Зилә Вәлиева фикеренчә, «Таткнигафонд» проектының максаты—татар телендәге әдәбиятны таныту.

Татарстанда яна китапның гадәти тиражы 2 мең нөсхәдән артмый. Бу Татарстан өчен дә житәрлек түгел. Шуңа күрә электрон форматтагы китаплар бик нәтиҗәле. Шул ук вакытта текстның чынлыгы да гарантияләнә.

Андрей Васильев фикеренчә, «Таткнигафонд» яшь авторлар өчен старт мәйданчыгы булып хезмәт итәргә мөмкин. Сайтта үз әсәрен урнаштырган язучы яки шагыйрь үз иҗатының ни дәрәҗәдә популярлыгын да белә ала.

### ЗИЛӘ ВӘЛИЕВАГА— РОССИЯ ХӨКҮМӘТЕ БҮЛӘГЕ

Зилә Вәлиева Алабугада музей комплексын булдырган өчен 2009 елда мәдәният өлкәсендә РФ Хөкүмәте бүләгенә лаек булды.

Әлеге бүләккә ТР Алабуга муниципаль берәмлеге башлыгы Илшат Гафуров та лаек дип табылды. Бүләк алучылар арасында язучы Валентин Распутин, модельер Вячеслав Зайцев, кинорежиссер Алла Сурикова һ. б. бар.

### ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ ИДАРӘСЕ УТЫРЫШЫ

22 гыйнварда—Татарстан Язучылар берлеге идарәсенең чираттагы утырышы булды. Аны берлек рәисе И. Ибраһимов алып барды. Утырышта катнашучылар Язучылар берлеге идарәсенең 2010 елның беренче яртыеллыгына эш планын карап чыктылар. Аннары яшерен тавыш бирү юлы белән 2010 елда Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә һәм Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, Язучылар берлегенең әдәби премияләренә кандидатлар тәкъдим итү булды. Утырышта «Мәгарә» дип аталган шигырьләр һәм поэмалар (Татарстан китап нәшрияты, 2005), "Ташка ордым башны» дигән хикәяләр һәм эсселар (Татарстан китап нәшрияты, 2008) китаплары өчен Ркаил Зәйдулла, «Бәхетсезләр бәхете" трилогиясе (Татарстан китап нәшрияты. 2001, 2005, 2007) өчен Фоат Садриев Г. Тукай исемендәге Дәүләт; шагыйрь, химаяче, нашир Дәрдемәнднең тормыш, иҗат юлын яктырткан хезмәтләре өчен Лирон Хәмидуллин—Г. Исхакый; «Шөһрәт» роман-дилогиясе (Татарстан китап нәшрияты, 2009) өчен Равил Вали-

ев—Ф. Хөсни «Кырык кыл» шигырьләр җыентыгы (Татарстан китап нәшрияты, 2008) өчен Илсөяр Иксанова—Һ. Такташ; «Визитная карточка» («Милли китап», «Мәгариф» нәшриятлары, 2008), «Күңел тәрәзәбездә ут сүнмәсен» («Матбугат йорты» нәшрияты, 2009) дигән китаплары өчен Мөдәррис Вәлиев Җ. Вәлиди исемендәге әдәби премияләргә тәкъдим ителде.

### «ТАТАР МОҢЫ»

«Татар моңы» телевизион Халыкара яшь башкаручылар конкурсы башта ике елга бер мәртәбә булыр дип уйланылган иде. Әмма оештыручылар аны быел да үткәрергә карар иттеләр. Январь аеннан сайлап алу туры башланды инде. Быелгы конкурсның яңалыгы—I тур читтән торып үткәреләчәк, ягъни, бәйгедә катнашучылар (15-30 яшь) аудио һәм видеоязмалар буенча сайлап алыначак һәм жюри карары нигезендә II турга Казанга (19-20 март көннәрендә) чакырылачак. II тур җиңүчеләре 25-26 апрель көннәрендә гала-концертта чыгыш ясаячаклар. Яңалык: быел конкурска «Гаилә ансамбльләре» дигән номинация дә кертелгән. Тагын бер яңалык—бәйгедә «Татар моңы»ның былтыргы лауреатларыннан кала, барлык республика һәм төбәгара бәйгеләрдә җиңүчеләр катнаша ала. Ниһаять, тагын бер сөенечле яңалык—»Татар моңы» бәйгесе кысаларында «Татарстан-Яңа гасыр» телерадиокомпаниясе «Җырлы-моңлы балачак» бәйгесе уздыра. Анда 4-6 һәм 7-14 яшьлек балалар ике төркемгә бүленеп көч сынаша алалар.

### КӨТЕЛГӘН БАСМА

Татарстан китап нәшриятендә, ниһаять, күптән көтелгән басма—2 томнан торган, берсе-берсе 750шәр битле булган «Әдипләребез» биобиблиографик белешмәлек дөнья күрде. Галимнәр, аспирантлар, студентлар, укытучылар h. б. 23 ел зарыгып көткән бу басма, элеккеләреннән аермалы буларак, шактый киң вакыт аралыгын үз эченә ала. Биредә узган гасырның 90 нчы елларына кадәр исемнәре һәм иҗатлары телгә алынмаган классикларыбыз да, Татарстан Язучылар берлегендә әгъза булган татар һәм рус телле язучылар да, Татарстаннан читтә яшәгән татар әдипләре дә, берлеккә соңгы елларда кабул ителгән яңа әгъзалар да үзләренең лаеклы урынын алган. Бу китап Йосыф Баласагуни, Сөләйман Бакыргани, Кол Гали, Котб, Сәйф Сарай, Мәхмүд Болгари, Мөхәммәдьяр, Кол Шәриф кебек әдипләр хакында мәгълүматлар белән дә тулыландырылган. «Совет Татарстаны язучылары» (1986) китабында 349 язучы турында белешмә бирелсә, укучыларыбызга тәкъдим ителгән бу энциклопедик характердагы икетомлык 575 әдипнең тормыш һәм иҗат юлы белән таныштыра.

Әлеге белешмәлекнең төп нигез өлеше күренекле тәрҗемәче һәм мөхәррир, әдәбият һәм китап белгече Рәис Даутов тарафыннан язылган һәм җыйналган иде. Әмма ул вафат булгач, бу эшне әдәбият белгече, шагыйрь Равил Рахмани ахырына кадәр төгәлләде.

Китапны Татарстан китап нәшриятеннән (Декабристлар урамы, 2, «Идел-Пресс» бинасы артындагы 3 катлы бина) яки нәшриятнең фирма кибетеннән (Бауман урамы, 29/11 нче йорт) алырга мөмкин. Бер комплектның бәясе—400 сум.

### БЕЗНЕКЕЛӘРНЕ БӘҺАЛИЛӘР

Казан дәүләт университетының актлар залында студентлар һәм мөгаллимнәр катнашында тантаналы кичә булды. Анда укуда, фәндә, җәмәгать эшләрендә, үзешчән сәнгатьтә, спортта һәм башка тармакларда җиңүче студентларның исемнәре игълан ителде. Быел, башка еллардан аермалы буларак, иң яхшы укытучы номинациясе буенча да ярыш оештырылган иде. Бу төр бәйгедә татар әдәбияте тарихы һәм теориясе кафедрасы профессоры Хатыйп Миңнегулов «КДУның иң яхшы мөгаллиме-тәрбиячесе» дип табылды. Җиңүчегә университет ректоры Мәкзүм Сәлахов тантаналы шартларда махсус кубок, лента, диплом һәм кыйммәтле бүләк тапшырды.

Шунысын да әйтеп узу кирәк: Хатыйп Миңнегулов безнең журналыбызның актив авторы һәм редколлегия әгъзасы да әле.

### «РУХИЯТ»НЕҢ ИГЕЛЕКЛЕ ГАМӘЛЛӘРЕ

Әлмәт шәһәрендәге «Яшьләр үзәге» мәдәният сараенда «Татнефть» җәмгыятенең «Рухият» рухи яңарыш фонды тарафыннан быел бастырып чыгарылган китапларны тәкъдир итү кичәсе булды.

«Татнефть» ярдәмендә 2009 елда Ризаэддин Фәхреддиннең «Асар», яшь шагыйрә Людмила Аланлының (Л. Янеева) «Бәхет телим сиңа», Дамир Гарифуллинның «Робагыят», Айдар Хәлимнең «Яшисебез килә!», «Милли җәүһәрләр» сериясендә шагыйрь Гамил Афзалның «Рәхмәт» китаплары һәм «Яшьләр авазы» җыентыгы дөнья күргән.

«Татнефть» ААҖ директоры урынбасары, «Рухият» фонды советы рәисе Рөстәм Мөхәммәдиев: «Рухият» эшчәнлегенең 10 елында гына да 142 исемдә 350 мең данәдән артык китап чыгарылды; язучылар өчен Сәҗидә Сөләйманова исемендәге премия булдырылды; иҗатчы студентларга стипендияләр бирәбез; Республиканың көньяк-көнчыгыш төбәгендә 7-18 яшьлекләр арасында 12 нче мәртәбә «Сандугач сайрар илем» иҗат конкурсы үткәрдек; Татарстанда милли сәнгатьне һәм башка халыкларның да сәнгатен үстерүгә бердәй

игътибар бирәбез»,—дип сөйләде.

Бу кичәдә язучылар да актив катнашты. Казаннан—Г. Рәхим, В. Нуриев, Л. Шәех, Чаллыдан—А. Хәлим, Сарманнан—Д. Гарифуллин, Әлмәттнең үзеннән—Д. Салихов һ. б. чыгыш ясап, «Рухият»нең игелекле гамәлләре өчен рәхмәтләрен белдерделәр.

## ЧИЛӘБЕНЕҢ ТАТАР ЧЫРШЫСЫ

Чиләбе өлкә Конгрессы татар балалары өчен чыршы бәйрәме үткәрелде. Дөрес, чыршы бәйрәмнәре элек тә ел саен оештырыла иде. Ләкин анда күбрәк Чиләбе шәһәре балалары гына катнашты, бәйрәм итүчеләр санының 60-80нән артканы булмады. Быел Конгрессның яңа җитәкчесе Лена Кәримова (Колесникова) бәйрәмне өлкә масштабында үткәрү бурычын куйды. 6 гыйнварда өлкәнең Халыклар дуслыгы йортын шыгрым тутырып Златоуст, Миас, Троицк, Югары Өфеле, Коншак, Копейск, Еманжелинск һәм башка калалар-авыллардан әти-әниләре, дәү әти-дәү әниләре белән бергәләп, 200дән артык бала җыелды. Алар Кыш бабай, Карсылу, Убырлы карчык, Шүрәле, урман җен-пәриләре белән шаугөр килеп спектакльдә катнашып, чын күңелдән бәйрәм иттеләр. Кунакчыл чәй табыны белән дә, Кыш бабайның Яңа ел күчтәнәче белән дә канәгать булып таралыштылар. Балаларыбызның байтагы туган телебезне яхшылап белеп бетермәсә дә, персонажларга кайбер сүзләрен русчага тәрҗемә итеп кабатларга туры килсә дә, бәйрәмдә тел проблемасы булмады. Тантана тулаем татарча, татар дәрте, татар рухы белән узды.

## «БАТЫР» ПОЕЗДЫ ЙӨРИ БАШЛАДЫ

Казан-Ижау арасында «Батыр Фәрдетдин» йөриячәк. Татарстан һәм Удмуртия башкалаларын тоташтыручы электропоездга әнә шундый исем бирделәр.

Мөслим районында туган Фәрдетдин Сәхәбетдинов—Бөек Ватан сугышы герое. 1943 елда ул үзенең хәрби очкычында гитлерчыларны утка тота. Ләкин очкычка снаряд тия һәм ул яна башлый. Фәрдетдин Сәхәбетдинов үзенең сугышчан дусты белән янып торган очкычны дошман ныгытмалары өстенә юнәлтә, җиргә егылып тәшкәнче тагын ике бомба ташларга өлгерә. Очкычны һәм батыр солдатларның сөякләрен 2002 елда гына табып алалар. Батыр Фәрдетдинне Ижауның татар зиратына, әнисе кабере янына җирлиләр.

Поездга «исем кушу» тантанасында катнашкан Татарстан Премьер-министры Рөстәм Миңнеханов әйтүенчә, бу чараның Бөек Җиңүнең 65 еллыгы алдыннан үтүе икеләтә куаныч. Әлеге тантана уңаеннан Казанга Фәрдетдин Сәхәбетдиновның сеңлесе дә килгән иде. Аңа Татарстан һәм тимер юл җитәкчелеге Казан-Ижау поездында еллык юл йөрү билеты бүләк итте.

## «СӨЙЛИ» ТОРГАН КОРЪӘН

Сукырлар өчен билгеләнгән республика китапханәсендә махсус тифлоформатта яздырылган Корьәнне (флеш-картага яздырылган «сөйләүче» китап) тәкъдим итү булды.

Шулай итеп, китапханә волонтерлары—үзләре үк начар күрүче «Рамазан» мәчете мәзине Марсель Гайфуллин (проект җитәкчесе) һәм Нәфыйк Һадиев (техник редакторы) тырышлыгы нәтиҗәсендә ислам диненә тартылучы сукыр кешеләр шундый китап белән беренче тапкыр танышу мөмкинлеге алды.

«Сөйләүче» Корьәнне тәкъдим итү ислам нигезләрен өйрәнү түгәрәгенең (аны һәр атна саен Марсель Гайфуллин уздыра) җыелышында үтте.

Хәзер инде якты дөньяны үз күзләре белән күрүдән мәхрүм инсаннар шушы китапханәгә килеп Корьән тыңлый алачак.

# ХУШЛАШУ СҮЗЕ



Татар мәдәнияте зур югалту кичерде: 2010 елның 8 гыйнварында 73 яшендә озакка сузылган авырудан соң күренекле шагыйрь, прозаик һәм тәрҗемәче **Рөстәм Гадел улы Кутуй** вафат булды.

Рөстәм Кутуй 1936 елның 11 ноябрендә Казан шәһәрендә танылган татар язучысы Гадел Кутуй гаиләсендә дөньяга килә. Урта мәктәпне тәмамлаганнан соң, 1955-60 елларда Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетында белем ала. Ул берникадәр вакыт Татарстан китап нәшриятында, аннары Казан телестудиясендә әдәби-драматик тапшырулар бүлегендә мөхәррир булып эшли. 1963 елдан соң ул профессиональ язучы сыйфатында әдәби иҗат белән генә шөгыльләнде, «Казан» журналы нәшер ителә башлагач, шактый еллар әлеге басманың әдәбият-сәнгать бүлеге мөхәррире булып эшләде.

Рөстәм Кутуй рус телендә иҗат итте. Аның беренче китабы—хикәяләр тупланган «Мальчишки» («Малайлар») җыентыгы 1961 елда дөнья күрә. Бер елдан соң «Я иду по земле» («Мин җир буйлап барам») исемле шигырьләр җыентыгы нәшер ителә. Соңрак та әдип иҗатында проза һәм поэзия жанрлары даими рәвештә үрелеп барды. Казан һәм Мәскәү нәшриятларында әдипнең өч дистәдән артык китабы басылды һәм әдәбият сөючеләрнең мәхәббәтен яулады. Рөстәм Кутуйның шигърияте сурәтле фикергә, катлаулы метафораларга бай булуы белән аерылып тора. Күп кенә шигырьләрендә ул татар тарихына мөрәҗәгать итә, үткәннәр мисалында киләчәкне гөманларга омтыла («Казан ятиме турында баллада», «Сөембикә», «Тукай үлеме» h. б.). Балалар өчен язган әсәрләрендә шагыйрь гүя үзе дә самими сабыйга әверелә, шул ук вакытта анардан сугыш вакытына туры килгән балачагының хатирәләре белән өртелгән моңсулык та бөркелә.

Рөстәм Кутуйның чәчмә әсәрләрен чын-чынлап «шагыйрь прозасы» дип атарга мөмкин. Аның күпчелек хикәяләре шигъри тел белән язылган нәсерләргә тартым, күләмле әсәрләрендә дә шагыйрьнең лирик каләмен ачык тоемларга була. «Годовые кольца» («Еллар боҗрасы»). «Ласточка птица деревенская» («Карлыгач авыл кошы») әсәрләре Рөстәм Кутуйны рус әдәбиятенең иң зур осталары сафына бастырды.

Рөстәм Кутуй тәрҗемә өлкәсендә дә җиң сызганып эшләде. Бик күп татар шагыйрьләренең һәм язучыларының әсәрләре аның тәрҗемәсендә рус укучысына барып ирешә, С. Хәким, Н. Арслан, Р. Фәйзуллин, М. Әгъләм, З. Мансуров, Акъегет кебек шагыйрьләрне ул даими рәвештә тәрҗемә итте Проза әсәрләреннән исә Г. Кутуйның «Рөстәм мажаралары» («Приключения Рустама»; Ә. Еникинең «Гөләндәм туташ хатирәсе» («Гуляндам») һәм башка язучыларның роман-повестьлары аның тәрҗемәсендә рус телендә дөнья күрде. Әдипнең үз әсәрләре дә дөньяның төрле телләренә тәрҗемә ителде.

Рөстәм Кутуйның әсәрләрен укыганда күңелдә нииндидер яктылык хисе пәйда була. Күңел киңлеге әсәрләренең дә офыкларын ачып җибәрә, төсләрнең җетелеге дә күзгә ныграк ташлана. Шуңа да еллар үткән саен бу иҗатның әһәмияте арта гына барыр, Рөстәм Кутуйның да исеме безнең хәтерләрдән җуелмас.

**Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, Татарстан Республикасы Язучылар берлеге.**

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Беренче биттә:* Татарстан Республикасы милли музее.

*Дуртенче биттә:* язучы **Рөстәм Сабиров**.

## Яңа китаплар




**Айдар Хәлим.** Яшисебез килә! (Сайланма публицистика). Казан: «Рухият» нәшрияты. 2009.—664 б. Тиражы—1500 данә.

Күренекле шагыйрь, язучы, җәмәгать эшлеклесе Айдар Хәлимнең бу китабына илле елдан артык (1957-2008) иҗат чорында язылган публицистик әсәрләре тупланган. Алар журналистиканың иң гади информациядән иң катлаулы аналитик мәкаләләргә кадәр жанрларны эченә ала.

Бу үзенчәлекле китап журналистика белән бәйле каләм ияләре өчен файдалы әсбап булып хезмәт итә алачак.

Китап шагыйрь Рәшит Бәшәрнең «Заман елъязмасы» дигән кереш мәкаләсе белән ачыла; китапның ахыр тышлыгында язучы Фәнзаман Батталның фикерләре дә урнаштырылган.




**Марсель Әхмәтҗанов**. Нугай Урдасы (татар халкының тарихи мирасы). Казан: Тат. кит. нәшр., 2009.—351 б. Тиражы—2000 данә.

Китапта Идел белән Урал арасында яшәгән татар халкының бабалары тарихына кагылышлы 70тән артык язма тарихи чыганаклар тасвирлана. Аларның күпчелек өлеше матбугатка беренче мәртәбә тәкъдим ителә. Алар арасында шулай ук болгар этногенезына караган язмалар да бар. Китерелгән шәҗәрә текстлары татар халкының Нугай Урдасы варислары да булуын раслый.

Хезмәттә файдаланылган шәҗәрә текстлары төрле телләрдә сакланган борынгы тарихи хроникалар, эпитафик чыганаклар, татар дастаннары белән берлектә комплекслы өйрәнелгән.



Рөстәм Сабиров

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)